АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

Из сокровищницы научных экспедиций

# НАЦИОНАЛЬНО-КУЛЬТУРНОЕ НАСЛЕДИЕ

*Нижний Новород*

2-е издание

КАЗАНЬ 2021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән

# МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАСЫБЫЗ

*Түбән Новгород*

2 нче басма

КАЗАН 2021

УДК 39 (470.341)+930.2+81.512.145’28
ББК 81.2=632.3+82.3(2=632.3)+85.12
М48

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Редколлегия:**

***К. М. Миңнуллин** (рәис), **А. М. Ахунов,***
***М. Х. Вәлиев**, **Д. В. Мөхетдинов***

**Төзүчесе һәм фәнни мөхәррире**

*филология фәннәре кандидаты* ***Э. И. Сафина***

**М 48 Милли-мәдәни мирасыбыз: Түбән Новгород.** – 2 нче басма. – Казан, 2021. – 384 б. – («Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе).

ISBN 978-5-93091-335-4

«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә дөнья күргән китап Түбән Новгород өлкәсендәге татар авыллары тарихы, гореф-гадәтләр һәм тел үзенчәлекләре турында бай мәгълүмат бирә. Анда шулай ук җирле осталарның кул эшләре һәм халык талантларының көй-сүз иҗаты белән дә танышырга мөмкин. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәренең тикшеренүләрен эченә алган әлеге басма киң катлау укучыларда кызыксыну уятыр дип ышанабыз.

ISBN 978-5-93091-335-4

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2011, 2021
© Х. Фәезханов исем. Түбән Новгород Ислам институты, 2011

*Тел – уйлауның коралы, уйның – калыбы...*
*Миллият бинасының нигез ташларыннан*
*иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы,*
*моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

---

*Язык – это инструмент мышления,*
*форма мысли… Самый прочный камень*
*в фундаменте бытия нации – язык… В языке*
*сокрыты душа народа, его мысли и чувства.*

Галимджан Ибрагимов

# КЕРЕШ

Һәр төбәкнең табигать тә, анда яшәүче кешеләр дә, аларның ышанулары һәм дөньяга карашлары да йогынты ясый торган язмышы, йөзе, рухи үзәге-асылы бар. Шушы үзенчәлекне тою-аңлау өчен, әлеге төбәктә яшәү, һич булмаса, андагы тормышны өйрәнү һәм халык белән аралашу кирәк. Болар төбәкнең хәзерге хәлхаләтен күзалларга мөмкинлек бирә.

Үткән-тарих исә күпмедер күләмдә чыганакларда саклана; аларны археологик тикшеренүләр үткәреп тергезәләр; архив документларыннан һәм тарихи һәйкәлләрдән, ташъязмалардан эзлиләр. Археолог-галимнәр борынгы кешеләр турында мәгълүмат сакланган урыннарда разведка уздыра, казу эшләре оештыра һәм, табылдыкларга нигезләнеп, бик ерак тарих хакында төгәл мәгълүматлар китерә. Археологик тикшеренүләр вакытында эралар-чорлар да, шул заманнарда билгеле бер урында яшәгән кешеләрнең кайсы халыкка каравы, көнкүреше, һөнәрләре, нинди технологияләргә ия булуы, ышанулары да, күпмедер күләмдә зәвыгы, мәдәни казанышлары да ачыклана. Алар язма тарихи чыганаклар булмаган ерак заманнарны кабат күзалларга мөмкинлек тудыра, архив материаллары, документлар, эпиграфик һәйкәлләр һ.б. исә безгә якынрак чорлар хакында сөйли.

Алар да күрсәтә алмаган бик күп сәхифәләрне шәҗәрәләр һәм гаилә истәлекләре дә; төбәк кешеләре хәтерендә буыннан-буынга тапшырылып килгән мифлар һәм легендалар, җырлар һәм бәетләр дә; халыкның тел-сөйләм, әдәби фикерләү хасиятләре, көнкүреш һәм мәдәни үзенчәлекләре; матди һәм мәдәни кыйммәтләр дә үзендә саклый. Боларны күрә, аңлый, өйрәнә һәм аңлата белергә генә кирәк. Гаҗәеп күренеш: археологик һәм тарихи чыганакларда сакланмаган мәгълүматлар еш кына кешеләр хәтерендә, төбәкләрнең тормыш-көнкүрешендә яшәвен дәвам итә! Аларны төрле тармак галимнәре төбәкләргә экспедиция-сәфәрләр уздырып барлый, таба, өйрәнә... Аннары бу материаллар кабат халыкка

# ВВЕДЕНИЕ

У каждого региона есть свой неповторимый облик, своя судьба, особая духовная составляющая, которые формируются под влиянием местной природы, живущих там людей, их мировоззрения, привычек и верований. Чтобы понять и почувствовать это своеобразие, необходимо здесь пожить или хотя бы понаблюдать местное жизнеустройство и пообщаться с людьми. Только так можно получить представление о современном состоянии региона.

Страницы прошлого в какой-то степени раскрываются в исторических источниках, их восстанавливают посредством археологических исследований, находят в архивных документах и исторических памятниках. Ученые-археологи проводят исследования в местах, сохранивших следы пребывания древних людей, организуют раскопки и, опираясь на сделанные находки, способны представить точную информацию об очень далеких эпохах. Во время археологических изысканий выясняются возраст рассматриваемых объектов, принадлежность населения данной местности к тому или иному народу, особенности их повседневного быта, используемые технологии и ремесла, их верования, эстетические предпочтения и культурные достижения. Археологи дают возможность представить те далекие времена, о которых нет исторических источников.

Исторические источники (архивные материалы, документы, эпиграфические памятники и др.) рассказывают о ближайших к нам эпохах. Многие страницы истории, которые не получили отражение в источниках, сохранились в родословных, семейных преданиях; в передаваемых из поколения в поколение мифах и легендах, песнях и баитах, в специфике разговорной речи и литературного мышления; особенностях повседневной жизни и культуры; в материальных и культурных ценностях населения данного региона. Нужно только увидеть, понять, изучить и правильно интерпретировать эти явления. Удивительно то, что материалы, не сохранившиеся в археологических и исторических источниках, часто продолжают

кайта, шушы урынның, төбәкнең һәм бердәм татар милләтенең тарихи-мәдәни байлыгына әйләнеп яши бирә.

Татарстандагы академик фән, тарихи, археологик тикшеренүләр белән бергә, төбәкләргә чыгып, урыннарда халыкның яшәешен, көнкүрешен, матди һәм мәдәни хәл-халәтен өйрәнү белән һәрвакыт шөгыльләнә. Мондый тикшеренүләр XIX–XX гасыр чикләрендә үк аерым татар зыялылары инициативасы белән уздырыла башлый: бик күп татар җырларын, әкиятләрен, мәкаль-әйтемнәрен, миф-легендаларны язып алырга, татарларның тел-сөйләм үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, К. Насыйри беренчеләрдән булып татар халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, тарихи-этнографик тикшеренү эшен башлап җибәрә, 1871 елдан үзенең «Казан календаре»нда фольклор үрнәкләре бастыра. Бу эшкә Р.Ф. Фәхреддин, Г.Н. Әхмәрев, Х.Б. Бәдигый, Җ.Җ. Вәлиди һ.б. бик күп фикер ияләре кушыла.

XX гасырның аерым чорларында мондый тикшеренүләрне оештыруда активлык күзәтелә. 1920–1930 елларда – бигрәк тә Гыйльми үзәк эшчәнлеге белән бәйле махсус экспедицияләр фәнни нигездә уздырыла башлый. Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Гобәйдуллина, К.С. Гобәйдуллин, С.Г. Вахиди һ.б. тарафыннан Арча, Әлки, Балык Бистәсе, Мамадыш, Минзәлә, Спас, Чаллы, Чистай төбәкләрендә шундый кыр тикшеренүләре үтә; аларда этнография, фольклор, сәнгать, тарихи-мәдәни мираска караган материаллар туплана.

Мондый эшчәнлек хәтта Бөек Ватан сугышы чорында да тукталмый. 1940 – 1980 елларда аерым тармак галимнәренең махсуслаштырылган экспедицияләргә чыгуы киң тарала. Бигрәк тә эпиграфик (Һ.В. Йосыпов), археографик һәйкәлләрне (С.Г. Вахиди, М.И. Әхмәтҗанов, М.Г. Госманов һ.б.), диалектларны (Л.Җ. Җәләй, Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова, Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова һ.б.), төрки-татар фольклорын (Х.Х. Ярмөхәммәтов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Мәхмүтов, Л.Ш. Җамалетдинов һ.б.) җыю-барлау максатыннан, Татарстанда һәм аннан читтә яшәүче татар авыллары һәм шәһәрләрендә тикшеренүләр уздырыла. Экспедицияләрдә тупланган материал «Татар халык иҗаты» (1951, 1954), «Татар халык әкиятләре», 2 томда (1946, 1956), «Татар халык җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты», 12 томда (1976–1988), «Татар халык сөйләшләре», 2 томда (2008), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләренең атласы»,

жить в памяти людей, в повседневном жизненном пространстве населения данной местности! Ученые и специалисты в различных областях знаний во время экспедиций в регионы находят, собирают, изучают эти особенности… А затем эти материалы, после комплексного изучения, возвращаются к народу и продолжают жить, став частью общего историко-культурного наследия татарского народа и данного региона.

Академическая наука Татарстана, наряду с историческими и археологическими изысканиями, всегда держала в центре своего внимания изучение жизни, быта, особенностей материального и культурного состояния татарского народа, проживающего в том или ином регионе. Подобные исследования проводились во время экспедиционных выездов по инициативе представителей татарской интеллигенции, на рубеже XIX–XX веков было записано много татарских песен, сказок, пословиц и поговорок, мифов и легенд; зафиксированы местные особенности татарского языка и речи. Например, К. Насыри одним из первых начал собирать материалы по устному творчеству татарского народа и по исторической этнографии; с 1871 года он регулярно публиковал образцы фольклора в своем «Казанском календаре». К этой работе присоединились Р.Ф. Фахретдинов, Г.Н. Ахмеров, Х.Б. Бадиги, Дж.Дж. Валиди и другие представители татарской интеллигенции.

В отдельные периоды XX века наблюдалась особая активность в организации подобных исследований. В 1920–1930-е годы начинают проводиться специальные научные экспедиции, что было связано с деятельностью созданного Академического центра. Подобные полевые исследования осуществляли Н.И. Воробьев, А.С. Башкиров, Ф.И. Терегулов, М.С. Губайдуллина, К.С. Губайдуллин, С.Г. Вахиди и др. в Арском, Алькеевском, Рыбно-Слободском, Мамадышском, Мензелинском, Спасском, Челнинском, Чистопольском районах, собирая при этом материалы по этнографии, фольклору, искусству, историко-культурному наследию данных регионов.

Эта работа не прекращалась даже в годы Великой Отечественной войны. В 1940–1980-е годы широкое распространение получили специализированные экспедиции. В Татарстане и за его пределами, в местах компактного проживания татар, проводились исследования по сбору эпиграфических (Х.В. Юсупов), археографических (С.Г. Вахидов, М.И. Ахметзянов, М.Г. Усманов и др.) памятников, изучению диалектов (Л.Дж. Заляй, Л.Т. Махмутова, Н.Б. Бурганова,

«Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) кебек фундаменталь хезмәтләр, мәдәният-сәнгать тарихы, милли һөнәрчелек, кульъязма һәм басма китап тарихы һ.б. өлкәләр буенча күпсанлы китаплар нигезендә ята.

XXI гасыр башында, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең системалы эшчәнлеге нәтиҗәсендә, бу эш яңа баскычка күтәрелә: һәр елны милләттәшләребез яшәгән төбәкләргә комплекслы экспедицияләр оештырыла башлый. Комплекслы рәвештә өйрәнгәндә, тел, әдәбият, фольклор, сәнгать юнәлешенең төбәк хәзинәсендә булган барлык төр байлыгы – буыннан-буынга тапшырыла килгән авыз иҗаты үрнәкләре, бәйрәмнәре, йолагадәтләре, музыкасы, бәйләү-чигү кебек кул эшләре осталыгы, йорт-каралты бизәкләре, кием-салымы, тел үзенчәлекләре, эпиграфик һәм археографик мирасы – һәрберсе барлана-туплана һәм җентекләп анализлап бәяләнә. Татарстанда Актаныш (2009), Апас (2010), Кукмара (2011), Чүпрәле (2012), Мамадыш (2013), Арча, Әтнә (2016), Минзәлә, Мөслим (2017), Азнакай, Буа (2019) районнарындагы татар авыллары һәм поселокларында шундый кыр тикшеренүләре уза.

Татарстаннан читтә: Түбән Новгород, Курган, Оренбург өлкәләре (2010), Мари Илендәге Бәрәңге районы (2011), Удмуртия Республикасы (2012), Пермь краендагы Барда районы һәм Әстерхан өлкәсе (2013), Омск һәм Самара (2014), Оренбург һәм Томск (2015), Чиләбе өлкәләре, Казакъстан Республикасы (2016), Новосибирск өлкәсе, Башкортстан Республикасының Стәрлебаш районы (2017), Ульяновск (2017, 2018), Иркутск, Киров (2018), Пенза, Төмән өлкәләре, Үзбәкстан Республикасы (2019) җирләрендә булып, анда яшәүче милләттәшләребезнең тел-сөйләш үзенчәлекләрен, тормыш-көнкүрешен, мәдәниятен, сәнгатен, кульъязма һәм ташъязма мирасын барлау, аларны фәнни эшкәртү, тикшерү эше җайгасистемага салына.

Экспедициядә җыйган материалларны тикшерү, өйрәнү, фәнни әйләнешкә кертү белән бергә, шушы вакыттан Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивында 1940–2000 елларда шул ук төбәкләргә, авылларга уздырылган экспедиция материалларын барлау, яңа кайткан мәгълүматлар белән чагыштыру башкарыла. Шул җирлектә фәнни хезмәтләр әзерләнә. Әйтик, бүген инде галимнәребез «Татар халык иҗаты»ның 25 томлыгын төгәлләү алдында.

Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова и др.), образцов тюрко-татарского фольклора (Х.Х. Ярмухаметов, И.Н. Надиров, Х.Ш. Махмутов, Л.Ш. Замалетдинов и др.). Собранные в экспедициях материалы легли в основу таких фундаментальных трудов, как «Татарское народное творчество» (1951, 1954), «Татарские народные сказки», в 2-х томах (1946, 1956), «Татарские народные песни» (1965), «Татарское народное творчество», в 12 томах (1976–1988), «Татарские народные говоры», в 2-х томах (2008), «Диалектологический словарь татарского языка» (2009), «Атлас говоров татарского народа», «Татары Среднего Поволжья и Приуралья» (1967) и многочисленных книг по истории культуры и искусства, народных ремесел, истории татарской рукописной и печатной книги и др.

В начале XXI века, благодаря системным усилиям Академии наук Республики Татарстан, эта работа вышла на новый уровень: началась организация комплексных экспедиций в регионы проживания представителей татарского народа. В ходе комплексного изучения собираются, тщательно оцениваются и анализируются все богатства духовной сокровищницы региона: язык, литература, фольклор, искусство, то есть все то, что передавалось из поколения в поколение – образцы устного творчества, праздничные традиции, обрядовая культура, музыка, искусство вышивки, убранство домов, одежда, особенности языка, эпиграфическое и археографическое наследие. В Татарстане подобного рода полевые исследования были проведены в деревнях и селах Актанышского (2009), Апастовского (2010), Кукморского (2011), Дрожжановского (2012), Мамадышского (2013), Арского, Атнинского (2016), Мензелинского, Муслюмовского (2017), Азнакаевского, Буинского (2019) районов.

За пределами Татарстана также налажена системная работа по сбору, научной обработке, изучению особенностей говоров, повседневного быта, культуры, искусства, рукописного и эпиграфического наследия татар, проживающих в Нижегородской, Курганской, Оренбургской областях (2010), Параньгинском районе Марий Эл (2011), Удмуртской республике (2012), Бардымском районе Пермского края и Астраханской области (2013), Омской и Самарской (2014), Оренбургской и Томской (2015), Челябинской областях и Республике Казахстан (2016), Новосибирской области и Стерлибашевском районе Республики Башкортостан (2017), Ульяновской (2017, 2018), Иркутской и Кировской областях (2018), Пензенской, Тюменской областях и Республике Узбекистан (2019).

Элегрәк җыелган һәм яңа гына алып кайтылган материалларны бергә туплау «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» гомуми исеме астында фәнни-популяр китаплар әзерләү эшен башлап җибәрергә этәргеч була. Бу эшнең максаты – халыкның рухи байлыгын үзенә кайтару, аны популярлаштыру, тарихка кертеп калдыру, шушы мәгълүматлар ярдәмендә татар халкының милли үзаңын ныгыту.

Бүген инде бу сериядән 20 китап дөнья күрде, яңаларын әзерләү дәвам итә. Китапларда экспедиция үткән һәр төбәкнең мәдәни тарихы, танылган нәселләр, авыллар-шәһәрләрнең үткәне, гореф-гадәтләре һәм тел үзенчәлекләре төрле яктан яктыртыла. Шулай ук шәҗәрәләр, җирле кул осталарының эш үрнәкләре, кызыклы экспонатлар турында бай мәгълүмат бирелә.

Татар халкының рухи асылын, тарихи-мәдәни сыйфат-билгеләрен бербөтен итеп күзаллау һәм тергезүнең иң нәтиҗәле һәм ышанычлы ысулы булып фәнни экспедицияләр, кыр тикшеренүләре тора. Чөнки бу яшәеш бик борынгыдан килә, татар халкы Евразиянең гаять киң территориясендә формалашкан! Төрле табигый, тарихи, конфессиональ шартларда, төрле этник тирәлектә (төрки халыкларның төрле төркемнәре, фин, угор, славян этнослары янәшәсендә) татарларның этнотерриториаль (Идел-Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары), субэтник (Казан, Касыйм татарлары, мишәрләр), субконфессиональ (керәшеннәр, иштәкләр, нагайбәкләр) төркемнәре барлыкка килгән. Бу төркемнәр кая гына яшәвенә карамастан, гомумтатар милли үзаңына ия. Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты уздыра торган экспедиция материаллары нәкъ шул хакта сөйли, һәр сәфәр шушы фикерне куәтли.

Әлбәттә, уртак милли үзаңның нигезен татар теле тәшкил итә. Төрки телләрнең кыпчак төркеменә караган татар теле иң борынгы телләрдән санала. Татар теленең төп лексик, фонетик, грамматик үзенчәлекләре борынгы төрки телдә үк формалаша. Шуңа күрә дә дөньяның төрле кыйтгаларында яшәүче татарларның, төрле сөйләш вәкилләре булсалар да, тел-сөйләмнәре уртак лексик, фонетик, грамматик калыпларга-кануннарга нигезләнә. Шуңа күрә без борынгы рун язулы истәлекләрне укып, эчтәлегенә төшенә алабыз, казакъ, үзбәк, азәрбайҗан һ.б. төрки телләрне дә аңлыйбыз, татар теленең төрле диалектларында да зур аермалар сизмибез.

Наряду с исследованием, изучением и введением в научный оборот материалов, найденных в экспедициях, ведется работа по сопоставлению новых сведений с материалами, которые были собраны в этих местах ранее – в 1940–2000-х годах и хранятся сейчас в архиве ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ. На их основе готовятся серьезные научные труды. К слову, на сегодняшний день завершается работа над фундаментальным 25-томным сводом «Татарское народное творчество».

Проведенные исследования на основе объединения всего комплекса собранных материалов позволили начать работу по подготовке научно-популярных книг под общим названием «Национально-культурное наследие» из серии «Из сокровищницы научных экспедиций». Возвращение народу духовного наследия, популяризация и сохранение его в анналах истории способствует укреплению национального самосознания татарского народа.

На сегодняшний день увидели свет 20 книг из этой серии, продолжается подготовка новых. В книгах представлены обширные сведения по истории региона, прошлом известных татарских родов, деревень и городов, а также об обычаях, традициях и языковых особенностях татар. Вместе с тем в книгах дается богатая информация о родословных, работах местных умельцев и других интересных экспонатах.

Единственно надежным и достоверным способом составления общего представления о духовных основах и историко-культурных особенностях татарского народа является организация научных экспедиций и полевых исследований. Это связано с тем, что образ жизни татар формировался с древних времен и на очень обширной территории Евразии. Различные этнотерриториальные (татары Волго-Уральского региона, сибирские, астраханские татары), субэтнические (казанские, касимовские татары, мишары), субконфессиональные (кряшены, иштяки, нагайбаки) группы татар сформировались в разнообразных природных, исторических, конфессиональных условиях и в сложном этническом окружении (рядом с разными группами тюркских народов, финно-угорскими, славянскими этносами). Несмотря на то, что данные группы татар проживают на различных территориях, они все объединены общетатарским национальным самосознанием. Каждая экспедиция ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ и собранные материалы неуклонно подтверждают это.

Татар милли әдәби теле исә XIX–XX гасырлар чигендә Казанда, Уфада, Оренбургта, Троицкида, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә һәм алар тирәсендәге авылларда гомумхалык теле булып оешып җитә. Тукай теле, Туфан теле, Еники теле – барыбыз өчен дә уртак байлык. Татар әдәби теленең үсеше барышында кайбер традицион хасиятләр һәм формалар югала, әмма алар сөйләшләрдә саклалып кала. Димәк, төрле урыннарда компактлы яшәгән татарларның сөйләшләре борынгы уртак телебезнең үзенчәлекләрен югалтмавы белән дә кадерле. Экспедицияләр материалы безгә шул хакта да сөйли.

Татарларның мәҗүси заман ышанулары ислам дине белән бәйле күзаллаулары белән беррәттән бүген дә халык арасында яши. Бигрәк тә безнең халкыбыз тарихында мең еллык урыны булган ислам диненең һәм матди, һәм мәдәни тормышка йогынтысы халыктан җыелган материалларда аермачык күренә. Каберташ язмалары, борынгы китаплар һәм кулъязмалар, шәкерт дәфтәрләре, күчереп язылган текстлар, әдәп-әхлак кагыйдәләре, йола-гадәтләр, ышанулар һәм күзаллаулар, бәйрәмнәр һәм ырымнарда татар халкының барлык этник төркемнәре өчен уртак булган мәдәни мирас чагылыш таба. Ислам мәдәнияте гадәти көнкүреш һәм кеше тормышындагы иң мөһим вакыйгаларга (туу, исем кушу, өйләнү, гаилә, бакыйлыкка күчү) бәйле йолаларда этник мәдәнияткә үрелеп китә. Вакытны күрсәткән азан тавышы, намаз-догалар, җомга көнне бәйрәм дип карау белән бергә, татар халкының мәдәни хәтеренә бәетләр, мөнәҗәтләр, дини-суфичыл текстлар кереп урнаша. Традицион йолалар һәм бәйрәмнәр: Сабан туе, Җыен, Корбан гаете, Ураза гаете, өмәләр, Карга боткалары һәм Яңгыр боткалары – болар да уртак байлыгыбыз һәм татарлыгыбызның аерылгысыз билгеләре.

Комплексны экспедицияләр вакытында төрле җирлекләрдә кием-салым, һөнәрләр, азык-төлек әзерләү рәвеше, архитектура, музыка сәнгате буенча да күзәтүләр ясала. Әйтик, төрле җирләрдә яшәүчеләрнең киемнәрендә үзгәлекләр булса да, татарларның традицион гомуммилли өс киеме Казан татарларыныкы йогынтысында формалашкан дигән фикер безнең материаллар белән дә тагын бер тапкыр раслана. Татарлар кайда гына төпләнмәсен – мәчет торгыза. Халкыбызның һәрчак белемгә омтылышы, балалар тәрбияләүгә зур әһәмият бирүе, олыларга аерым бер хөрмәт белән каравы, туган җир һәм нәсел-ыруның һәр кешене саклаучы-яклаучы

Разумеется, фундаментом общего национального самосознания является язык. Татарский язык, относящийся к кипчакской группе, считается одним из самых древних языков. Основные лексические, фонетические, грамматические особенности татарского языка сформировались уже в древнетюркском языке. Именно поэтому татар, проживающих в разных местах и являющихся представителями разных говоров, объединяет единая основа – общие лексические, фонетические, грамматические закономерности. Благодаря этому мы можем понять самые древние рунические письмена, понимаем казахский, узбекский, азербайджанский и другие языки, не ощущаем большой разницы между диалектами татарского языка.

Становление татарского литературного языка в качестве общенародного происходит на рубеже XIX–XX веков в городах Казань, Уфа, Оренбург, Троицк, Астрахань и др., а также окружающих их селах. Язык Тукая, язык Туфана, язык Еники – это наше общее богатство. В ходе развития татарского литературного языка теряются некоторые его традиционные свойства и формы, но они сохраняются в говорах. Поэтому говоры татар, компактно проживающих на разных территориях, ценны для нас сохранением особенностей нашего древнего общего языка. Материалы экспедиций говорят именно об этом.

В народе и сегодня продолжают сосуществовать древние домусульманские верования татар и представления, связанные с исламом. Материалы экспедиций особенно ярко демонстрируют влияние ислама на материальную и культурную жизнь нашего народа на протяжении его тысячелетней истории. Общее культурное наследие всех этнических групп татар ярко выражены в надгробных памятниках, древних книгах и рукописях, тетрадях шакирдов, списках литературных произведений, нравственно-этических нормах, обрядах и обычаях, представлениях и поверьях, праздниках и верованиях. В моменты самых важных событий человеческой жизни (рождение, имянаречение, свадьба, семейная жизнь, похороны) традиции исламской культуры тесно переплетаются с обрядами этнической культуры. Наряду со звуками азана, по которым определяли время, с молитвами, с обычаем считать пятницу праздничным днем и т. д. в культурную память татарского народа вошли баиты, мунаджаты, религиозно-суфийские тексты. Наши традиционные обряды и праздники: Сабантуй, Джиен, Курбан байрам, Ураза байрам, коллективные помочи (өмә), обряды вызывания дождя и встречи

көч дип санавы, шигъриятькә-иҗатка тартылуы да кыр тикшеренү нәтиҗәләрендә чагылыш таба.

Республикабыздагы күтәрелеш татар дөньясының җанлануына, милли үзаң уянуга, татарларның үзләрен бердәм халык итеп тоя башлавына китерде. Хәтта элек-электән туган җирләре, ватаннары бик еракта – әйтик, Польшада яки Литвада, Әстерханда яки Иранда, Уралда яки Себердә, Кытайда яки Финляндиядә булса да, уртак тарих, уртак мәдәният һәм Казан, Татарстан татарларны берләштереп торган үзәк булып кала.

Һәр милләт булып җитешкән бердәмлек төрле мәдәниятләрнең хасиятләрен үзенә туплый. Бу – аксиома. Көчле мәдәният үз тирәсенә башкаларны тарту сәләтенә ия. Алтын Урда чорында ук «татар казаны» күп кабиләләрне кайната, шул исәптән болгарларны да татар политонимына юнәлдерә.

Татар тарихы сикәлтәле, б.э.к. III гасырдан башлап язма истәлекләрдә эз калдыра. Шул ерак гасырлар чоңгылында Бөек кытай диварыннан төньяктарак төрки телле һуннарның империясе төзелә. II гасырда ул хәзерге Казакъстан далаларына күченә. Идел һәм Урал арасында угорлар белән укмаша, IV гасырда Европага юнәлә, халыкларның Бөек күчешен башлап җибәрә. Һуннарның нәсел тамгасы – казан – безнең башкалабыз Казанның да үзәгендә, Казансу буеннан милләттәшләребезне сәламли.

V гасырда Һун империясе таркала – Бөек кытай диварыннан Дунайга кадәр җирләрдә Бөек Төрки каганлык калкып чыга. Аның җимерелүеннән соң исә Болгар цивилизациясе чәчәк ата. Көнчыгышта куәтле татар халкы үзенең дан-шөһрәтен яңгырата. Алтын Урда таркалгач, аның варислары ханлыклар төзи. Бүген алар касыйм, әстерхан, себер татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, нагайбәкләр һ.б. атамалар белән исемләндереп йөртелгән төркемнәр буларак билгеле. Аларны бер тел, бер югары мәдәният – Мәрҗани фәһеме, Тукай шигырьләре, Сәйдәш музыкасы, Урманче сурәтләре берләштерә.

Татар асылын, аның рухи үзәген, татарлыкның гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатларын аңлау-төшенү өчен, һичшиксез, тарихи барышны гына түгел, бәлки халыкның хәтерендә яшәгән рухи кыйммәтләрне дә барларга, өйрәнергә кирәк. Татарстан Фәннәр академиясе, аның институтлары, шул исәптән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре әлеге юнәлештә эшлиләр. Дөрес, татарлар элек-электән күпләп яшәгән

весны – все это тоже наше общее наследие и то, что делает нас татарами.

Во время комплексных экспедиций в различные места проживания татар изучаются одежда, ремесла, традиции приготовления пищи, архитектура, музыкальное искусство и т. д. Например, наши материалы ещё раз подтвердили мысль о том, что, несмотря на некоторые различия в одежде татар разных регионов, очевидно, что традиционная национальная татарская одежда сформировалась под влиянием казанских татар. Где бы ни селились татары, они воздвигали мечети. Стремление народа к знаниям и просвещению, большое внимание, которое они уделяют воспитанию детей, особое уважение к пожилым, почитание родной земли и своего рода – как оберегающих и защищающих сил, склонность к поэтическому творчеству – все это отражается в материалах полевых исследований.

Разумеется, современная жизнь татар, где бы они ни жили, связана с Татарстаном. Общественный и духовный подъем в нашей республике способствовал оживлению татарского мира, пробуждению национального самосознания, осознанию татарами себя как единого народа. Даже для татар, чьей родиной давно является Польша или Литва, Астрахань или Иран, Урал или Сибирь, Китай или Финляндия, средоточием общей истории, общей культуры и единым связующим звеном остаются Казань и Татарстан.

Каждая общность, достигшая уровня нации, вбирает в себя свойства различных культур. Это – аксиома. Сильная культура обладает способностью консолидировать вокруг себя другие. В эпоху Золотой Орды в «татарском котле» перекипели многие племена, по той же причине название «булгары» стало татарским политонимом.

Перипетии татарской истории нашли отражение в письменных источниках, начиная с III века до нашей эры. В те далекие времена к северу от Великой китайской стены формируется тюркоязычная империя хуннов. Во II веке они переселяются в степи современного Казахстана. Сплотившись с уграми между Волгой и Уралом, они устремились в Европу, начав процесс Великого переселения народов. Не случайно родовая тамга рода хуннов – казан – сегодня приветствует наших соотечественников на берегу реки Казанки в центре Казани.

В V веке Хуннская империя распадается, и на землях от Великой китайской стены и до Дуная возникает Великий Тюркский каганат. После его распада получает расцвет Булгарская

барлык урынчылыклар да өйрәнелгән дияргә иртәрәк әле. Димәк, бу эш дәвам итәргә тиеш.

Фәнни күзлектән караганда, борынгы һәм бай тарихлы, үз әдәби теле, профессиональ әдәбияты һәм сәнгате булган бердәм татар милләте без. XX гасырда татар мәдәнияте, мәгариф һәм фән югары үсеш ала. Бу процесста төрле җирләрдә яшәгән, төрле этнографик төркемнәргә караган татарларның өлеше зур. Безнең көчебез – бердәмлектә!

* * *

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты үзенең 80 еллык эшчәнлеге дәвамында татар халкының барлык этник төркемнәрен, аларның рухи һәм мәдәни мирасын өйрәнү буенча зур фәнни үзәккә әверелде. Теоретик эзләнүләр алып бару белән беррәттән, Институт галимнәре ел саен Татарстан районнарына һәм татар халкы тупланып гомер иткән башка республикаларга, өлкәләргә экспедицияләр оештыралар. Әлеге экспедицияләрнең материаллары күпсанлы монографияләр, диссертацияләр, белешмәлекләр, сүзлекләр, диалектологик атласлар өчен җитди фәнни чыганак ролен үти.

Түбән Новгород өлкәсе (Нижгар) татарларының мәдәнияте белән Институт галимнәре электән үк кызыксынып киләләр. Үткән гасырның 50 нче еллар ахыры – 60 нчы еллар башында бу төбәккә махсус экспедицияләр оештырыла. Диалектолог-галимнәр Л.Т. Мәхмүтова, Н.Б. Борһанова үзенчәлекле тел материаллары туплаганнар. Х.Х. Ярми, И.Н. Надиров, Р.Ш. Башкуров, Т.Н. Галиуллин, Х.Х. Гатина, М.Н. Нигъмәтҗановлар фольклор әсәрләре үрнәкләрен язып алганнар. Алар борынгы озын лирик көйләрдән «Шәлче егетләр», «Җанашым», «Кайгырмыйк ла юк малларга», «Бәхетсез солдатың килә», «Ник үстердем буемны», шулай ук «Ташкай», «Дашкай», «Әхсән голова» кебек тарихи бәетләр, «Җимчәчәк» исемле йола җырының уникаль язмаларын фәнни әйләнешкә кертеп калдырдылар. Саналган әсәрләр барысы да Институт әзерләгән унике томлык татар фольклоры җыелмасына (1977–1988) кертелгән. Күренекле галим, тарихчы М.Г. Госманов оештырган экспедиция бу төбәктә фән өчен бәһасез кульязмалар таба. 1984, 1994 елларда ТӘһСИ галимнәре А.Х. Садыйкова һәм Р.Ф. Ягъфәров язып алган мөнәҗәтләр һәм бәетләр шулай ук махсус җыентыкларда дөнья күрделәр.

цивилизация. Могучий татарский народ во весь голос заявляет о себе на востоке. После распада Золотой Орды её наследники создают отдельные ханства. Сегодня их потомки живут как касимовские, астраханские, сибирские татары, мишари, кряшены, нагайбаки и другие группы. Их объединяют общий язык, общая высокая культура – интеллект и разум Марджани, поэзия Тукая, музыка Сайдашева, творения Урманче.

Для понимания сути народа, его духовной сущности, общих и специфических особенностей татарства, безусловно, надо изучать не только историю, но и сохранившиеся в памяти народа духовные ценности. Академия наук Татарстана, её институты, в том числе ученые ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, работают в данном направлении. Естественно, ещё не все местности и регионы исторического проживания татар охвачены и изучены. Значит, эта работа должна продолжаться.

Если судить с научных позиций, то мы – единая татарская нация с древней и богатой историей, имеющая свой литературный язык, профессиональную литературу и искусство. В XX веке культура, просвещение и наука татарского народа достигли очень высокого уровня. В этом процессе незаменима роль татар, проживающих в разных регионах и представляющих различные этнографические группы. Ведь наша сила – в нашем единстве!

* * *

Институт языка, литературы и искусства Академии наук Республики Татарстан в течение 80-летней деятельности превратился в крупный научный центр по изучению этнических групп татар, их духовного и культурного наследия. Наряду с теоретическими исследованиями ученые Института ежегодно выезжают в экспедиции в районы Татарстана и регионы компактного проживания татар. Материалы экспедиций являются серьезным научным подспорьем в ходе подготовки многочисленных монографий, диссертаций, справочников, словарей, диалектологических атласов и др.

Культурой татар Нижегородской области ученые Института языка, литературы и искусства интересуются давно. В кон. 50-х – нач. 1960-х гг. прошлого века в этот регион были организованы специализированные экспедиции. Интересные материалы удалось собрать ученым-диалектологам Л.Т. Махмутовой и Н.Б. Бургановой. Образцы фольклора записали в свое время Х.Х. Ярми, И.Н. Надиров,

Нижгар татарлары бу җирлектә бергә тупланып гасырлар дәвамында яшиләр. Хәзерге вакытта татарлар бу өлкәнең берничә районында, 35 авылында гомер кичерәләр. Алар – татар милләтенең бер өлеше. Төбәктәге татарларның саны 50 меңгә җитә, шуларның яртысы авылларда, калганы өлкәдәге шәһәрләрдә яши.

2010 елның май аенда ТӘһСИ хезмәткәрләре һәм аспирантлары Түбән Новгород өлкәсенә экспедициягә чыккан иде. Аның составында тарихчы-археограф, фольклорчылар, телчеләр, музыка һәм сәнгать белгечләре эшләде.

Түбән Новгород өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәте, аерым алганда, ул вакытта Х. Фәезханов исемендәге Түбән Новгород Ислам институты ректоры, ә хәзер, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисенең беренче урынбасары, Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсе имам-мөхтәсибе Дамир хәзрәт Мөхетдинов, «Мишәр дөньясы» газетасы баш мөхәррире Әнвәр Камалетдинов, шулай ук Кызыл Октябрь, Пилнә, Сергач, Спасс, Сеченов, Кнәген районнарының администрация башлыклары ТӘһСИ хезмәткәрләре булып киткән 20 авылның җирле үзидарә башлыклары, мәктәп директорлары һ.б. ярдәме белән, экспедиция эше өчен бөтен шартлар да тудырылган иде. Һәрвакыт ачык йөзле, тәмле сүзле, кунакчыл булулары белән халык та галимнәргә бик булышты.

Түбән Новгород татарлары – зыялы, югары мәдәниятле һәм үз тырышлыклары аркасында зур дәрәҗәләргә ирешкән халык. Алар арасында берничә Советлар Союзы Герое, бер Социалистик Хезмәт Герое бар, Ленин ордены һәм башка орденнар белән бүләкләнүчеләр ике дистәгә якын. Бу төбәктән берничә генерал, бер диңгез адмиралы, бик күп галимнәр, табиблар чыккан. Бүгенге көндә дә алар армый-талмый уртак ватаныбызга хезмәт итәләр.

Татар авылларының хезмәт сөючән халкы таза тормышта, шәп, нык йортларда яши. Авыллардагы берничә мәчетнең һәрберсендә намазга чакырып азан тавышы яңгырый. Кыскасы, экспедиция барышында Институт хезмәткәрләре Нижгар татарларының хезмәт сөючән халык булуына, гореф-гадәтләрен саклап, ислам динен хөрмәт итеп, гаилә учакларын сүндермичә гөрләтеп яшәүләренә тулысынча инанып кайтты.

Бу китапка элеккеге экспедицияләр һәм 2010 елгы экспедиция материаллары кертелде.

Тарихчы Р.М. Кадыйров мәкаләсендә татар авылларында табылган борынгы кульязма һәм эпиграфик ядкярләрне тикшерү

Р.Ш. Башкуров, Т.Н. Галиуллин, Х.Х. Гатина. Они ввели в научный оборот уникальные записи протяжных старинных лирических песен «Шәлче егетләр», «Җанашым», «Кайгырмыйк ла юк малларга», «Бәхетсез солдатың килә», «Ник үстердем буемны», а также исторических баитов «Ташкай», «Дашкай», «Ахсан голова» и обрядовой песни «Җимчәчәк». Все перечисленные произведения вошли в 12-томное собрание татарского фольклора, подготовленного ИЯЛИ в 1977–1988-е гг. Экспедиция, организованная известным ученым-историком М.Г. Усмановым, обнаружила в этом регионе бесценные для науки рукописи. Мунаджаты и баиты, записанные учеными ИЯЛИ А.Х. Садековой (1984) и Р.Ф. Ягафаровым (1994), также были опубликованы в тематических сборниках.

Нижегородские татары компактно проживают в этих землях на протяжении столетий. В настоящее время нижегородские татары – неотделимая часть татарского народа – проживают в 35 селах на территории нескольких районов области. Их общая численность по области составляет примерно 50 тысяч, половина из них живет в селах, остальные – в областных городах.

В мае 2010 года состоялась экспедиция ИЯЛИ в Нижегородскую область. В составе группы были ученые и аспиранты Института – историк-археограф, фольклористы, языковеды, музыковед и искусствовед.

При поддержке Духовного управления мусульман Нижегородской области, в частности, Дамира хазрета Мухетдинова – ректора Нижегородского Исламского института им. Х. Фаезханова (ныне он – первый заместитель председателя Духовного управления мусульман Российской Федерации, имам-мухтасиб города Санкт-Петербурга и Ленинградской области), главного редактора газеты «Мишәр дөньясы» Анвара Камалетдинова, глав администраций Краснооктябрьского, Пильнинского, Сергачского, Спасского, Сеченовского, Княгининского районов, глав местных администраций 20-ти сел, в которых побывали члены экспедиции, директоров школ и т.д. были созданы самые благоприятные условия для работы ученых. Радушие и приветливость местного населения также сыграли благоприятную роль в организации исследований.

Татары Нижегородской области – образованный, культурный и целеустремленный народ. Среди уроженцев этого края – несколько Героев Советского Союза, один Герой Социалистического Труда, около двух десятков кавалеров Ордена Ленина и других орденов.

нәтиҗәләре турында кызыклы мәгълүматлар китерелә. Бу төбәктә вакытында бик популяр булган «Мөхәммәдия», «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә» әсәрләре, фарсы шагыйре Сәгъдинең «Гөлестан» (Камка авылы) поэмасы табылды.

Тел белгече Ф.Г. Гарипова Сергач районы Камка авылы турында яза. Татарстанның Әлки районында урнашкан Камка авылы белән тарихи параллельләр китереп, нәселләр арасындагы туганлык җепләренең тарих тирәнлекләрендә үзара берегүен ачыклый.

А.Х. Башкурова-Садыйкованың мәкаләсе татар халкы арасында элек-электән бик популяр булган мөнәҗәтләргә багышланган. Мөнәҗәтләрдә халыкның тормыш фәлсәфәсе, ислам кануннары буенча яшәү мәгънәсе чагыла. И.Г. Закирова үзенчәлекле риваятьләр, легендалар һәм мифологик хикәятләр язып алган. Алар арасында «Җимчәчәк» йоласы, күренекле кешеләрнең, ишаннарның (Х. Әлмөхәммәтов, Садыйк абзый һ.б.) могҗизалары, гаилә тарихлары, авылларның үткәне хакындагы язмалар бар.

Диалектолог Ф.С. Баязитова сергач сөйләшен өйрәнү этапларын, аларның үзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, йолаларын яктырта. Д.Б. Рамазанова җирле сөйләшне башка сөйләшләр белән чагыштырып анализлаган бай, кызыклы материал тәкъдим итә. Л.Ф. Тукмачева үзенең мәкаләсен нижгар татарлары теленең синтаксик үзенчәлеген яктыртуга багышлаган.

Нижгарлылар – җырлы-моңлы халык. Бу төбәк татар халкына Татарстанның халык артистлары Рәшит Ваһапов (Актук) һәм Хәйдәр Бигичев (Чүмбәли) кебек бөек затларны бүләк иткән. 2010 елда да биредә бик күп туй, мәхәббәт, солдат җырлары, шул исәптән кыска җырлар да язып алынды. Шуларның бер өлеше, элеккеге экспедиция материаллары белән тулыландырылып, Л.М. Мөхәмәтшинаның төбәк татарлары халык авыз иҗатының популяр жанры булган җырларны өйрәнүгә багышланган мәкаләсендә урын алган.

Э.Р. Каюмова мәкаләсендә музыкаль әсәрләр ноталары белән китерелә. Монда яңа һәм иске җырлар, дини жанр үрнәкләре – мөнәҗәтләр, азаннар, салаватлар кертелгән. Галимә 80 информанттан мәгълүмат туплаган, музыкаль уен коралларында – мандолина, скрипкада башкарылган көйләрне дә яздырып алган.

И.Р. Шәрипов мәкаләсеннән татар-мишәрләрнең борынгы ышанулары, календарь, гаилә йолалары турында мәгълүмат алабыз. Аның шулай ук күптән онытылган «Күрше», «Җаника» (Камка),

На этой земле родились и выросли несколько генералов, один адмирал, много известных ученых и врачей.

В татарских селах области живут трудолюбивые, жизнерадостные люди, хозяйства у них крепкие, дома – удобные. С минаретов мечетей слышится призывный голос азана. За время экспедиции татарстанские ученые воочию увидели, что нижегородские татары умеют не только работать, но и бережно чтут старинные традиции и обычаи, уважают веру предков и семейные ценности.

В эту книгу вошли материалы прежних экспедиций и исследования 2010 года.

В статье историка Р.М. Кадырова приводятся интересные сведения по результатам исследований старинных рукописей и эпиграфических памятников, обнаруженных в татарских селах Нижегородской области. Были найдены произведения, бывшие некогда очень популярными среди татар, – «Мухаммадия», «Бэдавам», «Рисаляи Газизэ», поэма персидского поэта Саади «Гулистан» (село Камкино).

Статья языковеда Ф.Г. Гариповой посвящена селу Камкино Сергачского района. Она проводит исторические параллели с деревней Старое Камкино Алькеевского района РТ и указывает на наличие в глубинах истории общих родственных корней между населениями этих сел.

А.Х. Башкурова-Садекова в своей статье размышляет о мунаджатах, которые издавна были очень популярны в народе. В них нашли отражение философия народа и его жизнеустройство, подчиненное мусульманским канонам, а потому наполненное особым смыслом. И.Г. Закирова в ходе экспедиции записала ряд своеобразных сказаний, легенд и мифологических рассказов. Среди них – обряд «Җимчәчәк» (праздник первых цветов в конце апреля), чудесные истории, связанные с именами известных людей, ишанов (Х. Альмухамметов, Садык-абзый и др.), истории семей и сел.

Диалектолог Ф.С. Баязитова в своем материале освещает этапы своей работы по изучению сергачского говора, его особенности, а также традиции и обряды татар этого региона. Д.Б. Рамазанова предлагает интересный сопоставительный анализ, рассматривая сергачский говор в сравнении с другими. Л.Ф. Тукмачева посвятила статью исследованию особенностям синтаксиса нижегородских татар, взяв в центр внимания структуру предложения и своеобразие их речи и интонации.

«Вечерка» кебек халык уеннары турында язмалары укучылар өчен кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Р.Р. Солтанова мәкаләсендә нижгар татарларына хас кәсепләр, һөнәр төрләре, гамәли сәнгать турында бай мәгълүмат бирелә. Аерым игътибар татарлар яшәгән йортларның эчке һәм тышкы бизәлешенә юнәлтелә. Аларның бүгенге көндәге торышы бай иллюстратив материалларда чагыла. Л.В. Илтубаеваның татар-мишәрләр арасында киң таралыш тапкан декоратив-гамәли сәнгатьнең бер юнәлеше булган нәкышләп тукуны яктырткан мәкаләсе дә иллюстратив материалга бай.

Нижгар татарларының туган җирләре, ата-бабаларының атаклы, данлы үткәне, хезмәт сөючән, кунакчыл ул һәм кызлары тудырган рухи һәм мәдәни мирас үрнәкләрен тупланган бай материал укучылар күңеленә хуш килер дип ышанабыз. Җирле осталарның, халык талантларының күңел чишмәсе беркайчан да саекмасын, тырышлыгы, булганлыгы, гореф-гадәт һәм йолалары гасырлардан гасырларга күчә барсын иде.

***Ким Миңнуллин,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институты директоры,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*мөхбир әгъзасы*

Нижегородские татары – очень музыкальный народ. Этот край подарил татарскому народу великих сынов – Народных артистов Татарстана Рашита Вагапова (село Актуково) и Хайдара Бигичева (село Чембилей). В 2010 году члены экспедиции записали большое количество песен – свадебных, любовных, солдатских, в том числе коротких песен. Часть из них, дополненная материалами прежних экспедиций, использована в статье Л.М. Мухамметшиной, посвященной одному из популярных жанров устного народного творчества нижегородских татар – песне.

В статье Э.Р. Каюмовой приведены образцы музыкальных произведений, снабженные нотами. Здесь есть и новые, и старинные песни, образцы религиозных жанров – мунаджаты, азаны, салаваты. Э.Р. Каюмова записала все эти произведения от 80 информантов, среди собранных ею материалов есть и мелодии для исполнения на музыкальных инструментах – мандолине, скрипке.

В статье И.Р. Шарипова представлены сведения о древних верованиях, календарных и семейных обрядах татар-мишарей Новгородской области. Читателям также будут интересны заметки автора о давно забытых народных играх «Сосед», «Джаника» (село Камкино), «Вечерка».

В статье Р.Р. Султановой представлена обширная информация о ремеслах, видах рукоделия, прикладном искусстве нижегородских татар. Особое внимание уделено внутреннему и внешнему оформлению домов. Сегодняшняя жизнь татар области представлена в серии иллюстративного материала. Статья Л.В. Илтубаевой, посвященная широко распространенному среди местных татар виду искусства – орнаментальному ткачеству, – также снабжена фотографиями.

Надеемся, что читателям придутся по душе представленные в книге образцы духовно-культурного наследия, в котором еще слышны отзвуки истории, голос родной земли, слава предков нижегородских татар. Пусть не оскудеет родник вдохновения и творчества местных мастеров, и пусть продолжаются в веках лучшие качества этих сильных духом людей.

***Ким Миннуллин,***
*директор Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова,*
*член-корреспондент Академии наук*
*Республики Татарстан*

# ТАШЛАРНЫҢ ТАМЫРЫ ТИРӘН

## *Кулъязма мирас һәм ташъязмалар*

*Рәшит Кадыйров*

Хәзерге Түбән Новгород өлкәсе җирләрен болгарлар бик күптән үзләштергән. Монгол яуларына кадәр үк монда берничә болгар шәһәре булуы билгеле. Соңрак чорларда нигезләнгән Сараклыч исемлесе (хәзерге вакытта Россиядә атаклы Саров монастыре биләмәсенә керә) хакында «ул турыдан-туры Болгар дәүләте чикләре эчендә булган» дип язылды[1]. Чыннан да, монголлар явына кадәр мәмләкәтебезнең җирләре бик киң һәм иркен булган.

XVI гасырда, ягъни Казан ханлыгыбыз яшәгән чорларда, аның гаскәренең хәзерге Түбән Новгород (заманында – Ибраһим-кала) һәм Муромнарга кадәр барып йөрүләрен бары элекке нигезебезгә «кайтып килү» генә дип тә аңларга мөмкин. 1552 ел көзендә, Явыз Иван чирүе Казан өстенә ябырылганда, Нижгардан көньякка таба урнашкан авыллардагы һәм утарлардагы кавемдәшләребезнең аңа каршылык күрсәтүләре хакында мәгълүматлар бар.

XVII–XIX гасырларда милләтебезнең бердәмлеген ислам дине тәэмин иткән. Бу җәһәттән, Түбән Новгород мөселманнарының ислам динен һәр яктан яклавы, саклавы һәм үстерүе

---

[1] *Арсюхин Е.* Сараклыч: и все-таки он был! (Рассказ о том, как сначала «открыли», а потом «закрыли» золотоордынский город). – Нижний Новгород, 2006.

аерым игътибарга лаек. Сергач тирәсендәге һәм аның күрше төбәк авылларындагы мәчет-мәктәпләр, мәдрәсәләрнең күплеге үзе үк бик гыйбрәтле күренеш. Бу яктагы авылларга оештырылган фольклор, тел, археографик экспедицияләр вакытында милләтебез тарихы өчен шактый ук бай материал тупланган. Заманында (XX гасыр башларында) Түбән Новгород мишәрләренең гореф-гадәтләрен атаклы тарихчыбыз Гайнетдин Әхмәрев өйрәнә һәм бу хакта мәкаләләр язып бастыра. Сафаҗай авылында туган мәшһүр галим Хөсәен Фәезханов милләттәшләренең тормышын һәрьяклап тикшерүгә күп көч куя, болгар эпиграфикасы өлкәсендә зур ачышлар ясый, эпитафияләрнең телен (һәрхәлдә, андагы даталарны) дөрес уку юлын беренче булып таба.

Нижгар – Сергач төбәгендә яшәүче милләттәшләребез һәрзаман үзләрен бердәм милләт әгъзалары итеп тоеп яшәделәр һәм яшиләр. Бу хакта, бәлки, иң куәтле дәлилләрнең берсе – 1920 елда мөфти Галимҗан Баруди язып калдырган истәлектер. Көндәлек характерында язылган «Хәтер дәфтәре»ндә ул Мәскәүдән Казанга кайтышлый Сергач тимер юл станциясе перронына чыкканын каләмгә ала. «Минем яныма ике мишәр абзый килеп, үзләренең бик тә «Казан җөмһүрияте» (ТАССР) эченә керергә теләүләре, кызганычка, ул өметләре тормышка ашмавы турында сөйләделәр», – дип яза Галимҗан хәзрәт.

Сергач авылларындагы милләттәшләрен Казан арты яки Сембер якларында яшәгән актив милләтпәрвәр һәм дин әһелләре булган затлар һич тә онытмыйча, игътибар уңында тотканнар. Аларның иң күренеклеләре – Казан артындагы Оры авылыннан Хәбибулла бине Хөсәен әл-Орыви әл-Болгари (1762–1816) һәм Саратов губернасына кергән Кулаткы авылыннан Мөхәммәдсәед Җәгъфәр әс-сани әл-Кыпчакый әл-Болгари (1790–1862)[1]. Идел буе – Нижгар якларында соңгысы аеручa популяр булган. Нәкышбәнди шәехе Җәгъфәр әл-Болгари Сергач тарафы

---

[1] Бу хакта укы: *Усманова Д.* Мусульманское «сектантство» в Российской империи. – Казань, 2009.

мөселманнарының иң көтеп ала торган мөршиде (дини остазы) була. 1980 нче еллар ахырында үткәрелгән археографик сәфәр вакытында Чүмбәли саласында табылган бер кулъязма читендә олуг шәех турында «мөбарәк кадәмен (аягын) Мәдәнә авылына басты, анда бераз торып, Чүмбәлигә юнәлде», дигән сүзләр язылган. Бу хәбәр генә дә Җәгъфәр әл-Болгаринең Сергач төбәге мөселманнары арасында ифрат зур ихтирамга ия булуын ачык күрсәтә[1]. Шул исәптән, алар арасында Ханморза әл-Болгари исемле кешенең Казан арты Бәрәскә авылы мөселманнары белән якын элемтәдә булганлыгы (ихтимал, Бәрәскә мәдрәсәсендә белем алганлыгы) шулай ук кулъязмалардан билгеле булды.

Гомумән, Нижгар төбәге фәнни яссылыкта шактый өйрәнелгән. Бигрәк тә 1960 нчы елларда бу җирлек тарихын өйрәнүгә игътибар арткан. Археографик эзләнүләр биредә Миркасыйм Госманов җитәкчелегендә алып барылган. Ул үзе дә Сафаҗай (җирле әйтелештә «Сабацай» дип тә йөртелә) авылында шактый ук тикшеренү эшләре башкарып, шулар нәтиҗәсендә «Заветная мечта Хусаина Фаизханова» исемле китап (1980) бастырып чыгара, «Сафаҗай авылы тарихы» исемле кулъязма таба.

Әйтергә кирәк, ТӘһСИнең 2010 елгы комплекслы экспедициясе барышында Сергач якларыннан бик күп китаплар яки аерым өзекләр табып кайттык, дип мактана алмыйбыз, чөнки, әйткәнебезчә, моңарчы Нижгар төбәгендә археографлар җитди эзләнеп, шактый күләмдәге табышка ия булганнар иде инде. Хәзер ул якта гарәп хәрефле кулъязма китап табу шактый авыр (алар бик аз һәм сирәк). Дөрес, басма китапларга килгәндә, алар кайбер гаиләләрдә саклана әле. Араларында «Мөхәммәдия», «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә»ләр, һәм әлбәттә, Коръән нөсхәләре бар.

Аерым табышларга килгәндә, Камка авылында атаклы фарсы шагыйре Сәгъдинең «Гөлстан» поэмасы барлыгы ачыкланды.

---

[1] Мәгълүм булганча, Җәгъфәр әл-Болгаринең дәвамчысы Баһаветдин Хәмзә улы Вәисзадә әл-Болгари 1862 елда «Фирка-наҗия» оешмасын төзеп, дини вә милли азатлык хәрәкәте башлап җибәрә.

Зур Рбишчада авылның инкыйлабка кадәрге чорларда мәншүрле (указлы) муллалар тарафыннан бик пөхтә итеп язып тутырылган метрика дәфтәре табылу безнең өчен зур куаныч булды.

Нижгар якларына чыкканда, XIX–XX йөз башы гарәп язулы кабер ташлары (билгеташ) ягъни эпиграфика истәлекләре күбрәк очрар, дигән уебыз бар иде, ләкин чынлыкта алай ук булмады. Моның сәбәпләрен төгәл генә атау кыен. Ул тарафларда кабер ташлары кую традициясе бик үк тамырлы түгел дисәк, ялгышуыбыз ихтимал, чөнки, мәсәлән, Темников тирәләрендә XVII гасыр кабер ташларының табылып торуы мәгълүм. Әлегә, Нижгар төбәгендәге мөселман авылларында ташлар куелган очракта да, алар озакка чыдамый торган материалдан ясалган, дигән фаразга килергә туры килә. Мәсәлән, Чүмбәлидәге каберлектә берничә таш өслегенең тышкы язулы катламы кубып төшкәне күзгә бәрелеп тора. Аның өстенә яңа эпитафия язылып куелган. Даталары исә XIX гасыр азагы – XX гасыр башына карый.

XIX гасырдан башлап кабер ташларын Казаннан һәм Ижаудан китерә башлаганнар. Бу хакта безгә авыллардагы тәҗрибәле, белемле кешеләр сөйләде. Әлеге ташлар, аерым алганда, олуг шәехләр һәм мөдәррисләр авылы Сафаҗайда (бу авыл төбәктәге карьяләрнең иң борынгыларыннан, XII–XIII гасырда оешканнарыннан санала) һәм шулай ук борынгылыгы белән аерылып торган Камкада шактый санда бар.

Сафаҗайдагы эпиграфик истәлекләрнең язулары Казан ягының бик оста хаттатлары тарафыннан башкарылган. Иң әүвәл игътибарны мәшһүр Хәбибулла ибне Әлмөхәммәт ишанга куелган таш җәлеп итә. Ул – Идел буенда иң нык таралган «нәкышбәндия» тарикате шәехләреннән берсе (сүз уңаеннан, атаклы дин әһелләре Баһаветдин Вәиси Нәкышбәнди әл-Болгари, Галимҗан Баруди, Шиһабетдин Мәрҗани, Зәйнулла Рәсүли әл-Болгари һәм башкалар һәммәсе нәкышбәнди булганнар). Аннан ерак түгел Шәрәфетдин ибне Сираҗетдин Нәкышбәнди җирләнгән. Аның ташындагы язу бик оста, матур башкарылган. Сафаҗай зиратында мондый төзек ташларның саны җидегә җитә.

Сафаҗайның күп кенә дин галимнәре һәм имамнары Казан мәдрәсәләрендә укыганнар. Мисал өчен, Хәбибулла шәехнең улы Мөхсин хәзрәт Печән базары мәчетендәге (хәзер «Нурулла» мәчете дип йөртелә) мәдрәсәне тәмамлаган. Аның остазы – танылган композитор Мансур Мозаффаровның әтисе Хуҗиәхмәт ахун Мозаффари булган.

Камка авылындагы зур зиратта уннан артык гарәп язулы ташларны күрдек. Аларны билчән-тигәнәкләрне ера-ера күрсәтеп йөргәне өчен авыл имамы Габделкадыйр хәзрәткә ихлас рәхмәтебезне белдерәбез. Ташлары шактый ук зур, күбесенең язуы алда, артта һәм ян кырларында да бар. Хәзрәт әйтүенә караганда, ташлар Ижаудан кайтарылган.

# САЛАВАТ КҮПЕРЕНДӘ КАМКА ТӨСЕ ДӘ БАР

***Мәшһүр авыллар тарихыннан***

*Фирдәвес Гарипова*

Татар халкы сибелеп яши. Ләкин ул кайда гына торса да, үз көнен үзе күрә, тырыша, «кар өстенә ут яга». Матур йортлар сала, агачлар утырта, акыллы балалар үстерә. Татарлар бар өлкәдә дә өлгерергә тырышалар, укыйлар, зур дәрәҗәләргә ирешәләр. Кыскасы, төрле тарихи сәбәпләр нәтиҗәсендә башка җирлекләргә сибелгән милләттәшләребез сынатмый, дөбердәтеп тормыш алып баралар. Нигезләре, каралты-куралары нык, йортлары матур, таза, зур. Үзләре эшчән һәм гаҗәп дәрәҗәдә тырыш. Алар сәләтлеләр, булганнар һәм уңганнар.

## Камка авылы

Түбән Новгород өлкәсе Сергач районындагы Пьяна елгасы ярына урнашкан Камка – зур авыл. Авылда, нигездә, элек йомышлы (служилый) дип аталган татарлар гомер кичерә. Суның тормыш өчен кирәклеген аңлап халкыбыз авылларын һәм шәһәрләрен елга, күл, чишмәләр буена салган.

Тарихчылар, авыл өлкәннәре сөйләвенә караганда, камкалылар (ирләр) рус җирләре чикләрен күчмә халыклар һөҗүменнән саклар өчен төрле урыннарга җибәрелгәннәр. Бер төркем камкалылар Арзамас тирәсендәге Саров торак пунктыннан якын гына урнашкан Пуза засекасына барырга фәрман алганнар. Ә гаиләләре яшәгән урыннарында калган. Засека – атлы гаскәр үтә алмасын өчен аркылы-торкылы урнаштырылган агач

өемнәреннән ясалган өекләр. XVI гасырда мондый өекләр Арзамас төбәгенең көньяк-көнчыгыш өлешендә ясалган. Аның озынлыгы 200 чакрымга сузылган. Бу өекнең үтеп йөрү юлы ике урында булган. Берсе – Шаткы капкасы (Шатковские ворота), икенчесе – Собакин капкасы (Собакинские ворота) дип йөртелгән. Йомышлы татарлар саклау чигенең көньяк-көнчыгыш ягына урнаштырылган кереп-чыгу капкаларын саклаганнар.

Йомышлы татарлар Розбахта һәм Сөендек Телевлевлар Пузы төбәгендә Пузы капкаларын саклаганнар. Шушы төбәктәге Комка исеме алган рус авылы кайчандыр монда яшәгән, саклау хезмәтен үтәгән йомышлы татарлар һәм мордвалар истәлеге буларак саклангандыр.

Камкалыларның төп урнашкан урыннары Шаткы урманы белән Зур Келе ~ Зур Киле елгасы аралыгында була. Чик ныгытмаларын саклауны көчәйтү өчен монда 1585 елда Чики Енгильдеев җитәкчелегендәге Кадом татарлары да китереп утыртыла. Патша хөкүмәте Камка һәм Кадом татарларын шушы урнашкан урыннарында калдырырга теләсә дә, камкалылар үзләре элек яшәгән җирләренә, Пьяна буйларына кайтырга телиләр. Кадом татарлары җитәкчесе Чики Енгильдеев тырышлыгы белән татарлар элек торган урыннары Камкага кире әйләнеп кайталар. Камка авылы хәтта берникадәр вакыт, Чики Енгильдеевка хөрмәт рәвешендә, Чики усады, дип тә аталып йөри. Аннан соң бу атама онытыла. «Арзамасские поместные акты» хезмәтендә (М., 1915, № 169) язылганча, татар авыллары да урнашкан Пьяна елгасы буйлары руслар тарафыннан колонизацияләнгән вакытларда, Камка татар авылы булуына карамастан, Вечканов мордвалары карамагына бирелә. Авыл атамасы бу вакытта мордвача «Усть-Пилилей» дип йөртелә, Пилилей мордвача «елга колагы» була. Тора-бара бу исем дә онытыла. Халык әби-баба куйган исем-атамага турылыклы булып кала.

1603 елда авылларына кире әйләнеп кайткан камкалылар арасында Кадом татарлары да була. XVII гасыр урталарында бер төркем Кадом татарлары тагын Камка авылына килеп урнашалар. Бу мәгълүматлар А.М. Орлов китабындагы материаллар белән дәлилләнә.

Камка атамасы нәрсәне аңлата? Бу атама шактый серле. Камка авылы халкы хәтерендә сакланып калган легенда-риваятькә караганда, авылны Камка әби җитәкчелегендә дүрт татар кешесе нигезли. Легенданың икенчесендә башкачарак сөйләнә. Камка әби авыл урнашачак урынны күргәч, аның матурлыгына сокланып: «Бу урын чын мәгънәсендә *камка* икән», – дип әйтеп куя. А. Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә (Казан, «Мәгариф» нәшрияты, 2007. – 575 б.) камка – «кытайдан китерелгән җете чуар тукыма», дип бирелгән. Авыл яны табигате матур булганга, тирә-якта хәтфә кебек яшел үләннәр үсү, су-инеш, күлләр булу кешеләр күзенә матур тукыма кебек күренергә дә мөмкин. Икенчедән, әллә бу тирәләрдә камка (русча божья коровка) исемле бөҗәкләр күп булганга авыл шулай аталдымы икән, дип уйларга да нигез бар кебек.

Пьяна елгасы атамасын халык болай аңлата. Елга бик нык бормаланып-бормаланып ага. Шуңа халык аны Исерек, ягъни Пьяный елга дип йөртә. Елгага бу исем бик тапкыр куелган, чөнки елга агышы исергән кеше йөрешенә ошаган, боргалана да сыргалана. Тиз ага, суы салкын. Төбендә чоңгыллар бар. Куркыныч су.

Авыл тирә-юне географик берәмлекләргә бай, анда тарихи күзлектән караганда кызыклы гына атамалар бар.

*Төпсез күл.* Бу күл шактый гыйбрәтле. Авыл кешеләреннән «Төпсез күл» дип аталган кызыклы риваять язып алынган. Риваятьнең Камка авылы халкы күңелендә һаман саклануы әһәмиятле.

«Безнең авылдан ерак түгел бик матур бер күл бар. Ул түмтүгәрәк, тирәсендә зифа камышлар үсә. Бер ягында, калкулыкта, иске зират бар. Язларын анда чия агачлары шау чәчәктә утыра.

Элек заманнарда күл урынында авыл урнашкан булган, дип сөйлиләр. Бай һәм мул тормышлы булган анда яшәүчеләр. Йортлары нык, биек коймалар томалап торган аларны. Берзаман авылга хәерче карт килеп кергән. Үзе ач, талчыккан, аякларын көчкә өстери икән. Бер капканы шакыган – җикеренгәннәр, икенчесендә җавап та бирмәгәннәр, өченчесендә эттән талатканнар. Карт авылдан көч-хәл белән чыккан да калкулыкка

менгән, җан ачысы белән авылны каргаган. Шул ук минутта авылны җир йоткан һәм аның урынында күл хасил булган. Бу хәерче Хозыр Ильяс булган, имеш. Аны «Төпсез күл» дип йөртәләр, чөнки анда су кереп булмый, суыра, диләр.

Дөресме, юкмы, әмма кайберәүләр: «Хәзер дә иртәләрен күлдән тавышлар ишетелә, анда әтәчләр кычкыра», – дип сөйлиләр»[1].

Хозыр Ильяс – татар фольклорында киң урын алган легендар образ. Аның белән бәйләнешле халык авыз иҗаты мотивлары Республикабыздан читтә яши торган татарларда еш очрый. Бу исә татар халкы составындагы барлык этник төркемнәрнең дә кайчандыр бер казанда кайнап яшәвен, соңыннан гына төрле тарихи сәбәпләр аркасында төрле якларга таралуын дәлилли.

*Бакалдый* – Камка авылы янындагы кечкенә күл, баткак урын. Аны камкалылар «бака алдый» (кличет лягушка) дип аңлаталар. Бу атама авылда икәү. Берсе югарыда әйтелгән «кечкенә күл», икенчесе – авылның яңа урамы исеме.

Беренче Бакалдыйның «бака алдый» дип аңлатылуы бик ышандырып җиткерми. Бакалар һәр күлдә һәм баткак урында бакылдыйлар. Хәзер аларның бакылдаулары да бик ишетелми. Элек бака ансамбльләрен кызыксынып тыңлап йөргәннәрем булды. Матур бакылдыйлар алар.

Минемчә, Бакалдый атамасы *бакал* «кечкенә күл, кечкенә су чыганагы» + *дый (тай)* «елга» сүзләре кушылып ясалган. Бакалның «кечкенә күл, кечкенә су чыганагы» икәнлеген мин халык теленнән язып кайттым.

Су чыганаклары, гомумән, топонимнар арасында *тай ~ сай ~ чай ~ җай* компонентлары белән ясалган атамалар шактый күп. Бу компонентлар иске татар телендә «елга», «су чыганагы» мәгънәсендә кулланылган. Татар халкының «җайның күрке яр булыр, ярның күрке тал булыр» дигән гыйбарәсе дә *җай*ның «елга» төшенчәсен белдерүен күрсәтә.

Казаннан ерак түгел генә Бакалтай утравы (1957 елда ул су астында кала), Бакалтай пристане һәм Бакалтай урамы булган.

[1] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 256.

Бакалтай атамасы алган елгалар Камага һәм Зөягә килеп кушылалар. Татар телендә *д* һәм *т* авазлары чиратлаша. *А* һәм *ы* авазларының күчеше топоним һәм гидронимнарда күзәтелә.

Тарихчы галим Геродот хезмәтләрендә теркәлгән скиф кавемкабиләләре легендасы персонажларының Таргитай, Колаксай, Арпаксай һәм Липоксай исемнәре безнең өчен зур әһәмияткә ия. Аларның мәгънәләре, балкар галиме И.М. Мизиев язуына караганда, төрки телләр материалыннан чыгып аңлатыла ала. Аларның төзелешләре дә төрки исем-атамаларыныкы кебек. Мәсәлән, Таргитай исемен урта гасырларда кулланылган төрки Актай, Асутай, Ашиктай, Баритай, Даритай, Бурилтай, Камтай, Колимтай, Кутай, Кутуктай, Кяхтай, Манзитай, Ойратай, Атам-Тай, Сабуктай, Сартактай, Тай, Тубтай, Уйгутай, Усутай, Оратай, Хокутай, Чагатай һ.б. исемнәр белән бер рәткә куеп була. Шул ук ояга халык язучысы Г.Бәширов «Җидегән чишмә» романында беркеткән Чурмантай, шулай ук татарлардагы Сарытай һәм татар халык риваятьләрендә очрый торган Абылтай, «Идегәй» дастанындагы Субратай һәм Колатай исемнәре дә керә. Аларны тагын төрки социаль термин корылтай, хантай һ.б. атамалар белән чагыштырып булыр иде.

Татарстандагы Актай елгасы Әлки һәм Спас районыннан агып уза. Зәй-Каратай – Зәйнең сул кушылдыгы, шушы ук Лениногорск районында Мөэмин-Каратай авылы да бар.

Тай компоненты белән ясалган атамалар Оренбург, Самара, Ульяновск, Төньяк Кавказ, Урта Азия, Алтай, Якутия (Саха), гагаузларда, Ока, Дон, Днестр, Днепр елгасы бассейннарында очрый. Сергач районындагы *Бакалдый ~ Бакалтай* атамасы элекке СССР җирлегендәге Бакалтай, Тубыктай, Каратай, Чурмантай, Аксай һ.б. атамалар белән бергә бер ояга керә. Менә нинди ул милләттәшләребез яшәгән җирләр.

*Тёпой* шулай ук игътибарга лаек атама. Бу атама камкалылар теленә руслардан алынган тёплый сүзеннән кыскарган *тёп* компонентына *ой – уй* «уйсулык, уйсу җир» кушылып ясалган дип уйларга нигез бар. Анда әле җылы гына су да җыелып тора. Балалар анда коеналар да. Әмирхан Еники үзенең бер әсәрендә болай яза: «Уйсу җирләрдә зур чуар күлләр җыелды».

Бу типтагы аналогия Татарстанда да бар. Кече Уй елгасы – Чишмә / Шишмә суы кушылдыгы. Русча ул Кичуй елгасы дип йөртелә. Бабаларыбыз телендә ул Кече Уй, ягъни Кече елга дип әйтелгән. Руслар килеп утырганнан соң ул Кичуй дип үзгәртелгән. Кичуй > Кече Уй елгасы ярына Кичуй > Кече Уй авылы утырган. Анда татарлар һәм руслар гомер сөрә һәм авыл рәсми рәвештә Кичуй дип йөртелә. Топонимнар һәм гидронимнарда о һәм а, о һәм у күчешләре күзәтелә. Актаныш районындагы Тирән уй – Сөн елгасы кушылдыгы. Минзәлә районының Бикбау авылында Тирән уй үзәнендә тирән чокырлы урын бар. Бу атамалар бер системаны тәшкил итәләр.

*Озы ~ Узы* атамасы тарихилыгы белән игътибарны җәлеп итә. *Уз, гуз, угыз* – угыз кавем-кабиләләре атамасы. Бу турыда Н.А. Аристов һ.б. галимнәр яза.

Узы, Уз, Озы, Гуз, Угыз атамалары Татарстан топонимнары арасында да очрый. Угыз телләренә хас фонетик, морфологик үзенчәлекләр географик берәмлекләр ясалышында шактый еш очрый.

Уз, Узы / Узи елга-күлләре һ.б. чыганаклар, уйсу урыннар, сулы чокырлар, сулы урыннар Саратов, Пенза, Чиләбе һ.б. өлкәләрдә, Ока елгасы бассейнында, гагаузларда, Төньяк Кавказда, Дон бассейны гаскәриләре яшәгән төбәкләрдә, Украинада, Идел-Урал буйларында, Себердә һ.б. урыннарда очрый.

*Мәмәш иле куагы.* Мәмәш Карамышев – Мәмәш авылы помещигы була. Җир анықы булганга, аны Мәмәш иле куагы дип йөрткәннәр. Куак – алан дигән сүз. Иле элек дәүләт мәгънәсендә кулланылган, соңыннан мәгънәсе тараеп, авыл, торак пунктларны аңлата башлаган. Вакытлар үтү белән бу алан матур болынга әйләнгән.

*Манцал чокыры.* Молчанов фамилиясе Манцал булып үзгәргән. Винокурный чокыры белән параллель бара.

*Бару урманы.* Уваров фамилиясе Бару булып үзгәргән. Уваров җирләре белән ызандаш. Бу урман беткән.

Авылның тирә-юнендә географик берәмлек атамалары шактый күп. Күл, Күл авызы, Акмакай күле; Арткы Пьяна, Алгы Пьяна, Иске Пьяна (Пьяна елгасы юлын үзгәрткәннән соң калган

су), Бакалдый янынннан төшеп киткәч Луг (Болын) бар, Тальник (Таллык), Усаклык, Игнат урманы, Мотока чокыры, Мунчала болыны, Мельничный круг, Пустырь (Бушлык), Кыр келәү, Аю куагы, Муллалар чалуы, Адельша астыры, Абдей елгасы, Зур луг (Зур болын), Кривое озеро (Кәкре күл), Монахлар кыры, Вялиходж клины, Тау арты, Винокур чокыры (Аракы куа торган чокыр), Винокур урманы (халык аннан балан һәм гөлҗимеш җыйган), Кече куак (алан), Корей арты, Албут кырлары, Мещаннар кыры, Саит куагы (аланы), Мар, Иске каберләр, Суыксу елгасы, Яңа каберлек, Немец (Нимес) базары, Мильчә каршы (рус. Мельница сүзеннән); Урам исемнәре: Бакалдый урамы, Урталык урам, Яңа авыл һ.б.

Авылдан зыялы кешеләр шактый чыккан. Филология фәннәре докторы Айсылу Башкурова-Садыйкова фольклор белән шөгыльләнә. Ул Татарстан Фәннәр академиясе Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре. Рөстәм Шакир улы Башкуров Казан педагогия институтын тәмамлый, аспирантурада укый, филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсе ала. Әдәбият өлкәсендә бик әйбәт белгеч булып җитлегә. Габдулла Тукай әсәрләрен русчага тәрҗемә итә. Заманында «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре булып эшли.

Алимҗан Мостафа улы Орлов Түбән Новгородта Авыл хуҗалыгы институтында доцент булып эшли. Ул Түбән Новгород яклары һәм Камка авылы турында матур һәм эчтәлекле китаплар язган.

Рәшит Җаббар улы Баязитов Мәскәү янында мәчет, чиркәү һәм синагога салдыра. Камка авылында да матур мәчет төзетә. Ул экономика фәннәре докторы, татар халкының рухи мирасын саклау һәм үстерү «Хилал» хәйрия фондының президенты. Язучы В.П. Макарихин белән бу як турында китаплар язган[1].

Бу як Камкадан чыккан зыялылар авылларын онытмыйлар, аны зурлауның төрле юлларын табалар. Туган җир, туган туфрак һәркемгә кадерле...

---

[1] *Орлов А.М.* Мещера, мещеряне, мишаре. – Казань: Татар. кн. изд-во. – 1992.

* * *

Түбән Новгород өлкәсендәге Камка авылы тарихы турында язгач, әлеге авылдан, Казан ханлыгы басып алынганнан соң, Татарстанның Әлки районы Иске Камка авылына килеп төпләнгән камкалылар һәм алар нигез салган авыллар хакында да кыскача мәгълүмат бирүне кирәк дип таптык.

Кече Чирмешән суы ярына матур-матур авыллар тезелешеп утырган. Ул авылларның һәрберсе үзенә генә хас үзенчәлеккә ия. Берләре шактый зур, икенчеләре кечерәк, өченчеләре таралып бетә язган, буш йорт урыннары да бар. Кайберләре исә, дачаларны хәтерләтеп, урман авызына, су буйларына, чишмәләр мул булып җыелган урынга утырган. Аерым авылларның урамнары ямь-яшел, бакчаларында алма, слива, сырганак, чия, миләш, шомырт агачлары, балан, карлыган, гөлҗимеш, кура җиләге куаклары үсә.

Авыллар арасында Иске Камка авылы үзенең бай табигате белән аерылып тора.

Иске Камка авылыннан район үзәге Базарлы Матакка – 19 чакрым, якындагы тимер юл станциясе Норлатка – 67, су юлы Болгар пристанена кадәр 88 чакрым.

Д.А. Корсаков (1908) бастырып чыгарган тарихи белешмәдә Кече Чирмешән ярына утырган Иске Камка авылында 127 йомышлы, бер керәшен татары яшәгән дип күрсәтелә. Мәүләшә суы ярындагы Яңа Камка (Мәүләшә) авылында 19 алпавыт крестьяны, 60 йомышлы һәм бер керәшен татары яшәгән.

А. Артемьев (1866) китабында Иске Камка һәм Яңа Камка телгә алынган. Авылда мәчет эшләгән, 152 хуҗалыкта 481 ир-ат һәм 479 хатын-кыз яшәгән. Яңа Камка (Мәүләшә) авылындагы 76 йортта 256 ир-ат һәм 269 хатын-кыз көн иткән, авылда бер мәчет булган.

1898 елгы хезмәттә Яңа Камка һәм Иске Камка авылларында татарлар яши дип билгеләнә.

К.П. Берстель хезмәтендә (1908) Иске Камка авылында барлыгы 1394, Яңа Камка (Мәүләшә) авылында 608 татар кешесе яшәгәнлеге искәртелә.

Иске Камка тигез җиргә урнашкан. Авылны беренче нигезләүчеләр урынның матурын, су буен сайлаганнар. Бу төбәктәге Чирмешән суы татар халкының легенда-риваятьләрендә, җырларында еш искә алына. Чирмешән – тарихи атама. Болгар дәүләте яшәешенең аерым чорларында башкала хезмәтен дә үтәгән шанлы Биләр шәһәре шушы елга янында чәчәк аткан. Чирмешән исеменә төрле тарихи чыганакларда тап буласың. 921–922 елларда Идел-Кама Болгарстанына Багдад хәлифәлегеннән килгән илчелекнең сәркәтибе Әхмәт ибн Фазлан язмаларында ул Җәрәмсан, рус елъязмаларында Черемисан, Әлки районының Ташбилге авылы янында табылган кабер ташында Чәримсан рәвешендә бирелгән. Хәтта ул читтәге, әйтик, Марий Эл республикасындагы Бәрәңге районында татар авыллары зиратында да очрый. Шагыйрь Габделҗаббар Кандалый да Чирмешән суларын искә ала. Чирмешән суына багышлап шигырьләр, җырлар иҗат ителгән. Чирмешән суы күпне күргән, халыкның бәхетле чакларына да, кат-кат килгән афәтләргә дә шаһит ул.

Авыл тирәләрендә, Чирмешән яры буйларында балан, шомырт, кызыл карлыган, кара карлыган, бөрлегән, гөлҗимеш куаклары, кыргый суган, акбаш, какы, кузгалак кебек үсемлекләр бик күп үскән. Чирмешән суында чабак, кызылканат, җәен, ала балык яки керкә (форель) кебек төрле-төрле балыклар булган. Авыл тирә-юнендә күл, сазлыкларда торналар, кыр үрдәкләре һ.б. кыргый кошлар яшәгән. Елга, су буйларындагы үзәннәрдә ишелеп печән үскән.

Чирмешән суы – буеннан-буена тарихи җирлек. Аның яры буйларындагы авылларда «кала» сүзе белән бәйләнешле атамалар күп очрый. Иске Камка авылы утырган җирдә дә Кала тавы, Кала сазы урамы исемен алган берәмлекләр бар. Димәк, бу урында элекке чорларда кала төзелгән булган. Р.Г. Фәхретдиновның археологик һәйкәлләрне барлаган чыганагында Иске Камка авылы янында борынгы болгар чорына караган шәһәр хәрабәсе билгеләнгән. Бу турыда С.М. Шпилевский да яза (1877). Шул тирәләрдә тагын борынгы болгар һәм Алтын Урда чорларына мөнәсәбәтле шәһәр һәм авыл урыннары булуы да әйтелә. Мәүләшә, Карамалы һ.б. авыллар янында да борынгы Болгар

чорына мөнәсәбәтле истәлекләр табылган һәм тикшерелгән. 1927 елда авыл янындагы Кала урынында казу эшләре алып барганда, эре-эре сөякләр чыккан. Бу урынга килеп, авыл аксакаллары дога укыйлар, аны кадерләп тоталар. Әлеге җирләр, һичшиксез, безнең болгар-татар бабаларыбыз белән бәйләнешле. Менә нинди тарихи җирлеккә салынган ул Иске Камка авылы!

Авылны кемнәр, кайчан нигезләгән?

Иске Камка авылында яши торган Мирзаабдулла ага Дәүләтшин белән Зиннәт ага Хисамовларның сөйләвенә караганда, бу авылның оешу тарихы элекке Алатыр өязенең Пьяна суы ярына урнашкан Камка авылы белән бәйләнешле (алда әйтелгәнчә, Сергач районындагы Камка авылы). Түбән Новгород өлкәсендәге Камка авылының кайбер нәселләре, йомышлы татарлар сыйфатында, Кама аръягындагы ныгытмаларны саклау өчен патша хөкүмәте тарафыннан шушында китереп утыртылганнар. Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Иске Камка авылы кешеләре Түбән Новгород өлкәсе Сергач районында урнашкан Камка авылына барып чыккач, бу авыл кешеләре аларны бик олылап, зурлап каршы алганнар. Сез безнең кадерле улларыбыз дип атаганнар, кунак иткәннәр, авыл белән таныштырып йөргәннәр.

Иске Камка авылында берничә нәсел кешеләре яши.

Беренчесе – Нәмай нәселе. Бу нәсел шактый зур. Аны дәвам итүчеләрнең берсе – Абдул абый.

Икенче нәсел – Урманчеевлар нәселе. Шулай ук зур нәсел. Дәвам итүчеләре күп.

Өченче нәсел – Тукай нәселе. Сергач Камкасыннан Иске Камка авылына бу нәселдән беренче килеп утырган кеше Тукай исемле булган. Авыл халкы аны хәзер Тукай бабай дип искә ала. Бирегә килеп утыргач, башта ул авылның Карамалыга таба чыга торган ягында җир өй казып, шунда яши башлаган. Авыл тарихы һәм авылга кагылышлы географик берәмлекләр турында күп мәгълүматлы Мирзаабдулла абый Дәүләтшин шушы нәселдән. Ул үзләренең нәсел шәҗәрәсеннән түбәндәге буыннарны атады: беренче бабай Тукай > аның улы Туктый > Ибраһим > Нигъмәтулла (Нәмай) > Мөхәммәтша > Галим > Хәйдәр > Дәүләтша > Мирзаабдулла > Җәүдәт. Бу нәсел бик зур.

Авылның дүртенче нәселе – Бакнәй нәселе. Бу нәсел шулай ук Түбән Новгород өлкәсендәге Камкадан килгән. Ләкин алда әйтелгән Урманчеев нәселләре авылга алданрак килеп төпләнгәннәр. Шәҗәрә чылбырындагы исемнәр, авылдагы географик берәмлекләр атамалары авылның XVII йөздә нигезләнүен күрсәтә.

Камка атамасы шактый күп очрый һәм дәрәҗәле тарихи чыганакларда еш искә алына.

С. Мельниковның «Акты исторические и юридические и древние царские грамоты Казанских и других соседственных губерний» дип аталган җыентыгында (Казан, 1895) XVI–XVII гасырга караган үтенечләр, әмерләр һәм патша фәрманнары тупланган. Бу хезмәттә хәзерге Түбән Новгород өлкәсе, Сергач районындагы (хезмәттә ул Алатыр өязе дип бирелә) Камка һәм Әлки районындагы Камка (чыганакта ул Казан өязе, Кама аръягы Нугай юлы өсте дип бирелә) авыллары искә алына. Морза нәселеннән чыккан алатырлы йомышлы татар Урманчеевның улы Дербыш Ахмаметов 1686 елда патшага язган үтенечендә этисенең һәм үзенең тугрылыклы хезмәтләре өчен Алатыр өязенең Пьяна суы буенда урнашкан Камка авылы тирә-юнендә (хәзерге Сергач районы) җир һәм печәнлекләр белән бүләкләнүләре турында яза. Ләкин Урманчеев улы Дербыш Ахмаметов Казан өязенең Нугай юлы өстендәге буш җирләргә күчәргә теләк белдерә һәм шундагы җир һәм печәнлекләрдән файдалану өчен патшадан указ сорый. Патша аның үтенечен канәгатьләндереп, буш җирләрне хәзерге Әлки районы Камка авылы яныннан бүлеп бирергә дип Казан воеводасы князь Михаил Юрьевич Долгоруковка фәрман җибәрә. Князь М.Ю. Долгоруков патша әмерен үти, ул боерган урыннан Урманчеевка җир һәм печәнлекләр бирә. Шул рәвешле Урманчеев безнең яклардагы Камкага килеп урнашкан. Соңыннан бу Камкадан тагын Яңа Камка аерылып чыккач, халык Камка атамасы алдына «иске» аергычы куша, документларда бу авыл рәсми рәвештә Иске Камка дип атала башлый. Ул хәзер дә шулай дип йөртелә.

Документта бу урыннар буш җирләр (пустошь) дип атала, ләкин шул ук вакытта Камка атамасы да кулланыла. Бу исем, күрәсең, төп Камка, ягъни Урманчеевның элек яшәгән авылы

исеменә мөнәсәбәтле рәвештә кулланылгандыр. Нәмай нәселенең Иске Камкага Урманчеевтан иртәме яисә соңмы килгәне мәгълүм түгел.

Сергач Камкасы белән Иске Камка халкын берләштерә торган фактлар шактый. Әйтик, Сергач районындагы Камка һәм бездәге Иске Камка авылы халкы «ц» авазы кулланып сөйләшәләр (мәсәлән, Цирмешән – Чирмешән, цакрым – чакрым, цирәм – чирәм һ.б.). Ләкин алар телендә *ч* авазы да кулланыла. Мәсәлән, чәйнекне халык цәйнек дип әйтми, чәйнек дип йөртә. Бу да кызык факт.

Шунысы да әһәмиятле: Сергачтагы Камка белән җөмһүриятебездәге Иске Камкада яши торган халыкның көнкүрешләре, рухи тормышлары, күп кенә гореф-гадәтләре (кыз бирү, туй итү, мәет күмү, яңгыр сорау йолалары, им-том һ.б.) бер-берсеннән аерылмый.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Карамалы, Яңа Камка (халык телендә Мәүләшә) авыллары Иске Камкадан аерылып чыкканнар.

Иске Камка халкы буйсынмас, баш бирмәүчән булган, патша түрәләре тарафыннан китерелгән кәгазьләрнең асылына төшенмичә, тамга салып утырмаган. Динне хөрмәтләгәннәр, тырышып эшләгәннәр. 1878 елның 4 ноябрендә Казан губернаторы Н.Я. Скарятинның эчке эшләр министры А.Е. Тимашевка Казан губернасының Спас өязе Мораса волостендагы чуалыш-болганышлар турында язган белдермәсендә (донесение) татар авыллары Иске Алпар, Яңа Алпар, Иске һәм Яңа Үргәгар, Исәнбәт, Карамалы, Татар Мулла Иле авыллары искә алына. Анда каралты-кураларны янгыннан саклау максатыннан чыгып, аларны страховать итү бурычы куелгач, халыкның бик нык борчылуы, чуалышлар башланып китүе турында языла. Алар безне чукындырырга, христиан диненә чыгарырга телиләр, дип уйлыйлар һәм чуалышлар башланып китә. Ачулары килеп, авыл тирәсендәге урман-агачларны кисеп ташлыйлар.

Элек Иске Камка авылы тирәләрендә калын урманнар үскән. Борынгы Болгар, Алтын Урда дәүләтләре яшәүдән туктагач, бигрәк тә Казан ханлыгы Иван Грозный тарафыннан җимерелгәч,

бу тирәләр бушап кала. Халык төрле урыннарга качып китәргә мәҗбүр була. Ташлап киткән җирләрдә ерып чыккысыз урманнар үскән, аларда кыргый бал кортлары үрчегән. Соңрак килеп утырган халык чолыкчылык белән дә шөгыльләнгән. Вакытлар үтү белән урманнар киселгән, агачлар азаеп һәм сирәгәеп калган.

Иске Камка тирәсендә елга-инешләр, чишмә-кизләүләр, күл һәм сазлыклар бихисап. Инеш-күлләр тирәсендә камышлар, суында төнбоеклар үсеп утыра. Елга-инешләр суларын Кече Чирмешәнгә куалар. Елга-күл һ.б. атамаларын җыеп тикшерү авылның үткән тарихын күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә. Бу тирәләрнең урманга бай булуын аларның исемнәре үк күрсәтеп тора. Югары Урман, исеменнән үк авылның югары як басуында икәнлеген күрсәтә. Бу урыннарда заманында аюлар да яшәгән. Суларын Кече Чирмешәнгә илтә торган Аю аланы чишмәсе атамасы бу тирәне аюлар яратканны белдерә. Урман булган җирдә дым күп була, дымлы урында сазлык булмый калмый. Камка авылы тирәсендә дә сазлыклар байтак: Кала сазы, Әнҗерә сазы, Мүкле саз һ.б. Сожгысыннан элек халык мүк йолкыган. Йорт салганда бүрәнә араларына шуны салып калдырган. Якында сазлык яки буа булган басуларда иген уңа, печән яхшы үсә.

Елга атамаларының бер өлеше кеше исемнәренә, икенчеләре этнонимнарга, өченчеләре төрле мәгънә аңлата торган лексик берәмлекләргә кайтып кала. Фәхретдин елгасы, Фәрәзан (Фәризә) елгасы, Болан яки Аленка елгасы, Чуаш елгасы, Урыс елгасы һ.б. Бу атамалар теге яки бу күләмдә авылларның үсеш тарихын ачыкларга ярдәм итә. Чуаш һәм Урыс елгалары дигән атамаларның телдә йөрүе Иске Камка авылы халкының чувашлар һәм руслар белән күрше булып яшәүләрен күрсәтеп тора.

Авылда мәчет эшли. Халык зиратны карап һәм тәрбияләп тора. Аның тирә-юне тотып алынган, каберләр һәм чардуганнар, ташлар тәртиптә.

Яңа Камка (Мәүләшә) авылында күренекле прозаик һәм шагыйрь Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин, 1910–1989) һәм тәнкыйтьче, Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Мөдәррис Харис улы Вәлиев (Салих Маннапов, 1953) туган.

* * *

Шунысы әһәмиятле: татар халкы кайда гына яшәмәсен, легенда-риваятьләре, нигездә, бертөсле, төрле төбәкләрдә яшәүчеләр һәм этнографик төркемнәр өчен аерым закончалыклар, чыгармалар юк. Барлык рухи байлык татар халкының гомуми рухи мирасы җирлегендә, кануни кысаларында барлыкка килә. Бу үзгәрешсез кала торган хакыйкать.

Түбән Новгород өлкәсендә яши торган халык иманлы. Алар ата-ананы, туганнарны хөрмәт итәләр, бер-берсенә карата миһербанлылар, вакытны бушка үткәрмиләр. Йола-кануннарны, гореф-гадәтне нык саклыйлар, динне онытмыйлар. Зиратларны карыйлар, чистарталар, тәрбиялиләр. Аларның Мәскәү, Санкт-Петербург белән бәйләнешләре нык. Уңганлык – аларның канында. Шуңа күрә әйбәт яшиләр, дәрәҗәле урыннарда эшлиләр, дөньякүләм танылган зыялылары белән горурлана алалар.

Бу төбәк тарихы белән тирәннәнрәк кызыксынучылар өчен без бай әдәбият исемлеге тәкъдим итә алыр идек. Шулай да аларның берничәсен генә булса да атап үтик:

Мельников С. Акты исторические и юридические и древние царские грамоты Казанской и других соседних губерний. – Т. I. – Казань, 1859;

Морохин Н.В. Нижегородский топонимический словарь. – Н. Новгород, 1997;

Орлов А.М., Каримов А.А. Камкино: история и современность: Очерки по истории села Камкино Сергачского района Нижегородской области. – Н. Новгород, 2003;

Сентюкин С.Б. История татар Нижегородского Поволжья с конца XVI в. до 1-й трети XX в. – Н.Новгород, 2001;

Смирнов Д.Н. Нижегородская старина. – Н. Новгород, 1995 һ.б.

Түбән Новгород татарлары язмышы, аларның авыллары тарихы – халкыбызның катлаулы язмышыннан, зур тарихыннан кызыклы һәм гыйбрәтле бер сәхифә ул.

# ЙОМШАК ТЕЛЛЕ МИШӘРЛӘРЕМ

***Сергач татарлары сөйләше***

*Флера Баязитова*
*Гөлчәчәк Хәйбуллина*

Безнең татар халкы бай тарихлы. Аның тел һәм культура үзенчәлекләре дә төрле катламнардан тора.

Җирле сөйләшләребездәге тел һәм рухи байлыгыбызның көнләп түгел, сәгатьләп югала баруын истә тотып, диалектологлар экспедицияләргә чыгып материаллар туплауны соңгы берничә дистә ел эчендә тагын да тырышып, фидакярләрчә дәвам иттерделәр һәм иттерәләр. Соңгы елларда гына да әлеге кыйммәтле материалларны туплаган «Татар халык сөйләшләре» (2008) дигән ике томлык бик зур хезмәт дөнья күрде, «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (2009) басылып чыкты.

2010 елның җәендә Институтның бер төркем галимнәре – диалектологлар, фольклорчылар һәм музыка белгечләре Түбән Новгород өлкәсенә экспедициягә бардылар. Диалектология фәнендә ул көнбатыш, ягъни мишәр диалектының сергач сөйләше буларак билгеле. Бу – гаять кызыклы, борынгы үзенчәлекләрне саклаган сөйләш. Бу сөйләш вәкилләре фәнни әдәбиятта «нижгар мишәрләре» исеме астында да мәгълүм. 1948–1949 елларда бу сөйләшне Р.Ф. Шакирова өйрәнә һәм «Особенности говора татар Краснооктябрьского района Горьковской области» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый, мәкаләләр бастыра. Соңга таба бу төбәккә яңадан (төрле максатлардан чыгып) экспедицияләр оештырыла. 1986 елда Ф.С. Баязитова, 1989 елда Д.Б. Рамазанова,

Т.Х. Хәйретдиновалар тарафыннан да әлеге сөйләштән диалектологик материаллар туплана. Сергач сөйләше турында мәкалә «Татар халык сөйләшләре» (2008) дигән китапта бастырыла.

Безгә, диалектолог буларак, инде 40 елдан артык (студент елларыннан санасак, 50 елга якын) экспедицияләргә чыгып татар халкының җирле сөйләшләрен өйрәнү насыйп булды. Түбән Новгород өлкәсенә дә беренче генә килүебез түгел. Биредәге татар авылларында төрле яклап материаллар тупладык. Иң шатландырганы шул,  әле телебез дә, рухи байлыкларыбыз да, Аллага шөкер, саклана икән.

Авыллардагы җирле администрация башлыклары, мәктәп директорлары, укытучылар, музей һәм мәдәният йорты хезмәткәрләре – барысы да безгә ярдәм кулы сузып, үзләре туплаган рухи байлыклары белән дә уртаклаштылар, безгә юл күрсәттеләр, кызыклы шәхесләр, информаторлар, тел осталары, йола белгечләре белән таныштырдылар.

Авыллардагы җирле сөйләш һәм культура диалектологиясенең бергә үрелеп баруы бик кызыклы күренеш. Бүгенге көннәрдә дә халык хәтерендә (әйе, хәтерендә генә) әле «башкода килү», «кыз ярәшү», «колак сүwенеце», «шәл китерү», «сөлге бирү» турында истәлекләр саклана. Аларның бик күбесен әле яңартып җибәрергә дә соң түгелдер, бәлки. Элекке вакытта, совет чорында тыелган дини йолаларыбыз, мәчетләр яңартыла, һәр татар авылында тирә-якка нур сибеп айлы, өр-яңа дини биналар булуы да шатландыра. Шул исәптән, элек инде бетәргә тиешле искелек калдыгы, архаизм дип саналган бик күп дини сүзләребез дә кире кайтты: *мулла, мәчет, имам, азан, хатем, руз'а (ураза), корбан чалу* һ.б. Намаз уку, гает бәйрәмнәрен үткәрү өчен мәчетләргә килүчеләрнең саны күп булуы да куандыра.

Җеназа укып кешене соңгы юлга озатулар, никах укытып өйләнешүләр, азан әйтеп исем кушулар дини йола буларак та, электән килгән традиция-йола буларак та көнкүрештә ныклы урында тора.

Түбән Новгород өлкәсендә *никах, туй мунчасы, килен килгәч яхшы ат әйттерү* йолалары бөтен татар халкына үрнәк булырлык дәрәҗәдә саклана. Биредә борынгыдан килгән аш-су

атамалары да үзе бер тарихи дөнья: *күптермә, умак, куш катлама, чирәп бәлеше, чүлмәк бәлеше* һ.б. Ә ат итеннән *казы* (казылык) *тутыру* турында авыл осталарыннан әле бик күп серләрне өйрәнергә була.

Нижгар төбәгендәге кунакчыл һәм ачык чырайлы, киң күңелле өлкән кешеләргә, әби-бабайларга, безне каршы алып, озатып калган җитәкчеләргә без чын күңелдән бик зур рәхмәтләр әйтәбез.

Биредә бөртекләп тупланган тел һәм рухи байлык җәүһәрләрен халыкның үзенә кайтарып бирүне без изге бурычыбыз итеп саныйбыз. Алар китапларда һәм газет-журналларда кабат-кабат урын алырлар дип ышанабыз.

Татар халкының һәр төбәк, һәрбер диалект зонасы гомуми рухи байлыгыбызны үстерү өчен таяныч булып тора. Тел һәм иман байлыгы сакланганда татар халкы югалмас, көчле булыр, киләчәккә карап, алга барыр дип ышанабыз.

## Сергач сөйләшенең фонетик үзенчәлекләре

**Тартыклар.** Ц-лаштырып сөйләү сергач сөйләшенең характерлы үзенчәлекләреннән санала. *Ц* тартыгы сөйләштә әдәби телдәге ч авазы урынына килә һәм (аерым сүзләрне исәпкә алмаганда) сүздә төрле позицияләрдә очрый: *цыбыркы* – чыбыркы, *цәйнек* – чәйнек, *цана* – чана, *циләк* – чиләк, *цебен* – чебен, *церки* – черки, *цигелдәк* – чигелдәк, *цабата* – чабата һ.б.

Сөйләштә шулай ук *ч* авазын куллану очраклары да бар. Әдәби телдән аермалы буларак, *ч* авазы сөйләштә *тч* кушык авазы булып әйтелә: *тчаwка* – чәүкә, *котчок* – көчек, *тчаршаw* – чаршау, *тчык* – чык һ.б. Еш кына *тч* кушык авазы рус алынмаларында кулланыла: *тчихул* – чехол, *тчашке* – чашка, *тчэп* – цепь, *тчил* – цел, целый.

Сергач сөйләше – *й*-ләштерүче сөйләш: *йәй* – җәй, *йәйәү* – җәйәү (җәяү), *йома* – җомга, *йимеш* – җимеш, *йиде* – җиде, *йилкә* – җилкә, *йир* – җир, *йебегән* – җебегән.

Тел арты тартыклары *к, г, х.* Мишәр диалектының башка сөйләшләрендәге кебек, сергач сөйләшендә тирән тел арты тартыклары *(қ, ғ, ҳ)* тел арты *к, г, х* авазлары итеп әйтеләләр: *бага* – карый, *тага* – дага, *казан, сакал, хат, йакын, кыда.*

Гарәп-фарсы сүзләрендә исә тирән тел арты *ғ* тартыгы төшә: *йома* – җомга, *айып* – гайеп (гаеп), *үмер* – гомер, *адәт* – гадәт, *Үмәр* – Гомәр, *Алим* – Галим, *Азиз* – Газиз һ.б.

Тел арты тартыкларында түбәндәге аваз тәңгәллекләрен күрсәтергә мөмкин: *г~к: йага* – йака (яка), *тугызан* – туксан, *сигезән* – сиксән, *гарабдай* – карабодай, *цугынган* – чукынган, *цогор* – чокыр. Киресенчә: *к~г: тукыс* – тугыз, *сикес* – сигез, *цыккыс* – чыгыгыз.

*к~х: катын* – хатын, *курлык* – хурлык, *Кас'ан* – Хәсән, *йымак* – оҗмах.

*к~т: келәү* – теләү, *келәнү* – теләнү; киресенчә, *т~к: үтмәк* – икмәк.

Сергач сөйләшендә, дифтонглар монофтонглашканда, кыскартылган *й* авазы артыннан килгән *д, т, з, с, л, н, р, ч* тартыклары палатальләшәләр: *кан'ар* – кайнар, *ад'а* – әйдә, *бар'ам* – бәйрәм, *ат'а* – әйтә.

Тартык авазларның палатальләшүе гарәп-фарсы алынмаларында да күзәтелә: *Мус'а* – Муса, *Камал'* – Камал, *аз'ап* – азап, *Сад'эк* – Садыйк, *Сад'ри* – Садрый.

Әдәби телдә алгы рәт сузыклары белән, ә сөйләштә исә калынайтып әйтелә торган кайбер сүзләрдә дә палатальләшкән тартыклар күзәтелә: *ан'а* – әнә, *мон'а* – менә, *ал'лә* – әллә, *кын'дык* – кендек.

Абзый сүзендәге з авазы палатальләшеп, *абз'и* формасында әйтелә.

Авазлар тәңгәллегендә түбәндәге үзенчәлекләр күзәтелә:

*п~б: петү* – бөти, *петерү* – бетерү, *пот* – бот, *капыста* – кәбестә;

*б~п: кирбетч* – кирпеч, *кабак* – капка, *шурба* – шулпа, *йебәк* – йепәк – йефәк (ефәк);

*п~ф: керпек* – керфек, *топрак* – туфрак, *Пәрикә* – Фәрихә, *Пәридә* – Фәридә, *партык* – рус. фартук, *пеләгә* – рус. фляга;

*б~w, в: бакыт* – wакыт (вакыт), *багун* – рус. вагон, *бинек* – рус. веник һ.б.;

*д~т: дустыган* – тустыган; сүз уртасында *л, н* борын авазларыннан соң *(лт, нт): селдәү* – селтәү, *йандар* – йантар (янтар), *былдыр* – былтыр.

Ике сузык уртасында *бд~пт: абдырау* – аптырау, *ибдәш* – иптәш.

*з~җ: пәзи* – пәҗи – киндер, *энзе* – энҗе, *кизе* – киҗе, *кәзә* – кәҗә, *баз'а* – баҗа, *уз'ым* – уҗым.

Аерым сүзләрдә күзәтелә торган тәңгәллекләр. *б~м: бун'* – муйын (муен); *т~д: тисбе* – дисбе; *т~к: үтмәк* – икмәк, *т~ч: тиш* – чиш, *тишен* – чишен; *д~н: урмандан* – урманнан; *н~д: пиц алны* – мич алды; *н~м: нөгез* – нүгез – мөгез, *мөнкин* – мөмкин; *й~д: йәшә* – дәшә; *дз~җ: дзиңә* – җиңги, *мөрдзә* – мөрҗә (морҗа); *с~ч: ацкыс* – ачкыч, *тыскан* – тычкан; *ч~с: чимйә* – симйә (семья), *кәрәтчин* – керосин; *р~л: шурба* – шулпа; *арткыры* – аркылы; *л~р: зурлак* – зуррак, *бирләк* – бирерәк, арлак – арырак, йогарлак – йугарырак (югарырак).

*ж~ш:* сүз ахырында килгән *ш* тартыгы яңгырау тартыклар алдында саңгыраулаша: *пиж башы* – мич башы, *аж бар* – аш бар, *биж йәш* – биш йәш (яшь), *биж йыл* – биш йыл (ел).

Рус теленнән кергән түбәндәге сүзләрдә *җ~ж* билгеләнгән: *җәллим* – рус. жалею, *җилет* – рус. жилет.

Тел уртасы *й* тартыгы сөйләштә актив кулланыла, ул сүз башында да, сүз уртасында да килә: *йолдыз, йиде* (җиде), *йимеш* (җимеш), *йогор* – йөгер.

Сөйләштә аваз өстәлү һәм аваз төшү күренешләре дә бар.

Фарингаль *һ* авазы, башка сөйләшләрдәге кебек, сүз башында, сүз уртасында төшеп кала: *awa* – һawa (һава), *аман* – һаман, *өнәр* – һөнәр, *ушсыз* – һушсыз, *әләк* – һәләк, *зин, зийен* – зиһен, *мәәр* – мәһәр, *шәәр* – шәһәр.

Ләкин сөйләштә *һ* авазының кулланылу очраклары да бар: *һәрбер, һәрбакыт* – һәрвакыт, әһә. Ымлыкларда шулай ук *һ* авазы әйтелә: *һай, ай-һай.*

Аваз өстәлү: *йаңгызак* – йалгыз (ялгыз), *арткыры* – аркылы, *кецерткән* – кычыткан.

Аваз төшү күренеше: *л: йугатты* – йугалтты (югалтты); *й: әзем* – йөзем; *т: шитем* – ишеттем; *н: урдык* – урындык; *р: барымын* – барырмын, *күремен* – күрермен.

**Метатеза:** *кабак* – капка, *азбар* – абзар, *күреш* – күрше, *җымак* – оҗмах.

**Сузык авазлар.** *а* сузыгы бу сөйләштә саф, иренләштерү төсмере булмаган аваз итеп әйтелә: *ай, каз, камыр* һ.б.

*ә, ү* авазлары, мишәр диалектына хас булганча, алгырак позициядә ясалалар һәм нечкәрәк әйтеләләр.

*у, ү* сузыкларына *у*$^{о}$, *ү*$^{ө}$ дифтонгоид авазлары тәңгәлләшү күзәтелә: *кү*$^{ө}$*мер* – күмер, *кү*$^{ө}$*п* – күп, *ту*$^{о}$*кта* – тукта һ.б.

*и* авазы сөйләштә алгы рәт сузыклар һәм палаталь тартыклар гына түгел, арткы рәт сузыклары янында да килә: *кимак* – коймак, *сийа* – сыйа (сыя), *сила* – сыйла һ.б.

Сүз ахырында сөйләштә -*ый* урынына киң *и* авазы әйтелә. Мәсәлән: *кат'им* – кайтыйм, *кар'им* – карыйм, *кан'и* – кайный һ.б.

Сузыклар өлкәсендәге башка үзенчәлекләр аваз тәңгәллекләренә кайтып кала.

*ы~а: йаңы* – йаңа (яңа), *лампы* – лампа, *кагыз* – кәгазь, *самаwыр* – самовар, *йарамастый* – йарамастай (ярамастай);

*э(е)~ә: күгерцен* – күгәрчен, *мәктеп* – мәктәп;

*ә~и: кәрәк* – кирәк, *шәкәр* – шикәр, *нәк* – ник, *тәк* – тик, *тәкле* – тикле, мәләш – миләш, әпәй – ипи;

*и~ә: синәк* – сәнәк, *пике* – пәке, *фирештә* – фәрештә, *кифен* – кәфен, *пилмин* – пилмән, *үлгинцәк* – үлгәнче.

Тамырдагы и сузыгы урынына аның киң әйтелешле э варианты әйтелә: *эр* – ир, *йәр* – җир, *шәрбәт* – ширбәт, *эртә* – иртә, *эләк* – җиләк, *элек* – җилек;

*э(е)~ү: кемәц* – күмәч;

*о~у* актив күренешләрнең берсе: *он* – ун, *от* – ут (үлән), *орман* – урман, *топрак* – туфрак;

*у~о: бутка* – ботка, *тукмац* – токмач, *куңгыз* – коңгыз, *суңыдан* – соңыннан;

*ү~ө: үмә* – өмә, *йүгән* – йөгән, *нүгез* – мөгез.

Сергач сөйләшендә *ө~ү* күренеше дә күзәтелә: *өрдәк* – үрдәк, *өрмәли* – үрмәли, *бөре* – бүре, *көңел* – күңел, *бөрк* – бүрек;

*ү~и: үкмәк* – икмәк, *күсәү* – кисәү, *күгәwен* – кигәвен;

*ы~у: йыва* – йуа – юа (үсемлек), *кыwык* – куык, *шында* – шунда, *шылай* – шулай, *мынца* – мунча, *быйау* – буйау (буяу).

**Сузыклар гармониясе.** Аңкау гармониясе. Әдәби телдәге алгы рәт сузыкларына сөйләштә арткы рәт сузыклары тәңгәл

килә: *корка* – күркә, *ацы* – әче, *мацы* – мәче, *анакай* – әнкәй, *бар'ам* – бәйрәм, *ар'ан* – әйрән, *ат'а* – әйтә, *ад'а* – әйдә, *тутай* – түтәй, *йанаша* – йәнәшә (янәшә).

Әдәби телдәге арткы рәт сузыкларына алгы рәт сузыклары туры килү очраклары түбәндәге бер төркем сүзләрдә күзәтелә: *кецеркән* – кычыткан, *кецетә* – кычыта, *әз* – аз, *йәсәми* – йасамый (ясамый).

**Ирен гармониясе.** *о, ө* ирен сузыклары, мишәр диалектындагы, шулай ук урта диалектның аерым сөйләшләрендәге кебек, иренсезләшәләр һәм *ы~е* булып әйтеләләр: *селге* – сөлге, *быдай* – бодай, *сылы* – солы, *кыда* – кода.

Иренсезләшү күренеше *ы~(е) ~ у~ү* тәңгәллегендә дә чагыла: *пых* – пух, *фартык* – фартук, *тегел* – түгел, *беген* – бүген һ.б.

Ләкин сергач сөйләшендә, аерым очракларда беренче иҗектәге *о, ө* ирен сузыклары, үзләреннән соң килгән иренсез *ы, е* сузыкларын иренләштерәләр дә: *йогора* – йөгерә, *болон* – болын, *төтөн* – төтен, *төзөлөш* – төзелеш.

**Дифтонглар.** Сергач сөйләшендә, мишәр диалектының башка сөйләшләрендәге кебек үк, дифтонглар монофтонглашалар.

Әдәби телдәге *-ай/-әй, -уй* дифтонгларына сөйләштә *а, ә* авазлары туры килә, бу вакытта дифтонгтан соң килә торган тел очы тартыклары йомшара: *ат'а* – әйтә, *бар'ам* – бәйрәм, *кар'ы* – каеры, *әлән*ә – әйләнә, *ун'ау* – уйнау, *мун'* – муйын (муен), *кун'* – куйын (куен), *кури'к* – койрык, *кан'ар* – кайнар, *кан'н'а* – каенана һ.б.

*-өй* дифтонгына *ү* (*ү* – өй, *кү* – көй, *үрә* – өйрә, *сү* – сөй) яки *-ев*/*-үв*/*-үw* (*тевен*/*түвен* – төйен (төен), *севен*/*сүвен* – сөйен (сөен) туры килә.

*-ой, -ый* дифтонгларына *-ий* дифтонгы тәңгәл килә: *кийаш* – койаш (кояш), *кийар* – кыйар (кыяр), *кимак* – коймак.

**Авазлар төшү.** *у: руз'а* – ураза, *марта* – умарта; *ы: кырк* – кырык, *халк* – халык, *э(е): бүрк* – бүрек, *күркле* – күрекле.

## Морфологик үзенчәлекләр

**Исемнәр.** Сергач сөйләшендә исем ясалышы һәм аның төп грамматик категорияләре татар әдәби телендәге чаралар белән билгеләнә. Кайбер аерымлыклар тартым категориясендә генә күзәтелә.

Кеше исемнәрен, бер яки ике иҗеккә калганчы кыскартып, – *-кай/-кәй, -ук/-үк* кушымчалары ялгап сөйләү актив: *Шамкай* – Шамил, *Зәйнүк* – Зәйнәп, *Найлүк* – Найлә, *Апт'ук* – Габдрахман, *Хал'ук* – Халидә һ.б.

Иркәләү кушымчасы *-кай*/*-кәй* еш кына туганлык мөнәсәбәтен белдергән сүзләргә ялганып килә: *анакай, балакай, абзыкай.* Мәсәлән: *Анакай дип әтүнең хакы олырак.*

**Алмашлыклар.** Зат алмашлыклары составы, төрләнеше ягыннан татар әдәби теленнән аерылмый. Тик сергач сөйләшендә мин зат алмашлыгының иялек килешендә *минең* (минем) формасында әйтелүен генә күрсәтеп үтәргә кирәк: *Минең китап. Минең кыз.*

Күрсәтү алмашлыклары. Сергач сөйләшендә күрсәтү алмашлыклары күп төрле: *бу, әнә, теге, мына* – менә, *шол* – шул, *ол* – ул, *шынди* – шундый, *шылай* – шулай.

Шуның белән бергә, сөйләштә күрсәтү алмашлыкларының әдәби телдә булмаган күп кенә синонимнары, фонетик вариантлары да кулланыла: *тәнә* (әнә), *мынагынак* (менә), *бахшол* (шул, шушы), *бахшонта* (шунда), *бахындый* (шундый).

Рус теленнән кергән күрсәтү алмашлыклары да сөйләштә шактый актив: *вата, ватагынак, вана, ваташол* (менә, менә ич, менә шул): *Без вата кас'ы йирдә эшлибез.*

Күрсәтү алмашлыкларына тартым кушымчасы турыдан-туры ялгана: *Бусы кимагы, сез кабартма ат'асез. Улсы* (анысы) *инде озон җиңле бишмәт.*

Билгесезлек алмашлыгын сорау алмашлыкларын кабатлау юлы белән дә ясау күзәтелә: *кас'ы-кас'ы* – кайберәүләр; *кас'ы-кас'ы гына эрләк бәли.*

**Саннар.** Әдәби телдән аермалы буларак, сергач сөйләшендә *сигез, тугыз* саннарыннан ясалган җыю санын (сигезәү, тугызау) куллану актив: Б*ез анда тугызау бардык. Сигезәү цыгып киттеләр.*

**Рәвешләр.** Сергач сөйләше рәвешләрнең ясалышы, кулланылышы ягыннан мишәр диалектының башка сөйләшләреннән аерылмый. *-ча/-чә* (сөйләштә *-ца/-цә*) кушымчасы исемнәргә, алмашлыкларга, сыйфатларга ялганып, рәвеш ясый: *татарца әйтем.*

*Үзе* билгеләү алмашлыгына *-ча/-чә, -ца/-цә* кушымчасының турыдан-туры нигезгә ялгану очраклары күзәтелә: *Укымыш инде үзецә* (үзенчә).

*-лата/-ләтә* кушымчасы ярдәмендә исем, сыйфат сүз төркемнәреннән рәвешләр ясала: *Сөт алмыйлар, майлата бирәләр. Йомырканы цилэтэ эцеп булмый.*

*-лый/-лий/-ли* кушымчасы сыйфатларга ялганып, рәвеш ясалу күзәтелә: *кан'арли* (кайнар көе), *йылылый* (җылы көе), *кырыли* (коры көе).

*-лый/-лий/-ли* кушымчасы ел фасылларын белдергән исемнәргә ялганып, вакыт рәвешләре ясый: *йазлый* – йазын (язын), *кышлый* – кышын, *җәйли* – җәйен (җәен), *көзли* – көзен.

Татар әдәби телендәге бераз рәвешен *берцәк* формасында куллану актив: *берцәк аша. Берцәк сүләдем.*

**Фигыль** формалары, нигездә, татар әдәби телендәгечә кулланыла. Кайбер үзенчәлекләрне күрсәтеп китәбез.

**Затланышлы фигыль формалары.** Хикәя фигыль. 3 нче зат берлек саны *-дыр/-дер, -тыр/-тер* кушымчалары белән ясала: *ол окидыр* – ул укый. *Кыдалар килгән, дир.*

Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең 1 нче зат формасын сөйләштә *-ган/-гән* кушымчасы белән белдерү очраклары бар: Мин сезне күргән (күрдем).

Нәтиҗәле үткән заман хикәя фигыль *-ып/-еп* формалы хәл фигыльгә нигезләнеп ясалырга мөмкин:

| | |
|---|---|
| *Мин барыпмын* | *Без барыпбыз* |
| *Син барыпсың* | *Сез барыпсыз* |
| *Ул барган* | *Алар барганнар* |

*-ып/-е*п формасы 1 нче һәм 2 нче затларда гына килә, ә 3 нче – *-ган* формасы белән белдерелә. Бу форма юклык кушымчасы да ала.

| | |
|---|---|
| *Мин бармапмын* | *Без бармапбыз* |
| *Син бармапсын* | *Сез бармапсыз* |
| *Ул бармаган* | *Алар бармаганнар* |

Юклык формасын (бармап) зат кушымчасыннан башка куллану очраклары бар. Бу вакытта бармап формасы куй, бак сүзләре белән килә: Бармап бак – бармый кара, булмап куймасын – булмый калмасын.

Күптән үткән заманның, әдәби *-ган иде / -гән иде* конструкциясе белән беррәттән, билгеле үткән заман (-ды) һәм иде ярдәмче фигыле белән ясалган диалекталь формасы актив кулланыла: *мин алдым иде, син алдың иде, ул алды иде, без алдык иде, сез алдыгыз иде, алар алдылар иде.*

Юклык формасы: *алмадым иде, алмадың иде, алмады иде* һ.б.

Билгеле киләчәк заман сөйләштә татар әдәби телендәге формалар белән белдерелә, юклык формасы сөйләштә *-ацак/-әцәк* (-ачак/-әчәк) + *төгел/тегел* (түгел) рәвешендә ясала: *Мин сиңа барацак төгел.*

**Боерык фигыль** әдәби телдәгечә ясала.

Сөйләштә киңәш, киңәшле боерык мәгънәсендә *-гы/-ге* кушымчалы фигыль + *иде* конструкциясе кулланыла: *Эцкидең* (эчке идең), *нәк эцмәдең* – эчәргә иде, ник эчмәдең.

Киңәш, нәзакәтле кушу, теләк, үгет мәгънәсендә *-гай* кушымчалы фигыль + *иде* (баргай иде) тезмә формасы кулланыла: *калдырып киткәй идең* – калдырып китәргә иде.

*-гай/-гәй* формасы, татар теленең башка сөйләшләрендә кебек, *-ма/-мә* юклык кушымчасы белән дә: бармагайы, китмәгәйе. Бу форма, күп кенә башка сөйләшләрдәге кебек, ис китүне белдерә: *Сүлим выт' – Сүләмәгәйең, сүлә.*

Сөйләштә теләкне *-гы кели* (-асы килә) төзелмәсе белән белдерү актив: *баргым кели, баргың кели, баргысы кели, баргыбыз кели, баргыгыз кели, баргылары кели, ашагым кели, ашак кели.*

Заман, юклык күрсәткечләре ярдәмче фигыльгә ялгана: *баргым кели, баргым келәде, баргым кели иде, баргым келәми, баргым келәмәде.*

*-ма кели* төзелмәсе ниятне белдерә: *барма келим, барма келисең, барма келибез, барма келиләр.*

**Шарт фигыль.** Шарт фигыльнең ясалышы әдәби телдәгечә: *Кан'на йакшы булса, килен мактаулы була.* Әмма, әдәби телдән аермалы буларак, сергач сөйләшендә *-гы иде* (баргы иде – барса) формасының шарт мәгънәсен белдергән очраклары бар: *Бикләп китке идем, ыспакуйны була идем* – Бикләп китсәм – тыныч була идем.

Затланышсыз фигыль формалары. Инфинитив. Сергач сөйләшенә инфинитивның *-(ы)рга/-(е)ргә* формасы хас: *Бибисара кыр-*

*га бара. Кыр эләге эзәргә* (җырдан). *Кушкатламаны кыз белән йегет икесе генә ашарга.*

**Исем фигыль** сөйләштә әдәби телдәгечә *-у/-ү* кушымчалары белән ясала: *Паңгы ашау йук бездә, җыйу йук.*

Хәл фигыль нигездә, әдәби телдәге кушымчаларның мишәр диалектына хас вариантлары ярдәмендә ясала:

*-гац/-гәц* (-гач/-гәч): *Килен килгәц, бусага бирнәсе куйа. Үгә кергәц, әпәй белән цәй эцерәм.*

*-гынцы/-гинце, -гынцак/-гинцәк* (-ганчы/-гәнче): *Туйгинца ашагыз. Картайгинцак эшләдем.*

*-уwынца/-үwенцә: Кат'уwынца кер.*

*-ып/-еп* формалы хәл фигыльнең юклыгы *-мыйца/-мицә, -мыйцак/-мицәк* кушымчалары белән ясала: *Сүләшмицә ашагыз. Ницек үлмицәк калыпбыз.*

**Ярдәмлек сүз төркемнәре. Бәйлекләр.** Сөйләштә татар әдәби телендәге бәйлекләр һәм диалекталь бәйлекләр дә кулланыла: *цаклы/цәке* – чаклы, *тәкле* – хәтле.

*Ката, сәтә* бәйлекләре вакыт аралыгын белдергән сүзләр янында килеп, дәвамлы вакытны белдерә. *Ката,* нигездә, *төн, кыш, йаз, көз* сүзләре, *сәтә* исә *көн* сүзе янында килә: *төн ката* – төн буе, *йаз ката* – йаз (яз) буе, *көнсәтә* – көн буе.

**Кисәкчәләр.** Татар әдәби телендәге кисәкчәләр дә, сөйләш өчен хас булган диалекталь вариантлы кисәкчәләр дә актив кулланыла: *тәнә* – энә, *выт/вет* < рус. *ведь* – бит, *мона, вата, ватагынак* – менә, менә ич, *аллә* – әллә кисәкчәләре бар *(Тәнә зур ызба).*

## Синтаксик үзенчәлекләр

Сорау кисәкчәсе *-мы/-ме,* мишәр диалектының башка сөйләшләрендәге кебек, зат һәм сан кушымчаларыннан алда, ягъни фигыль нигезенә ялгана: барамысын – барасыңмы.

Моннан тыш, сорау кисәкчәсенең җөмләдәге урыны логик басым белән бәйләнгән. Ул сорау интонациясе төшкән теләсә нинди җөмлә кисәгенә ялганырга мөмкин: *йәж кил ен йакшымы йуган идәнне? Ислеме төгел мунцасы? Озакмы торасыз бездә?*

## Лексик үзенчәлекләр

Сергач сөйләшенең төп сүзлек составы татар әдәби телендәгечә. Диалекталь сүзләр мишәр диалектының башка сөйләшләре

белән уртак. Сергач сөйләшенең үзенә генә хас лексик берәмлекләре дә бар. Диалекталь лексиканы берничә лексик-семантик төркемгә бүлеп карарга мөмкин.

**Туй йолалары белән бәйле сүзләр:** *башкыда* – яучы, *билге* – вәгъдә бүләге, *целбәй йандыру* – магик йола, *паклунный* – туйдан соң кыз ягына кунакка бару, *бусага бирнәсе* – яшь килен бүләге, *силәзән йөретү* – туйда яшьләр мәҗлесе һ.б.

**Туганлык, нәсел-нәсәп, кардәшлекне белдерә торган сүзләр:** *кан'ши* – каениш, *кан'на* – каен ана, *кан'игәц* – хатынның апасы, *татарым* – ирем, *тутак* – туташ, *авыз түтеш* – иренең апасы һ.б.

**Бала туу белән белән бәйле йолаларга караган сүзләр:** *түрәү* – тудыру, *аwырайак* – авырлы (хатын), *аш сайлау* – аш талымлау, *бәбәй әбисе* – кендек әбисе, *абдалцы* – сөннәтче, *абдаллату* – сөннәткә утырту, *сөннәт бар'амы* – сөннәткә утырту хөрмәтенә уздырылган мәҗлес һ.б.

**Үлгән кешене соңгы юлга озату йолаларына караган сүзләр:** *үдер, үдергә бару* – үлгән кешене озатырга, төн сакларга бару, *кифен пецү* – кәфен кисү, *гүр цабу* – кабер казу, *иске каберл ек* – иске зират, *үлек күзе* – үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган ашамлык, вак пәрәмәч һ.б.

**Ел фасыллары белән бәйле йолалар:** *йомырка бар'амы, раштыва, кәрәли йөрү, ташу карау, зимцәцәк әтү, тын тыннау, йаңгыр келәү, куйыртырга бару* һ.б.

**Йорт-җир, каралты-кура атамалары:** *азбар* – абзар, *аран* – җылы абзар, *йорт* – ишегалды, *карызба* – аш өе, *кецурдык* – өйнең мич алды ягындагы сәке һ.б.

**Аш-су атамалары:** *алма кимагы* – вак коймаклар, *кийәү цигелдәге* – кияү хөрмәтенә пешерелгән вак бавырсаклар, *цираб бәлеше* – чүлмәк бәлеше, *йомошак* – бодай күмәче, ак икмәк, *турпин* – пәрәмәч, *ләкшә* – токмач, *киндераш кәкәше* – киндер орлыгы белән пешерелгән пәрәмәч, *үтмәк* – икмәк.

**Савыт-сабалар:** *купы* – аш чүмече, *балайак* – бал кисмәге, *куцарка* – кисәү агачы, *цәбе* – чүпрәк, *таган* – өчаяк, *тчашка* – чынаяк, *цулпы* – чыбыктан үрелгән чүмеч.

**Кием-салым, бизәнү әйберләре:** *басма* – ситса, *цулка* – оек, *бөтү* – муенса, *фартык* – алъяпкыч, *кәпәц* – түбәтәй, *церге* – киез, *цергитек* – киез итек, *әкәй* – баш киеме, *сыкна цылка* – тула оек.

**Хайваннар дөньясы белән бәйле сүзләр:** *куй* – сарык, *куцат* – әтәч, *цыпур* – кызыл таракан, *алаша* – ат, *сал'ускан* – саескан, *цаука* – чәүкә һ.б.

**Үсемлек атамалары:** *картуш* – бәрәңге, *киндераш* – киндер, *нәркәмәс* – әрем, *үгез күзе* – гөлҗимеш, *томарцык* – бөре, *вак борцак* – ясмык һ.б.

СЕРГАЧ СӨЙЛӘШЕНДӘ
ГАИЛӘ ЙОЛАЛАРЫНА КАРАГАН ЛЕКСИКА
(җирле сөйләш текстлары яссылыгында)

**Туй, өйләнешү йолалары**

**Башкода килү**

***Башкода*** – кыз димләргә, кыз сорарга килүче кеше.

– Башкода килә. Ул матца астына өстәл цитенә. Урындыкка ни булса да тиз генә астына куйа. Йәнә зиңә инде.

– Эц башкыда йерделәр әстәйгә (апага). Әстәйебез бик матур иде. Берсе Көсәйен атлы, берсе Алимҗан атлы йегетләрдән килде башкыда. Мин Көсәйенгә барамын, диде әстәй. *(Чүмбәли)*

**Башкода булып килү көннәре**

Башкода булып килү өчен иң уңышлы көн дип *баш кен* – дүшәмбе көн, *кечатна кен* – пәнҗешәмбе көн, уңышсыз көн дип *буш кен* – сишәмбе көн саналган.

– Башкыда буш кенне килмәсен. Баш кенне килсә йакшы, чәршәмбе, кечатна кенне килсә йарый.

– Буш кеннән башка кас'ы кенне килсә дә йарый. Буш кенне туй да итмиләр, буш була, диләр. *(Тат. Моклокасы)*

**Туй йасау көннәре**

– Атна кич (пәнҗешәмбе), йома кен (җомга көн) йасилар иде туйларны. Бибиайшаның атна кич туйы булырга, чәршәмбе кен бара керләр йуварга. Ул батып үлә, туйы йылап кат'адыр *(бәет турында)*.

– Туйны буш кенне (сишәмбе) эшләргә кушмилар картлар. Анарга карамый, минем тәтә, буш кенне тештем, эмере ыризык биләдем, дир, дәүләт ийәсе булып тырдым, дир. Кенне бер дә кимсетергә йарамый, бар да йахшы. *(Мәдәнә)*

***Сүз салу*** – кыз ярәшү, кыз килешү турында сөйләшүләрне башлап җибәрү.

– Йегетнең эти-әнисе килә, сүз салалар, сүләшәләр, киңәшәләр, сөлге дә алып китәләр.

***Сүз бетерү, сүз өзү*** – ике гаилә арасындагы сөйләшү-килешүләрне төгәлләү, кызны бирергә ризалык билгесе бирү.

– Сүз бетергәндә сөлге бирәләр, ышанып торорга. Халыкны йәшәләр. *(Камка)*

***Мәһәр*** *(гар.)* – кияү тарафыннан кызның ата-аналарына бирелә торган акча, кием-салымнар, туй үткәрү өчен азык-төлек һ.б.

– Сүз өзгәндә кызга мәһәр сүлиләр, өс кийеме сүлиләр. Мәһәрләтә, акчалата сүлиләр. Бар барынча, йук дарманынча дигәндәй бирәләр мәһәрне. *(Бозлау)*

***Билге*** – мишәр диалекты сөйләшләрендә кыз ягыннан егет йортына вәгъдә бүләге итеп бирелә торган әйбер.

***Бирү билгесе*** – ризалык билгесе итеп сөлге бирелә торган булган.

– Биргәне ара өзә. Ара өзгәндә бирү билгесе итеп сөлге бирәләр малайга, аның раднуйларына, кардәш-кабиләләренә.

– Үзе тугыган селгене бирде әни башкыдага бит себерергә. Үзе эрләгән, үзе тугыган. *(Ыргу)*

***Колак сүwенеце*** – кыз ягыннан бирелә торган ризалык билгесе; гадәттә сөлге бирелгән.

– Колак сүwенеце була. Колак сүwенецен кыз йагы бирә, оцлы сөлге булды, кызыл оцлы. *(Мәдәнә)*

Тастар сару – кызның башына сөлгесыман ак яулык бәйләтү.

– Килешкәц колак сүwенеце алалар. Колак сүwенеце алуга кызның башына ак тастар сара булганнар. *(Петрякс)*

***Селге алу*** – кыз ягыннан вәгъдә бүләге итеп бирелгән сөлгене алып кайту.

Селгене йегетнең этисе алып китә. Аны тенге wакытта алып китә, кеше күрми. Иртә торып чыкканда хәбәр тарала инде су йулларында, шул кызны килешкәннәр, сүз өзгәннәр, селге алганнар, дигән хәбәр тарала. Бик хуwат оцлы селге була, селгегә оцлар йалгилар, йүлиләр. *(Чүмбәли)*

### Кияү ягыннан бирелгән бүләкләр һәм туй үткәрү чыгымнары

***Задатка*** – туй алдыннан кияү ягыннан бирелә торган акча һәм продуктлар.

***Зур задатка*** – туй алдыннан кияү ягыннан бирелә торган бүләкләр һәм продуктлар.

– Зур задатка китергәндә йәшиккә төйиләр зимешләр, перәннек, цигелдәк, айбагыр, цитләвек. Аның эценә бирнә куйалар, күлмәклек. Аны бик цәцәкләп, цуклап бәлиләр. Кийәүне утырталар, цигелдәкне бирми. Кыз тарта, кийәү бирми. Кийәү шунда кызны бага инде. Цигелдәкләр алу зур задатка була. *(Тат. Моклокасы)*

***Кеце задатка*** – туй алдыннан кияү ягыннан бирелгән акча.

– Кеце задатка кийәү йагыннан акца китерәләр күпме булса, кийәүнең атасы атлар йигеп утырып килә. Каршы алып хүрмәтлиләр.

***Туй үткәрү*** – туй чыгымнары өчен акча һәм азык-төлекләр бирү:

– Йегет йагы итен куйа, казын, коркасын, чи куй да куйа туй күтәрергә, шикәрне башы белән куйган.

– Туй күтәрергә сулиләр. Май, ит, йарма, бал, күпме кирәк. Кирәгенцә сүлиләр. *(Камка)*

***Шәл сүләү*** – киленгә шәл китерергә вәгъдә бирү.

– Шәл сүләгәннәр башына, кийемнәр сүләгәннәр.

«Йукны кирәк таптыра», – диләр. Дамы?

***Шәл китерү*** – кызның ризалыгын алгач, егет ягыннан бүләк итеп зур матур шәл китерәләр.

– Шәл китерү була. Йегет йагыннан зур шәл китерәләр, өстенә көмеш тәңкәләр тезгән. Шунда китерәләр аны йегетнең йакын кардашлары. Аларга кыз йагыннан падаркы бирәләр. *(Чүмбәли)*

***Кызлар бисидасы*** (< *рус*. беседа) – кызлар мәҗлесе, кызны ярәшкән көнне кыз өендә үткәрелә

– Йарашкан көнне бик хуат кызлар бисидасы була.

Ап-ак карны, ап-ак карны
Ап-ак карны таптадык.
Ап-ак битле Алтынайны
Шәкүр өцен сакладык. *(Ыргу)*

***Целбәй йандыру*** – магик йола. Туй алдыннан ярәшелгән егет яки кыз янында урамда ут яндыру йоласы, янәсе, егет яки кызның икенче кеше турында уйлап йөргән уйлары, элек сөйләшеп, яратып йөргән кешесе булса, ут аны ашый, юкка чыгара дип ышанганнар булса кирәк.

– Туйга тикле йегет белән кызның сүләшкәне, йаратышканы булса, алар бетсен, йуwалсын дип йә мамык, йә цәпе йандыралар. Целбәй йуwалды инде, ут ашады. Алдына ук йагалар, хыт салам йандыр. Беләләр инде, йанды. Урамда зилышалар да чыс кына ут куйып алалар. Йук, целбәй йук, без сүwешмә-алышма келәмәдек итенәләр. *(Чүмбәли)*

***Никах*** – гаилә төзүне, өйләнешүне шәригатьчә, махсус дога укытып беркетү йоласы; ягъни, мөселманнарның өйләнешү йоласы. Ул берничә өлештән гыйбарәт: өйләнүченең яучы җибәрүе, кыз ярәшү, аклашу, кәләшнең эти-энисе яки иң якын туганнары белән мәһәр турында сөйләшү, килешү, никах укыту (Коръәннең дүртенче сүрәсеннән аятьләр уку), егет белән кызның вазифалары турында үгет-нәсихәт сөйләү һәм туй мәҗлесен үткәрү. Никах мәҗлесе, никах туе кыз өендә үткәрелә, анда олы кешеләр, картлар, егетнең һәм кызның эти-эниләре, туганнары була. Никах мәҗлесе тыныч, салмак, изгелек һәм бәхет теләү сүзләре белән уздырыла. Никах мәҗлесенә исерткеч эчемлекләр куелмый, туй ашамлыклары белән бергә, йола ашы итеп бал-май, баллы су – ширбәт куела. Никах йоласын халкыбыз изге итеп саный, тылсымлы көчкә ия дип ышана.

***Никах сывы, никах ширбәте*** – никах укыган вакытта өстәлгә куела торган баллы су.

– Никах укытыр алдыннан эстәлгә чәйнек белән су куйалар, никах сывы булыр. Ул чәйнек эченә никахка килгән кешеләр парлап-парлап кемеш акчалар салалар. Имештер, кемеш шикелле йалтырап, парлап гомер итсеннәр йәшләр. Никах сывы авыз итәләр. *(Камка)*

***Ширбәт каптыру*** – кияү белән кызга баллы су каптырып каршылау. Кан'на ширбәт каптыра алма-тилмә.

***Бал каптыру*** – кияү өенә төшкәч тә кызга бал каптыру, авызландыру йоласы.

– Азбарга эстәл куйып кайнанасы бал каптырып каршы ала киленне. *(Мәдәнә)*

***Кийәү келәте*** – кияү белән кәләшне бергә йоклату өчен әзерләнгән урын.

– Кийәү келәтендә куналар кыз белән йегет. [**Ырым:** кыз белән кияүне «бозым»нан саклау]:

– Кыз белән кийәү келәткә кергәц, келәт ишегенә тимер кендек белән бәрәләр икән, йә кендекне шыл тирәгә ташлилар. Йегет көцсез кала икән. Кендекне табып укырга кирәк, белгән кешедән укыталар. *(Чүмбәли)*

***Кийәү булгыц*** – кияү буласы, ире кеше.

– Кийәү булгыцым белән кабаг аша гына сүләшә идем. *(Петрякс)*

***Кыз тешерүчеләр*** – кызны кияү өенә китерүчеләр.

– Кыз тешерүчеләрне кийәү йагындагы кардәшләре басып силилар.

***Сондок кертүчеләр*** – яшь килен сандыгын өйгә кертү өчен алдан ук билгеләп куелган кешеләр.

– Сондок кертүчеләр була туйда. Алдан әйтеп куйалар, сондокны сез генә кертерсез, дип. Бер генә никахлы, тигез, йахшы тора торган ир булсын, ике никахлы булмасын. Кызның урыннарын сүтмицә кертәләр. Сондок, сондок өстенә куйа мендәрен, адийалын, шыны сүтмицә, йалтайтмица, цыбалтмица кертеп утырталар. *(Тат. Моклокасы)*

***Туй кодалары*** – каршы яктан туйга килүчеләр.

– Туй кодалары үзләренең кәләшләре белән туй атларында киләләр иде йырлап-йырлап. Малайлар китерә аларны туй кодаларын. *(Чүмбәли)*

***Кийәү белән кызны күрештерү***

– Кыз белән кийәүне зенә кеше күрештерә. Зенә кеше күрештергәндә кийәү бүләк бирә зенәгә.

***Кийәүли бару, кийәүләп йөрү*** – туйдан соң кияүнең кыз йортына, үзенең кәләше янына кунарга йөрүе.

– Бер кийәү кийәүли барыга икән. Анасы әйткән, түгәрәкләрне сүлә. Кийәү сүли икән, йоморка да кал'уса. – Кезге кеннең акылы – кийәү акылы, кергеле дә цыккылы. *(Мәдәнә)*

**Туй атлары**

– Кызны алып киткәндә алаша кузгалып китсен дә бер дә туктамасын. Алаша туктаса – нидер була. Алашалары тыварыла, ул да йакшыга тегел.

***Тубал алашасы*** – тубалга салынган күчтәнәчләр куелган туй аты.

– Тубал алашасы кыз утырган вәдәк артыннан килә. Вәдәк ничек әйләнеп керә туй ызбасына, тубал алашасы да алай керә. Кура кабак эстенә тукти алаша. *(Чүмбәли)*

**Атларны сөлгеләр белән бизәү**

Һәр туйда атларны сөлгеләр белән бизәүгә зур игътибар ителгән. Сөлгеләрнең матурлыгына карап, яшь киленнең уңганлыгы бәяләнгән. Татар халкының төрле төбәкләрендә сөлгеләр төрлечә аталып йөртелгәннәр, туйларда иң затлы бүләк, бизәү әйберсе булып торганнар.

***Алмалы сөлге*** – түгәрәк бизәкләр белән чүпләп сугылган сөлге.

– Алмалы сөлгеләрне дуга башына эләргә дип атап сугалар кызлы кешеләр.

***Оцлы селге*** – озын итеп сугылган кызыл башлы сөлге.

– Бик хуват озын селгеләр була, оцлар йалгилар, туй атларының башына эләләр. *(Мәдәнә)*

***Вәдәк, мәдәк*** – 1. Туй көймәсе. 2. Кияү йортына алып киткәндә яшь киленнең әйберләре төялгән өсте ябулы арба яки чана.

– Кыз инде йылый, чыга капланып. Аның айаг астына куйалар бер адийал, шанда утырталар кызны вәдәккә. Вәдәккә күтәреп абыйсы меңгезеп куйа малай ман икесен. Вәдәкнең эстен йабалар кызыл киҗеле чаршау ман, шандый чаршау ман йабалар.

Мәдәк җырулары – кызны туй көймәсенә утыртып алып киткәндә җырлана торган җырлар.

– Мәдәккә утырталар кызны кийәү белән. Шунда атны кийашка әйләндереп бер тыкырыктан менеп китәргә кирәк. Кийаш уңайына әйләндерәләр. Мәдәк йырулары бу, кызны ару алып киткәндә йырлыйлар. шул мәдәкнең эценә кызны утырталар. Күләп йырлый, йылый:

Аг эләнкәй царшау комац бау,
Кор дисәгез дә кормамын.
Инде генә китеп барамын,
Тор дисәгез дә тормамын.

Миннән калган киндер урынымны
Әти кунацага цыгарсын.
Ат, канатым, Әхмәт туганым,
Вәдәгемә басып шул барсын. *(Тат. Моклокасы)*

***Ару зату, ару китеру*** – кызны кияү йортына үзенең әйберләре белән бөтенләйгә озату.

– Кызның радителләре әзерләгән була кызга сандык, урын-йир, йастыгыдыр, адийалыдыр. Билгеләнгән бер көнне кызны әйберләре белән алып киләләр малай йортына бөтенләйгә. Озата баруцы кодалар утыра. Кийәү белән кыз аткамы, машинагамы утыра. Алып китәләр аруга. Кыз озата баруцылар була инде. Кийәү йортына төшкәц тә кыз аруга китергенце өстен-башын тишенми әле, аруга китергәнце кыз үзенеке өйөнә кат′ып йөри әле кунарга, пастил бит анда калган була. *(Чүмбәли)*

[Кызны озатканда икмәк, күмәч куялар]:

– Кыз зата барганда буш бармилар. Әwәле йомшаг иде, йомшак пешереп итәләр иде.

– Тырантаска йәш килен йанына ук куйалар иде, мәдәккә куйалар иде күмәцләрне. Кыз анасы куйа. «Ашлы-сулы булсын», – дип куйа анасы. *(Мәдәнә)*

**Кунаклый цакыру**

– Аруга төшергәч, кыз ана йагы цакырмыйцы бармый, барыга дерес тегел. Ана цакыра, йәшмицә килми. Бер эц кеннән йәшә, кунаклый цакыра анасы.

***Паклунга бару, паклунный*** (< рус. поклон, поклониться) – туйдан соң кыз ягына кунакка бару:

– Анай кәбәм цакырды цәйгә, паклунный әйтәбез инде. Ирең бара, кан′анаң бара, кан′атаң бара. Пирбуй чәйгә чакыру була инде. Анда йөретәләр ыруларың, кардәшләрең мәҗлескә. *(Зур Рбишча)*

**Яшь киленне туй атларында кияү йортына керткән вакыттагы магик йолалар**

– Атны бизиләр селгеләр белән. Авылны тыгырыклардан, урамнардан әләнәләр. Йегетнең йортына барып кергән wакытта кийаш цыгышыннан керергә кирәк.

– Йәш киленне килеп алалар ат белән, атлар бизәгән, селгеләр, калакуллар таккан, дугаларына цуклар бәләгән. Уникеләп ат була. Аwыл буйы әйләнеп, җырлап китерәләр. Кийаш цыгышыннан китерергә тырышалар, әләндереп китереп җиткерәләр каниш үwенә. Ницек тә кийаш цыгышыннан китерергә тырышалар. Азбарны себереп торалар митла белән. Кан′әни йәш килен белән

күрешә, соло сибә, канфит сибә. Пиц арасына кертәләр йәш киленне. *(Чүмбәли)*

– Мәдәккә утырталар кийәү белән кызны. Шунда атны кийашка әләндереп бер тыгырыктан менеп китәргә кирәк. Кийаш уңайына әләндерәләр.

Бийек икән тавыгыз,
Каршы йава карыгыз.
Йәж киленне китерәбез
Каршы цыгып алыгыз.

– Бөтен халык йәш киленне каршы алырга зийыла. Бер кеше митла белән болар керә торган йулны капкадан өйалдына кадәр себереп бара, бозомнар булмасын, сывырлы булмасын, дип.

– Азбарны себереп торалар митла белән кан′иш үвенә төшкәндә.

**Яшь килен көймәдән төшкәндә, кияү өенә кергәндә аяк астына нәрсә дә булса кую, җыю**

***Церге эстенә бастыру*** – киез өстенә бастырып төшерү.

– Кызны төшәчәк йортына илтәләр. Өстәл куйалар, өстенә йәйәләр церге. Шунда кийәү белән кыз килеп баса. Кан′ана каршы ала, аның түбәсенә кем шәлүнкә, кем күлмәк куйа. *(Тат. Моклокасы)*

**Кияү йортына кергәндә яшьләрнең өстенә ни дә булса сибү**

Яңа төшкән яшь килен белән кияү өйгә кергән чагында, алар өстенә төрле әйбер: ашлык бөртекләре, бавырсак, конфетлар һ.б. сибү йоласы бик күп халыкларда бар. Ул яшьләргә бәхетле, мул, матур тормыш килсен дигән теләкләр белән сибелә дип аңлаталар.

***Зурн′а*** (< рус. зерно) ***бәрү*** – бөртекле ашлык сибү.

– Кызны кийәү йортына төшерәләр, азбарга кергәч, кийәү белән кызның башларына зурн′а бәрәләр, житы. Кызның эрпәге була, шуны йабынган бәбәккә тимәсен өчен, каты бәрәләр зурн′аны.

– «Үмер буйы ашлык белән булсын, башлары ашлыктан цыкмасын, туклык булсын». Табак белән цыгаралар, шуны бәреп бетерергә кирәк. Улсы да бәрә, монсо да бәрә. *(Тат. Моклокасы)*

***Канфит белән соло сибү.***

– Савытта солы, канфит була. Йәш килен белән кийәүнең түбәсенә сибәләр.

«Кругум икмәкле булып торсон», – дип. Ап-ак солы агдаралар канфит катыштырып, көмеш акца катыштырып.

***Көмеш акца бәрү.***

– Йәш киленне йегет йортына керткән вакытта кабаг аша уң йагыннан көмеш акца бәрә.

**Пич каршына илтү, пичкә терәү**

Яшь киленне кияү өенә кергәч тә мич каршына китереп бастыралар, мичкә териләр. Шул вакытта аңа ботка каптыралар. Бу борынгы йола яшь киленне әлеге гаиләгә ияләндерү, яраклаштыру максаты белән, борынгы кешеләр фикерләвенчә, «йорт ияләре» белән таныштыру өчен үтәлә торган булган. Идел буендагы башка халыклар, мәсәлән, чувашларда да бу йола булган.

– Киленне пиц алнына кертәләр, кешеләргә күрсәтмәстән бастырып торалар туйлар цыгып киткәнце.

– Пиц арасында куцарка, цуйыннар йанында көне буйы, көнсәтә басып тора идек. Шынди закун булган.

**Бусагага утырту**

– Зур эрпәк шәл йабындырып йәш киленне бусагага утырталар. Шәлендә тәңкәләр тезгән. Канишне олылау була. *(Тат. Моклокасы)*

**Түшәг-урнысын кергезү**

– Кызның түшәг-урнысын куйалар сандыг эстенә. Кас′ы өц падушка бирә, кас′ы ике падушка бирә. Дүрт кыз баса арбага, озатуцы кызлар шуны коцаклап тотып баралар аумасынга. Кергезгәндә зинау алалар йегет эвендә, ыштубы бер йастыгы, бер цәпесе дә төшмәсен, түшәг-урны тетелмәсен. Бер әйбере тетелсә, боларның тормышы тетелә була, шикле була. *(Чүмбәли)*

***Бирнә*** – кыз тарафыннан кияүнең ата-анасына һәм туганнарына бирелә торган бүләк; кызның өй бизәү өчен алып барган әйберләре һәм савыт-сабалар, өй кирәк-яраклары.

– Бирнәгә ү бизәкләре, алмалы сөлгеләр, царшау алып килә килен булдац кеше. Царшауны пецеп баралар, тиз генә йүләп баралар. Бусага салып кердеме, царшауны матцага коралар.

***Бирнә бетерү*** – туй алдыннан кызлар җыеп, кызның бирнәләрен әзерләп бетереп кую:

– Кызлар йийылалар кыз үwенә никах туйы үткәргинцә. Кызлар цакыралар, йегет йагыннан да, кыз йагыннан да киләләр.

Алар бирнә бетерәләр, кызның бөтен булган падаркаларын йүләрдәйен йүлиләр, тегәрдәйен тегәләр. Берсе энә күзләп тора. Селгеләр йүлиләр. Селгеләр күп китә иде падаркага. Үдә тугыган сөлге, уртасы ак, шакмаклы. Тугуцы әбиләр була иде. Оцлары селекнең терле йепләрдән. Оцына комац куйалар, кызыл комац, ак бәс оц куйалар. Шыларны сандыкка салып куйа селгеләрне.

Зур бисида булмаса да кызларга цәйне куйалар. Царшау йүлиләр, зениләр үлцәп килгән була. Царшауны бүлеп йүләргә түгел, тотын да бетер пецеп баруынца, тиз генә, бүленмийенце генә йүләп бетер, шунарга бирнә бетерү дигәннәр дә, өзеп йүләргә йарамый. *(Чүмбәли)*

***Царшау пецәргә бару*** – туй алдыннан егет өенә барып чаршау кисеп теккәннәр, чәй мәҗлесе ясаганнар.

– Йегет эвенә царшау пецәргә бара идек. Бер-ике йеңгә бара. Аларга йегетнең анасы падарка куйа, халеннән нәрсә килә, цолкамы, йаулыкмы, сөлгеме. «Царшау пецәргә киләләр беген», – дип әттеләр. Күрше йәш киленнәр дә керә царшау пецәргә. Элек бик кызык булган.

**Царшау йүләгәндә усал кеше кермәсен**

– Царшау йүләгәндә энәнең түтәсе белән кадилар икән усал кешеләр. Йегет көцсез булсын, кызлыгын ала алмасын дип.

***Бусага, бусага бирнәсе, бусага китерү, бусагалый китерү, бусага салу*** – яшь киленнең кайнана бусагасын беренче тапкыр атлап кергәндә бүләк бирү йоласы. Бусага – ишекнең атлап керә торган урыны, башка бик күп халыкларда да бусага өчен бүләк бирү, корбан чалу йолалары булган, чөнки бусага ул башка, чит рухлар белән ике арадагы чик булып исәпләнгән. Посаг, посага сүзләре бирнә мәгънәсендә рус сөйләшләрендә, шулай ук украин һәм белорус телләрендә билгеле.

– Кыз белән йегет йәнәшә керергә тийешләр бусагадан, керә-керә бусагага селгене элә. Күләкләр (күлмәкләр) дә элә, сүwәрдийерәкләрне, сүкемлерәкләрне бусагага сала да бусагага тез чүгә, бирнәсе йанына инде. Тез чүгә дә керә, мич алнына утыра. Туйлар үткәнче эленеп тора бусагага салган селге, бит сибермиләр әле. Аларны үмер буйы да саклилар.

– Кыз падаркасын салып, тез цүгеп керә бусагага. Күлмәклек куйа, зур селгене, кызлар йүләгән селгене куйа. Ишектән

кергәндә кыз җиңгәсе бирә. Канишенә була селге, бусага бирнәсе дийелә иде.

– Йәш килен килә дә ишек башына бусаганы салып калдыра, селге куйа. Эстәлгә салфит йаба.

– Килен бусага бирнәсе бирдеме, бусага салып кердеме, шунда ук зенәләр шаршауны коралар, пәрдәләрне тәрәзәләргә коралар.

– Үгә кергәндә килен бусаганы ишек башына сала. «Бусага салып керде», – диләр инде. Йакын туганнары, күршеләре цакырса да кунакка барганда бусага салып керә. Ир туганынамы, кыз туганынамы барса. Бисмилла әйтеп бусаганы куйа.

– Менә син килен кеше безгә киләсең пирвуй рас, бусага салырга тийеш, бирнә бирәсең. Кан′н′а этә, «әле син бусага салмаган, керә алмисың әле аларга», – диләр. *(Мәдәнә)*

***Кыз түене*** – кызның кияү йортына төшкәч өләшү өчен алып барган бүләкләре.

– Кызны йегет үвенә китергәндә кыз түен түнәп куйа. Анда була сөлге дә, күлмәк тә, берничә төрле әйбере булырга тийеш. Ул түенне китерә килә бер йенгә, кызлар белән. Алар йәйәү киләләр. Түендә була инде йаулыклар күп кенә.

***Кыз приданы*** – кызга ата-анасы йортыннан бирелә торган әйберләр.

– Кыз приданы килә алашларда (атларда). Сондок энийем йибәрде, түшәк, ике йастык, бер куй салып йибәрде, биш пар чашка, ике тарилка, ике кашык, чаршау ызбага, нүwешеңә кororга кыз белән кийәүгә.

***Сындык ацу*** – яшь киленнең әйберләре куелган сандыкны ачу йоласы.

– Сындыкны кан′ана кемнән тели шынардан ацтыра. Үзенен бик тә йакын кешесеннән ацтыра. Ин пирут падарка бирә сындыкны ацуцыга. Сындыкның эчендә падаркылар була. Ике пара чашка, ике чәй кашыгы, ике аш кашыгы, тәрилкәләр буш куйылмый, йә бал, йә пичинҗә, йә айбагырлар була. *(Чүмбәли)*

***Үгә сөлге элү*** – яшь килен сөлгесе белән өй бизәү.

– Зур сөлгеләрне эстинәгә элеп куйалар иде. Бик красивый була иде, ике башы кызыл. Безнең алмайныкы да бар иде. Эстәлгә эскәтер йәйәләр.

Йәш килен бер сөлге элә бит себерергә (сөртергә), и берне элә чашкалар себерергә, чашкалар цәпесе дибез инде.

***Силәзән йеретү*** – никахтан соң уздырыла торган яшьләр мәҗлесе. *Силәзән* < *рус*. селезень ‘ата үрдәк’.

– Силәзән йөретү кызга никах кенендә була. Йегет йагыннан да, кыз йагыннан да киләләр. Керәләр кийәү йегетләр йырлап. Утыралар, тотыналар силәзән йеретергә. Силәзән йереткәндә йегет йагында да, кыз йагында да йырлыйлар. Берсе силәзән – йегет йагы, берсе үрдәк – кыз йагы. Бездә ата үрдәккә силәзән диләр. Силәзәнне йертеп бетерделәр, цәй эцәләр йегетләр, пилминне ашыйлар. Йегетләрнең уртасына утырган була кийәү, алар үрәләр ашап тырмыйлар, цәй генә эцәләр дә сибеләләр. Йәсницә (тәбә) ашыйлар. *(Чүмбәли)*

***Силәзән йырлары*** – туйда яшьләр мәҗлесендә җырлана торган җырлар.

– Силәзән йырларын йырлый идем туйда, йырлакли идем. Күпме йөрдем үмеремдә туйларга, силәзән йырлары онытыла. Кем йакшы йырли, шуны йәшәләр силәзәнгә. Цукларны алыр өцен көрәшәләр. Силәзән белән үрдәк йырлаша. Цукны кесәсенә сала силәзән. Кызлар керә багарга. Ике цук йасилар цәпедән. Кыз йагы үрдәк, йегет йагы силәзән йыры йырлилар.

Олы йулкайларда тилигырам
Адашкан кошларны тезлидер.
Китерегез тизерәк үрдәккезне,
Силәзәнкәй килгән, эзлидер.

Безнең астыбыз бер милчә
Кап-кап бодайлар тартадыр.
Йөрмә, йан кисәгем, күз алдымда,
Ансыз да шикем артадыр.

Алтынкай йөзек, берлиант каш
Кисә килешәдер йегеткә.
Йәштин үскән зиба буйым
Халәл булсын сөйгән йегеткә.

Челтәрлекәй күпер өсләрендә
Тагалыкай атның эзләре.

Әүлийадый микән үзләре,
Балдин татлы әйткән сүзләре. *(Камка)*

***Туй алдырыш*** – туйда катнашучыларның туй кунакларын мәҗлескә алуы.

– Туй алдырыш китә, туйда кемнәр йөрделәр, шулай туй алдырыш йасилар.

***Килен цәйе*** – килен төшкәч, яшь килен хөрмәтенә оештырылган чәй мәҗлесе. Яшь килен кунакларга үзе чәй ясап бирә.

– Самавыр керттерәләр. Самавырга селге урилар. Озын гына булалар алар. Йакшы кийенгән кыз сынлы була самавыр. Йәш килен шул самавырны кертеп куйа. Халык тезелешеп утырган була, күз текәп торалар. Цәй йасый килен. Акца салалар цәйгә.

– Кийәү белән кыз азбардан кергәч онытыпмын әле, самаwыр кертәләр, оцлы селге белән. Шул селгене, бик хуwат күркле селгене бәлиләр самаwырга. Ул инде йәш килен керткән самаwыр була. Самаwырны тагын котлилар, андан сун инде йәш килен цәйе дип цәй эцәләр (Тат.Моклокасы).

***Чәй йөретү*** – туй вакытында яшь килен кунакларга чәй ясап эчертә, кунаклар киленне котлап бүләк яки акча куялар.

– Кийәү йагыннан кызлар, кан′сеңелләр күренергә килгәч йәш килен кийенеп чыга чәй йөртергә. Чөче чәй йасап китерә ыстаканнарга. Шул ыстаканны эчкәч манит сала инде чәй эчүчеләр.

– Кийәү белән кыз азбардан кергәч самавыр кертәләр сөлге белән, шул сөлгене бәлиләр самавырга. Аннан инде йәш килен чәй йөретә кунакларга.

– Чәй йөреткәндә кунаклар йырлаклилар:

Кара урман уртасында
Минем атым йефәк тышаулы.
Минем җаныкайны сорагыз,
Йусеф-Зеләйхага ошаулы.

Албут бакчасында муйыллар,
Үтә алмый былбыллар.
Алырмын, җаным, алмый калмам,
Азрак уза төшсен лә бу йыллар.

Агиделгә төшеп зидым
Руза цәцәк куцасын.
Шул цәцәкләр куцасына
Тормышыгыз ошасын.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мирхәйдәр.
Каwыштыгыз, айрылмагыз
Кийамат көнгә кадәр.

Йаңгыр йаwа, йаңгыр йаwа,
Көтәм циләк тулганын.
Йаңа тормышка күчәсең,
Бул бәхетле, туганым.

И дускайым, бергә йәшик,
Бергә йәшәү күңелле.
Бергә йәшәп без үткәрик
Киләчәктә үмерне. *(Чүмбәли)*

**Кыз цәйен котлау**

– Кыз ызбасында цәй эцәләр дә кыз цәйен котлап чашкага акца салалар: «Көмеш кебек йалтырап торсоннар». Йырлилар кыз цәйендә:

Лимун турим, лимун турим
Чашка түгәрәгенә.
Сезләрне мин ошатамын
Җәннәт күбәләгенә.

Лимун салам, лимун салам
Салам ак чашкаларга.
Үзегезнең мәхәббәтне
Бирмәгез башкаларга.

Йырактан ук күренәдер
Мәдәнә калалары.
Бергәләп гумер итегез
Сандугач балалары.

Берегез алма, берегез цийә,
Сезгә тагын ни кирәк.

Сезнең кебек пар килгәннәр
Бу дөньяда бик сирәк. *(Мәдәнә)*

**Ат әттерү**

Туйдан соң кияүнең туганнарын бергә җыеп, аларга карата яшь киленнең ягымлы итеп эндәшү сүзләрен әйттерү.

– Малайның кыз туганнарымы бар, ир туганнарымы бар, олы апаларымы бар, апасының туганымы бар, аларга ат әттерәләр. Минем биш кан′игәцем бар иде, ат әттерәләр миннән.

***Йакшы ат әтү*** – кияүнең туганнарына матур, ягымлы эндәшү сүзләре әйтү.

***Кан'игәчләргә*** үз атлары мынан ат′миләр киленнәр, йакшы ат әтәләр. Гонаг имеш аты белән ат′са.

– Туган алмай, абыз алмай, кунак алмай. Тансык тутай, курләк тутай.

***Кан'сеңлесенә*** ат′кан, мин сиңа ницек атим?

– Аппак кыз, цибәр кыз. Тансык абыстай, севәр абыстай, сүгән алем абыстай, туган абыстай. Кунак абыстай, йаным абыстай, алем абыстакам.

***Йаным цәцәк*** дип әйттем, буй кыз булып килә иде берсе.

– Күркле йегет, ак йегет дидем кеце энесенә.

– Менә кан′сеңлесе Фәхриҗийан атлы булган. Ницек мин сиңа ат атим?

«Фәкыт-фокыт, Фәхриҗаным, бер генә абыз тутакай», дип ат′дигән.

«Йари, ницек булса да атерем», – дигән.

***Кан'агага ат'а:***

– Абзыкай, алем агай, алем абыз агай, чибәр агай, күwәз агай.

***Йанагайга:*** ак йегет, күркле йегет.

Сергач төбәгендә килен белән кайнана икесе бер исемдә булса, кайнана киленгә исеме белән эндәшми.

– Килен белән кан′ана икесе бер исемдә булса кан′ ана ат′а малайының исеме белән, әтик малайы Фатих булса, әтә: «Фатих катны, цәй эцәргә кер». Исеме белән әтми, үз аты белән әтми.

Ир белән хатын бер-берсенең исемен әйтмиләр:

– Йеренең атын әтми, әй диб әтә йәшкәндә.

– Ылан туганчы «Әй, сиңа әтәм», – дип эндәшә, аты белән әтми. Ылан тугач әтисе дип әтә. *(Чүмбәли)*

***Тудый*** – туганнан туган.

***Тудый тәтә, тудый тудыка*** – икетуган сеңел.

***Тудый абзий*** – икетуган эне.

***Тумачи*** – өчтуган (эне, сеңел).

– Тудыйларның оланнары тумачи була.

***Торачи*** – тумачиларның оланнары торачи була.

– Троюродныйдан туганнар тума йат була, торачи була. Аларга үләнергә йарый.

***Абыз түтеш*** – иренең апасы.

***Запун будыру*** [< рус. запон] – туй мәҗлесендә кунаклар алдында яшь киленгә алъяпкыч бәйләтү, аны, гадәттә, кайнана булган кешедән бәйләттерәләр. Шул вакытта килен кешедән барлык кунаклар алдында «әни» сүзен әйттерәләр.

– Йәш киленгә запун булдыра кан′әни. Кунаклар сорыйлар киленнән:

«Кем запун булдырды?» – «Әни». Өц мәртәбә сорыйлар. Кас′ы сабын, кас′ы йаулык, кас′ы акца бирә киленгә кыртлап. *(Чүмбәли)*

**Яшь килен су алып кайтканда үтәлә торган магик йолалар**

– Туй беткәннән сун кызны тешерәләр суга. Падругалары чиләкләр белән кийыга алып китәләр йәш киленне. Суны бер генә йилкә белән китерергә тийеш кыз, уң йилкә белән. Кыз йагыннан килгән кеше, кыз анасы әзерләгән була күмәц, йә кызныкы йиңгәсе китерә. Крайын кисеп суга сала күмәцне. Аннан сың суга килгән кешеләргә дә ул күмәцләрне кисеп-кисеп өләшәләр. Кийыга тәңкә кыралар, йәш килен суга тәңкә кыра.

– Йәш киленне танда иртүк суга илтәләр. Анда алып төшәләр бер күмәч. Аны йегет анасы пешерә. Кыз цумыртып ала суны, күвәндә белән йилкәсенә куйа, биш-алты адым атли шының белән. Аны китерәләр ап-ару болдорнын төбенә, кабакның төбенә кадәр китерәләр. Аны куйа. Зинәләр әбиләр йәшеп алалар, әбиләр кемеш тәңкә салалар суына. Суга тәңкә дә кыра йәш килен, авызына кабып авызы белән кыра суга тәнкәне.

– Йәш киленне цыгаралар суга. Анда күмәцләр өләшәләр. Йәш киленнән су тарттыралар өц мәртәбә. Шул суны үгә кертә. Кайнатасы, кайнанасына, кан′сеңелләренә эцерә. Йәш килен суы дип эцәләр ул суны.

– Йәш киленне алып цыгалар су алырга кийга. Аның китергән суын кайниш йагына да эцерәләр, бу йакка да эцерәләр.

– Йәш киленне суга алып китә дзиңә кеше. Суны алгац кый эценә кемец акца кыра. Кый йанында ук йәш килен күмәцен эләшәләр тураклап бала-цагага. Йәш килен китергән суын бер циләген сийрга, кадулага салалар, икенцесен кертеп өстәлгә кыдалар алдына китереп куйалар да селге белән йабалар. Кунаклар шында акца салалар. Йәшләр икесе цыгып басып тыралар. Бер дзиңә ике чашка кунакларга йөртә. Кунаклар шыл чашкага акца сала, теләк телиләр.

– Йәш килен суга бара. Йанында зиңәләр, оланнар бара. Йомошак күтәреп баралар суга барганда. Йомошакны кисеп-кисеп оланнарга бирәләр, берцәк кисеп кийга суга да сала йәш килен. *(Ыргу)*

**Килен хезмәте**

***Квашн'а//куwашн'а басу, әпәй пешерү.***

– Арыш онынннан квашн'а бастыралар бер сигез-тугыз әпәйлек. Кулны суга маныл-маныл, күп онны салып оннары ойышып калмасын, әпәй тәмне булсын, уңсын. Ап-ару суга атлап.

Пиц кыза, куцарка белән көлләрен, күмерләрен тартабыз. Пумаланы суга манып себерә пицнең эцен.

Әпәй көрәгенә он сибеп әпәйне куйа, аны пиц төбенә сала. Ул анда кызып пешә, йанмый да, күми дә. Әпәйдән он цыкса, уңмаган килен була, йакшы басмаган әпәйне, цулак дийә. Әле тәңкә акца сала, табып алырга килен. *(Мәдәнә)*

– Йәш киленгә әпәй басарга бирәләр. Аңарга көмеш салалар камырына, белдермицә сала. Тапса – уңган килен, тапмаса – цулак була. Пирбуй куwашн'аны басканда ук тапса кемешне, киленем уңган, – диләр.

– Кичтән үк шынди кулкөлтәләр бәлисең саламнан. Иртүк ирең эшкә киткенцә, картлар торгонца шыл салам белән пиж йагып, ашыңны пешер, әпәй сал, табакүмәцләр пешер. Саламны коцаклап кертсәң сибелә, бәләп кертсәң сибелми берцәк. Кулкөлтә итеп бау белән бәлисең.

Элек куwашн'ада әпәй басалар иде. Берәр пот оннан сала, тугызар әпәй була. Ике куллап баса идек. Кулыңа йәбешсә берцәк суга тыгасың кулыңы.

Салам йагып пицне кыздыралар, көлен алалар. Анан йевеш пумала белән көл йәбешмәсен дийеп себерәләр. Цыш-цыш итә ташы. Анан сун керәккә он сибеп әпәйне куйалар пицкә. Квашн′а басканда тәңкә акца сала кас′ы кан′н′а, сыный киленне, йакшымы баса квашн′аны. Шыл тәңкә акцаны табып алса, йакшы баскан була, уңган була. Тәңкә акца цыкмаса, әпәйне кеше алдында кисмиләр. Атерләр: «Килен цулак, әпәйне йакшы басмаган». Шылай беренце квашн′ага акца салалар икән.

Бөген килгән килен инде чашкаларын себерә, суга бара, самывар кан′ата. Әби-бабай цәй эцкән чашкаларын себерә. *(Чүмбәли)*

***Кан′ тоту, кан′ага тоту*** – кайната, кайнага белән сөйләшмәү, олылау, зурлау.

– Царшау короп пиц арасында ашаганнар киленнәр. Утырмаганнар да, сүләмәгәннәр дә.

– Кецурдыкта (өйне пич алды ягындагы сәкедә) ашаганнар киленнәр элек. Беркацан киленнәр кан′иш йанына утырып ашами иделәр.

– Карызбада (аш өе) киленнәр ашап утыра булган. Аларга чыгара булганнар кискәләп шәкәр, кискәләп әпәй.

– Йәж килен төшкәц әле кецурдык йакта гына аши, картлар монда утырып аши. Картлар белән, кан′ага белән сүләми дә, алар йанында ашами да. Кан′ тоту, кан′н′а тоту була. Анаң үwенә дә рөхсәтсез барми идек, йибәрсәләр генә бара.

– Кан′ тоттым бер ун йыллар. Пиц алдында аши идем утырып. Ул кан′ тоту була иде. Кан′ым этте: «Утыр, кызым, кан′ тоту йитәр, цәй эц, аша», – диде.

– Йәш килен ызбага кергәндә тезләренә чүгәләп керә. Кан′ата, кан′ана алдында олылап керә йәш килен кеше.

– Килен кан′ага белән сүләшми, кан′еләре белән сүләшә. Кан′ага тотабыз, цылкалар белән йөри идек, күрсәтми идек цәлдерләрне, галишайак йалан айак, йалан өс йөрөмәдек. Абзай – зәңкәй белән сүләшә идек. *(Мәдәнә)*

## Кием-салымнар

***Йебәк эрпәк*** – ефәк шәл.

– Йәж килен төшкән wакытта йебәк эрпәк йабынып төшкән.

***Сынны наwат*** – билле бишмәт.

***Наwат*** [< рус. на вате] – җылы өске кием.

– Сүз өзгәндә кызга өс кийем сүлиләр, сынны нават булган, билле инде, цабуы кабарып тора торган булган. Анарга зур шәл.

***Әкәй*** – яшь киленнәр кия торган тәңкәле баш киеме.

– Киленнәр цәц цыбалмасынга әкәй кигәннәр тәңкәләр тезгән, сабаклаткан тәңкәләр. Әкәйне бик оста теккәннәр. Әнилә рдән калган әкәйләр әле дә бар. *(Чүмбәли)*

***Тастар*** – башка бәйли торган урама: ул сөлге кебек озын, баш-башлары чигелгән яки бизәкләп сугылган була.

***Тастар сапмасы*** – тәңкәле баш киеме – әкәйнең өстеннән урап, аркага салындырыла торган башы чигешле тукыма.

– Тастар сапмасының ике кырыйы кызыл белән биг оста теккән була, аны әкәйнең өстеннән урыйлар иде. Бит кенә күренә, артка оцон салындырып куйалар. Аны аруга картлар кигәннәр. *(Тат. Моклокасы)*

***Кукиш калпак*** – «мөгезле» калфак (дүрт почмаклы калфак).

***Цит*** – яулык, юка шәл.

– Кара кукиш калпак, кара цит белән килен булып төшә идек. Шыл бер калпак йөри иде аwылда. Дүрт цитле калпак ул кукиш калпак. Аның өстеннән кара цит шылай. Түмәләре маңгайында була.

***Абуркалы күлмәк*** – бала итәкле күлмәк. *(Чүмбәли)*

***Басма күлмәк*** – ситсы күлмәк.

– Басма күлмәк була иде. Итәген йырта да оланны төрә иде.

***Озон зиңле күлмәк*** – озын җиңле күлмәк.

***Партык*** [< рус. фартук] – алъяпкыч.

Ак партыклар мин бәләдем
Билдән тегел кигецле.
Үтте лә шыл үмерем үтте
Бигерәк үкенецле. *(Мәдәнә)*

***Запун*** [< рус. запон] – алъяпкыч.

***Аршауский запун*** – бала итәкле алъяпкыч (аршау > Варшава сүзеннән дип аңлаттылар).

– Үзебездә запуннар, озон зиңле күлмәкләр. Аршауский запун дип анарга киң абурка тоталар иде. *(Камка)*

***Аршау бөтүләре*** – Варшавадан китерелгән мәрҗән.

– Аршау бөтүләрен китергәннәр Аршаудан бабаларыбыз. *(Камка)*

***Көмеш тәңкәле күкерәк*** – көмеш тәңкәле изү, күкрәкчә.

– Йәшләр көмеш тәңкәле күкрәкләр, абуркалы озын күлмәкләр кигән. Әле бит алай түгел. *(Камка)*

***Церге итек*** – киез итек.

– Церге итекләр кидек аwыл йирендә, әле дә шылай кийәбез.

***Цолка*** – оек.

– Айагында цолка, башында йаулык. Гал′иш айак кан′иш каршына цыкмилар. *(Тат. Моклокасы)*

**Бала туу белән бәйле йолалар**

***Аwырайак*** – авырлы хатын.

– Мин аwырайак идем, йыгылыпмын. *(Чүмбәли)*

***Аш сайлау*** – аш талымлау.

– Дары боткасы пешерәм аш сайлаганда. Ул бик файдалы була иде дары боткасы.

***Кисү*** – тулгак. ***Кисү алу, кисүләү*** – тулгак тоту.

– Кисү ала катынны, кисүлей. Шул арада бал каптырасын, баланы тизерәк түрәләсен дип. Бал кисүне кузгый. *(Мәдәнә)*

***Бала түрәү, түрәләү*** – бала тудыру.

– Бала түрәде киленебез, олан туды. Олан түрәләргә кинала килен.

***Бәбәй әбисе*** – кендек әбисе.

– Бәбәй әбисе шылай ылан таптырып йери булган. Эрәнгән инде ул. Кас′ы куш күлмәклек бирә, кас′ы берне.

**Бәбәй әбисе кендеген кисә**

– Бәбәй әбисе баланың кендеген кисә, цәпе белән бәли, баланы йывындыра.

**Бәбәй әбисе соңгылыкны күмә**

– Соңгылыкны бәбәй әбисе эргәгә идән астына күмә, цәпегә (чүпрәккә) цормап. Тирәнрәк күмәләр. *(Ыргу)*

***Сүвенце алу*** – сөенече алу.

– Бала тугац кан′әнидән сүвенце алалар. Кыз әнисеннән дә алалар, малай әнисеннән дә алалар. Йомырка бирәләр, сүвенцегә.

– Тәтәй кинала түрәләргә. Йүгереп килдем: «Зизни, сүwенце, ике улың», – димен. «И, балдыз, келмә инде». «Йук, келмимен,

ад′а, ад′а». Зизнине илттек, ике олан, ике йастыкта йата, белдеңме. Зизни йаулык алып бирде сүwенцегә. *(Чүмбәли)*

**Бәбәйне бишеккә салуцы**

– Бәбәйне бишеккә салуцыга садака бирәләр иде, кан′н′аңмы сала, кан′игәцеңме сала бишеккә.

**Айателкөрси укып бишеккә салу**

– Бишеккә пирбуй салганда айателкөрси укып салалар иде. Шылай пирбуй салуга айателкөрси кирәк. *(Мәдәнә)*

**Кайыры бишек**

– Йүкә агацының кайырысыннан бишек эшләгән, кайыры бишек. Аның дүрт цитенә (почмагына) йепләр (баулар) бәлиләр, аннан йепле ыргакны puталактагы бер шипкә (кадакка) эләләр.

***Цәпе бишек*** – киндер чүпрәктән эшләнгән бишек.

– Цәпе бишекләр дә булды кас′ы кешедә.

**Бишектәге бала**

– Ике килен була. Бишек пиц арасында була. Олан йылый, оланны таба алмый. Дүрт айакланып эзлим дир. Он эценә салып куйган йилпуцка. Йокы арасында әле дә тора ул катын. Ызбабыз кецкенә дир, олан йылидыр. Кыцкырып атергә йакшысынмим, кан′агам бар дир. Ирем ата, нәг оланны алмисың, дир. Кан′ белән дә, кан′ага белән дә сүләмиләр. Ирем крута, мин тиха үткәрәмен, кинаша иде, түндәкләрне йыгыта иде.

– Матцага кага идек шип, йүкәдән йасаган бишек, шында элә идек. Оланнар тәүфикле була иде. *(Тат. Моклокасы)*

**Бишеккә цыбылдык кору**

– Бишекне дүрт цитеннән йеп белән puталакка эләләр, пыружина була. Цыбылдык коралар бишеккә. Цебенме ашамасын, йоклый торган булса күз тимәсенгә. Оланны шылай цыбылдык эценә салалар йакшы итеп, шылай коргоцлар, цыбылдыкдар корган.

**Бишек селкетү**

– Бишекне селкетәләр такмаклап.

Йылама балам, йылама,
Йылы катык сорама.
Йылы катык пицтә,
Анаң килер кицкә.

– Аналары китә выт′ кырга уракка, ылан выт′ йыли.

Тедер-тедер дудкасы,
Пешер арыж буткасын.
Ашасын да кикерсен,
Цитән аша сикерсен. *(Чүмбәли)*

**Бала тудырган хатынга ашата торган ашамлыклар**

***Аж белән килү*** – бала тудырган хатынга ашамлыклар алып килү.

– Олан тапкан әнине багарга киләләр аж белән. Йә катлама, йә пирашкилар пешерәләр. Сөтләш гарабдайдан, ристан пешерәләр, суп пешерәләр.

***Сетләш*** – тары, дөге һ.б. ярмадан сөткә пешерелгән ботка.

– Кас′ы сетләш китерә, күз салып ук китерә сирлылар.

– Сетләш китерәләр, чашкы эсте белән май куйалар, күз йасап салмыйлар. Китерелгән күвенә киленгә каптыралар.

***Цумар*** – чумар.

– Бездә бала тугац китерәләр цумар. Цумарны катык белән, каймак белән каталар. Шул цумарны ашаталар балага сөт булсын, хал′ алсын дип.

***Бәбәй цәйе*** – бәбәй туу хөрмәтенә уздырыла торган мәҗлес.

– Бәбәй цәйенә китерә адийал, йастык, мендәр. Ике көнме йийа, бер көнме йийа. Кем мендәр китерә, мендәргә кемеш кади пыцмагына. «Кемеш кебек йалтырап торсын» – дип.

– Бәбәй цәйенә китерәләр, цәйенә китерәләр цүлмәк белән цумар, шуның кәтле цумарлар катыкка салган. Кайберләре китерә күмәцләр, кайберләре сайук китерә, аг икмәк магазиндан. Бутка да китерәләр. Кем нәрсә тели, шуны китерәләр.

– Бәбәй цәйе уздыралар өстәлләр короп. Цумар пешерәләр, катык белән ашилар, сетләшләр куйалар.

– Кемдер китерә тары буткасы, хыт карындашы, хыт күршесе булсын. Өсенә куйа чашка белән майын. Кас′ы китерә күмәц. Бәбәй цәйенә килә.

– Бәбәйгә күмәцләр китерәләр, үзләре дә күмәцләр белән цәй эцеп китәләр. Сетләш пешереп китерәләр. Шылай иде әwәле.

– Бәбәй багарга киләләр. Йарты митыр басмага изү уйган, бау куйган, бер кисәк сабын, падарка китерә.

**Балага исем куйу, ат куштыру, ат кыцкырту**

– Балага исем куйалар. Ак мендәргә салып өстәлгә китереп куйалар баланы. Мулла исем куйа. Кан′әнисе баланы бишеккә сала, падаркы бирә бәбәй анасы кан′анасына.

– Исемен йаратса олан йылами, йаратмаса йылый булган.

– Берницә көннән ат куштыралар, озак тотмилар оланны. Атын кыцкырталар мулла белән, бутка пешерәләр, олан буткасы була. *(Чүмбәли)*

***Абдалцы*** [гар. афтал + цы] – сөннәтче.

***Абдаллау*** – сөннәтләү.

***Абдаллатуцы*** – сөннәткә утыртучы.

– Абдалцы бабай килеп йөрде, абдаллатып йөрде. Килә дә, рөхсәт сорый да керә, абдаллый иде. Церегән агацның wагын алалар иде абдаллатуцы бабайлар.

– Абдаллауцы диләр, шылай ат′алар. Абдаллату диләр. Бөтен оланнарымны абдаллаттым. Абдаллатмыйца йарамый. Зурлаклар да этә дир, абдалсыз китмибез, абдаллатабыз диләр. Ахирәт бар бит. *(Ыргу)*

***Сөннәт бар′амы*** – баланы сөннәткә утырту көнен шулай зур әйткәннәр.

– Сөннәт бар′амы – шатлыклы көн. Абдалцы килә, оланның пипийенең башын гына кисеп ала, имән цереге сибә. Аш пешерәсең, цай куйасың, кайырын бирәсең. Әwәле беркемгә белгертмәгәннәр сөннәт бар′амын, үзләре күрешләре генә белгән. *(Тат. Моклокасы)*

***Иске*** – бала чүпрәге.

– Аwырайак кеше, корсаклы кеше үзенең күлмәк итәген хәстәрләп куйа бәбәй төрергә, өстән цоргый торганын хәстәрли, тузган шәле дә йарап куйган. Искеләргә төргән, шылай иде.

[Бала атасына сөйкемле күренсен өчен ырымлау]:

– Кайберләре әтәләр: «Атасының күлмәгенә цорнарга кирәк, атасы йарата төшәр», – диләр. Элек иске күлмәкләрдән йасилар иде цорнарга. *(Зур Рбишча)*

## Им-томнар, ырымнар

**Курку кийу**

– Олан нәрсәдән булса курыкса, курку кийалар иде. Шынди кургашын була, самавырдан эргән кургашын. Шуны эретәләр,

ыланның башына дустыган белән су тоталар. Шуны кийалар суга.

– Ни кийасын? – курку кийам.

– Ни кийасын? – курку кийам.

Нәрсәдән куркынган, шул сипат анда тешә. Мацыданмы куркынган, коцоктанмы, шул сипат тешә. Курку киганда оланны бусагага утыртып кийа, түндәккә утыртып. Суда күренә.

Ул куркуны кийасың, курку тешә куркынган кешедән. Сорыйлар:

«Ни генә кийасың?

Курку гына кийамын».

Кургашынны эретеп, оланның башындагы суга кийа. Шыны, кургашынны, мендәр астына салып йокли да, аннан кийәш байыган йакка ыргыта. Ыргытканда бисмилла да әйтмә, кешегә дә әйтмә. Йен зарары ул башка суга ди.

– Курку кийа иде әни. Кургашынны эретә, суга шыл куркынган әйбернең сифаты төшә иде.

– «Ни кийасың? Курку кийам. Кемгә кийасың? Шынарга кийам».

– Өц мәртәбә эткән, шул кургашын ереп төшә. Коцоктан курыкса, коцок сифаты, каздан курыкса, каз сифаты, кешедән курыкса кеше сифаты. Шыны эрәттеләр миңа.

– Берсендә шайтан төшкән, мәләwен төшкән, шыл фурмада. Шыннан сың куркуwы бетте.

Шыл кургашынны икенде белән ахшам арасында зиде йулга цыгарып бәрә:

«Бир миңа шифа, бир иминлек».

Сүз кушмаска, артыңа бакмаска кирәк.

**Күз авыртса имләү**

– Күзләре кеци, пешек тешә. Кецегәц мунца ташына су сала, аска савыт куйа. Шыл су белән күзен йуалар. Анын дуасы бар. Аны укып су аша инешнең икенче йагына бәрәләр.

**Арпа имләү**

– Арпаны арпа белән басалар.

Арпа-арпа мә күкиш
Төбең-табың артмасын,

Башың цәцәк атмасын.
Арпа булсаң син дә кайт.

**Тимерәү имләү**

– Тимерәүне күмер белән сыза иделәр. Ул күмерне, сызган күмерне, ишеккә кыса иделәр.

**Бүсер имләү**

– Бүсерле кешегә пыцкыны, йә пыцакны каптыралар. Пыцак имгәц бүсерне кат′ара ул. Пыцакның кырайын кабып имеп тора иде минем кан′ым, шынди бүсерле иде. Тимер баса ул бүсерне.

**Шайтан цирен имләү**

– Шайтан цире цыга кас′ы кешегә, саташа башли. Муст төбенә су салалар иде укып өшкереп. Әнәс мулла суга өшкереп бирә иде.

**Авызына гөмбә булганда имләү**

– Ыланның авызы гембәли. Нугымның авызын алган иде. Әбигә бардык, камырдан салма йасап бирде. Иртән коцокка бәр, диде. Коцокка бәрдем иртә белән, ап-ару шуннан китте. Цөце камырдан түмә-түмә тоссыз эшләде салманы. Төн кунсын, иртән коцокка бәр, диде. *(Чүмбәли)*

**Ныжы имләү**

– Әпәй сала идем. Әпәйне алгац, йылы пиц кала. Оланны көрәккә салам, әпәй көрәгенә, төреп бәлим дә пицкә тыгып алам. Берәү сорап тора: «Ни курасың? Ныжы курам». Крута эссе миц тегел ул. Кас′ында ныжы бар, шунарга эшләдем.

– Аwырлы wахытта мацыга, йә коцокка типсәң, ныжы тешә икән ул оланга. Ныжы булса айаклары тартыша, йылый.

Әби ныжы курганда мин цыгам да тышка, ухватка атланам да: – «Әби, ни генә курасың?» – «Ныжы гына курам». Өц мәртәбә шылай этергә. Ыланны керәккә бәләп тыгып ала пицкә.

Эц йаны диләр, ныжылы диләр, выт шыны куралар. *(Ыргу)*

– Әwәле ныжы өтәләр иде. Пиц төбенә агац көрәкләр белән икмәкләр салалар иде. Ныжылы оланны шыл агац көрәккә утыртып пицкә тыгып өтәләр икән, йылы пиц инде ул, әпәйләр пешеп цыккан, суынган.

«Нәстә өтәсең? Ныжы өтәм».

Шыннан бетә икән ул.

– Пицкә үпмәк салган көнне йылы пицкә тыгып алалар ныжылы оланны.

«Ныжы булса – ныжы бетсен,
Күздән булса – күздән кат′сын».

– Йон эрли торган орцыкны кырыкка йаралар. Шыл орцыкны кырыкка йарып, аны патнус өстенә куйып йандыралар. «Ныжы курам, ныжы курам», – дип төтәттерәләр. Шыннан бетә иде.

– Йәш бала туган, ныжылы ди. Аны әни әтә иде, бусагага саласын ди оланны. Ашасыннан коцокны цыгарырга кирәк, дийә иде.

– Күзеккән оланны үзем имлим. Өц эспичка йандырып, башын төшерәмен чашкадагы суга. Суwын бутыйм да өц мәртәбә бисмилла әтеп тәрәзне сызам бармак белән.

Илаһи, бир йиңеллек, бир шифа, дисең.

Өц мәртәбә өстәл цитен йуwасың. Аннан ары ишек сапларын йуwасың. Шыны йугац, бармак белән оланның эценә шыл суны сөртәсең. Аннан ары ишекне ацасың да:

Илаһи, бир йиңеллек.
Күздән килдең – күзгә кит,
Йилдән килдең – йилгә кит.
Әбийең-бабаң йоласы.

Олан күзеккән булса, эце таш кебек каткан була. Шыл сүзләрне әткәц, ишек сапларын ул йактан да, бу йактан да паклисың да, артыңа борылып бакмисың. Үгә керәсең дә ишекне шып итеп йабасың.

Йылан шешеген имләү.

– Йылан шешеген кат′ара өшкерүце. Йылан бит цага. Йыланнар белән барып сүләшеп килә иде. Аны цакмилар, тешләмиләр, сүләшә. Бу килә дә өшкерә. Шында ук йылан шешеге кат′а.

## Кешене соңгы юлга озату: күмү һәм искә алу йолалары

***Үдер, үдергә бару*** – мәет булган өйгә төн сакларга бару.

– Үдергә цакырмыйца да йөриләр, йийылалар кеше үлсә. Үдергә барабыз дийеп, йардам итәргә баралар. Үдергә кем нәрсә китерә. Күбесе сөлгеләр, ир күлмәкләре, садака куйалар үдердә.

– Соңгы йулга озату, хушлашу була үдергә бару. Әллә кайлардан да киләләр үдергә, төн кунабыз, дисбе тартабыз.

– Үдергә барабыз, тәлилгә. Үдердә тәлил тартабыз. Садака илтәсең, сөлгеме анда. Падарка алып киләбез, төн ката утырабыз. Мин йоклами идем. Кас′ы йоклап, каталап китә тәлил тартканда. Көнсәтә дә утыралар, төнката да. Мәйетне йуwындырып ченазага салып цыгаргац, мулла барлык тәлилләрне багышлый бергә.

– Үдергә бер кеше дә бушлый килми, садака алып киләләр, күлмәк йә ситсылата китерәләр, сөлге китерәләр. *(Мәдәнә)*

– Үдергә бара идек. Без бара идек әнигә ийәреп. «Син мине өйрәт йасинга. Мин бит көңөлдән белмимен, кеше артыннан гына барамын», – димен. «Кызым, син үдердән калма, күңелдән *үрән», – дир. (Чүмбәли)*

***Төнәтү*** – төн саклап утыру.

– Төнәтү диләр, алар укып куналар. Башкалары тыңнап тора. *(Тат. Моклокасы)*

***Кифен пецү, кифеннек пецү*** – кәфен кисү.

– Кифен пецәргә үзем йөрим.

«Тар кабереӊ киӊ булсын, илаһи,
Караӊгы гүреӊ иман нуры белән тулсын, илаһи,
Иманыӊны йулдаш кыл, илаһи,
Калебеӊне пак кыл, илаһи.
Белеп кылган, белми кылган гөнаһларыӊ
дөнйалыкта калган булсын, илаһи».

Кифеннекләрне пецәбез дә цамбыр белән төтәштерәбез, цамбыр исе цыга.

Кифен пецкәндә, йүләгәндә әммәбез шылай әтәбез:

Сөбханаллаһи, вә биһәмдиһи,
Сөбханаллаһи, вә биһәмдиһи.
Лә илаһы илалаһы
Караӊгы гүрем йактысы.
Лә илаһы илаллаһы
Сигез ожмах ачкычы. *(Зур Рбишча)*

***Кифеннек пецүце*** – *к*әфенлек кисүче.

– Кифеннек пецүцеләргә кас′ы йаулык, кас′ы сабын бирә.

***Гүр цабу*** – кабер урынын билгеләү, чабып чыгу.

– Гүр цабу диләр. Бер кеше балта белән гүрне цабып цыга. Шыл кырыйдан тотыналар кабер казырга. Гүр цаба уки белгән кеше. Әлхәмне, кылыхуалланы уки. Үлцәп буйын алган агацка салыр әтәләр, аны кабер өстендә калдыралар. Икенце кеше кабер казыганда шыл салыр белән үлциләр. *(Мәдәнә)*

**Гүргә төшерү**

– Сөлгеләр белән алып бер кеше төшерә, өцәр митырлы сөлгеләр белән. Күлләр белән камыш урып китерәләр, кабергә салалар. *(Ыргу)*

– Кабер өстенә чардуган куйган, шунда барып йаңгыр сорыйлар, намаз укилар.

**Гүр садакасы, кабер садакасы**

– Тавыкны тоттыра кулына муллага, зирна. Зирнаны цүпләгәндә аның гынаһларын цүпләсен тавык дип әйтәләр.

– Гүр садакасын гүр цабуцыга бирәләр, кем гүрне пирбуй цаба.

– Кабер садакасына тавык бирәләр, урам аша цыгарып бирергә, бер йәтим катынга бирергә кирәк. Көнчыгышка бирергә, көнчыгыш йагында, рәде бар. *(Бозлау)*

**Мәйетне өйдән алып чыккач,
цамбыр (чабыр үләне) йандыру**

– Үлене алып цыгып китәләр дә цамбыр (чабыр) йандыралар.
Урынына он, тоз куйалар.

– Үлекне алып киткәц он куйалар, тоз куйалар урынына, катыннар кала дисбе тартып.

**Ызбаны йыву**

– Ызбаны йывалар үлекне алып киткәц тә. Циллата йывалар, элеңгеләрне, үлек урынын йывалар.

**Үлек цыккан үдә ашамау**

– Үлек цыккан үдә ашамилар, күршеләренә кереп цәй эцәләр. Алар цакырып ала. *(Чүмбәли)*

***Тәлил, тәүлил*** (гар.) ***ат'у*** – тәһлил әйтү. Урта диалектта мәетне өйдән алып чыкканда әйтелә торган дога сүзләре: Лә илаһә иллә аллаһы – «бер Алладан башка Алла юк» дигән җөмләне әйтү.

– Ирләр ченазага куйып алып цыгалар, абзарга алып цыгалар да тәһлил ат'алар. Тәһлил ат'уцылар йакын нәсел-нәсәбәләре була.

***Җеназа*** – 1. Мәетне озату; 2. Җеназа агачы, үлгән кешене күтәреп зиратка илтү өчен махсус җайланма.

***Ченаза астыннан үтү*** – мәетне салган җеназа агачын кешеләр күтәргәч, шуның астыннан якыннарын үткәреп җибәрү.

– Ченаза астыннан йакыны, улы, кардашы үтә. Мулла үтсә дә йарый. Элек мулла гына үтә иде.

***Ченаза башына дуга куйу*** – яшь кыз үлгән вакытта аның җеназасы өстенә дуга ясап куеп, чаршау белән каплау.

– Ченаза башына дуга куйалар, анарга царшау, мәдәк коралар кыз бала үлсә.

***Ченаза намазы*** – җеназа намазы.

– Азбарда ченаза намазы укилар, садака өләшәләр. Ченазаны йилкәләренә күтәреп китәләр каберлеккә.

– Мулла уки ченаза намазын. Ченаза белән илтәләр каберлеккә. Ченазага куйалар үлекне башы белән кибла йагына таба. Укилар урамда, мулла уки, нийәтли. *(Мәдәнә)*

**Ченазага сөлге элү**

– Ченазага сөлгеләр бәләп куйалар, ап-ак сөлгеләр. Ул сөлгеләрне каберләр өстендә ченазадан алалар күтәреп баруцылар. *(Чүмбәли)*

**Кабер башлауцы**

– Кабер башлауцыга йә күлмәк, йә зур селге бирәләр, нәселнәсәбәсеннән укымыш кеше булса башлый кабер.

***Каберенә дуга куйу*** – кыз баланың каберенә дуга ясап куеп, анда яулык яки тасмалар элеп кую.

– Буйга йиткән кыз бала үлсә, аңарга каберенә дуга куйалар. Анда платугын бәлиләр, или линталар бәлиләр. Кыз баланың туйы урынына була инде ул, мәдәк урынына була. *(Тат. Моклокасы)*

***Иске каберлек*** – иске зират.

– Бер күл бар, төпсез күл. Төпсез күлнең бу йагында иске каберлекләр. Элгәре сука белән сукалаганнар, кеше сүwәкләре цыккан. Сүwәк цыккац шында йама күтәрәләр, шыл иске каберлекләр була. Элек халык бик зур булган, кесәләренә сукаларын тыгып йөргәннәр, себеркеләрен (тырмаларын) аркаларына асып йөреткәннәр. Шылай сүли иде эти. Әцәтләр (әтәчләр) кыцкыра икән. Кабер әһелләренең рухына дыва кылабыз. *(Бозлау)*

***Үлек бар'амы, үлеккә аж илтү*** – үлгән кешене искә алу мәҗлесенә ашамлык белән бару

– Үлеккә аш илтәбез, кецерәк пәрәмәцләр, цигелдәкләр. Элгәре ашсыз барми идек үлек бар′амына, әле аш илтмиләр.

***Үлек күзе*** – үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган ашамлык; ул бик вак итеп, итле пәрәмәчләр формасында пешерелгән. Аны олы кешеләр генә хәтерлиләр, яшьләр белмиләр.

– Үлек күзен йеде кицендә пешерәбез. Мәйетне йыл да искә алганда да пешерәбез. Ул бик әҗерле, саwаплы. Без олан wакытта шылай әниләр үлек күзе пешерделәр.

– Үлек күзе диләр иде, хазер алай йук – wак кына итеп, күзгә ошатып эшлиләр иде. Шылай ат′алар иде картлар. Өстәлгә куйалар, ашап беткәннән суң ул.

– Кимаклар, күпертмәләр, үлек күзләре пешерә идек. Менә шының тәкле генә йәймә, пилмин йәймәсе кебек. Шының тәкле генә берцәк ит куйасың да бөрәсең. Вәт ул үлек күзе. Пицтә пешерәбез үлек күзен. Ашап беткәц табак белән китерәсең дә куйасың өстәлгә.

– Үлек күзен бар да кесәсенә сала иде, оланнарга дип. Үзләре берәрне генә кабалар, шылай тийеш. Оланнарына алып китәләр.

«Оланнарым озын өмерле булсын,

Оланнарның күзләре йакшы күрсен», – дип, выт аны барысы да уцлап кесәләренә салалар иде.

«Айак өстендә, акылың дөресендә,

*Күз дарйагыз белән үмер итегез». (Мәдәнә)*

***Үлек пәрәмәце*** – үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган вак пәрәмәчләр.

– Үлек пәрәмәце диләр. Аны бик вак кына итеп пешерәләр. Элек аны үлек күзе дип тә ат′каннар. Үлек пәрәмәцен йедесенә, йеде кицәсенә пешерәләр, куй итеннән.

Элек цөцедән генә эшлиләр иде, ацыдан йарами диләр иде wак пәрәмәцне, үлек пәрәмәцен. *(Мәдәнә)*

**Бутка**

– Үлек ашына бутка пешермиләр. Бутка буталып пешә, үлек куйыра, күбәйә дир. Үлек ашына картук белән ит куйалар бездә. *(Чүмбәли)*

***Өц кицәсе*** – өчесе.

– Өц кицәсенә үдәге таwыкны суйып хатем укыталар.

– Бездә, Камкада өц кицәсе йуктыр.

– Бездә Чембилидә өц кицәсенә кимак пешерәләр. Түлке бутка куймилар бутка бүртә, куйыра. «Үле куйыра, күбәйә», – дир. Wак бөкмә йасилар, ит бөкмәсе.

***Йеде, зиде кицәсе*** – җиденче көнендә үлгән кешене искә алу.

– Зиде кицәсендә зиде әйбер пешерәләр. Белен, бераз кимак, цигелдәк, әрбер киц башына бер аш була зиде кицәсендә. Зиде кицәсенә халкны цакыралар.

– Зиде кицәсендә сетләш куймилар, аның урынына куйалар зиде төрле аш. Кимактыр, цигелдәк, сомса, шундилар куйалар. Сетләшне куймилар шуның өчен, йорттан үле кат-кат цыкмасын эцен, куйырмасын, күбәймәсен, дип. Сетләш-бутка куйырта, дир.

– Зиде кицәсе – аш була, шурба. Бутка куйылмый, үле куйыра ди. Коры ашлардан зиде төрле аш була: цәй, кан′ар аш, пилминчә, катык йазалар, катлама, белен, кимак, цөце катлама.

– Йедесенә куй суйалар, шул ук иттән пәрәмәцләр пешерәләр wакларны гына. Үлек пәрәмәце диләр.

***Кырыгы*** – кырыгында инде пәрәмәц пешермиләр. Куй суйып хатем укилар.

**Бер йылы, зур хатем, үлек бар′амы**

– Бер йылында зур хатем була. Хатемдә ирләр кәпәцтән, хатын-кызлар ак йаулыктан утыралар.

Зур хатемдә элек цәй эцә идек таба ашы белән. Әле инде таба ашы тегел, әле пирут үрә ашилар.

– Теләгән кеше цәпесен өләшә, акца өләшә. Әле инде кем барды үлек бар′амына, әммесе акца өләшә.

Йылын үткәрәләр, кан цыгаралар. Пецтергән куй кирәк, куцкар йарами. *(Ыргу)*

### *Аш-су йолалары*

***Йемешли бару*** – кыз өенә күчтәнәч ашамлыклар белән бару.

– Никах көнендә йемешли баралар иде кызга, йемешләр илтәләр иде. Кызның ызбасыннан баралар малайның туганнары. Күмәцләр салып илтәләр, йакшы йемешләр. Короли барып булмый. Алар да падарка биреп йибәрәләр иде. *(Мәдәнә)*

***Тубал ашлары*** – туй вакытында тубалга салып китерелә торган күчтәнәч ашамлыклар.

Тубал ашлары түбәндәге ашамлыклардан тора:

***Йомошак*** – бодай күмәче.

***Куш катлама*** – икесен бергә төреп пешерелгән юка.

***Күптермә*** – төче камырдан пешерелгән күмәч.

***Умак*** – бодай оныннан пешерелгән вак күмәчләр, ул так санда була – егерме бер яки кырык бер.

– Тубалга кыркбер умак куйалар, кас′ы йегерме берне куйа, тегел[1] булмасын, тегисез кирәк, дүрт цитенә дүрт күптермә куйалар, кийәү белән кызга бер йомошак куйалар, бер куш катлама. Умак түгәрәк, йакшы камырдан була.

***Цитлавык*** – чикләвек.

Цитлавык китерәләр тубалда, кодацаларга өләшәләр.

**Куш катлама**

– Куш катламаны келәткә кертәләр дә кийәү белән кызга икәү генә ашарга кушалар, кешегә ашатмаска. Ашап бетерергә тийеш аны йегет белән кыз. Ашап бетерә алмаса сирга каптыралар, йарый, диләр туарга[2].

– Куш катлама цөцедән пешергән, берсе өстенә берсен каплап пешергән була.

– Куш катламаны никах көнне кыз ызбасына кертәләр. Алар аны икесе генә ашап бетерергә тийеш. Аны калдырырга йарами дир.

– Куш катлама, менә камырны тәгәрәтәләр, ишәсең дә куйасың. Ике катлама була инде ул.

– Куш катламаны ашап бетерә алмаса туwарга каптыралар. Йари диләр туwарга, шылай сүләделәр аны. *(Чүмбәли)*

***Тубал ашы гүснице*** – тубалга салып китерелгән туй ашамлыкларыннан өйгә биреп җибәрелгән күчтәнәч.

– Тубал ашларын кисәкләп-кисәкләп кенә кешеләргә дә турап куйалар.

[1] Тегели – җөп санда.

[2] Туар – хайван.

«Тубал ашы кап, бәхетле булырсың, үмерле булырсың», – диләр. Тубал ашын турилар да, күптермәсен дә үгә биреп йибәрәләр, тубал ашы гүснице[1] диләр.

«Тубал ашы гүснице оланыма алып барыйм, оланым үмерле булыр», – диләр.

***Тубал илтүче*** – тубалга салынган туй күчтәнәчләрен илтү өчен махсус билгеләп куелган кеше.

– Тубалны алаша белән илтәләр. Тубал илтүче бәхетле кеше булсын, ике кибенле[2] булмасын, бер генә кибенле булсын. Шуңардан илттерәләр тубалны. Алган цагында да шылай алдырталар, бер генә кибенле булсын, бәхетле кеше булсын, шылай итенәләр. Тубалны эстәлгә кертеп куйалар, дыва кылалар.

***Тубал китерү*** – егет ягыннан кыз ягына тубалга салып күчтәнәчләр, туй ашлары илтү.

– Тубал китерәләр туйга кызны йәрәшкәц. Никах кенендә китерәләр. Йүкәдән йасаган зур тубал була. Ат белән китерәләр тубалны. Йәрәшергә килгәндә пирутки кенне йегет анасы китерә тубал, кыз иткән көнне кыз анасы кайтара тубал.

– Никах көнне китерәләр тубал. Кабакта көтеп торалар. Тубалны тиз генә эләктереп пайытка кереп тә китәләр. Алаша белән китерәләр, күтәреп тә китерәләр. Өстенә цәпе цорнаган тубал була.

– Элек бушли килми иделәр, тубал китерәләр иде никах укыганда ук. Ул тубалга пешергән каз, күптермә, умаклар куйалар, куш катлама кийәү белән кызга.

***Тубал кайтару*** – кыз ягыннан кияү ягына тубал белән туй күчтәнәчләре илтү.

– Тубал кайтармица йарамый. «Ыризыклары тулы булсын», – дип кайтаралар тубал. Кайтармаса шикле була, «безгә ыризык катнаштырмый», – диләр.

– Тубалны кат′аралар кодали дәшкән wакытта. Падарка куйып бирәләр тубалга. Кыз анасы куйа.

***Бал сүләү*** – кыз ягына бал китерергә вәгъдә бирү.

– Никахка тәкле сүләгәннәр балны.

[1] Гүсниц – (рус. гостинец) – күчтәнәч.

[2] Кибенле – кәбенле, ягъни никахлы.

**Бал китерү**

– Тубалга куйып бал китерәләр малай йагы, йакшы йармалы бал китерәләр.

***Балайак*** – бал кисмәге.

– Балайак белән йакшы йармалы бал илтәләр. Балайак белән балны каршы цыгып ала. Агац балайак белән бал килә. Хазер кимак балайагы булып калды.

«Балайак тулы сары бал,
Кодаги цыгып каршы ал». *(Тат. Моклокасы)*

Туйда йырлилар кодагига:

«Балайак-балайак бал алганда
Цөцеме иде, кодаги.
Кызыңны алып китәбез,
Йылама инде, кодаги».

**Бал каптыру**

– Кан′н′а бал каптыра кийәү белән кызга.

«Татлы булыгыз,

Тату торыгыз», – дип.

– Азбарга эстәл куйып кайнанасы бал каптырып каршы ала киленне.

***Йәш килен майы*** – кияү йортына килгәч яшь килен атлаган май. Аны туйда кунаклар алдына куялар.

– Кыз китергәц кыздан май атлаталар, кунакларга куйарга кирәк. Йәш килен майы була, шынарга барсы да акца салалар. Пүгрәптән алып та куйалар ци майны. *(Чүмбәли)*

***Кийәү кимагы, алма кимагы*** – кыз ягында кияү өчен махсус пешерелгән коймак.

– Мунцадан цыгуга иң йакын кешеләре кимак кертәләр. Кимакны тәрилкәләргә тезәләр. Теце кимакны, уртага цынайаг эсте белән май куйалар, кийәү кимагы була. Кийәү акца сала кимакка.

Алма ашасаң иде,
Кабыгын ташласаң иде.
Шыл ызбада кийәү булып
Кимак ашасаң иде...

– Кийәү килгән, кимак ашап утыра дир. Берсе кергән дә этә: «Ад′а кыз йанына, син монда кимак ашап тораин». Бусагадан кергән дә кийәүгә ат′кан шылай. Ә кийәү этә икән: «Әле берцәк кимак бар бит». «Ә, кимак ашап торасыңмы әле син», – дип, кийәүне гурласыннан эләктергән дә алып цыгып та киткән. Шынди хал′ булган дип келгәннәр иде.

– Кийәүгә кимак пешерү бар иде. Гарабдай онынннан кимак пешерделәр, безнең заманда бодай оны йук иде. *(Чүмбәли)*

***Алма кимагы*** – вак коймаклар.

– Кызлар царшау артында, йегетләр алма кимагы белән селтиләр, кызлар канфитлар белән селтиләр. Кызлар-йегетләр белән утырми иделәр. Май эцендә пешерәләр алма кимагын.

***Кашык кимагы*** – вак коймаклар.

– Кийәүгә агоннан кашык кимагы пешерәләр. Чашка табагына куйалар, аның уртасына сары май куйалар. Кийәү шыл кецкенә кимакны, кашык кимагын аши иде кан′ар сары майга манып. Кимакны бик оста пешерәләр и йоморо кимакны шылай тәрилкәгә куйалар иде.

Кашык кимагын кийәү ашап бетерсә – **атаман** дигәннәр. Ашап бетермәсә – монарда рәт йук, эш йук дигәннәр. Ә кийәүнең атаман булгысы келәгән, ашап бетерергә тырышкан.

– Мунцадан цыгуга кимаклар куйалар кийәү белән кызга, цөцедән атлап. Кийәү кимагы була. Май куйалар манып ашарга. Борай онынннан пешерәләр, ул бик тәмле була.

– Кийәүләр килә. Кийәүне урта бер йиргә утырталар. Кимакны китерәләр тарилкага куйып. Уртасына куйалар бал да, май да. Шыны, кимакны кийәү дә, кийәү йегетләр дә шынарга тертеп ашилар. Выт шылай иде бездә. *(Чүмбәли)*

***Кийәү цигелдәге*** – майда пешерелгән вак бавырсак.

– Ак йаулыкка бәләп кыз ызбасынннан кийәүгә цигелдәк илтәләр, йемешләр салып. Кийәү цигелдәге була ул (Тат.Моклокасы).

***Цирәб бәлеше*** – чүлмәк бәлеше.

– Цирәб цүлмәктә пешә цирәб бәлеше. Анарга кирәк гарабдай белән ит, суган. Итне тапап, анарга май, суган күп кенә сала. Берцәк картуп катыштырса да йарый. Аның өстенә йәймә йәйеп каплилар. Цирәб бәлеше шынди бәлеш була. Цирәб бәлеше

дип кабырганы тапап, картушын турап, пицкә куйа булганнар. *(Мәдәнә)*

***Төпле бәлеш*** – куй итеннән. Гарабдай йармасын бик йакшы йывалар. Куй итен йывалар, тапилар, суган күп салалар. Була шынди цирәб цүлмәге. Шында салалар ит белән йарма, суганны. Өстенә йәймә йәйеп каплилар шылай камыр белән. Ул була **төпле бәлеш.** Ул йәймәне кубарып ала да бәлешне табакка сала.

**Эц-карын бәлеше**

– Куйның эцәген, ашказанын бик ару гына йуwа, аны пешерә, вак кына тапи, бик күп суган тури. Камыр йәйеп, камырга салып пешерә.

**Шулпалы бәлеш**

– Сугым суйгац, кабыргасыннан пешерәләр бәлеш. Итне кисәкләргә тапилар сүwәге белән, йуwалар бик йакшы. Ун-унике литырлы цуйынга сала. Пешә ул бик йәмле, бөтен майлары итләргә сеңеп пешә. Ул бәлеш аруга ит. Ул шулпалы бәлеш була. *(Чүмбәли)*

***Йомошак*** – бодай күмәче, аны кызны алып киткәндә көймәгә куялар.

– Йомошакны мәдәккә йәш килен йанына ук куйалар иде, кыз анасы куйа. «Ашлы-сулы булсын», – дип куйа кыз анасы (Тат. Моклокасы).

– Кас'ы кеше йомошак кына пешерә кунакка. Йакшы сөткә басып, майын салып пешерә, дыружи сала тиз кабара торган. Туйга йомошак салалар иде, зур-зур кисәкләр белән кисеп куйалар иде.

– Йәш килен суга бара. Йанында зиңәләр, оланнар бара. Йомошак күтәреп баралар суга барганда. Йомошакны кисеп-кисеп оланнарга да бирәләр. Берцак кисеп кийга суга да сала йәш килен. *(Мәдәнә)*

**Күптермә**

– Кичен атлисың он белән, манни кушасың, йомырка сытасың, май саласың. Манни күпкәк йаси, тәмле була. Ә кас'ы кеше манныйсыз гына пешерә, анысы белен була. Ә моның аты күптермә була.

– Пиҗ йагып, утка каршы, жар эчендә күпереп, кызарып пешкән күптермә була. Аны шылай дүртәргә кисеп куйабыз.

Цөцегә пешергән катламаны ашамилар. Ә күптермәне сүриләр генә. *(Мәдәнә)*

***Пәрәмәцә*** – пәрәмәч.

– Итне тапи, суган сала. Дружалы камырны йәйеп, эценә тапаган итне салып май эцендә пеширә.

**Турпин**

– Турпин ул пәрәмәцә кебек, түлке май эцендә пешермиләр. Ул утка каршы пешкән була, майсыз. Турпин ул йарлыларда булган. *(Бозлау)*

***Пирмин, пилмин*** – пилмән:

– Кийәү йегетләренә үтә кан′ар пирмин куйалар икән. Ә тегеләр пирминне аши алмилар, аска тийи баралар икән.

«Бетте пирмин, тагы китерегез».

Тегеләр китереп сала булганнар. Кас′ы пирмингә күмер салалар икән, кас′ы тоз куйалар икән.

– Әwәле пилмин ашарга йәшкәннәр сугым суйгац. Пирут пилмин, аннан бәлеш ашарга, тагын ит.

***Ләкшә*** – токмач.

– Ләкшә кисә йомыркага гына басып, әле инде ләкшә, элек салма иде кыз төшкән көнне.

***Салма*** – чумар.

– Туйга да салма пеширәләр иде, ләкшә пеширү йуг иде. Салма – кунакларны зурлау иде. Камыр басасың үзләтеп, бармак кебек кәбәрә ишәсең, бармак кебек әвәлисең, кисеп шулпага саласың.

– Салма пеширәм. Су кан′и, картуш салам, аның өстенә салма салам. Йәшел суган белән йомырканы курасың табада, аннан саласың шурбага. Катык катып ашисың. *(Ыргу)*

**Киндераш табакүмәце**

– Табакүмәц йәйәсең агондан. Аның бу йагын пеширәбез. Ал′андырабыз да йомырка сытып, сарымай салып киндерашны түwеп йагабыз. Ул киндераш табакүмәце була.

**Киндераш кәкәше**

– Киндераш кәкәшен пеширә идек картушка болгап. Камыр өстенә йәйәбез түгәп киндераш белән картушны.

**Киндераш пирмине**

– Зур казанны тутырып киндераш пирмине пеширә иде нәнәйебез.

**Киндераш бөкмәсе**

– Киндерашны киптереп түwәсең, илисең иләктән. Аңа эре иләк, зур тишекле иләк кирәк. Киндерашны киледә түwәбез, оннана ул.

– Камыр басасың, кецкенә йәймәләр йәйәсең, киндераш онын саласың, суган, йомырка. Шыны эценә саласың да бәгеп куйасың. Киндераш бөкмәсе зур була, дүрт-бишне ашасаң тук буласың. Катык катып ашибыз.

– Бөкмәне суган, йомырка белән пешерәбез. *(Мәдәнә)*

**Талкан**

– Талканны бик ашаганнар элеке. Бодайны йуwып киптерәләр. Кипкәц аны тирмәндә тарталар. Кан′ар суга болгатып ашаганнар, майлы талкан ашаганнар. *(Ыргу)*

**Табакүмәц**

– Табакүмәц пешерәләр бер ике таба. Кара ондан асты, өсте ак ондан була иде табакүмәцнең.

**Картуп табакүмәце**

– Картуп табакүмәценең асты кара ондан, өстенә картуп йаба идек түwен.

***Эремцек кәкәше*** – эремчек пәрәмәче, шәңгә.

– Табакүмәц өстенә эремчек йаба йомырка белән бутап. Эремцек кәкәше була.

***Картуш кәкәше*** – бәрәңге пәрәмәче, шәңгә.

– Картуш кәкәше пешереп алдылар кызлар вичиринкада.

***Әпәй*** – икмәк.

– Мин әле туган гына булыпмын. Килеп кергән бер келәнце саилце. Кызым, миңа әпәй бирмәссеңме?» Үзенә дә аз гына була әпәйе, ә бирә. Теге рәхмәт уки, дыва кыла. Шында зур кызыл ут күренә. Абыстай сори: «Бу ни булды?» Теге ат′а: «Бу садакага биргән әпәйең сиңа килә торган бик зур бәлаңне кире кат′арды», – дир. Килә булган бәла, аны белгән келәнце.

***Карикмәк*** – арыш икмәге.

– Карикмәк салганда куас камыры калдыра, тагын әпәй сала ацытып.

***Үтмәк*** – икмәк.

– Мунцалалап бәләгән зур бәләм, йагасың. Салам йагып үтмәк саласың. Пицне себерәсең дә пумалалап, көрәккә куйып пицкә тыга. Алтышар үтмәк әwәләп куйа, пицкә тыга.

– Үтмәкне күрше сорап керсә күршегә дә бирә. Табагацына элеп үлци, циртек циртеп куйа. Күрше үтмәк пешергәц кертә, тагын табагацына элеп үлци. Үтмәк кадерле булган. *(Чүмбәли)*

***Питырац*** – кечкенә икмәк, аны хәергә бирү өчен пешергәннәр.

– Карикмәк салганда куwашн′аны кыра йакшы гына, питырац салам дий иде. Бер кецерәк питырацны куйалар келәнцегә бирергә. Хазер келәнце йук.

**Цергән картуш, былбыл**

– Бакцада цергән картуш, әни керәк белән кайыра. Цергән картушны былбыл дип ат′а идек, туңган картушны, күмәц итеп аши идек.

**Тозлаган каз**

– Лар була иде. Бер йагы оннықы, бер йагы игеннеке. Тозлаган казларны йаз башын ызба башыннан төшереп күмәләр иде шыл иген эценә.

***Казы*** – казылык. Аны ат итеннән тутыралар.

– Казы тутыралар. Бер сугым суйа, умбишәр-йегермешәр казы тутыра. Арт ботында ит күп. Аны бик йакшы кисеп алалар сүwәгенә хәтле. Тар-тар гына итеп тапилар, кисәләр. Ул кийашта пешә, майы эри. Йаз ката ашилар казыны. Казы шулбасы пешерә, берцак кисә дә шулбага сала. Шылай казы тутырып, ызба башына меңгереп эләләр иде. *(Ыргу)*

***Кеце сый*** – зур туйдан соң якын туганнарын гына чакырып үткәрелгән мәҗлес.

– Кеце сый кыз йагында да, йегет йагында да була.

***Мәҗлестә аш-су бирү тәртибе***

– Кодаларга элек цәй куйалар иде, аннан ары сың суб ашатабыз. Аннан сөтләшне ашаган, ит белән картуш. Казы кисәләр, кийар куйабыз.

– Туйда цәй, самавар, оло гына, самса, белен, ватырушкалар, бал. Цәй артыннан үрә лапша белән, итен дә үрә эценә салалар. Бутка, сетләш инде, тары сетләше китереп куйалар йомошак кына,

уртасында күзе була май белән. Сетләштән сун китереп куйалар кимак паднус белән, чигелдек белән. бер кимакны йегет белән кыз бүлеп кабалар. Кийәү йегетләр ул кимакка акца салалар. *(Чүмбәли)*

**«Бутка болгаган өчен» бүләк бирү**

– Кечкенә нәни кызларга «бутка болгаган өчен» йаулыклар бирә (Тат.Моклокасы).

## Сөйләп мәгълүматлар биргән тел осталары һәм йола белгечләре

***Мәдәнә:*** Насыйбуллина Халисә, Шийапова Зәйтүнә, Үмәрова Халисә, Галәветдинова Фәһимә, Таһирова Зәйнәп, Вилданова Зәкия, Юсипова Фаилә.

***Петрякс:*** Сабиров Сәяр, Галәветдинов Абдрахман, Зарипов Мансур, Зарипова Сафия, Бәдертдинова Рәшидә.

***Краснай:*** Әхтәмова Венера, Сәитов Харис, Сәлахова Сәлимә.

***Чүмбәли:*** Шийапов Абдулвәдүт, Нәҗметдинов Муса, Сәйҗанова Әделбану, Залялова Рахимә, Камалетдинова Кадрия, Бәдретдинова Надия, Якупова Хадичә, Абдуллина Зәйнәп, Ниязова Кадрия, Аймалов Мөнир, Аляутдинова Садәт, Пәйертдинова Сания.

***Сафаҗай:*** Камалетдинов Әнвәр, Камалетдинов Вафа.

***Зур Рбишча:*** Ситдикова Фәния, Ибраһимова Йамалия, Хөсәенова Әминә, Алимов Салих, Билалов Рәшит, Абдуллина Хава.

***Куй суы:*** Мирсийапова Зөбәйдә, Миначева Алимә, Мостафин Әнвәр.

***Семеновка:*** Арифҗанова Әминә, Сәлахетдинов Марат, Фәйзрахманова Равия, Әхмәтова Таирә.

***Камка:*** Саипова Нурия, Аблязова Мөшфирә, Сәфәрова Хәбирә, Мангушева Нәфисә, Курмаева Хәүлә.

***Тат. Моклокасы:*** Юнисов Хөсәен, Хөсәенова Зөһрә, Кукерова Галия, Насифуллина Зөлхия, Сәлахетдинова Сара, Хәйруллина Айшук, Юсипова Ахадия, Хөсәенова Мөршидә, Сәлимуллина Камилә.

***Бозлау:*** Бәдертдинова Нәймә, Усманова Мәрьям, Усманов Ибраһим, Үмәров Салих, Хәсәнов Фатих.

***Ыргу:*** Хәсәнова Маһинур, Азизова Маһинур, Салахова Зәйнәп, Идрисова Адия, Юсипова Марифә, Идрисова Мәхмүзә, Азизбаева ***Халисә, Атаджанова Нурия.***

***Яндавишча:*** Сәйфетдинова Надира, Ибраһимова Зәйнәп, Сәлахова Рафия, Хәсәнова Зәйтүнә, Сәлахова Рафия, Галләмова Мөнирә, Ибраһимова Флюра, Үмәрова Рәйсә.

# КАРДӘШЕМӘ ЯКЫН ИТЕП ДӘШӘМ

## *Туганлык атамалары үзенчәлекләре*

*Дария Рамазанова*

Барлык татар сөйләшләренең тасвирламасы тупланган «Татар халык сөйләшләре» (2 китапта, 2008 ел) дигән хезмәттән аңлашылганча, татар телендә 50 дән артык сөйләш бар. Алар көнбатышта Рязань өлкәсеннән башлап, көнчыгышта Кемеровога кадәр сузылган территориядә таралганнар. Ләкин әлеге сөйләшләр татар халкының таралуы нәтиҗәсендә түгел, бәлки татарларның тарихи ватанын төрле административ үзәкләргә бүлгәләү, өлкәләр һәм республикалар составында үзенчәлекле тарихи үсеш-үзгәреш кичерү аркасында формалашканнар.

Башка халыклар чолганышында (еш кына изоляцияләнү шартларында) көн итү, күршеләр белән тормыш тәҗрибәсе уртаклашу һ.б. факторларга бәйле рәвештә сөйләшләрдә берникадәр үзенчәлекләр барлыкка килгән. Аларда татар теле үсешенең борынгырак чорларына хас архаик күренешләр сакланып калган. Мәсәлән, пермь сөйләше борынгы болгар теленә хас үзенчәлекләрне, башка сөйләшләргә караганда, күбрәк саклап килә. Кавказ ареалындагы карачай-балкар, кумык, шулай ук чуваш телләре, татар теленең керәшен, нократ сөйләшләре белән аерым уртаклыгы булу пермь сөйләше турында шундый фикер әйтергә мөмкинлек бирә. Нократ сөйләше вәкилләренең бабалары монгол яуларыннан соң Идел буеннан төньяккарак күчеп утырырга мәҗбүр булганнар һәм татар теленең шул тарихи чорга хас авазлар системасын, грамматик фор-

маларны, диалекталь лексиканы хәзергә кадәр саклап киләләр. Кызганычка каршы, хәзерге чорга хас көчле глобальләшү шартларында аларга, касыйм татарлары кебек үк, руслашу яный.

Түбән Новгород өлкәсендә таралган сергач сөйләше дә – шундый ук уникаль, фән өчен бик әһәмиятле сөйләшләрнең берсе. Аның авазлар системасында да, сүзлек составында да башка сөйләшләрдән аерылып тора торган кызыклы күренешләр табыла. Мәсәлән, *у – ү, о – ө* авазларын борынгы төрки телгә хас вариантта да әйтү шундыйларның берсе: $^{у}$*орман* – урман, $^{у}$*орам* – урам; *к*$^{ү}$*өп* – күп, *к*$^{ү}$*өлмәк* һ.б. Мондый типтагы әйтелеш мишәрләрнең башка сөйләшләрендә инде сирәк очрый.

Түбән Новгород өлкәсендәге авылларда *и* авазының әйтелешендә дә борынгылык шактый тотрыклы. Билгеле булганча, безнең борынгы бабаларыбыз хәзерге *ә, и* авазлары урынына *иэ* авазы, *о, ө* урынына *у, ү, у – ү* урынына $^{у}$*о* – $^{ү}$*ө* әйтеп сөйләшкәннәр. Әлеге авазларны шулай үзара алыштырып сөйләү хәзерге татар сөйләшләрендә сирәк күзәтелә, аерым сүзләрдә генә сакланып калган, сергач сөйләшендә исә $^{и}$*эртә* – иртә, $^{и}$*эмән* – имән, $^{и}$*этек* – итек рәвешендә сөйләү әле дә актив. Бу исә бик борынгы, уникаль күренешләрнең берсе.

Шундый ук уникаль, тел тарихы күзлегеннән караганда гаҗәп әһәмиятле күренешләрнең берсе – *ц*-лаштыру. Бу да Көнчыгыш Европа территориясендәге телләрнең бик ерак заманнарга тоташа торган характерлы үзенчәлекләреннән берсе. *Ч*-лаштыру – *ц*-лаштыручы төркемнәргә бүлү, татар теленнән тыш, Кавказ ареалы телләрендә дә күзәтелә, 1303 елда төзелгән мәшһүр Коман сүзлегендә дә *ц*-лаштыру чагылган. Ә бу сүзлекнең мишәр диалектына бигрәк тә якын икәнлегенә В.В. Радлов, Л.Т. Мәхмүтова кебек танылган галимнәр күптән игътибар иткәннәр һәм зур-зур фәнни хезмәтләр язганнар. Рус галимнәре дә (мәсәлән, Л.П. Смолякова) *ц*-лаштыру күренешенең рус сөйләшләрендә дә таралган булуын язып чыктылар.

Кыскасы, татар теленең тарихы бик бай һәм кызыклы. Аның шундый оригиналь сөйләшләрен саклау бик мөһим.

Мишәр сөйләшләрен өйрәнү белән махсус шөгыльләнү барышында, сергач сөйләшенең туганлык атамалары системасында да

үзенчәлекле күренешләр, аерымлыклар булуына игътибар иткән идек. Биредә бу мәсьәлә белән бәйле берничә фактны яктыртып үтәргә уйлыйбыз.

Туганлык атамалары системасы халык тарихының бик борынгы чорында ук формалаша һәм, шуңа күрә дә, тарих өчен, тел тарихы өчен аеруча әһәмиятле лексик төркемне тәшкил итә. Тикшеренүләр күрсәтүенчә, аерым сөйләшләрдә шул төбәктәге кайчандыр йотылган этник төркемнәрдән кергән атамалар да табыла.

Сергач сөйләшендә төп мишәр сөйләшләреннән аермалы туганлык атамалары һәм кайбер атамаларның башкачарак мәгънә төсмерләре күзәтелә. Билгеле булганча, татар теленең Урал төбәге сөйләшләрендә *картата* (бабай), *картәни* (әби) атамалары кулланыла. Мишәр сөйләшләрендә дә бу атама бар, әмма ул башка мәгънәләрдә йөри: бабайның әтисе (темников сөйләшендә), әтисенең бертуган апасының ире (ләмбрә сөйләшендә), әнисенең беренче ире (хвалын сөйләшендә) һ.б. *Картәтий* сүзенең шушы ук мәгънәләре сергач сөйләшенә караган авылларда да очрый. Ләкин әлеге сөйләштә бу атаманың төп мәгънәсе Урал төбәге татар сөйләшләрендәгечә: бабай, әтисенең яки әнисенең әтисе.

Сергач сөйләшендә иренең энесен (каене) *йанагай* атамасы белдерә. Шулай итеп, әлеге сөйләш, янәшә территориядә таралган чүпрәле сөйләше белән берлектә, төп мишәр сөйләшләреннән аерыла һәм татар теленең борынгылыкны аеруча нык саклап килә торган керәшен, нократ һәм шулай ук минзәлә, тау ягы сөйләшләре төркеме, Оренбург өлкәсендә, Башкортстанда таралган сөйләшләр белән уртаклык күрсәтә.

Туганлык атамалары өлкәсендә сергач сөйләшенең тагын бер үзенчәлеген билгеләп үтәргә кирәк. Бу сөйләш мишәр диалектының *туган* сүзен *бертуган эне* мәгънәсендә куллана торган сөйләшләре төркеменә керә: ләмбрә, кузнецк, байкыбаш, алтата сөйләшләрендә *туган* – эне; стәрлетамак сөйләшендә *туган* сүзе I, II, III зат кушымчалары ала һәм үзеннән кече булган туганнарга яисә чит кешеләргә эндәшү сүзе буларак кулланыла (туганым, туганың, туганы). Чагыштыр: минзәлә сөйләшендә *апайым, апайың, апайы.*

Сергач сөйләшендә дә иренең кече туганнарына иркәләп, матур сүзләр белән эндәшү йоласы киң таралган. Бу эндәшү

сүзләре әлеге сөйләштә бигрәк тә *цәцәк* сүзенә нигезләнгән: *йаным цәцәк, гөлемцәцәк, гөлцәцәк* һ.б. Мишәр диалектының башка сөйләшләрендә бу очракта *абыстай, абыз, апа, астай, туташ* сүзләрен әйтү хас: *сүгәнем абыстай, абыз лачын, абыз туташ* һ.б.

Сергач сөйләше каенегә эндәшү сүзләренең составы белән дә аерылып тора. Башка мишәр сөйләшләрендә иренең энесенә зурлап, яратып *кеwәз абзикай, шәкерт абзий, абызагай, күркле морза* дип эндәшү гадәткә кергән булса, сергач сөйләшендә төп сүз ролендә *йанагай, йегет* (чагыштыр: себер диалектларында *егет* – бала, малай) сүзләре йөрүчән: *сылу дҗанагай, мулла дзанагай, севәр дҗанагай, яки кʸөркле йегет, сылу йегет, ак* (русча: благородный) *йегет* һ.б.

Сергач сөйләшенең үзенчәлеге итеп тагын *тутак* – әдәби телдә туташ – кыз кешегә мөрәҗәгать итү формасы, *татарым* – ирем сүзләрен дә күрсәтергә мөмкин, алар башка мишәр сөйләшләрендә күзәтелмиләр.

Чит тәэсирләргә тиз генә бирешми торган, борынгылыкны даими саклый торган туганлык атамалары системасында шушындый аерымлыклар булу сергач сөйләше вәкилләренең этник формалашуы тарихы катлаулы юл үткәнлеген күрсәтә. Керәшен, тау ягы һәм казан арты төркемнәре сөйләшләре белән уртаклык әлеге аерымлыклар барлыкка килүнең болгарлар тарихы белән бәйләнешле булуы турында фараз итәргә мөмкинлек бирә.

Кайбер аерымлыклар исә рус дәүләтенең чукындыру сәясәте алып баруы белән бәйле рәвештә барлыкка килергә мөмкин. Билгеле булганча, XVIII–XIX гасырларда Тамбов губернасында һәм Түбән Новгородта чукындыру гамәлләре башкарылган. Миссионерлар бик зур җитезлек белән керәшен телендәге әдәбият таратуга керешәләр, әмма, барыбызга да мәгълүм булганча, чукындыру кампаниясе туктатыла. Шулай да, сергач сөйләшендә чукындыру мәгънәсендә *ал'андыру/аләндерү* фигыле сакланып кала. Бу сүз керәшен сөйләшләрендә дә очрый.

Сергач сөйләшендәге үзенчәлекле сүзләр башка тематик төркемнәрдә дә табыла. Биредә без шуларның кайберләрен генә күрсәтеп үтәбез: *беде* – дөге, *целенце* – вак сәдәп, *целтер* – чулпы, *целдер(т)* – чәчкапның бер төре, *цәцә бармак* – чәнчә бар-

мак, *цәцәк тузаны* – серкә (үлән үсемлекләрдә), *цәпитек* – сукно кунычлы аяк киеме, *цәнтер айак* – яланаяк, *цәке* – хәтле, *сабак* – куныч, *цырцык* – сыерчык, *кыр эләге* – җир җиләге, *өргә* – өрәңге, *астан кигец* – эчке күлмәк, *умак* – ачыга пешерелгән вак кабартма, *турпин* – пәрәмәч, *титибаш* – аңгыра, *бөтү* – муенса һ.б.

Гомумән, ничә гасырлар буе башка халыклар чолганышында, төп татар халкыннан аерымланган хәлдә тормыш итүгә карамастан, нижгар мишәрләре үзләренең гореф-гадәтләрен, рухларын саклап гомер кичерәләр, диннәрен саклыйлар. Аларның гаять әһәмиятле һәм матур яңгырашлы туган телләре дә сакланып калсын иде.

Түбәндә сергач сөйләшеннән сөйләү үрнәкләре китерелә.

## Сергач сөйләше

**Авыл тарихы** турында. Безнен аwылга иске йортлардан йегерме сигез баба килгән: Сарука, Сурмали, Мәрҗәни, Курмай, Чынвәли. Аwылнын исеме дә шыннан энде Чембилей. Искеләр диләр, бабалар шуннан килгәннәр, аран[1], пайыт[2] тезегәннәр. Курмайдан дᵞөрт тармак киткән: Кантимер, Җәгфәр, Актимер, Биктимер. Иске йортлар йырак төгөл, тугыс киламитыр, каберләр бар анда. Варис бабай кабере бар, чардуганнары таштан. Чүмбәли бер меӊ алты йөз дүртенче йылда Искеләрдән килгән. Йакшы урын эзләгәннәр, булдыклы булганнар бабалар. Анын аты йугала да китә эзләп. Ике күлне күрә, ад'агыз, күценәбез, ди. Карт абиларыбыз зийәрәт кылырга баралар анда, минен бабакай үᵉлде инде, эз-дүᵉрт йыл үтте энде. Искелеккә[3] барып теләккә цыга тырган булганнар. Шаари Булгардан сибелгән калык без. Без бабаларыбызны булгар, дип йерибез. Монда керәшеннәр дә булган, аларны куганнар, безнекеләр цугынгысы келәмәгәннәр, бик каты карыша булганнар. Авыллары да Тәрбиле – тәре бирелде, Чүте –

---

[1] Аран – бураган абзар.
[2] Пайыт – лапас.
[3] Искелек – элек яшәгән җирләр.

чүт цугындырмаганнар, дигән сүз. Тоугзан йәшлек бабабыз әтә иде, Кызыл җарда керәшеннәр күбрәк булган. Питр'акста (ав. ис.) керәшен урамы булган.

*Сөйләүче: Шияпов Вәдүт Хуҗи улы*
*Сергач районы Чүмбәли авылы. 1988*

Йорт анасы бар диләр. Йорт анаңны китердең ол. Бер катын ат'а, мин китердем. Ницек? Ад'а киттег инде, ад'а калма инде. Бер тайак башына цәпе[1] бәләгән, пумала белән цакыра, ад′а инде, мин сине калдырмимын инде дийеп, кэтердем, дийер. Мин кэтердем йорт анасын, дийер.

**Күз тигәндә**. Маңгайга кыранташ сертәләр, кешенең күзе шынарга бәрелсен пирут. Элке бәләгәннәр, йылаwык була балага. Бәбәй анасына бал кертәләр иде, бишек кабыкныкы булган. Цәпе[2] китерәләр иде, бәбәй цәйенә йәшә идек. Кендек күлмәге китерәләр тугац кийә тырган. Имезек йасый идек, кайа да булса кэтсэк, тамак тугайтырга төгел инде, аwызы бош төгел, йыламый.

**Туйлар турында.** Элке әни-әтине тыңнаганнар, дөрт, биш кеше йөри башкода. Иң әвәл кызны килешергә киләләр иде, селге бирәләр инде берәр. Кецкенә күмәц белә дә йөрешәләр иде. Зур задатка биреп йибәрәләр, кан'н'ага зур селгеләр берәр тәңкә көмеш куйып өстенә. Зур задаткасыннан сун балын китерә көпме сүли, цәйен, шәкәрен. Зур задатка була, аннан күмәцли киләләр, нәсел-нәсәбе бар да килә, кыз цигелдәк (төш) ала, аннан кийәүне күрендерәләр, падарка бирәләр барысы да. Күмәцли барганда күрендерәләр кийәүне. Әвәле күмәцләр алып баралар иде, әл инде кем нәстә. Кыз үwенә пирут киләләр, анан икенце кенне йегет үwенә баралар, кыз бармый, кайда эшең тешкәндә генә бара. Әвәл кеце күмәц тә бар иде, пирвый кеше әз килә, зур күмәцкә кеше күбрәк килә.

Кыз артыннан сийлашу була. Нихактан ике кен узгац, каниш ийенә китерәләр. Тубал ашы китерә келәткә йебәргәндә: күмәц, киймак, күпермәләр. Нихакның артыннан бик зур той була.

[1] Цәпе – чүпрәк.
[2] Цәпе – биредә: бала искесе.

Карындашларың алдыра, бер он ызбага йериләр иде ашап, нихакнын иртәсен йәшешәләр.

Кызны тешерәләр арганнар белә. Кыз кукиш калфак кигән, шарыплар бәләгән, пар алашада килә, алыннарында кучыр. Мында тешәләр, каршы алуцы зеңәләр кетеп тыра. Кайнатаң йортына кергәндә бусагаларга күлмәкләр салып керәсең, кан'га, кан'н'ага күлмәк, ботка болгаганнарга күлмәк-йаулыклар. Йәш килен кергәц үк царшау кора, эстәкерләрен йаба, селгеләрен элә. Кадаклык цәй бар иде, әвәл йәш киленгә шыны башлаталар, гал'никлар дийә идек без, тәнә[1] касы тыра вед, цәйнек. Икенце кенне партык будыралар да акца салалар. Кой[2] туwары бирәләр, іоры айаклы дип таwык бирмиләр. Кыз атасы үwенә йери. Казны бездә бар'амда пешерәләр бездә күберәк, муллалар турый. Цигелдәкнең эценә тейәгәннәр цитлаwыкны да, сабынны да, кырым цитлаwыгы[3], wак цитлаwык[4], айбагар цитлаwыгы[5].

*Сөйләүче: Алимканова Зәйнәп (1904 нче елгы).*
*Сергач районы Чүмбәли авылы. 1988*

**Туганлык атамалары.** Без Казанга бардык кыдага. Йырлар да бар.

Сары сандал, сары цулка
Килешми безнең суртка.
Килешер иде безнең суртка,
Йуктыр ул безнең йортта.

Кыдага баргы кели, керәсең күрешкә, тыңнап тыр[6] кост'умыңны.

Безнең җизни тәтәйне үләнде, китте акца зийарга эшкә. Хатында йаза була:

---

[1] Тәнә – әнә.
[2] Кой – сарык.
[3] Кырым цитлаwыгы – әчтерхан чикләвеге.
[4] Wак цитлаwык – урман чикләвеге.
[5] Айбагар цитлаwыгы – эрбет чикләвеге.
[6] Тыңнап тыру – биреп тору.

Сары туфл'аларың кийеп
Вак-вак кына атлыйсың;
Син бит минем ыруза гелем,
Цәцәк кенә атмыйсың.

Кан'анасына кий[1] казыттылар. Аг ызбасы, карызбасы сәстрасының улына калды. Әле күрдем ийе үзен, йәшәйепсен дир, шылай ике җәйәгемне[2] тытып, маңлайымнан үпте, н'әмуй[3] кызы бар.

Безне әтиләребез эрексәт бирмәделәр. Без бармадык узгынча гына. Башкода йебәрелде күреш катны дзеңи, әткәйнен быратынын катны. Анан мәгәр сүләделәр, мәгәре бит аның акца. Сездә дәме шылай әтелә? Анда картлар үләндерә, аннары сың туй, нихак келәткә[4] йебәрәләр. Мәәрне түлә, түләмәсәң бирмиләр кызны. Пухоwой йаулык, пал'тә, беләзек, кылакка элә тырган кылагалка. Килне, ике нугы йанында, абзий, минән эз йәшке ылы, дывайуртний бырат, анын әнисе, минен әти туган ыланнары. Быратымнын катны бире киләдер, анын бер уолы бар. Буwысы туганым (сеңлем), кеце минән, әнинен туганының кызы. Иремнең тәтәсенең (апа) кызы калды, бар'ам бит, шының кырк киче иде.

Мәскәүдән кызым килә картуш эзәргә аwыз[5] азактамы. Ил'вира айтә, әнкәй, джума, путалакны[6] сырларга[7] кәрәк. Ике сира[8] сырлаган идем. Кайенем, иремнең быраты да килде сырлашырга. Быраты булгац иремнән кеце, олысын кан'ага әйтәбез. Абыстай дир миңа, әнинең тәтәсенә[9] тәт'ай ат'абез. Кайынсеңлемнең ыланнары, аның кан'игәценең ыланнары бу. Карындашларыбыз ызванит итте. Ийалцан ийем, йерәгемнен уртасы[10], зин[11] болма-

[1] Кий – кое.
[2] Җәйәк – яңак.
[3] Н'әмуй – телсез.
[4] Нихак келәт – зөфаф кичәсе өчен билгеләнгән урын, гадәттә келәт.
[5] Аwыз – август.
[6] Путалак – түшәм.
[7] Сырлау – буяу.
[8] Сира – мәртәбә.
[9] Тәтә – апа.
[10] Йерәгемнең уртасы – иркәләп эндәшү сүзе.
[11] Зин – зиһен.

ган, аwылда калдым. Кәләшем бала түрәми[1], таза әмән ирләр. Ике мал'унка ипи китерә, килә зәрә тамагыннан[2]. Килендәше белән дускынай атешәләр иде. Абыз тутай, алма тутай ат'асын олы кешеләргә, тутакай, абыз тутакай, олылыйсын энде. Минем әнекәй укытучы булган, анарга бөтен аwыл этә иде абыс тутай дип. Биг әwәле этешәләр иде тудыкалар, дусай дир, дуслар энде. Туган ланнары, үги ланнары көп болган ол тутамның. Тумацу туган дигән сүздер. Нугым[3] килде килен белән җан тартырга[4]. Сез килепсез, без үдә булмапбыз. Иремнен эз быраты үлде с$^{\text{ү}}$огышта, малайым, кызым Мәскәүдә, ыланнар да к$^{\text{ү}}$өп төгелбез. Иргә килгәндә кан'ым, кан'анам иде. Әwәлге картлар ат'кәннәр, ирсез катынның кене, ген'аглы кешенең гүре дип. Бер тәтәм тыра Мәскәүдә, әбети ат'амын мин анарга. Әни-этинең тәтәләре булса тутай була. К$^{\text{Ү}}$өп болсалар алма тутай, чәчәк тутай, абыз тутай ат'абыз. Бик өлкәннәргә – туташ, тутай йәшрәк кеше. Туган абий бертуган була. Әни-этинеке абийларын абзий/дәдәй ат'абыз. Йәшмәгән кунак – дзунмаган тайак. Без ике туган, мының әнийесе минем этийем бертуганнар.

Иргә кэлдем. Татарым (ирем) йакшы кеше иде, кан'сеңелләренә йаным цәцәк, гөлцәцәк, энесенә сеwәр җанагай эттем. Татарымнын ике туганынын кызына дә гөлцәцәк, аппак кыз, улына – сылу җанагай. Кан'амнын туганына[5] абыстуташ.

Тудыкай булса, йакын туганнар, дывайуртный булса да, тумаци – тырайуртныйлар буладыр. Картанайыбыз[6] бар иде, картәни, картатайлар да була вет, выт анайнын анасы, эткәйнен атасы. Әнекәйеннен иң олы тәтәсе абыз тәтәй, кецерәкләре икәү иде, Асма тәтәй, Айникамал тәтәй, этинекен тутакай дидек без, олырагы – абызтутакай. Үзеңнекеләргә алма тәтәй, эләк тәтәй, аларнын ыланнары миңә этәдер үземә берсе алма апа, берсе – эләк апа.

---

[1] Түрәми – тапмый.
[2] Зәрә тамагыннан – иртә таңнан.
[3] Нук – онык.
[4] Җан тарту – ял итү.
[5] Туган – сеңел.
[6] Картанай – этисенең беренче хатыны.

Патима апам абыстай, бун'ы тулы петү[1], ак күлмәк, аг алйапкыц йабынган ул. Күкрәк[2] эләләр иде көмеш түмәле, пелүш белән түгәрәкләтеп теккән, тәңкәләр уртасында. Артларында өцәр ойа алка, дөрт ойалы да була иде, өцәр ойалы да була. Зур ойалысын алканын цәцкә бәләп куйа иделәр, кецкенәсендә дә айлы кашлы, зурысында цәцәкләр[3] була иде. Кыстиңка ике рәт цәпегә йегермешәр тин тезгән була иде. Алка тәмам эшләгән, сабы белән бау кадап, хыт цәцеңә эл, кыт нишлә. Алканы да, кыстиңканы да үзебезнең авылда сугалар иде безнен. Целтер[4] цәцнең оцында була, мәдәкце[5] сата иде. Йандар тумада[6] тәңкә тезгән петүләр була иде, мәрд'ән петүләр. Кырук калпаклар, кукуш калпаклар булган әвәле, карсагырак[7] кыруклы бүрек, сай бүрек, алнысы цигешле. Әвәл тастар бәләп йериләр икән, ул нинди тастар булгандыр. Кецкенә, цәцәкле шәлләр, шакмаклылар бар иде. Кызыл астан бәләгецләр[8] бәлиләр иде, эц цитле[9] генә, кызыл булырга тийеш, фыранцузыскийны.

**Кием-салым, бизәнү әйберләре**. Үөремдә[10] линта, былай кырку[11] төгел, кызыл линта, малинни[12] линталар өреп саласың. Эшкә цыккан цакта цабата иде, кәркешләрен[13] куйабыз да ийокны тешертмәсен, кәркешләр к$^{Y}$өренмәсен дийеп. Әвәле инде урак белән генә уралар икән, касы цалгы цаба, касы ураг ура. Калфакны цумарцаклары була сәлендергән, йәмне. Йегетләр айытта багалар

---

[1] Петү – муенса.

[2] Күкрәк – изү (бизәнү әйбере).

[3] Цәцәк – бир\u0435дә чулпының челтәре урыны күздә тотыла.

[4] Целтер – чулпы.

[5] Мәдәкце – кырыктартмачы.

[6] Йандар тума – янтарь муенса.

[7] Карсак – биредә: сай.

[8] Астан бәләгец – яулык астыннан, чәч күренмәсен өчен киелә торган башлык.

[9] Цит – почмак, як.

[10] Үөрем – толым, үрем.

[11] Кырку – киселгән.

[12] Малинни – рус. малиновый.

[13] Кәркеш – киндерә.

ийе, айыт укыганда без йийылабыз, катыннар. Алар карап җериләр шунда, багып йериләр, йеңәсеме. Тәңкәләр безгә ләкмәде ул. Безнең әни сүли иде. Цәцкә кыстиңка артка, өрем белә өрәләр иде. Цәпегә[1] тәңкәләр тезгәннәр. Анын йанында ацкыцлары да була. Әбиләр киленнән кацырып бикләп куйалар. Тәңкәләр цәпегә тезгән, түшкә икән. Кемештән былаугалар (булавка) эләләр иде, сәлеңгеце дә була иде, ике кемеш була иде. Беләзекләр кийә иделәр кашлыларны, касы кийә әл дә. Сәдәпләр тезелеп, тәңкәләр әкерт кенә алалар икән дә батыррак киленнәр. Әвәл, бездән әвәл ызба булган, ишек башында тишек булган, төндөк. Әл дә безнен белгәндә ызба төндөкле иде, дөнҗа көреп тырмаганнар. Битләрне буйый идек, ай-ай куwаналар иде. Без бой кызларны күрә идек үскәндә, кершән йагыналар иде. Кырк йәшенә йеткәц үләнәләр икән йегетләр. Әни әтә иде, мине ад'ур арбага[2] утыртып төшерде атагыз мине, ат'ә иде. Партык дибез, запун ат'елә, баулы тегел, кигецле. Ул wахытта кигецле атәләр иде, алнына петү шикелле кызыл тасма тыткан, канатлы була. Бабайларнықы фарт'ук балта эшендә эшләгәндә, мишукнықыннан[3]. Безнен йак вед шундый тел белә сули. Йүкә башмагы үдә, тәрән[4], йаз башында[5] да кийәләр. Цабатанын асына су кермәстән калутка сугалар. Бай кызлары, йаза белмәгәннәр, безнен әнигә йериләр иде. Муллаларга биргәннәр, картлар алганнар аwаннап[6], кыз баргысы keләми, атасы бирә. Бик хыwат[7] иде бабайым, шәм шырагацы кебек. Мин татарыма[8] көреп килдем. Той белән, өцәр алаша, ул wахытта бит тырантас, ызбыруйлар, берне алынга йебәрәләр, кылакуллар белән, селгеләр бәләп алашаның дугасына. Зата киләләр иде унбишәр олау белән, бер оцы Мәдәнәдә (ав. ис.) иде минем тойымның, бер

---

[1] Цәпе – чүпрәк, тукыма.
[2] Ад'ур арба – арбаның бер төре.
[3] Мишук – биредә: киндер.
[4] Тәрән – тирән.
[5] Йаз башы – яз көне.
[6] Аwаннап – көчләп, ирексезләп.
[7] Хыwат – гайрәтле.
[8] Татарым – ирем.

башы Цүмбәлидә, ике цагырым. Йауцы, башкода диб әйтәләр, күп китергән иде, йакшы, сәленә тырган өрфәк, йакшы пал'толар, кылаг алка, кылаг элгец алка[1], элгец кадыйлар, анда бау гына. Сай бүрек кийәләр икән, безнен заманда тастымал дийәләр иде, анын эстенә йаулык, кецкенә инде тастымал, бер цит[2] кебек кенә. Ак йаулык бәлисен бумажныйны[3], йынныкын. Бар'амда ләште картларга, Мәскәүдән җүләп җибәрде бу тастымалны[4].

Сондокта искедән кийә тырганнарың, йаңыдан кийә тырганнарың. Сөлге бит себерә тырган, цашкалар себерергә дә бирәләр, кешеләр алндан йибәрәләр (табында) селге, аны китерәләр. Айагыңны күрсәтергә йарамый иде кан'ишка. Бер сира[5] йакшы тапычкалар кидем дә, кан'н'ам, бул'шы бу эшең, булмасын, дир. Айагыңны к[ү]өрмәсен ыштубы. Чаршау асында эцә идең цашканы әкерт кенә килеб аласың.

Тездән цолка бәлиләр, кызыл бойлы да яшел бойлы алача ыштаннар кийә идек. Батиңка[6] буладыр цергедән[7]. Ул wахытта итек, цергитек. Цергедән ул вахытта урдыкка[8] йабарга йасыйлар икән. Церге камыт астында да була. Күн итек булган, кайышныкылар[9] хырмовой итек була. Бәбецләр[10] ул wахытта сирәк булган. Күлмәкнен цабулары әвәле бит ызын була, йиләнне муллалар әвәл кигәннәр, хазер йуктыр чәй[11].

Сак пелүштән, катыннар кийә, җиңнәр белән, кесәләре дә бар, йагысын[12] үзеннән үк тешергән. Кара линта куйган йагага,

---

[1] Кылаг элгец алка – махсус чылбыр ярдәмендә муенга бәйләп куела торган зур алка.

[2] Цит – почмак, косынка.

[3] Бумажный – ситсы.

[4] Тастымал – ситсы яулык.

[5] Сира – мәртәбә, тапкыр.

[6] Батиңка – киезката.

[7] Церге – киез, цергитек – киез итек.

[8] Урдык – сәке.

[9] Кайыш – яхшы күн.

[11] Чәй ( < рус. чай) – ахрысы.

[12] Йагысын – якасын.

кушаклары да була, арка пр'амой. Озон йиңне бишмәт, тез титен[1], бөргән, арты сынны чапан атластан. Казан бәбецләр, башмаклар, күннән, сай. Бариткалар кийәләр мәскәүцеләр.

**Мәзәкләр**. Кийәүли бара икән. Кер инде, аш суwына дир. Кийәү әткән, йарар аш түгел, суwынми, ашлык төгел кийылми.

Кунак килде, кунак сүләр дигәннәр. Ниндине сүлим. Күргәннеме, ишкәннеме? Анда бер батыр булган. Канишны күргәнне, ишкәннән күргән артык, дигән.

Ацыдан ацы ни ацы, үлем ацысы. Катыдан каты ни каты, ат тийагы. Татлыдан татлы ни татлы, үләнмәгән йегет кызга үләнсә ул татлы диләр.

Ул бик башлы кеше диб әйтә, дир. Китерегез, дир, үгез бозау, үгезне суй күршеләргә бирәдер. Әти үдә йук, хамләсе бар, мунцага китте бала түрәргә[2]. Бу килә, кызны алып китә. Тора. Ике сукацы киләдер, ә ахмак, кыннаган алашанын сете бер, кыннамаганныкы йук. Патша кат'кац, әтәләр, әле дә катның булды, берберебезне үтерә идек. Патша әтә катынына, булмый, син тырмыйсын, теләгәнеңне алып кит, дир. Катын ашата, эцертә патшаны, алып китә. Берцәк[3] киткәц патша ан'ий[4]: «мин каа барам?» Син вет теләгән нәстәңе алып кит, диден. Wәт шылай йарлының да зихнесе[5] булган.

Кеше кас'агы тәмне,
Кеше катыны йәмне.

*Сөйләүче: Алимханова Зәйнәп (1904 елгы).*
*Кызыл Октябрь районы Чүмбәли авылы. 1988*

---

[1] Титен < тиңетен – хәтле.
[2] Түрәү – табу, тудыру.
[3] Берцәк – бераз.
[4] Аний – айный.
[5] Зихнесе – зиһенлесе.

# СҮЗГӘ СҮЗ ЯЛГАНЫР ХИКМӘТ БЕЛӘН

## *Җөмлә төзелешенә җирле сөйләш йогынтысы*

*Ләйсән Тукмачева*

Бүгенге көндә татар теленең үзенчәлекләре турында күп төрле хезмәтләр язылган. Шуңа карамастан, телне өйрәнү, аның байлыгын энә күзе аша үткәрү барыбер дәвам итә. Чөнки күп кенә мәсьәләләр әле дә хәл ителмәгән, фәндә актуаль проблемаларыбыз җитәрлек.

Теге яки бу телне, сөйләшне халыкның үзе белән аралашмыйча, ягъни читтән торып кына өйрәнеп булмавын күздә тотып, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре күп еллар дәвамында төрле районнарга экспедицияләргә йөриләр.

Чираттагы ун көнлек экспедиция Түбән Новгород өлкәсендә уздырылды. Без Пилнә, Сеченов, Кызыл Октябрь, Сергач, Спасс, Кнәген районнарының татар авылларында булдык. Һәр авылның үзенә генә хас үзенчәлеге бар, ләкин биредәге татар авылларын бер нәрсә берләштерә: анда кунакчыл һәм милли җанлы кешеләр яши. Якташлары турында «Мишәр дөньясы» газетасында шул як язучысы, журналист Әнвәр абый Камалетдинов болай дип яза: «Асылында мишәрләр тормышка гашыйк, батыр, горур һәм бик мөһим булган азатлыкның бәясен белүче халык».

Мишәрләр, мәгълүм булганча, Татарстанның Буа, Чүпрәле, Чистай, Алексеевск, Аксубай районнарында, Башкортстанның кайбер районнарында һәм Россиянең Түбән Новгород (элекке Горький), Пенза, Рязань, Тамбов, Ульяновск, Самара (элекке Куйбышев),

Саратов өлкәләрендә яшиләр. Аларның саны бер миллионга җитә. Алар Казан татарларыннан тел, кыяфәт ягыннан берникадәр аерылалар. Мишәрләрне кайбер эзләнүчеләр татарлашкан фин-угырдан дип тә әйткәннәр. Татар милләтенең шактый зур өлешен тәшкил иткән халыкның «мишәр» дигән атамасы кыпчаклар мөселман динен кабул иткән гасырда барлыкка килгәне билгеле.

Мишәр сөйләшләре ике типка – *ч*-лаштыручы һәм *ц*-лаштыручыга бүленә[1]. Икенче төркем нәкъ менә Түбән Новгород губернасыннан чыккан дип тә санала. Фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре ягыннан караганда, бу төбәктә яшәүче мишәрләрнең сөйләше шуны исбатлый.

Мәгълүм булганча, бу төбәктә көнбатыш диалектының сергач сөйләше киң таралган. Фәнни әдәбиятта әлеге сөйләш вәкилләре «нижгар мишәрләре» буларак мәгълүм.

Тел тарихы һәм тарихи диалектология мәсьәләләрен хәл итүдә җирле сөйләшләрнең синтаксисын өйрәнү зур роль уйный. Ләкин, кызганычка каршы, диалектларның үзенчәлекләрен тикшергәндә, синтаксик күренешләр еш кына игътибардан читтә кала бирә.

2008 елда басылып чыккан ике томлык «Татар халык сөйләшләре» хезмәтендә татар теленең урта, көнбатыш һәм көнчыгыш диалектлары сөйләшләренең фонетик, грамматик һәм өлешчә лексик үзенчәлекләре тасвирланган. Бу китапта көнбатыш диалектның сергач сөйләшенә аерым бүлек багышланган. Анда сөйләш фонетик, морфологик һәм лексик яктан тәфсилләп күрсәтелгән, ә синтаксик үзенчәлекләрдән бары тик *-мы/-ме* сорау кисәкчәсе турында гына мәгълүмат бирелгән[2].

Бүгенге көндә диалекталь синтаксис проблемаларын өйрәнүне җәелдерү татар диалектологиясе каршында төп бурычларның берсе булып санала[3]. Шуны күздә тотып, без «нижгар мишәрләре» сөйләшендәге кайбер синтаксик үзенчәлекләргә игътибар бирергә булдык.

---

[1] Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 8.

[2] Шунда ук. – Б. 184.

[3] *Рамазанова Д.Б.* О достижениях и задачах татарской диалектологии // Научный Татарстан. – 2000. – № 3. – Б. 83.

**Сүзтезмәләр.** Ияртүчесе фигыль булган сүзтезмәләрдә бер төркем фигыльләр, әдәби тел белән чагыштырганда башка килешне башкаралар: *Былдырны* (болдырдан) *менгән wакытта кийәү белән кыз култыклашкан булалар. Мында йегетләр, кызлар җийылалар бу ызбада* (ызбага – йортка). *Үлек ызбасындагы кешеләргә* (кешеләрне) *күршеләр сыйларга тийеш.*

**Хәбәр.** Исем хәбәрләр зат кушымчалары ала: *Бик тәртипле иде безнең ул wакытта йегетләребез дә, кызларыбыз да бик тәртиплеләр ие* (тәртипле иде). *Ирләр зийылган ызбага кемнәр куркымсызлар* (куркусыз), (шулар) *бара.*

**Гади җөмлә.** Мишәр диалектының башка сөйләшләрендәге кебек, сергач сөйләшендә җөмләдә инверсия күренеше, ягъни җөмлә кисәкләренең үзара бәйләнеш тәртибе иреклe булу хас. Төрле җөмлә кисәкләре инверсияләнә.

Ия инверсиясенә мисаллар: Б*ездә кунаклар йәшкән wакытта да умак пешерәбез без.* – Без кунаклар чакырган вакытта да умак пешерәбез. *Әле аларны белмиләр йәшләр.* – Яшьләр әле аларны белми. *Шының белән бик тиз табабыз без.* – Без шуңа күрә бик тиз табабыз.

Тәмамлык инверсиясенә мисаллар: *Быз күп китсә, быйыл кызлар күп китәләр кийәүгә.* – Боз күп китсә, быел кызлар кияүгә күп китә. *Зеңи ала инде ул акцаны.* – Ул акчаны җиңги ала иде. *Җир астында казыйбыз подвал.* – Җир астында подвал казыйбыз. *Урманга бардык күрешем белән, тийәдек урманны.* – Күршем белән урманга бардык, агачны төядек.

Хәл инверсиясенә мисаллар: *Кышкы wакытта бара идек таwларга.* – Кышын тауларга бара идек. *Үлене куйалар түндәккә күтәреп.* – Үлгән кешене урынга күтәреп куялар. *Калхузга пецәнгә бардык йәш вакытда.* – Яшь вакытта колхозга печәнгә бардык.

Аергычларның инверсияләнүе юк диярлек. Мишәр диалектының чистай сөйләшендәге кебек, сергач сөйләшендә дә иялек килешендәге исем яки алмашлыклар белән белдерелгән аергычларның инверсияләнү очраклары[1] бар: *Пример, бәрәмнәр шылай уза безнең.* – Мәсәлән, безнең бәйрәмнәр шулай уза.

[1] Татар халык сөйләшләре: Ике китапта: Икенче китап / Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова һ.б. – Казан: Мәгариф, 2008. – 235 б.

Югарыда китерелгән үрнәкләрдә хәбәр җөмләнең төрле урынында урнашкан. Хәбәрдән соң гына җөмләнең башка кисәкләре килә (ия, аергыч, тәмамлык, хәл). Кайбер мисалларда хәбәр составындагы фигыльләрнең генә урыннары алышына. Мәсәлән: *Арзамаска крахмалга йөрдек келәнергә* (теләнергә йөрдек). *Кыз белән йегетне китергәннәр күрешергә* (күрешергә китергәннәр). *Әле бу йегет тытынган ашарга* (ашарга тотынган). *Син тотынасың кацарга* (качарга тотынасың).

Җөмләдә сүзләрнең кире тәртибе Нижгар ягының барлык районнарына һәм авылларына хас. Өлкән яшьтәге кешеләрнең дә, яшьләрнең дә сөйләмендә хәбәр һәрвакыт алда килә. Әлеге сөйләш бу үзенчәлек белән әдәби телдән аерыла.

Гади җөмләләрдә тиңдәш кисәкләр еш очрый: *Үлекне күмеп килгәц, өстәлгә он куйалар, тоз куйалар.* – Үлгән кешене күмеп килгәч, өстәлгә он куялар, тоз куялар. *Туй өстәлендә әпәйме анда, суп, бутка, картуф.* – Туй өстәлендә ипи, аш, ботка, бәрәңгеме. *Без менә җийылышабыз: картлар, карцыклар, кардәшләр.* – Менә без җыелышабыз: картлар, карчыклар, туганнар. *Берәр калак шәкәр, берәр әцмуха цәй бирәләр.* – Берәр кашык шикәр, берәр әчмуха чәй бирәләр. *Зур көтү була иде: сыйырлар, куйлар, кәзәләр.* – Зур көтү була иде: сыерлар, сарыклар, кәҗәләр.

**Сорау җөмләләр** *-мы*/*-ме* кушымчасыннан башка, бары тик интонация ярдәмендә генә дә формалаша: *Шыны да белмисең* (белмисеңме)? *Бергә анда барасың* (барасыңмы)? *Сез үзегез тырмыштаалар* (тормыштамы)?

**Кушма җөмлә.** Мишәр диалектының башка сөйләшләреннән аермалы буларак, сергач сөйләшендә кушма җөмләләрнең аналитик төренә караганда, синтетик төре ешрак очрый.

Иярчен хәл җөмләләр: *Лугка салам цыктык тийәп, мин үзем генә калдым, майым.* – Болынга (саламны) төяп чыктык, мин үзем генә калдым, маем.

Иярчен вакыт җөмләләр: *Бызлар ташкан wакытта инде, бик зур су булганда, йегра идек багарга.* – Бозлар ташкан вакытта инде, бик күп су булганда, карарга йөгерә идек. *Йегет кыз үwенә килгәц, цәй эцәләр мында.* – Егет кыз өенә килгәч, монда чәй эчәләр. *Башкода кергәц, йомшак цепрәк куйып утырталар ийе.* – Башкода

кергәч, йомшак чүпрәк куеп, утырталар иде. *Без укып цыккаң, сикес йыллык булды.* – Без укып чыккач, сигез еллык булды.

Иярчен шарт җөмләләр: *Ул сине йаратса, йыр йырлый.* – Ул сине яратса, җыр җырлый. *Олан күзеккән булса, ишек бауларын йуwалар.* – Балага күз тигән булса, ишек бауларын юалар. *Уласа, күбрәк шикләнәләрдер.* – Уласа, күбрәк шикләнәләр. *Катык китерсә, катык белән ашаган ашны цумар дибез без.* – Катык китерсә, катык белән ашаган ашны без чумар дибез. *Баланың эце авыртса, җебетеп йабалар иде мунцаланы эценә.* – Баланың эче авыртса, эченә мунчаланы җебетеп ябалар иде.

Иярчен кире җөмләләр: *Элгәре йәш килен миннән бер йәшкә олы булса да, әүwәл анықын йуwабыз, аннары безнекен.* – Элек яшь килен миннән бер яшькә олы булса да, башта анықын юабыз, аннары безнекен. Н*ицек кенә эл еккеге гадәтләргә кайтырга теләсәләр дә, кийенү йулын, тәртип йулын үзгәртмичә булмый.* – Ничек кенә элекке гадәтләргә кайтырга теләсәләр дә, киенү ягын, тәртип ягын үзгәртмичә булмый.

Кушма җөмләләрдә шулай ук инверсия күренеше чагылыш таба: *Туй башлана, кыз төшкәч.* – Кыз төшкәч, туй башлана. *Балешне атәләр бездә ит белән картош куйсаң.* – Ит белән бәрәңге куйсаң, бездә бәлеш дип әйтәләр.

Шулай да мишәр сөйләшенә характерлы булган аналитик төзелешл е җөмләләр дә бар: Анда нәрсә белән ашатасың, кем белсен (гади җөмләләре үзара мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнгән аналитик иярченле тәмамлык җөмлә). *Нәрсә кәрәк, шыны пешерәм* (гади җөмләләре үзара мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнгән аналитик иярченле тәмамлык җөмлә). *Кайчан сугыш уже бетә башлады, шыл wакытта калхузга килә башлады он* (гади җөмләләре үзара мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнгән аналитик иярченле вакыт җөмлә). *Кемнең исемен кыцкырды, ул мәцене тотарга тийеш* (гади җөмләләре үзара мөнәсәбәтле сүзләр ярдәмендә бәйләнгән аналитик иярченле ия җөмлә).

Сөйләмгә аерым җөмләләре үзара санау интонациясе аша бәйләнгән тезмә кушма җөмләләр дә хас: *Без йәшлегебезне сагынып ерлауларыбыз бар, йәшлегебезне сагынып бийүебез бар.* – Безнең яшьлегебезне сагынырлык җырларыбыз бар,

яшьлегебезне сагынырлык биюебез бар. *Бетен нацийәнең дә кыңгыраты бар: йапон бар, немец бар, китай бар, әрмән бар, грузин бар.* – Бөтен милләтнең дә кушаматы бар: япон бар, кытай бар, әрмән бар, грузин бар. *Күрешләр пешерә, туганнар пешерешә.* – Күршеләр пешерешә, туганнар пешерешә. *Малайым да йакшы, килнем дә йакшы, нукларым да йакшы.* – Малаем да яхшы, киленем дә яхшы, оныкларым да яхшы. *Бичеркага кемдер ике бәрәңге илтә, кемдер шының хәтле ит илтә, кемдер икмәк илтә, кемдер шәкәр илтә.* – Вечеркага кемдер ике бәрәңге илтә, кемдер шуның хәтле икмәк илтә, кемдер шикәр илтә.

Сөйләштә модаль кисәкләр, ягъни сөйләүченең чынбарлыкка, тыңлаучыга, җөмлә эчтәлегенә, төзелешенә мөнәсәбәтен белдерә торган кисәкләр бик актив кулланыла. Арада бик үзенчәлекле сүзләр очрый, шуңа күрә аларга аерым тукталып китәсе килә.

Җирле халык белән аралашкан вакытта диалог төп сөйләм стиле булып тора. Шуңа күрә сөйләүченең тыңлаучыга яки гомумән табигать күренешләренә мөрәҗәгатен, мөнәсәбәтен белдерә торган эндәш сүзләр[1] игътибарыбызны җәлеп итте. Нижгар мишәрләренең ачык йөзле, киң күңелле, күркәм гадәтле булулары да аларның бер-берсенә эндәшкәндә кулланыла торган сүзләрендә чагылыш таба. Шулай төрле районнарда һәм авылларда туган-тумачаларга, дусларга, хәтта таныш булмаган кешеләргә карата әйтелә торган *маем, алмай, анай, брат* (хатын-кызларга карата да) сүзләрен күрсәтергә була. *Май* сүзе Ходайга (Аллага) мөрәҗәгать иткәндә дә кулланыла. Эндәш сүзләргә мисаллар: *Без башакка йөрдек, тирмән* (тегермән) *тарттык, майым. Минем Асийә май цабата кигән. Алла май дидем дә, цыгып киттем. Майларым, мин бик аwырлык күрдем. Алийә алмай белеп ала да, белгәнен укырга тора. Күз тигәндә хатеме* (догасы) *бар иде, анайым. Менә шул, анайларым. Әллә ниндиләре бар инде, брат, искә төшми бит.*

Билгеле булганча, кереш сүзләр сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, төзелешенә һәм сөйләм обстановкасына мөнәсәбәтен белдерәләр[2].

[1] *Зәкиев М.З.* Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек / М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 113.

[2] Шунда ук. – Б. 114.

Сергач сөйләшенә рус сүзләрен файдалану хас. Рус теленнән кергән модаль сүзләр белән бирелгән кереш сүзләр еш очрый: *Вот пример, минем абзыйым үләнде. Ул бәрә дә, например, штандыр дип кыцкыра. Шындый тәкем* (шуның хәтле) *көрәк, сабы озын, идән йуwа торган тайак кебек микән, да.*

Сөйләштә татар теленең модаль сүзләре очрамый диярлек. Шул ук вакытта татар һәм рус сүзләрен берләштереп әйтү дә бар. *Вот шылай* кереш сүзе шундыйлардан. Ул җөмлә башында да, ахырында да килә ала: *Вот шылай, каждый кызлар утыралар. Аннан шикләнмисең инде, мацы керде инде, вот шылай.* Кайбер авылларда *менә вот шылай* кереш сүзе очрый: *Менә вот шылай, л'убой йортта йорт анасы бар диләр.*

Бу сөйләштә кереш сүзләр төрле сүз төркемнәре белән бирелә: алмашлыклар *(ни, шулай),* рәвешләр *(исән-сау),* фигыльләр *(әйтим инде, беләсеңме; бак, ягъни кара)* белән. Мәсәлән: *Тимәсә, ни, кире киләләр. Исән-сау, ул күмәцне үзебез пешерә идек. Без инде, атим инде, бетенесен эшкәртеп нитеп готовийны. Ул бит йырлый йырлый гына искә төшә, бак, нинди йыр!*

Сөйләштә кереш җөмләләр дә күзәтелә: *Кушылып ерлаганбыздыр инде, ни атим инде. Третий лишме* (лишний) *уный идек, беләсеңме аны.*

Гомумән алганда, сергач сөйләшендә кулланыла торган эндәш һәм кереш сүзләр халыкның сөйләм телен баета, аңа үзенчәлекле төсмер өсти һәм мишәр диалектының кайбер башка сөйләшләреннән аерылып торуын күрсәтә.

Йомгак ясап, шуны әйтергә була: сергач сөйләшендәге синтаксик үзенчәлекләр көнбатыш диалектның башка сөйләшләренә охшаган. Шулай да сүзтезмәләр ясалышында, гади һәм кушма җөмлә төзелешендә үзенчәлекле яклар да бар.

Авылдагы өлкән яшьтәге кешеләр әйтүенчә, күп кенә яшьләр Мәскәүгә китеп урнаша һәм шуңа күрә русча гына сөйләшә. Шулар йогынтысында һәм якын-тирәдә күпләп урнашкан рус халыклары тәэсирендә сөйләштә рус сүзләре күпләп кулланыла. Бу бигрәк тә грамматик үзенчәлекләрдә, модаль сүзләрне куллануда чагылыш таба.

## Җирле халыктан язып алынган материаллар

### *Рухи мәдәният*
### *(гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, йолалар)*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Каз өмәсендә гармуннар иде. Каз өмәсендә йырлап-йырлап йолкалар иде, бииләр иде, йырлыйлар иде. Мунцада йылкалар, тышта йуалар. Бәлешен пешерәләр, аш пешерәләр. Өстәлен кырасың бит, майым, пироглар, бәлеш, бер каз асасың.

Рузә байраме бар иде. Халык бездә рузә белән котлап бар да халеннән килгәнцә азерләнә, калдырмаска тырыша. Элек тә шылай. Бездә халык коммунист заманда да ураза тытты. Йәшертен тыттылыр, бик кысынкы wакытта да тыттылар. Укыган wакытта безнең уразаларыбызны ацтыралар иде, совет заманында. Зийан дийәләр иде. Даже фел'дшерыбыз килеп дарулар эцереп китә иде.

Аннан корбан байраме. Халык корбаннар суйып, кунаклар йәшеп, үткәрә иде. Традицийалар элеккецә. Примерно мин үзем дә үдәрдән килдем бүген. Үзем башкардым. Мәйетне үзем башкардым, йудым.

Безнең бит заманда торпа суга идек. Вота сыйырның мусоры була бит, туарларның навозы, аны йандыралар иде пицтә. Безнең оланнарның эше шул иде, уйнарга wакыт йук иде. Торпа сугалар иде. Аны айландыралар иде, картук бутыйлар иде. Зур көтү була иде: сыйырлар, куйлар, кәзәләр. Шында саклап торалар иде, куып кертәләр иде. Көтүцегә ике-өц йомырка цыгарасың. Первый көнне көтүцегә бирәсең. Чулпан бабай рухына, дип дога күтәрәсең (ул әwәлге гөнаһсыз бер карт булган). Ул туарларның патшасы була инде. Аның рухына катем укытасың.

Йаңгыр алласына дуwасын укыйлар. Каберләр өстенә менгәц, дуwалар укыйлар. Күке кыцкырса, шул йортта (берәү) үлә диләр. Без ырымнамадык, майым.

Җомга көнне айет көне әбәрендә. Муллалар катем укып йөриләр. Кругом ул wакытта туылган сөлгеләр бар иде, туылган сөлгеләрне барсын да ыштаннарны крепкий итеп ясыйлар. Эцкырлы ыштан, вот шылай. Җомга көнне кереп, катем укып йөргән муллалар. Ызбаларны җыештырып, муллаларны көтеп тыра

идек. Муллалар хәр ызбага керәләр ийе. Байрәм көн шикелле. Без катлама пешерә идек, картуш йаккан табак күмәч. Менә камыр басасың, аны җәйәсең, пичтә пешерәсең бер кат. Аннары соң картушны төйәсең, йомырка сытасың, сөт саласың, шул җәймәгә шул картушны йагып тагын да пешерәсең. Кып-кызыл була. Җәймәнең өстендә картуш кала.

**Пилнә районы Чүмбәли авылы.** Сабантуйга алашалар җигеп бара идек. Питрякска бара идек. Алашалар куйыштыра иде. Сатулар бара, колгага менәләр иде. Кем йакшы менеп төшкәнгә – нәрсәдер бирелә иде.

Сулар аккан вакытта гармуннар белән ирләр, кызлар су алырга төшәләр иде. Март айларында багарга бара идек. Йегетләр кызларны багалар. Быз күп китсә, быйыл кызлар күп китәләр кийәүгә. Терәлеп-терәлеп китсә, кызлар әз китә.

Корбан байрәменә умаклар пешерә идек. Цәйләр куйып, урам беткәнцә йөри идек. Толпом-толпом йөри идек. Анда йырлау йук, нитү йук.

**Сергач районы Камка авылы.** Каз йолки идек. Бу инде ийәсе пешерә иде. Казлар суйа иде. Без инде, атим инде, бетенесен эшкәртеп нитеп готовийны. Кайсы кызлар йәшә иде. Үдә утырта иде. Шурпа пешерәләр иде. Бәлеш пешерәләр иде. Умак пешерәләр иде.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Йаз көне паска бар. Балалар йомырка йыйалар. Корбанга куй суйалар. Мөгезле булсын, ранлары булмасын. Мәҗлес кыралар. Күрешләрне чакыралар. Итне кисәкләргә бөлеп ләшәсең: йәтимнәргә, ирсез хатыннарга.

## *Туйлар*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Бездә башка аwылларга бакканда, барәмнәр, туйлар, ницектер йәмле, тәртипле була. Халык бездә усал тегел, йәрдәмчел. Башкода килү булды, ул килә дә инде утыра шылай. «Без сезнең кызны йаратабыз, аны безгә бирегез», – дип атәләр. Берсәк йылап та ала идек инде. Кызга атәләр: «Ул йегет сиңа тиң тегел». Башкода кергәц, йомшак цепрәк куйып утырталар иде. Аның кырыйына чашка, кашык, саwыт китерәләр. Ул ызбада бит инде чаршау эләләр иде, өстәлгә кләйенка.

Туганнар арасында да бар. Вот пример, минем абзыйым үләнде, сем´йаланды. Мин аңарга «зеңи» аттем, абзыйның хатынына. Ә ул миңа «тансык абыстай» дийә иде. Иренең туганнарына «кунак абыстай» атә иде. Вот примерно шылай. Иренең братына «сүәр агай» дийә булганнар. Без «әни» атә идек, «әти» атә идек, ә минем оланнарым «әннә, эттә» атәләр, ә нукларым минем үземне кызык интерес китте әле. «Кызым, майым, аппагым» атә идем. «Кызым, майым» – нугыма, ә ул миңа «әннә майым» атә, «әннә май». Ә күбесе «карт әни, карт әти». Бездә килен килеп төшкәч, каннә (каенана) сладкий цәй каптыра, былдырдан. Былдырны менгән wакытта кийәү белән кыз култыклашкан булалар. Артта монда туй килә, халык керә. Каннә кеше цыгып, монда бу йактан каршы алып, бисмилла атеп, пирут малайына каптыра, аннан киленгә каптыра цәйне. «Бәхетле булыгыз» дип атә. Тыштан ук былдыр эстенә цәпәй җәйелә. Цәй каптыргач, үгә кертәләр. Өстәле кырган була. Туй башлана, кыз төшкәч.

Кийәү бирә мәхәр, ул мәхәр акчасына родител'ларга зуррак әйберләр алалар. Вот пример, безнең заманада цигә идек без, селге кырыйлары цигә идек, кул'йаулыклар цигә идек. Йуклык иде, үзебез эшли идек. Кагыздан эленге тегә идек. Ызбаларда туңа идек.

Туй ашына элек пешерәләр иде, атәләр иде йомшак дийеп, камырдан йасыйлар әпәй, шылай йомшак кына, ул әпәйне кисәкләп кисәләр дә, шундый табакка төйиләр, табак белән китереп өстәлгә куйалар. Без оланнар, кецкенәләр тезелешеп утырган була идек. Вут шул әпәй белән туйда шулбасын да, цәен дә. Цәй йанына лимун турау бар иде. Цәйне йомшак белән эцәләр иде. Элек кодагыйлар китерәләр иде күмәц. Минем исемдә әле әни минем туйга китсә, үзе пешерә иде күмәц. Теце камырныкы ул, эстенә йомырка сертә, сеткә баса. Бик йахшы күтәрелә иде. Аннар соң аны инде йәмне генә пешкәц, күмәц итә иде.

Кыз белән егетне китергәннәр күрешергә. Первай өстәлгә кимак куйалар. Кийәү дә кереп утыра инде арага. Ашамаска тиеш була икән. Кийәүне китерәләр иде кызны күрергә, элек китергәннәр. Кызны күрергә кергинцә, аның кулында подаркасы да бар икән. Бу йегетләр белән өстәл артына кереп утра. Бу өстәлгә куйылган

кимак. Йегетләр шул кимакларны кабалар. Кийәү тиеш акца цыгарырга. Әле бу йегет тытынган ашарга. Кимакны ашый гына дийер, ашый гына дийер. Әле бер кеше бусагадан кергән дә кийәүгә ымлый дийер: «Анда бар кыз янына, нәрсә анда ашап торасың?». Йегет күрсәтә диер: «Кимак бар бит». «Әй, кимак ашап торасың» – дигән дә, өстәл аша сузылган да, кийәүнең гурласыннан эләктереп, ызбадан алып та цыккан.

Тубал ашын нихак көнне китерәләр. Аны инде кыз йагындагылар кабакка ийылышып торалар. Тубални тиз генә эләктерәләр дә, паэтка кереп тә китәләр. Шунда ашыйлар. Аннан соң эцемлек тә була. Тубалга цәпе цорнаган. Эцендә садакасы да бар.

Балага кабыктан бишек йасыйлар иде. Йүкә кабыгыннан. Аны айырым кешеләр йасыйлар. Баланың баш кийеменә мәрзән куйалар иде. Анарга «йылан башы» дийәләр иде. Йәмне сәдәпме шунда. Йәмне сәдәпләр бар иде бит элек тә. Ниндидер цветнуйлар була бит инде.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Кызларны ырлыйлар иде. Минем туйым булмады. Башкода йебәрәләр, йат кешене. Анда мәһәр сүли. Кызлы кешегә ир кеше килә, башкода. Анда кергәцтен йастыгын алып, астына куйа. Шуннан соң инде тотына, шул кешегә синең кызыңны алырга келибез дийе. Ну анда бирәсеңме, бирмисеңме, бирергә риза булса, килешәләр. Мәһәр диләр инде шул, урыста әйтелә калым дийеп. Туйны уздырырга. Кызның анасына, атасына акца бирергә кыз өцен. Туйның расхотын сорыйлар кийәүдән. Шәкәр күпме кирәк, цәй күпме кирәк. Берәр калак шәкәр, берәр эцмуха цәй бирәләр. Анда шылай бирәләр иде. Күлмәк бирәләр иде, подарка нәстә булса.

Туй өстәлендә эпәйме анда, суп, бутка, картуф. Ну самогонка диләр инде, аракы. Йегет кыз үwенә килгәц, цәй эцәләр мында. Алар бер-берсен күрмицә торалар. Даже кем икәнен дә белмицә, безгә кадәр заманда. Атлар белән булган әwәл, атлар джигәләр. Урам буенца баралар, мәцет кырыйына баралар. Теге инде атларның, «нар'аженый» диләр. Сөлгеләр эләләр.

Туйда кардәшләр, күрешләр була. Кардәшләр күбрәк була. Ынукларны биргәндә, мин хакын сүләдем – унбиш-егерме мең. Әле бит шылай сүлиләр.

Башкода килеп килешәләр. Мәһәр сүлиләр, кызны килешеп киткәч инде. Кийәү күрендерәләр. Вот шылай цигелдәк китерәләр иде. Йәш килен кара күлмәк кийә иде. Башында калфак кидерәләр иде. Минем Асийа май цабата кигән.

**Кызыл Октябрь районы Яндавишча авылы.** Исем кушканда мулла килә. Оланны йастыкка куйалар. Уф, уф дип өрәләр, колагына кыцкыралар. Ну вот, йәшәсең бәбәй цәйенә. Ул инде сиңа или илле тәңкә акца китереп бирә, или бәбәйгә иске цәпләр, күтенә цорнарга. Акца бирәләр инде, бәбәй цәйенә килдек диләр. Цәй эцерәләр, балын куйалар, әпәй куйалар. Күз тимәсенгә маңгайына төртәләр зеленка белән. Цамбыр белән төтәштерәләр күзексә. Шындый үлән бар, цамбыр. Ут йебәрәләр дә төтене цыга, оланга иснәтәләр. «Ак күз, күк күз, шунда түз», – диләр. Ныгы куwыралар. Вот шындый көрәк алалар, агац көрәк, лопата, күргәнең бар? Шындый тәкем (шуның хәтле) көрәк, сабы озын, идән йуwа торган тайак кебек микән, да.

Шында оланны бәлиләр, пицкә тыгалар да, да. «Нишлисең, әби?» -«Ныгы куырам». Тагын бер кат тыга шында баланы. Да, да. Агац көрәккә бәлиләр. Аны тиз генә пицкә тыгалар, син керәсең дә тиз генә атәсең: «Нәрсә куwырасың, әби?» – «Ныгы куwырам. Өц кат тыгып аласың, сырхау төшеп кала.

Малайларны йәш оланнарны пецәләр инде. Әwәл йөриләр иде. Абдалцы кацып йөри иде, чөнки ул доктор тегел.

Кендек әбисе кендек кисә инде. Кемнең хале ницек, майым, кем йаулык бирә, касы садакасын бирә. Менә олан тугац, айакларын җыйа. Пицкә көрәгенә куйасың: «Ни куwырам?». «Ныгы куwырам», – диләр. Агац көрәккә бәлиләр дә, оланны пицкә тыгып алалар иде.

**Сергач районы Камка авылы.** Җиде көн йөриләр иде. Пирут йөрешәләр инде. Башкода килә, сүз салалар, килешеп китәләр. Аның арты тойга көн куйалар. Аннан нихакка киләләр, да. Икенце көнне зеңи кеше инде мунца йага. Мунцаның тәрәз төбенә кийәү белән кыз акца сала. Зеңи ала инде ул акцаны. Вот, икенце көнне кызны кийәү ызбасына төшерәләр. Тубал итәләр. Аның эченә пирок куйалар. Каршы алалар. Шуннан анда була той. Икенце көнне кеце сый була кыз үwендә. Аннан йегет үwендә. Аннан

кодалар йәшәләр. Аның оцы кырый йук. Бер ай кыз анасы ызбасына кайтып тора. Йәш килен су ташый инде. Ул кайнанасына чаршаулар элә, кыргыцлар элә, тәрәз цәпеләре. Подарка итеп күлмәк китерә иде йәш килен. Кайнага бер сөлге, кайнатага бер сөлге. Кем ызбасында бар, килен кеше бөтенесенә дә подарка бирә.

Мени мине пирут килештеләр, аннан бер атнадан соң акца китерәләр иде. Аннан туй көнен куйалар иде, аннан туй эшләнә иде. Мени бездә бирнә йөз тәңкә иде. Килен төшергәндә метла белән себерәләр иде. Аннан мендәргә бастыралар иде. Киленгә кайнә бал белән май каптыра. Килен цәпеләр китерә иде, ызба эцендәгеләргә бирәләр иде. Кийәүгә падаркалар бирәләр иде. Кемнең ницек халеннән килә. Безнең wакытта мени ак күлмәкләр йук иде. Кемнең нәрсәсе бар.

Пирут ат кушалар, аның арты кунак йәшәләр. Бәбәйне китерә, өстәлгә куйа. Карт-коры акца куйа йастыкка.

### *Кеше күмү йоласы*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Үлгән кешене йәмне килеш күтәреп алып китәләр туганнары, дуслары. И монда, ызбарда да, мәетне чыгарып куйалар шыл ченазага. Шында ченаза намазы укыйлар вот, аннан инде садака эләшәләр. Аннан цыгарып урамга куйып, анда ченаза намазы укыйлар. Выт шылай итеп аны күтәреп алып китәләр каберләр өстенә. Каберләр өстендә инде минем барганым йук, белмим нәстә, анда тешерәләр инде каберенә күмәләр, күмгәннән соң садака эләшә торганнардыр инде. Выт шылай.

Эц кице бар, биш кице бар, йеде кице бар. Эц кицне, биш кицне алай бик зурламыйлар, биш алты кеше йәшеп кенә хатем укыталар. Йеде кицне бик зурлыйлар, күп кеше йәшәләр: дусларын, туганнарын да. Анда да садака эләшәләр. Аннан сон кырык кицен уздыралар. Кырык кицтән соң илле бер кицен уздыралар. Бер йыл үткәц зурлап уздыралар. Бездә инде күбрәк гарабодай буткасы була. Гарабодай буткасы пешерергә дә йеңел. Бер киц кунса, берни дә булмый, бузылмый.

Кеше үлә, элекке формаца, йаткыралар. Аwылда ирләрне ирләр тезәтә, хатыннарны хатын-кыз тезәтә. Мәйетне йаткырып

куйалар, и укып торабыз, дисбеләр тартабыз. Алладан аның гөнахларын йарлыкауны сорыйбыз. Менәджәтләр укыйбыз, күләп укыйбыз. Илаһи теләп бирсен, сынап бирмәсен. Бездә кор′ан белән амәл кылабыз. Вот примерно, бездә элеккеге бабайларның гореф-гадәтләре белән. Күреш авылларда, вот примерно Питрякста булсын, анда ырым белән. Анда ырымлы халык. Анда чуашлар күп. Анда, пример, ырымнар күп. Мин атәм андый ырымнар белән шикләнеп торгынца сез иманны өрәнегез.

Үлек цыккац, ашамыйлар бездә. Үлек эстендә дә ашамыйлар, үлек үwендә. Күрешләр йәшәләр. Менә шылай күрешләрдә ашыйлар. Йеде кицендә кырк кицендә куй суйалар. Кырк киценнән суң илле бер кицен уздыралар, анда да кеше күп йәшмиләр.

Үлекне күмеп килгәц, өстәлгә он куйалар, тоз куйалар. Хатем ашына пируклар разный пешерәләр, умак, күптермә куйалар. Өстәл йанына чыгаралар да куйалар. Нәстә генә куймыйлар. Алай ук күп йарамый да. Үзе инде пешерәлми, күрешләр пешерә, туганнар пешерешә. Калган ашларны кунакларга эләшәләр, бүләләр. Үлгәнгә аш суйалар, үлгән кеше рухына.

**Пилнә районы Чүмбәли авылы.** Без менә җийылышабыз: картлар да, карчыклар, кардәшләр. Йасин укыйбыз: бер укыйбыз, ике укыйбыз. Үлекне йундыргац, дуwа кылалар. Аңа йасиннарны багышлыйлар. Аннан төнәтәләр, йасин укып утыралар. Өчендә ирләр җыйыла, бишендә – әбиләр. Кырыгында да әбиләр, бабайлар. Илле бер көнен дә үткәрәбез. Үлекнең тәненнән иттән сүwәге куба.

Өчесенә кадәр үдә ашарга йарамый. Үлек ызбасындагы кешеләргә күршеләр сыйларга тийеш. Үлекне алып киткән көнне кемдер йәшә, аннан тагын берәр кем, кицен тагын да. Өц киценә бер куй суйыла. Халеннән килгән кеше өц киценә дә суйа, җиде киценә дә суйа. Ул бик саwап, үлек өстендә кан цыгару диләр.

**Сергач районы Камка авылы.** Үлене куйалар урындык күтәреп урындыкка. Без йылыйбыз гына, тәсбик тарталар. Мулла йуwындыра, катынны – катын. Бик аwыр көннәр була, анайларым. Җидесен үткәрәләр. Илле бер көнен үткәрәбез. Гүрдә куйган көне бик аwыр көне була икән. Кеше кемне җисаң да була. Без этийемә куй суйдык.

### *Уеннар*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Аннан инде үсеп киләбез. Кызлар утыралар вечеркада, йегетләр утыралар. Имештер мыселләрен беләләр. Аның өчен римен алалар. Вот имештер синең целбәйең йыгылган. Ул сине йаратса, йыр йырлый. Шул римен белән бәрәләр.

Бер әбинең ызбасына кереп, тәрәзләрне кырып, шәмнәр йандырып, шылай бик каты тәртипле утыра идек. Бик тәртипле иде безнең ул вакытта йегетләребез дә, кызларыбыз да бик тәртиплеләр ийе. Алар безне әлеге кулдан да тытмадылар, әлеге нишләмәделәр дә. Рәхмәт үзләренә безнең тиңнәргә, рәхмәт үзләренә. Шындый хәлләр.

Күңел ацу иде инде ул. Кылупка безне әти-әниләр йебәрмәделәр. Без кылупка йөрмәдек. Бичеркага кемдер ике бәрәңге илтә, кемдер шының хәтле ит илтә, кемдер икмәк илтә, кемдер шәкәр илтә. Шылай йыйналабыз да, цәй эцеп утыра идек, сүләшеп йегетләр белән, йәшләр белән.

Йырлар инде элеккеге «Сарман» иде, «Рамай» иде. Иске урам йырларын йырладык. Анда әти-әниләр безнең анда киткәнне белмиләр иде. Бичерка гул'ат итәсең. Безне йегетләр йанына йебәрмәделәр. Кемдер жалауа бирсә, вот кызың шул йегет белән сүләште, дисәләр, безне курлыйлар иде. Әни дә курлый иде, әти дә курлый иде. Йебәрмәделәр, үз теләгәннәренә, үз теләгән йегетләренә бирделәр.

Цийырта уйни идек без үскән wакытта, аны уйни идек, умали уйни идек. Умали уйни идек балцыктан йасап, кулларыбыз йарылып бетә. Ул биш ыштук йасыйсың да, цуэп-цуэп уйнисың, оланнар утырып. Ару балцыктан үзебез әвәли идек, түгәрәкләр йасый идек. Биш ыштук. Аның төрле-төрле спосуплары бар. Ницек аңлатыйм соң мин сиңа? Иң беренце берәрне куйып аласың, аннан икешәрне куйып аласың, аннан эчәрне куйып аласың, ике йакка. Цүэп-цүэп аласың аннары. Йәш wакытта без шыларны уйни идек, әле аларны белмиләр йәшләр.

Мәц тидереш уйни идек. Бездә бит мәц диләр. Вот без йәшлегебезне сагынып сүләрлегебез бар, без йәшлегебезне сагынып йырлауларыбыз бар, йәшлегебезне сагынып бийүwебез

бар. «Әпипә» бии идек, рускины бии идек, бийегән wакытта. Мәктәптә укыган wакытта «Шәл бәйлимен»не бии идек.

Бызлар ташкан wакытта инде, бик зур су булганда, йегра идек багарга. Бызлар таша, бызлар таша. Шул гына.

Безнен цакта атәләр иде бичерка дийеп. Тотынышып төшә идек пол'анага. Кызларның дус йегетләре була. Йәшмәгән кеше йөрми. Кызлар күп йийыла.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Кыла сугыш уный идек. Шар уный идек. Шар дийәләр иде, түгәрәк шындый. Тукмар белән шыны суга идек. Шар казанышлары йасый идек.

Йиде йәшемдә йәтим калдым. Кецкенә цакта шылай йәтим калып үстек. Укырга булмады, әни йук, әти фронтта. Урам уртасында калдык, алай да алабута ашыйдек. Беләсеңме алабутаны. Картук терергә картук. Всиравно үзебезне тоттык, майым. Вичерлар кора идек, көлә идек, уный идек. Бийергә йөри идек йырларга йөри идек. Третий лишни уный идек, беләсеңме аны? Аннан шундый клеткалар йасый идек, шуннан сикереп уный идек. Аннан күзне бәләп уный идек. Әллә ниндиләре бар инде, брат, искә төшми бит. Җийылышып урамга цыгып нитә идек. Әүwәл, майым, нәрсә бәләм ташый идек. Кырдан ырлап саламга цыга идек. Кырга бара идек, тыцкан үwе йасый иде. (Цыкма, Ибрай, әлдә кәрәк син!) Аның үwенә башаклар ташый иде тыцканнар. Без барып айак белән баса идек. Йымшак была иде. Аннан чиста башаклар цыга иде. Аны мишукка төйи иде. Шындый азапландык сугыш wакытында, аннан соң да инде. Үсә төшкәч тә.

Урамга кайа булса шылай малай белән сүләшергә бара идек. Ласкутларны беләсеңме ласкутны? Аңардан йупка йүнәтә идек. Аны краскага мана идек: берсе яшел, берсе күк, берсе кара иде, берсе кызыл иде. Йаңгыр яуса, бөтен краскаларыбыз йөзебезгә төшә иде. Какуй анда ни кап-кара була иде. Әнә күзегезне сылыйсыз бит. Анда нәстә, майым, шылай сүләшә идек тә китә идек. Каца идек, боларны күргәц.

**Пилнә районы Чүмбәли авылы.** Түгәрәккә утыралар, байкалга утырып суга батыралар иде. Тойларда, ниләрдә бер кешене цыгаралар иде уртага, аннан соң аны «Байкал күле»нә батыралар иде. Җырлап-җырлап батыралар иде. Аннан кемдер тартып

цыгара аны, аның урынына үзе керә. Тартып цыгаргац. «Байкал күле» өстенә батырабыз, аны балык ашасын. Шындый җырлар җырлана, аны кемдер булса белә торгандыр, да. Ни, аны инде полностью батыралар, и арада бер кеше аны инде йахшы җыр белән сүгән йегетеме или анда кызымы тартып чыгара. Син бит минем йакын дустым дип тартып ала. Тартып алгац, моны батыралар. Вот шуның белән шылай дәwам итә. Туйгач, уйын бетә.

Элегрәк аулак өйләр дә булган, менә, җыйыла торган булганнар шылай аулак өйләргә кызлар күбрәк. Малайлар килгән шында. Уйыннар уйныйлар нитә. Бер кыз белән бер йегетне чоланга җибәрәләр. Аннан үзгәләре чыга. Җырлар җырлыйлар, уйыннар уйныйлар.

М'ач белән бәреп нитә идек, менә җыйыласың, кемдер булса бәрә. Шылай уйныйлар иде. Штандыр атала иде. Ул бәрә дә, например, «штандыр» дип кыцкыра. Бар да сибелә. Кемнең исемен кыцкырды, ул мәцен тотарга тиеш. Ул мәцне ала кулына и круг тирәли баса, туктала инде. Стоп дип әйтәләр, и аны бер йакынрагы сайлый да, бу шул мәце белән өч шаг атлый шул мәце белән тидерергә тиеш. Тимәсә, ни кире киләләр, да.

**Сергач районы Кучкай Пожары авылы.** Вот сем'йадан кемдер кунакка китә. Алар китәләр кунакка. Мында йегетләр, кызлар җийылалар бу ызбада. Урнаш аталадыр. Урнаш ашыйбыз. Ул урнаш инде алардан башка отделный аш пешерәләр. Кем нәрсә китерде, вот дийер, берәр чогыр дийер. Касы йарма китерер, касы нәрсә. Вот уйлыйлар да, аш пешерәләр. Тегеләр как будто кунакта ашыйлар, болар мында. Катык китерсә, катык белән ашаган ашны «цумар» дибез без.

Без җийылышып, шул ызбада пәтәнә уйни идек. Күзләрне йаулык белән бәлисең, үзең тотынасың эзләргә. Тегеләре каца, да. Тоткац инде аныкын бәлисең. Син тотынасың кацарга, бу инде ызбада.

**Кызыл Октябрь районы Рбишча авылы.** Айак сикереш, ике кыз шылай утыра. Айак башына бармакларны куйа. Килеп берсе сикерә, батыррагы. Аннан уйни идек кулйалык салыш. Басалар кызлар, берсе кулйалыгын тотып йөри йөри дә, сизми дә кала, берсенең кулына сала, вот шылай. Аннан күпер күпер уйни идек. Алышасың шылай. Вые шылай уйни идек.

Уйыннар, ни, кышкы wакытта бара идек тауларга. Салазкалар белән бара идек. Кызык. Урамда гармуннар уйныйлар иде. Әле бит ул йук. Кызлар йәшәләр иде йегетләрне. Вичерлар иде инде. Кушылып йырлаганбыздыр инде, ни атим инде. Ниндидер уйыннар уйныйлар иде. «Бармак салышлы» уйныйлар иде.

**Сергач районы Камка авылы.** Кызлар утыра идек без менә үдә. Цыра белән утыра идек. Йегетләр белән бергә. «Римен сугышлы» уни идек. Тышка цыгаралар инде имеш.

Без ашык уни идек. Йорт эцендә дә. «Түмә салыш» уни идек. Җирне казый идек. Уй казый идек. Шында түмәләр салабыз. Шобак (шобага) тота идек. Кемгә пирут бәрергә цыга. Синә ницә цыга, да.

**Кызыл Октябрь районы Татар Моклокасы авылы.** «Качыш» уни идек инде. «Гөр гөр» атә идек. Аты аның «гөр гөр». Берәү күзләрен бали дә, без каца идек. Утыра да идек, такмак атә идек бер беребезгә.

«Түмә» уйный идек. Түмә кецерәк шындый, сәдәп, шыны базга сала идек. Аны ун тийенлек акца белән бәрә идек. Отсаң – сиңа, отмасаң – үңгә уйынцыга. Менә шул, анайларым. Калганы истә түгел инде, анай.

Тагын соң нәрсә? «Сакцы» уйни идек. Бер йегет белән басасың. Бу бер йакка йогыра, теге бер йакка йогыра. Кем йетешми, нишләгәннәрдер инде.

### *Солдатка озату*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Йегетне солдатка ызатканда үдән арты белән цыгаралар иде. Элек кецкенә күмәцләр салалар иде. Шул күмәцне тешләтеп, теш эзен калдыртып, китүце кеше үзе йота иде. Ә калганы монда калып, аны саклыйлар иде, ул катып килгенцә. Ул күмәцне үзебез пешерә ийек. Вот пример, минем малайымны ызаткан wакытында. Мин башканы белмим.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Армийәгә киткәндә, тәмәке саwыты теге кисет диләр, кулйаулык бүләк иткәннәр. Вичер утыралар иде, кем бер кисәк әпәй китерә, кем нәрсә. Солдат озату вичеры.

### *Аш-су*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Бездә кунаклар йәшкән wакытта да умак пешерәбез без. Камырдан менә шындый кецерәк кенә плюшкилар пешерәләр. Плюшки өстенә песок сибәләр, ә монда просто шылай пешерелә. Табаларга куйып пешерәләр. Балешне атәләр бездә только ит белән картош куйсаң, или ит белән йарма.

Вот, кунакларга барганда төрле мәзәкләр була торгандыр. Аны бит уйлап табарга кәрәк. Нәк? Була торгандыр, бездә күберәк рус телендә.

Умакның эцендә бер ни йук, түгәрәк кенә ул, ну бик йахшы камыр була, и шундый түгәрәкләр, пирожкилар йасыйлар.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Нәрсә кәрәк, шыны пешерәм: пәрәмәц, өцпоцмак, умак, катлама. Ул шылай тесто йасыйсың да, әнә шылай круг йасыйсың, тестоны изәсең.

Салма эшлиләр иде, «игәрче» икенче исеме. Игәрче салма диләр. Бар нәрсә дә бар, шөкер Кодайга.

**Кызыл Октябрь районы Пашат авылы.** Преженчә пешерәләр иде. Милцәдә тарттырган он. Шылай пешерәләр иде. Әни бер савыт картуш пешерә иде. Картуш кәкәше эшли идек.

**Сергач районы Камка авылы.** Камыр басасың, пилмән камыры. Бөкмә йасыйсың. Береп эшләгән йәмле бөкмә була иде.

Шул кунак йәшәләр иде. Шул туй килә. Кийәү белән кыз акца калдыралар. Кибеш суwына көмеш акца салалар иде. Мунцадан соң кимак пешерәләр. Эремцектән кәкәш пешерәләр. Эремцеккә майын саласың, йомыркаңны сытасың. Түгәрәк кенә кәкәшләр йасыйсың. Шул ватрушка инде ул.

Өстәлгә кәптер куйалар. Таба күмәц ул. Сөткә камыр басалар. Шының калынлыгы була, начинкасы да кирәкми.

### *Җир-су (төрле ышанулар)*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Йаңгыр теләүгә цыгуны «истискага цыгабыз» диләр ийе. Истиска намазы укыйлар ийе, белмим ницек. Минем әни белән барганым бар. Безнең тау башында анда иске каберлек бар. Ул каберлекләр инде бик күптәнге каберлекләр. Шул каберлекка менәләр иде. Бийыл да

йаңгыр йаумица торды. Бийыл да бардылар. Мәцеттән картлар бардылар. Шыннан соң гына йаңгыр йауды. Анда Илахидан сорыйлар инде. Без кецкенәләр идек, атәләр иде безгә әниләр: «Йылап-йылап сорагыз, – дийеп, – Илахидан бир, – дийеп, – ацлыкта калдырма». Без куркып-куркып йылый идек.

Ходайга ышанмастай, хәлгә төшсә, ызбага аждахы төшә. Ул ут шикелле булып төшә ызбага. Кемне сагына, шуның кыяфәтендә төшә, имеш. Без белмибез инде, безгә эләкмәде. Атәләр иде керде дип. Ирләр зийылган ызбага, кемнәр куркымсызлар бара. Ызбада атканнар – мылтык тавышы цыгарганнар. Йергәме атканнар, күккәме атканнар.

Шылай сүләгәннәр иде. Фатыматтайның ире үлгән. Ире үлгәц, бик уйлаган. Аннан ире күзенә күренә башлаган. Бу хатын кецкенә бүлмәгә йаткан. Монда ишетелә тавышы, шыпыр-шыпыр сүләшәләр. Кемгәдер сүли. Ибрахим иде аның аты. «Абрам» дийә иде ул аны. «Абрам шул тенлә килә», – ди. «Нишләргә соң?» – дийә. Вот шындый хәл булган, имеш. Болар бик элеккеләр.

Муцалакурик кийаш байыгац йөри булган, көндезен күренми ул. Төнлә генә, кийаш байыгац.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Йорт анасы тора кайwakытта. Ул ницектер звук цыгара, улыймы анда. Уласа, күбрәк шикләнәләрдер. Цәцләрне ул бутый. Кемне ул сүми, аның цәцен бутап бетерә. Тоз куйып китәсең, йорт анасына өстәлгә.

**Пилнә районы Чүмбәли авылы:** Йорт аналары ниләр алар инде бездә менә инде бар. Без ышанабыз да. Кайчан-кайчан йорт анасы сүми диләр. Алашларны сүсә, йалларын үрә икән. Сүгән туwарларын йорт анасы үреп тора икән. Ул кешегә күренеп тормый.

**Кызыл Октябрь районы Пашат авылы.** Пашатта атәләр иде мырмыр бар, дийеп. Бер хатын кеше чыга нигә әле охотага. Бер мужик инде аны тотмак кели. Әле үгә керә, тәрәзәләрне йаба. Бу инде мырмыр үгә кереп кала. Ул бит хайван да тегел, кеше дә тегел. Морзәдән цыгып киткәндә бармагы кысылып кала. Икенце көнне кем собранйага килмәгән. «Нәк килмәгән?» – диләр. Мицкә менеп йаткан, шул колдун булган.

Элек адәмнәрне бозганнар. Ул бозыкны бер-берсенә передавать ителгән имеш. Берәү ызба йанында тора, дийер. Берәү үтеп бара, дийер. «Йә инде нәрсә соң сиңа кирәк? – дийер. – Ашаган, эцкән, тамагың тук, йөрмә инде, кешеләрне куркытып», – дийер. «Йахшы сүз белән атәм, – дийер, – начар сүз белән айтмим», – дийер. «Серавно бер-ике мәртәбә әйләнде ызба кругымны», – дийер. Бу Ләлләр (кеше исеме) йанында булган хәл. Мәүлет бабай: «Төнлә тешләрем сызлый, – дийер, – йоклый алмыйм, – дийер. – Азбарга тчыктым да, – дийер. – Йаныма мырмыр килде», – дийер. Әле син дә килдеңмени дидем дә, – дийер, – ишек терәүгец белән бәрдем, – дийер. «Ә-ә, Мәүлет, запомню», – дип әйтте», – дийер.

Озын цәцле хатын-кыз кыйәфәтендә су ийәсе булган, да, да. Йорт анасы хайваннарның йалларын үрә иде.

**Сергач районы Камка авылы.** Берсендә мунцага кердем. Бактым, уголда баскан тора иде. Үзе баскан. Тцыкты, ишек тә ацылмады. Кешегә ошаган, борыны да. «Алла май», – дидем дә, тцыгып киттем. Белмимен ницек цыкканымны да. Шуннан үзем генә кергәнем дә йук мунцага.

Йорт хуҗалары бар, анай. Хуҗа Бахаветдин электән элек килгән. Сыйырың бугаз була, саклап йөрисең, сыйырың бозауламый. Көтәсең, көтәсең, бер цыкмаган көнең була. Шында йорт хуҗасы кычкырып уйата. Безнең күргәнебез йук аларны, анай.

Мунцада мәләвен була. Бисмилла атеп керегә кирәк. Бисмилла атеп цыгарга кирәк. Бер әби йаңгыз гына керә мунцага, ире нәк кермәгәндер инде – белмим. Пәпи Али алмай була бу. Бу йаңгыз гына була. Мәләвен сеңлесе булып керә. «Нишлисең анда?» – дип сорый. «Нишлим – кулым авырта, цәцемне дә үрә алмыйм», – ди. Теге шайтан керә дә, үрәсе итә. Алийә алмай белеп ала да, белгәнен укырга тора. Ут булды да, йук була теге шайтан.

## *Йорт салу*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Йорт салганда бисмилла атеп тытыналар халык. Ишкәк эшлиләр, аннан йорт беткәц, нәзер хайваннар суйып, корбаннарга куйалар, суйып нәзер эстәлләр кыралар. Йорт хуҗаларына бар да по возможности подаркалар

белән килә. Элек бар иде, майым. Йорт йуwарга күрешләрне, туганнарны җыйалар. Мин мында килгәндә йәш килен булып вот, алдымда да, йанымда да киленнәргә булыша идек. Әлеге йәш килен миннән бер йәшкә олы булса да, әүwәл аныкын йуwабыз, аннары безнекен. Ике йак күрешебезнекен дә йуабыз. Бер көнне беребезнекен, икенце көнне икенцебезнекен йуwабыз, вот. Шылай итеп ызбалар йуwышып, йырлап-йырлап йуа идек, майым. Әле алай йук.

Мацы кертү бар. Мацы кертеп йебәргән идек без йаңа ызбага кергәндә. Аннан инде әйберләр ташыла. Иске-төцкыларны кертмиләр инде. Матца астына дуwалар куйып калдырдык. Ызбага кергәц, аш суйалар, шул куй суйалар инде.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Ызба котлыйлар. Хозяин керсә, үлә диләр, мацы кертәләр – мацы үлә диләр. Аннан шикләнмисең инде, мацы керде инде. Вот шылай.

**Пилнә районы Чүмбәли авылы.** Бер ызбадан икенце ызбага күцкәндә туфрагын алып күцәләр. Иң беренце ызбага, әwәл заманда, йаңа ызбага бер ике кой кертеп калдыралар. Ул йортта хайваннар булсын өцен.

### *Тормыш-көнкүреш*

**Пилнә районы Сафаҗай авылы.** Ул вакытта бердән сугыш иде, икенцедән бик засуха булды ул вакытта бездә. Игеннәр урырлык тегел иде, тебе белән сугып йейдылар, вот. Аннан йаңгыр йаумады, картош та шиңде. Бердән ацлык, икенцедән засуха, шыңардан булды сугыш вакыты. Калхузда, ул вакытта мин эшләдем калхуз кантурында, калхузнын бетен складтагы игеннәрен барысын да сугышка ызатып бетерделәр. Анда халыкка булмады, кайчан сугыш уже бетә башлады, шыл вакытта калхузга килә башлады он. Тоннами иген килә иде. Аннан безгә атәләр иде, без – кантор работникларына, давайте список тезегез, ызбада ницә кеше бар, кеше исәбенә. Без список тезебиз дә инде анда онның количествосын алып бүләләр. Дүртәр киломы, бишәр киломы, шылай он бирә башладылар, шыннан соң халык ацка үлүдән туктады. Бу конце войны була иде инде. Выт шындый хәлләр.

Мин бигерәк бәхетле. Малайым да йакшы, килнем дә йакшы, нукларым да йахшы. Икесе дә йаш. Икесе дә йегетләр инде. Берсе йегерме дүрттә, берсе йегерме алтынцыда инде. Үләндерергә кирәк аларны. Әле торалар да китәләр урамга. Бушка йөремәгез мәтәм, үләнергә кирәк.

**Сеченов районы Краснай авылы.** Киттем кырык өценце елны фронтка, вот. Фронттан соң кырык дүртенце йылның соңында кайттым аннан. Аннан тотындым учетчик тракторной бригады эшләргә.

Мин булдым Кривой Рогта, Хар'ковта. Иң элек илттеләр Казанга. Вот, ийун' айында сорок первыйда Украинага Харьковка кадәр. Анда киттек поход белән пешком. Кривой Рогта бойга кердем. Анда беренце ранение булды. Аннан госпиталь, аннан тагын строй. Кременчукка эләктем. Аннан Белорусийә, Румынийәгә җиттек. Кырык дүртенце йылда инде бу. Колхозда сикзән бишенче йылга кадәр эшләдем.

Йылга аша цыкканда бик немецкий самолетлар бомбит иттеләр. Безнең самолет немецларны куwа, алар безне куwа. Мурталар кебек. Безнең железный бочкалардан тектек. Аннан рәттән немецкий взводта булдык. Анда противогазлар, спецодеждалар күп иде. Постларда тора идек, саклап тора идек.

Минем этийем генә иде. Повестка килгәч, күрештем дә киттем. Вот киттем абзый йанына. Турыдан-туры киттем Уразовкага. Киттем Сергачка. Тауwарный вагонга утырттылар инде безне, вот шылай. Мине Себер йагына озаттылар.

Бара идек шындый ниләргә, анда л'убой кину була, кылуб була иде. Үдә берсәк эти-эниләр курлыйлар да. Йәш wакытта берсәк йөрисең дә, аннан салам белән мунцалар йага идек. Кырдан салам китерәбез, иртә белән мунца йагабыз. Анда кызыклы малайлар бар, без уналты-унҗиде йәшендәгеләр, без дә шылай, алар да шылай. Мунца йаккан wакытта алар безнең берсәк wакытны, эцтә анда тәрәз бар, салам белән йаккан мунца. Әли зеңи безгә кызыклы хәлләр сөйли, без шыны тыңлап торабыз. Сәләмә күлмәкләребезне алганнар да малайлар, кызык итеп инде. Әле берцәк торгац йуныргa цыктык инде, тишендек инде. Бер казанда су йылына бер тамцы, шуның белән дә йунып торабыз

инде. Кайа соң барырга – заман бит шындый. Әле тәрәзәдән «На рубашка, на штана», – дийәргә тотындылар малайлар. Аннан бирәләр инде. Цыккац орыш йук инде, әле йәшләр орышалар. Ул wакытта безнең орыш йук. Шышылай гына сүләштек тә. Аннан бер малайның шындый бер кисәк әпәйе булган. Тамагыбыз да ац бит инде. Кыр буйында йөрибез тыцкан ойалары ашап. Шул әпәйне безгә бүлеп бирә шул малайыбыз.

Сугышка минем ирем китте дүрт йылга. «Үгә кайтым дигән wакытта сугыш башланды», – ди. Әле алар биш йыл сугышта булалар. «Даже күн итекләренең төпләрен ашадылар солдатлар», – ди. «Йуклык бит», – дийер. «Бетенесе үлеп бетте», – дийер. «Түлке мин тере калдым», – дийер. «Башкирийәдән берәү бар иде», – дийер. «Халык ашап беткәц, миңа берсәк норма бирә иде, – дийер. – Шуннан исән калдым мин», – дийер. Әле аннан инде мескенкәйем килә. Мин инде әле аннан кецкенә кыз калган идем, буй кыз булыпмын. Мин звеноводка булып эшли идем. Кешеләрне эшләтәм. Мин эшлимен сетмой поледа, калхуз бүленгән иде. Безнең бригатта йегерме кыз иде. Ул wакытта олан салу йук, таба да таба тап кына. Анда нәрсә белән ашатасың, кем белсен. Минем үземнеке дә алты. Әле бер мужчинадан салам суктырам, аркама асып киләм. Ике кеше басканнар. Аркама астым да капчыкны, киттем кырга. Кызларга атәм: «Солдатлар кайткан, берегезгә була». Алар атә: «Берсе сиңа». Миңа йурап куйдылар. Элеккеләр истә калган шул инде. Ирем белән безнең урамыбыз бер. Әле кырга баралар алар. Солдатларның берсе атә: «Цалгына кем алып цыкты бу йорттан?»

Мин кантурга кереп киттем, болар мине көтеп торалар. Нә соң болар мине көтеп торалар? «Урамга цыгасызмы?» – ди. Мәтәм: «Цыгабыз». «Синең белән сүләшергә можномы?» Мин атәм: «Пожалуста». «Мин сине күрүгә тәнем кайнарланып китте», – дийер. Алтмыш йыл тордык татарым белән, вот.

**Мәгълүмат бирүчеләр исемлеге**

***Кнәген районы Ыргу авылы:*** Идрисова Мәхмүдә, 1926 елгы; Мөлекова Рабига, 1937 елгы; Шамсунова Хәмдия, 1956 елгы.

***Кызыл Октябрь районы Рбишча авылы:*** Абдрахманова Афия, 1926 елгы; Насыйбуллин Хәйрулла, 1922 елгы.

***Кызыл Октябрь районы Пашат авылы:*** Алиәкбәрова Гүзәл, 1976 елгы; Алиәкбәрова Хәлимә, 1930 елгы; Сәйфетдинова Бибинур, 1930 елгы.

***Кызыл Октябрь районы Яндавишча авылы:*** Җиһаншина Мәрзия, 1946 елгы; Шакирова Алия, 1928 елгы.

***Кызыл Октябрь районы Татар Моклокасы авылы:*** Айзатуллина Наилә, 1921 елгы; Закирова Әминә, 1927 елгы; Нивнанова Рауза, 1940 елгы.

***Пилнә районы Сафаҗай авылы:*** Баһаутдинова Сара, 1931 елгы; Галәветдинова Фәһимә, 1925 елгы; Иматова Фатыйма, 1946 елгы; Таһирова Зәйнәп, 1924 елгы.

***Пилнә районы Чүмбәли авылы:*** Аляутдинова Равиля, 1947 елгы; Бигичева Назыймә, 1918 елгы.

***Сергач районы Камка авылы:*** Абдуллова Наилә, 1952 елгы; Мангусова Мәгрифә, 1929 елгы; Салкина Мөхлисә, 1928 елгы.

***Сергач районы Кучкай Пожары авылы:*** Усманова Равилә, 1929 елгы; Юнисова Фәридә, 1928 елгы.

***Сеченов районы Краснай авылы:*** Әбүлханов Ибраһим, 1925 елгы; Әбүлханова Сания, 1928 елгы; Җәләева Әминә, 1925 елгы.

***Спас районы Бозлау авылы:*** Ганиева Наимә, 1936 елгы; Исхакова Рәшидә, 1937 елгы; Салихҗанов Зиннур, 1932 елгы; Салихҗанов Рамил, 1950 елгы.

## МОҢ ЧИШМӘЛӘРЕ ТИРӘННӘН ЧЫГА

### *Түбән Новгород мөнәҗәтләре*

*Айсылу Башкурова-Садыйкова*

1996 елның матур җәе. Мәүлет аенда мин туган авылым Камкада ялда идем. Һәр өйдә мәүлет укыталар. Ачык тәрәзәләрдән Коръән укыган авазлар ишетелә, мәүлет мөнәҗәтләре яңгырый.

«Мәүлет» мөнәҗәте – атаклы төрек шагыйре Сөләйман Чәләби (XV гасыр) әсәре. Ул татар халкында күптән яратып укыла, бигрәк тә мәүлет аенда еш башкарыла.

Мин бу әсәрне бик тәэсирләнеп, кабат-кабат тыңлаганнан соң, күршебез Зәйнәп апа Мәхмүтовага кердем һәм мөнәҗәт әйтүен үтендем. Әби 1912 елда туган, ул кышын шәһәргә китә, җәйләрен авылга кайтып үзенең тыйнак кына өендә яши. Өе бик күркәм, аны зәп-зәңгәр тәрәзә яңаклары бизәп тора. Әби үзе дә бик мөлаем. Ул авыр тормыш юлы үткән, ире сугышта үлеп, тол калган. Ялгыз башы өч бала үстергән. Әмма ул, мин белгәннән бирле, шат күңелле, җор телле апа. Бәйрәмнәрдә толыпны әйләндереп киеп, бүрекне күзенә төшереп, шаяртып та йөри иде әле. Үзе әйтмешли, «маскарцы» иде.

Зәйнәптәйдән мин мәүлет мөнәҗәтләрен язып алырга теләдем. Ул үзенең чаршаулар элеп матурлаган өендә мине гади генә артсыз түндәккә утыртты, сандык төбеннән яулыкка төргән иске китап чыгарды һәм, күзлек киеп, көйләп укый башлады. Әсәр пәйгамбәргә салаватлар әйтеп башкарыла. Анда бер изге хатын кыйссасы бәян ителә. Ә бәян болай. Шул хатын, үлгәндә, улына мирас итеп акча калдыра. Улы бер заман мәүлет укыган җиргә

туры килә. Бу уку аны тетрәндерә. Төшендә фәрештәләр аны җәннәткә чакыра, җәннәт нәби (пәйгамбәр) туган көнне хөрмәт иткән кешегә насыйп була, диләр. Бу егет мирас акчасына аш үткәрә һәм мәүлет укыта. Һәр ел шулай эшли һәм бу дөньядан үткәч, җәннәтле була, җаны рәхәткә чума.

Әлеге әсәрнең пәйгамбәр тууына багышланган өлеше аеруча популярлык казана. Ул мөнәҗәт булып йөри һәм «Әминә ханым – Мөхәммәд анасы» дип атала. Мөнәҗәт пәйгамбәрнең тууын иляһи бер күренеш итеп, фольклор мотивларын файдаланып тасвирлый:

Әминә ханым – Мөхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән тугды энҗе данәсе.
Ул – Мөхәммәд, дөньяга тәшриф итәр,
Вакыт ирештe килмәгә хәйрел-бәшер.

Пәйгамбәр туар алдыннан дөнья нурга күмелә. Фәрештәләр саф-саф булып, Кәгъбәне тәваф итәләр. Өч хур кызы ана янына килеп, хәбәр бирәләр.

«Диделәр: Углың кебек хөрмәтлене
Ул Ходa һичбер анага бирмәде!
Бик олуг дәүләт иясе буласың,
Холкы күркәм бер угыл тугдырасың!»

Зәйнәп әби бу мөнәҗәтне салаватлар әйтеп тәмамлады. Соңыннан үзенең моңлы такмакларын да әйтеп күрсәтте: аларда дөнья фәлсәфәсе, фаҗигале мөнәҗәт мотивлары бар.

Әй бу дөнья, әй бу дөнья,
Уйлагац – уелдырды.
Чәчәк аткан чагыбызда
Чәчәкне коелдырды.
Без бит шылай яшьләй калдык,
Утыз яшендә генә,
Балаларны асрый-асрый
Кипте күз яшьләрем дә.
Кара коңгырт чәчебезгә
Ленталарны үрмәдек.
Азяпларны бик күп күрдек,
Рәхәтләрне күрмәдек.

Бу такмакларда язмышларын сугыш көйдереп киткән ялгыз аналарның моңы яңгырый. Зәйнәп әби 90 яшен узып, кызы Афия тәрбиясендә яшәп, бу дөньядан үтте. Аның мөнәҗәт әйткән тавышы магнитофон тасмасында калды. Җәннәт насыйп булсын Зәйнәп әбигә.

Соңгы 10–15 елда татар халкында мөнәҗәтләр аеруча популярлашты. Барлык өлкәләрнең татар авылларында мөнәҗәт әйтүчеләрне табарга була. Мөнәҗәтләр район газеталарында басыла тора, текстлары музейларда саклана.

Мөнәҗәтләр – татар фольклорының иң борынгы жанрларыннан берсе, ярымфольклор – ярымъязма әсәр. Мөнәҗәт – ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, ярлыкавын сорап, Аллаһы Тәгаләгә ялвару.

Көнчыгыш фольклорында һәм әдәбиятында мөнәҗәтләр VIII гасырда Гарәбстанда иҗат ителә башлаган, дип яза галимнәр. Иң беренче булып аларны изге Рабига иҗат иткән, диелә. Бу жанр гарәпләрдә, фарсыларда, төрекләрдә бик киң таралган.

Төрки шагыйрьләрдән мөнәҗәтләрне Әхмәт Ясәви (XII гасыр), Сөләйман Бакыргани (XIII гасыр) иҗат иткән. Ясәвинең «Кемләр өчен килде рәсүл» дигән мөнәҗәте халыкта хәзерге көндә дә башкарыла. Бөек төрки-татар шагыйрьләре – Кол Гали, Харәзми, Сәйф Сараи, Кятиб, Сәйади, Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр, Г. Утыз Имәни, Һ. Салихов, Ә. Каргалый, М. Акмулла, Г. Кандалый, Ш. Зәки, Дәрдемәнд һәм Тукайлар шулай ук мөнәҗәт жанрында аерым әсәрләр иҗат иткәннәр. Аларның әсәрләрен халык күп гасырлар дәвамында үзенеке итеп сөйләгән, яисә аерым строфа-мотивларын алып, яңа мөнәҗәт чыгарган. Бу уникаль күренеш тоташ грамоталы, язу белгән халыкта – татарда гына була алган.

Нижгар өлкәсе татарлары күп гасырлар элек үк гарәп телен яхшы белгәннәр, шул телдә укыганнар, язганнар.

Нижгар төбәгендә беренче ислам уку йорты Куй суында (Овечий Овраг) ачыла. XVIII йөз башында бирeдә 85 шәкерт белем алган, муллалар, азанчылар һәм мөгаллимнәр әзерләнгән. Атаклы мәгърифәтчеләр – Абделҗәлил мулла Биккинин (XVIII гасыр), Хәбибулла ишан Әлмөхәммәтов (XIX гасыр), Садек хаҗи һ.б. халык хәтеренә изге шәхесләр булып кереп калган.

Дөрес, XX гасырда дин әһелләренә хакимият тарафыннан караш төрлечә була.

1919 елда, Семочки авылындагы фаҗигалы хәлләр вакытында, коткы таратуда гаепләп, 6 мулланы атып үтерәләр. Бу хакта халык үз фикерен риваятьләрдә мәңгеләштерә, аларны шәһитләр дип атый, истәлекле урынны – каберләрен онытмый, зиярәт итә.

«Дин – агу», «дин – әфьюн» дигән шигарьләр яңгыраган шартларда барлык диннәргә, дин әһелләренә дә һөҗүмнәр булган. Әмма элекке гасырларда ук ныгып калган исламны татар халкы үзе саклаган. Дини фәлсәфә, үгет-нәсыйхәт тулы әсәрләр-мөнәҗәтләр иҗат ителгән, халыкны иҗаттан туктатып булмаган. Мәчетләр ябылып, манаралар киселсә дә, көнкүрештә Нижгар якларында дин яшәп килгән. Никахлар яшереп кенә укылып, туйлар тиешенчә үткән, мәетләр дин кушканча озатылган, алар рухына Коръән сүрәләре укылган. Дини бәйрәмнәр үткәрелгән, корбан чалу туктамаган. Бәйрәмнәрдә гает намазларын аерым өйләргә җыелып укыганнар.

Минем балачак хәтеремдә мондый истәлек бар: 1953–1954 еллар иде, миңа 6–7 яшь. Чүмбәли авылында яшибез. Бик иртә, таң сызыла. Бик күп кеше кулларына фонарьлар тотып, тәкбир әйтеп, урам тутырып бара. Мин дә өлкәннәрнең кулында, җай гына ритмга талгын чайкалып, ишетеп барам: «Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр! Ля иляһә иллаллаһ!» Тагын бер истәлек: Камка авылында яшибез. Без, 8–10 яшьлек бала-чагалар, бер апаның өе янында уйнап йөрибез. Мәчет инде манарасыз, биктә. Ә бу өйдә уразадан соң авыз ачу, җәмәгать намазы була. Шуннан соң олылар чыгып балаларга йөзем өләшәләр иде.

Шулай итеп динне, иманны халкыбыз үзе саклады, югалтмады. Соңгы 20 елда, дин иреге тугач, Аллаһыга шөкер, һәр авылны азан аһәңе хисләндерә. Һәр авылда бер генә түгел, берничә мәчет төзелде. Камка авылында хәзер 3 мәчет. Дин тотарга, иманны ныгытырга бөтен шартлар бар.

Халык иҗатында да дини жанрлар җанланып китте. Бигрәк тә мөнәҗәт жанры чәчәк атты, халыкның дингә, Аллаһыга, пәйгамбәрләргә булган хисләре шигъри яңгыраш алды. Жанрның үсешендә җирле матбугат та зур роль уйнады. «Туган як» газе-

тасы (Сергач; редакторы – Р.А. Абдуллин) татар халык иҗатын, мәдәниятен халыкка җиткерүгә, күтәрүгә зур өлеш кертте. Әлеге газета битләрендә бик күп мөнәҗәт-бәетләр дөнья күрде. Алар 2000 елда басылып чыккан (2010 елда кабат басылды) мөнәҗәтләр[1], бәетләр җыентыкларына кертелде. 2010 елда Түбән Новгород өлкәсенә оештырылган экспедиция дәвамында да бу газетадан мөнәҗәтләр язып алынды.

Мөнәҗәтләр галимнәр тарафыннан берничә төркемгә бүлеп анализлана. Без язып алган мөнәҗәтләр арасында Аллаһыга, исламга, пәйгамбәрләргә, Коръәнгә мактау-мәдхияләр, ялварулар тулы дини әсәрләр, яшәү һәм үлем турында, ана белән бала мөнәсәбәтләре турында әсәрләр бар.

1994 елда «Туган як» газетасында Печә авылыннан Гөлбагда Мусина мөнәҗәте басылган иде. Ул безнең китапка да керде. Әсәр «Сиңа сыгынам, йә Аллаһ», дип атала.

Яраткан Иляһым Син-Син,
Тугрылык падишаһы Син.
Кайда гына яшәсәм дә,
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ.

Биредә җир кешесенең Аллаһыга булган ярату хисләре, аңа сыгынып ярдәм көтүе, өметләнүе ачык күренә.

2010 ел экспедициясе вакытында Краснай (Красный Остров) авылында Йолдыз Фатыйх кызы Хәйретдиновадан 6 мөнәҗәт язып алу мөмкин булды. Алар традицион дини мөнәҗәтләр рухында язылган.

Иляһым, рәхмәтең бик киң,
Җәһәннәм утларын сүндер.
Сөекле колларындин кыйл,
Мөхәммәд өммәте иткел.

Әсәрләр Аллаһыга ялварып, гөнаһларны кичерүгә, җәннәтле булуга өмет итеп язылган. Бу мөнәҗәтләрдә Иляһ-Аллаһ, пәйгамбәр, өммәт, җәннәт, ахирәт, җан, әҗәл, салаватлар, фәрештәләр, мизан, тәмуг, кыямәт һәм диннән килгән башка сурәтләр, Коръән фәлсәфәсе, ышанулар урын алган.

---

[1] Мөнәҗәтләр / төз.: Р. Ягъфәров, А. Садыйкова. – Казан: Иман, 2000.

Түбән Новгород татарларында ислам фәлсәфәсен анализлаган галимнәр (С. Сенюткин, О.Н. Сенюткина, А. Хабутдинов) бу як татарларында суфичылык киң таралган булуы турында язалар. Суфичылык исламнан һич тә аерылмый, идеяләре бер үк, шуңа күрә аңа ияргән ишан-муллалар булган. Хәбибулла хәзрәт, Садек абзилар ишан, хаҗи булган, дигән фикер бар.

Кучкай Пожары авылында XIX гасырның бик тәкъва, изге карты Садек бабай бар иде. Ул намазын беркайчан да, хәтта Беренче бөтендөнья сугышы окопларында да калдырмаган. Көндәлек тормышта да ул гел намазда. Дога-фатиха сорап, авылның барлык кешесе аңа килә иде. Садек бабайны халыкта «Мөрит бабай» дип атыйлар. Димәк, каядыр якын-тирә авылларда, искәртеп үткәнчә, ишаннар да булган. Бу изге бабай гаиләсендә 4 укытучы – Бакый, Әнвәр, Һаҗәр, Сания үсте. Алар белемле, тәртипле, акыллы, хезмәтчән иделәр. Бер улы – Әнвәр абый озак еллар Кукмара районында (Татарстанда) укытучы, директор, район мәгариф бүлеге мөдире булып эшләде. Изге гамәлле мөрит Садек бабай халыкка аң-белем бирүче, мәгърифәтле балалар, иманлы нәсел калдырды, 90 яшен узып, дөньядан үтте, урыны җәннәттә булсын.

Ишаннары, мөритләре булган бу якта дини әсәрләр язылу бик табигый. Суфичылык идеяләренең күпмедер таралганлыгын Красный Островта язып алган мөнәҗәт тә раслый (Йолдыз Хәйретдиновадан 2010 елда язып алынды). Ул дога булып яңгырый, анда дога кылынырга тиешле кешеләр атала. Алар – бөек Шәрекъ суфилары, реаль шәхесләр. Атнаның берәр көнендә аларны искә алырга кирәк, диелә бу язмада.

**Шимбә көн** – Солтан Баязит Бәһтанигә (Бистами, XIV гасыр) – Иран суфие, җәзалап үтерелә.

**Якшәмбе** – Солтан Әхмәд Ясәвигә (XII гасыр) – бөек төрки шагыйрь, Ясәвия тарикатенә нигез салган атаклы суфи, аның хикмәтләре татарларда күп гасырлар дәвамында укылган.

**Дүшәмбе** – Солтан Ибраһим Әдһәмгә. Бу шәхес Бәлх солтаны булган, тәхетен ташлап, дәрвиш булып киткән, бер Аллаһыга гыйбадәт кылып гомерен үткәргән.

**Сишәмбе** – Солтан Исмәгыйль Сәмәнигә.

**Чәршәмбе** – Солтан Мәхмүт Газнәвигә (Иран солтаны).

**Пәнҗешәмбе** – Солтан Мөхәммәд Хасаравигә.

**Җомга** – Сәнҗан Мәдыйгага.

Укып, рухларына дога кылырга, дип тәмамлана бу язма.

Бу шәхесләрнең өчесе – бөек Шәрык суфилары. Түбән Новгород татарлары, димәк, суфичыл идеяләрне күпмедер үзләштергәннәр. Гади дин тормышында исә, суфиларга ияреп, бу дөньяны вакытлы санап, мәңгелекне уйлау тиешле. Аларда туктаусыз гыйбадәттә булып, теге дөньяда Аллаһының дидарын күрергә омтылу бар. Бу фикерләр дини мөнәҗәтләрдә еш очрый.

Мөнәҗәтләрнең бик күбесе гомер үтү, картлык житү, дөньядан китү, әҗәл җитү кебек темаларга багышлана:

Бу дөньядан тәмам туйды хыялым,
Ахырысы бу дөньяны куярмын.
Вакыт җитте бу дөньядан китәргә,
Кара җир астында нихәл итәргә?
(«Үтте гомерем»)

Әҗәл-үлем, күмелү гамәлләре, җир астында булу, гөнаһлар өчен җавап бирү, Алладан җәннәт өмет итү, пәйгамбәрдән өммәтенә ярдәм сорау – мондый мотивлар барлык мөнәҗәтләр өчен дә хас.

Түбән Новгородта язып алынган әсәрләрдә шундый ук хисләр һәм исән калганнарга теләкләр яңгырый:

Дусларым, китәм, бәхил булыгыз,
Сәфәрем ерак, дога кылыгыз.
Төштем фәрьядка, китәм еракка,
Кайтмамын инде, күмеләм туфракка.

Мөнәҗәтләрдә бик еш очрый торган тагын бер тема: ана белән бала мөнәсәбәтләре. Бу әсәрләрнең язылу тарихы төрлечә: ана белән баланы фаҗига, йә үлем аерган, ана кайгыда; йә баласы каядыр еракта, ана аны сагынып, күз яшьләре белән мөнәҗәт яза. Мондый әсәрләр язылуның иң үзәк өзгеч сәбәбе – ананың ялгыз калуы. Бу төр мөнәҗәтләрдә, үскәч балаларның әниләрен онытулары, хәбәрсез булулары, яисә якын кешеләренә катылык күрсәтүләре фаш ителә.

Түбән Новгород өлкәсендә дә мондый әсәрләр языла. Әйтергә кирәк, бу әсәрләр, күчереп язылып, бер җирдән икенче җиргә

күчеп тә йөри. «Туган як» газетасыннан алынган «Моңлы ана мөнәҗәте» «Мөнәҗәтләр» томына да кергән иде.

Ялгыз ана, ялгыз ана,
Күзләреннән яшьләр ага.
Балалары үсеп җиткәч,
Аналары ялгыз кала.

Анага мондый мөнәсәбәт киң таралган, дип уйларга кирәкми. Безнең татар халкында анага искиткеч ярату, ихтирам, мәрхәмәт белән карау кабул ителгән. Ә бу әсәрләр тәрбия функциясен үти, үгет-нәсыйхәт бирә, балалар анага кадер-хөрмәтле булырга тиеш, дигән фикер үткәрә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) «Җәннәт аналарның аяк астында» дигән хәдисе татар балалары өчен изге санала һәм үтәлә. Аналарга багышлап күп җырлар иҗат ителгән һәм мөнәҗәтләр дә язылган.

Актук авылында шундый риваять яши: кырларында Тораташ дигән изге урын бар икән. Имеш, борынгы заманда бер бала анасын бик рәнҗеткән. Бәгыре каткан ана баласын «Тораташ булып кат», дип каргап, куып чыгарган. Бу бала күкләрдә очып йөргән дә, биек тау итәгенә төшеп, ташка әверелгән. Авыл халкы бүген дә бу таш өстенә садакалар куеп калдыра, диләр.

Мәгълүм булганча, татар халкында ана хакы бик олы булган. Бу риваять аналарны тыңламауның бәхетсезлек китерүен аңлаткан «Сак-Сок» бәетенә бик охшаш. «Сак-Сок» бәетендә дә ана каргышына дучар булган балалар кошларга әвереләләр һәм мәңгегә аерылалар, өйгә кайта алмыйлар. Бу бәетне татарлар яшәгән бөтен төбәкләрдә беләләр, көйләп башкаралар. Аны ишетеп үскән балалар тәрбияле, мәрхәмәтле булган. Бу бәетнең бер версиясен мин 1984 елда Сергач районы Камка авылында Сюбаева Фатыйма ападан язып алган идем. «Сак-Сок» татар халкының күркәм холкын – балаларның итагатьлелеген, аналарның сабырлык сыйфатын тәрбияләгән.

Мөнәҗәтләр арасында вафат булган әниләренә ятим калган балалар тарафыннан багышланганнары бар. «Үксез кыз» дигән әсәрне мин 1984 елда Сергач районы Шөбиле авылында Сәмерханова Һаҗәр Шәрәфетдин кызыннан (1900 елда туган)

язып алган идем. Бу әсәр төрле төбәкләрдә төрле вариантларда мөнәҗәт итеп башкарыла. 1980 елда ул Башкортстанда язып алынган, 1997 елда Чаллыда чыккан «Мөнәҗәтләр» китабында басылган. Әсәрләрдә аерым юллар үзгәрсә дә, бер үк эчтәлек. Аларның ахыры сүзгә-сүз охшаш:

Мә, әнием, тот кулымны,
Тартып ал, әнкәем.
Бергә ятыйк, гүр эчендә,
Бергә булыйк мәңгегә.

Нижгар татарларында шулай ук әти-әнигә дөньяда чакта ук игътибар күрсәткән, аларга кайнар рәхмәт хисләрен белдергән әсәрләр дә иҗат ителә. Мәсәлән, «Туган як» газетасында Ыргу авылыннан Садекова Рәхимә Билял кызының «Әниемә» дигән мөнәҗәте дөнья күргән:

Үсеп җиттек, таралыштык,
Җидебез җиде якка.
Бәхетле булып яшәдек
Әти-әни бар чакта.

Түбән Новгород өлкәсендә җыелган материаллар арасыннан без оригиналь, моңа хәтле китапта басылмаган әсәрләрне алып анализларга тырыштык. Әмма репертуар моның белән генә чикләнми. Халыкта басылып чыккан, китапларга кергән әсәрләрне дә башкаралар, мәсәлән, киң таралган «Муса», «Фирак көне», «Ля иляһә иллаллаһы», «Үлем хәле» һ.б. әсәрләр көйләп укыла. Язып алган әсәрләр арасында борынгылыгы, китабилыгы сизелеп торган әсәрләр бар. «Гасый булдым, Раббым Аллам, үзеңә», «Тугры юлдан, Раббым, яздым мин» дигән әсәрләрдә гарәп сүзләре күп, алар гөнаһлардан ваз кичеп, Аллаһыга ялварып язылган, классик көнчыгыш мөнәҗәтләре дәрәҗәсендә яңгырый. Анда адәм үз-үзен кимсетә, гөнаһлар вәсвәсәгә бирелүдән килә, дип аңлый. Бу фикерләр Шәрекъ суфиларының мәләмәтийә дигән юнәлешенә хас (мәләмәтийә – үз-үзеңне кимсетү, ягъни Аллаһы Тәгалә каршында ким булуыңны белү).

Әйтелгән әсәр борынгы суфи шагыйрьләр иҗаты булып, безнең көннәргә килеп ирешкәндер.

Гасый вәсвәсәне тыңладык,
Нәфес теләвене куймадык.
Хак Тәгалә әмерен тоймадык,
Тәмуг газабыннан курыкмадык.
(«Гасый булдым, Раббым Аллам, үзеңә»)

Мондый классик әсәрләр белән рәттән гади, әмма ихлас җан талпынышларын, хис тирәнлеген белдергән әсәрләр Нижгар татарларында һаман иҗат ителә. Димәк, сәләт, иҗат куәсе халыкта саекмый, бетми әле.

«Истәлек» дигән әсәрне Ыргу авылында М.Адиәтуллина язмасыннан 2010 елда күчереп алдык.

Гади генә сүзләр тормыш фәлсәфәсен аңлата: яшьлек үтү, гомер узу, картлык җитү, дөньяның фанилеген аңлау һәм сабыр итү:

Яшь чакларымда һаман эш көтә,
Картайгач кына бар эш тә бетә.
Фани дөньяда кемнәр булмаган,
Пәйгамбәрләр дә мәңге тормаган.

Соңгы ике юл бик күп дини мөнәҗәтләрдә яңгырый. Барлык мөселманнар да теге дөньяда пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) ярлыкавын өмет итәләр.

Рәсүлулла сорар безне –
Өммәтемне ярлыка, дип.
Шушы булган өммәтемне
Тәмугларда калдырма, дип.

Түбән Новгород татарларының мөнәҗәтләре милли традицияләребезне дәвам иттерә, халкыбызның өметләрен чагылдыра, Аллаһыга, дингә тугрылыгын, иманыбызның ныклыгын белдерә.

Үзебез мөэмин, динебез ислам,
Шөкерана кылырлык бар.

Әлхәмдүлиллаһи шөкер, халкыбызда ныклы иман бар һәм аның киләчәге якты, бәхетле булыр.

## Әминә ханым – Мөхәммәд анасы

Әминә ханым – Мөхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән тугды энҗе данәсе.
Ул – Мөхәммәд, дөньяга тәшриф итәр
Вакыт ирештe килмәгә хәйрел-бәшер.
Имде аның килмәсе булды анук,
Күп галәмәт заһир улды аннан ук.
Ул рәбигыль-әүвәл аенда иде,
Уникенче кичә – дүшәмбе, диде.
Диде: «Күрдем, – ул Мөхәммәд анасы, –
Бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы!
Ялт итеп чыкты ивемнән шул заман,
Күкләрә тик нур белән тулды җиһан.
Һәм һава үзрә түшәлде бер түшәк,
Аты сөндүс, түшәгән аны мәләк.
Өч әләм дәхи тегелде өч йирә,
Аралары бик ерак бер-берийә.
Берсесе – мәшрикъ, берсе – мәгъриптә аның.
Берсе – нәкъ уртасында Кәгъбәнең.
Белдем аннан ул мөбарәкнең нурын,
Заһир улды килмәсеннән әүвәлин.
Инде күктән күп фәрештә сафы-саф,
Кәгъбә кеби кылдылар ивем тауваф.
Заһир улды дәфгатән өч хур кызы,
Билгесе улмады кайдан кердеге.
Өчесе дә янымa утырдылар:

---

Сәдәфтән – энҗе кабырчыгыннан.
Энҗе данәсе – олуг ак энҗе.
Тәшриф итәр – хөрмәт күрсәтер.
Хәйрел-бәшәр – Кешелекнең иң хәерлесе.
Анук – анык – ачык билгесе.
Ивемнән – өемнән.
Аты сөндүс – алтын белән чигелгән ефәк.
Заһир улды – ачык күренде.
Әүвәлин – алдан, элек.
Сафы-саф – саф-саф булып.
Ивем тауваф – өйне әйләнеп йөрү.
Дәфгатән – көтмәгәндә, кинәттән.

«Мостафа киләә!» – диеп гәп ордылар.
Диделәр: «Углың кеби хөрмәтлене
Ул Хода һичбер анага бирмәде!
Бик олуг дәүләт иясе буласын,
Холкы күркәм бер угыл тугдырасың!
Бу угыл гыйлемледән солтанидыр,
Бу угыл тәүхиде гыйрфан кянидер!»
Васфыны шул рәсмә тәртип иттеләр,
Ул мөбәрәк нуры тәргыйп иттеләр!»
Диде Әминә: «Вакыт йитте тәмам,
Килә инде дөньяга хәйрел-әнам.
Эсселектән сусадым гаять каты,
Шул вакыт эчерделәр бер ширбәте.
Ак иде, кардан дәхи салкын иде,
Эчтем аны, барча әгъзам булды нур.
Килде бер аккош канат илә очып,
Аркама сөяде ул, монда төшеп.
Тугды әүвәл сәгатьтә ул солтандин,
Нура гарык улды сәмәүват-зәмин!»
Гәр шәфәгать ләзем улса, эзләңез,
Ул рәсүлнең сөннәтеннән бизмәңез!
И Мөхәммәд Мостафа син, и рәсүл,
Кыл шәфәгать безләрә йәүмүн-нозуль!

*Камка авылында*
*Зәйнәп Мәхмутовадан (1912 елда туган)*
*А.Х. Садыйкова язып алды. 1996*

## Сиңа сыгынам, йә Аллаһ!

Мин үз башым белән уйлап,
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ.

---

Тәүхиде гыйрфан кянидер – Бер Аллаһыны танучы кеше.
Васфыны шул рәсмә – сыйфатларын шул рәвешле.
Тәргыйп иттеләр – сөендерделәр, шатландырдылар.
Хәйрел-әнам – кешеләрнен иң яхшысы.
Солтандин – солтаннардан.
Сәмәүват-зәмин – күкләр-җирләр.

Гөнаһлардан сакланып,
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ.
Яраткан иляһым Син-Син.
Тугрылык падишаһы Син.
Кайда гына яшәсәм дә
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ!
Вафасыз дөнья – илендә
Качып иблис әмереннән
Вә куркып ул көннән
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ.
Тәмуг күкрәсә ул көнне,
Оча башласа очкыннар,
Дәхи дә куркып ул көннән,
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ.
Ничә еллар һаваланып
Йөрдек без хаталык белән.
Бу көн рәхмәтләрең сорап,
Сиңа сыгынам, йә Аллаһ.

*Гөлбагда Мусина (Пецә авылы)*
*язмасыннан («Туган як», 1994)*
*А.Х. Садыйкова күчерде*

## Иляһым, рәхмәтең бик киң

Иляһым, рәхмәтең бик киң,
Җәһәннәм утларын сүндер.
Сөекле колларыңдин кыл,
Мөхәммәд өммәте иткел.

Асанлык белән алсаңчы
Газиз җанымны алганда.
Йөзебезне кара кылма
Үз хозурыңа барганда.

Шәрәфтәндин газиз җанны
Ничекләр бирербез инде.
Тар кабергә, салкын гүргә
Ничекләр керербез инде.

Аллаһ, изгелек арттыр,
Сиратлардин җан кичер.
Гамәл дәфтәрләребезне
Уң якларыбыздан китер.

Иман белән ал җанымны,
Җиргә тамызма канымны.
Күп рәхмәтләр янына сал,
Иляһием, бу җанымны.

Дөньялыкта хөрмәт иттең
Дөнья нигъмәтләрең белән.
Ахирәттә хөрмәт иткел
Җәннәт нигъмәтләрең белән.

Җиде тәмуг утларына
Хәрам кыл тәннәремне.
Үзеңнең рәхмәтеңне сал
Без зәгыйфь бәндәләреңә.

Салаватларны күп әйтик
Рәсүлулланың үзенә.
Кыямәт көн мизаннарда
Килербез бит хозурына.

Уйлыймын да булам хәйран,
Ниләр килер бу башыма.
Ничекләр җавап бирермен
Яраткан Аллам каршында.

Кыямәт көн шундый көн ул,
Һичкемсәдән ярдәм булмас.
Хәсән белән Хөсәенне
Кылгыл үзең безгә юлдаш.

Рәсүлулла шуны әйтте,
Соңгы сүзен Фатыймага.
Мөэминнәргә шәфәгатьче
Син булырсың мизаннарда.

Сират күперен узганда
Фатыйма түгәдер яшен.
Мөхәммәд өммәте өчен
Күтәрми сәҗдәдән башын.

Беренә мең әҗер бирер
Кыямәт көн Аллаһ Тәгалә.
Салават әйтмәгән бәндә
Шәфәгатьтән мәхрүм кала.

Кайсы өйдә мәҗлес булса,
Фәрештәләр шунда иңә.
Догага кул күтәргәндә
Алар безгә «амин» дия.

---

Хәбиб – сөекле.
Дус – Мөхәммәд пәйгамбәр.

* * *

И дусларым, гамәл кылыйк,
Гамәлдән соң дога кылыйк.
Бер Ходайның үзендин
Фирдәвес җәннәтен сорыйк.

Салаватларны күп әйтик,
Кылыйк гамәл таң атканчы.
Укыйк Коръән, укыйк тәһлил,
Кара туфраклар басканчы.

Бу дөньялар безгә фани,
Ахирәт юллары бакый.
Зинһар, сүз йөретмәгез,
Кеше үтерүдән дә каты.

Кыямәт көне булганда
Барча тәнем тетрәп торыр.
Шул вакытта Рәсүлебез,
Өммәтем, дип безне сорар.

Рәсүлулла сорар безне,
Өммәтемне ярлыка, дип,
Шушы булган өммәтемне
Тәмугларда калдырма, дип.

Хода бәндәм, дияр Алла,
Ярлыкадым өммәтеңне.
И хәбибем, синең хакка,
Багышладым җәннәтемне.

Иманлы булган бәндәне
Фәрештәләр каршы алыр
Ходайның рәхмәте белән
Җәннәтләргә алып барыр.

Гөнаһларны гафу әйлә,
Күндерсәнә изге юлга.
Ходайның рәхмәте белән,
Намазларны бирер «уңга».

Сабыр итик, сабыр итик,
Сабыр итүләр хуш булыр.
Сабыр итмәгән бәндәнең
Гамәл дәфтәре буш булыр.

Ахирәт хәлләрен яздым,
Дәфтәр сызып, «сыр» буйлап.
Күңелең таш булса да, эрер
Кыямәт хәлләрен уйлап.

Карап йөрим кара җиргә,
Керермен, дип кара гүргә.
Атам-анам белән бергә
Булуларны насыйп әйлә.

Әй, дусларым, сезгә әйтәм,
Күктә Гайсә пәйгамбәр бар.
Үзебез мөэмин, динебез ислам,
Шөкерана кылырлык бар.

* * *

Ялгыз башларым ялгыз гүрләрдә.
Рәхим кыл, мәүлам, без зәгыйфьләргә.
Үлем хәлләре бигрәк елата,
Күрәчәкләрне каты уйлата.
Дөньяга килдек, гомерләр сөрдек,
Гомерләребезне җилләргә бирдек.
Үтәдер гомер искән җил кебек,
Без дә китәрбез башкалар кебек.

* * *

Алтын нисар ак энҗене
Ак ефәккә тезмәк кирәк.
Үлем ачысы «ачы» диләр,
Ни хәл белән түзмәк кирәк.

Җаныбыз тәндин аерылгач,
Карап торырлар тезелеп.
Сөягем ятар сузылып,
Елаучым калыр өзелеп.

Зәгъфран кебек саргаер,
Боздин салкын булыр тәнем.
Тәндин китәр җаннарым,
Ерак торыр якыннарым.

Үлде, диеп елашырлар,
Малың калса, өләшерләр.
Җеназаңа ябырылырлар,
Фирак көне булыр бер көн.

Кабер дигән мәкам сарай,
Ишеге юк, кереп булмый.
Аңа кергән кешеләрнең
Хәлләрен дә белеп булмый.

Ничә еллар аша кичте,
Ничә нигъмәт аша үтте.
Ак атластин туннар киде,
Ахры – кәфен кияр инсан.

---

Нисар – алтын тәңкә, көмеш тәңкә.

* * *

Һәр заман сүз башланыр бисмилладан,
Һәрвакыт эш башланыр бисмилладан.
Яхшылар бисмилласыз эш кылмаган,
Эш тәмам бисмилласыз һич булмаган.

Динне тоту – утлы күмер кебек:
Төшсә – сүнә, тотсаң – пешерә.
Динле булсаң, хаклык шунда булыр,
Диннән чыгу түбән төшерә.

*Краснай авылында Хәйретдинова*
*Йолдыз Фатыйх кызыннан (1951 елда туган)*
*И.Г. Закирова, А.Х. Садыйкова язып алды. 2010*

## Үтте гомерем

Бу дөньядан тәмам туйды хыялым,
Ахырысы бу дөньяны куямын.
Вакыт җитте бу дөньядан китәргә,
Кара җир астында нихәл итәргә?
Ниләр килми бу адәмнең башына,
Карышып булмый Ходайның язмышына.
Һич рәхәтсез үтте гомерем, хушларым.
Үләр булсам, юып, илтеп куярсыз,
Бу дөньядан туеп китте диярсез.
Әй, иляһи җиңел кылсын үлемне,
Рушан кыл ята торган гүремне
Мөнкир-Нәнкиреңне җибәр.
Күркәм холыклары белән.
Фәрештәләр каршы алсын
Җәннәт коллары белән.
Дусларым, китәм, бәхил булыгыз.
Сәфәрем ерак, дога кылыгыз.
Төштем фәрьядкә, китәм еракка.
Кайтмамын инде, күмеләм туфракка.

---

Фәрьяд – ялвару.
Рушан – нур.

Дусларым, мине озата барыгыз,
Бер Ходайдан ярдәм сорагыз.
Кабрем өстенә чатыр корыгыз,
Агач утыртып, нурландырыгыз.
Яфраклар ярса, кошлар сайраса,
Рухым шатланыр, догалар барса,
Әй, бер Ходаем, килдем каршыңа,
Бер ялгыз башым, рәхмәт кыл миңа.
Әй, бер Ходаем, куркам үзеңдин,
Өмет итәмен киң рәхмәтеңдин.

*Юнисова Заһидә язмасыннан («Туган як»,*
*1992, 27 март) А.Х. Садыйкова күчерде*

## Әй, картлык көнем...

Әй, картлык көнем, бик ямьсез иттең,
Матур яшь вакыт, син кая киттең.

Йөгереп йөрүләр барсы да кала,
Әкрен йөреп тә аяклар тала.

Чәчем агарды, төште тешләрем,
Башым әйләнә, бетте көчләрем.

Чәчне буятып яшьлек киләлми,
Беткән саулыкны кем дә биралмый.

Яшь вакытым уйлап, күңелем тула,
Шатлыклы вакыт яшь чакта була.

Матур внуклар «әбкәем» дияр,
Яшь вакытларым алдыма килә.

Күздән нур сүнгәч, күрә алмыйлар,
Аркаң бөкрәйгәч, төзәтә алмыйлар.

Дуслар, яшь чакта эшләү кадерле:
Кайтарып булмый узган гомерне.

Тәүбә кылыгыз, руза тотыгыз,
Үлем хәлләрен истә тотыгыз.

Квартир, дачалар, байлык, балалар,
Алар барысы да үлгәч калалар.

Кылган гыйбадәт, изге абадәт
Үзегез белән бергә баралар.

*Кызыл Октябрь районы Чүмбәли авылында*
*Халык музеендагы «Халык иҗаты» дигән*
*кулъязмадан Р. Ягъфәров күчергән*

## Дөнья кудым

Газиз гомеремнең кадерен белмәдем
Дөньяны кудым, рәхәт күрмәдем.
Дөнья малыннан туя белмәдем,
Үлем килер, дип уема алмадым.
Явыз нәфесемне тыя алмадым,
Гөнаһ кылдым, һич оялмадым.
Үлемне уйламыйм, уйлыйм торырга,
Тагы әлләниләр уйлыйм кылырга.
Картлык та җитте, чәчләр агарды,
Әҗәл күренгәч, чәчләр агарды.
Әҗәл читләми, килде кинәттән,
Һич тә калмак юк анда китмәктән.
Чирләп ятамын, түшәкне буйлап,
Күңелем белән терелмәкне уйлап.
Дусларым килә хәлне белергә,
Дога кылалар миңа терелергә.
Терелү кайда ул, әҗәл хастасы,
Ачык булса иде җәннәт капкасы.
Кайда терелү, килде әҗәл чире,
Чирем көчәя, көннән-көн кире,
Чирем көчәйгәч, күңелем йомшарды.
Кыямәт булуга тәмам ышандым,
Әҗәл әрнүе йөрәккә күчте,
Якамнан тоткач, исемә төште.
Сәламәтлекнең кадерен белегез,
Тәүбәгә ашыксын, дуслар, күңелегез.

Исән вакытта үлү юк икән,
Якаңнан тоткач, дуслар, соң икән.

*Р. Мостафина язмасыннан*
*(«Туган як», 1992, 27 март)*
*А.Х. Садыйкова күчерде*

**Бу дөньялар бездән калыр**

Мөнәҗәтем әйтим әле,
Дусларыма ошар микән?
Шушы мөнәҗәтемне әйтсәм,
Тулган калебем бушар микән.
Әйдә барыйк изге юлга,
Изге юл нур белән тулган.
Безгә нигә инде байлык
Мөхәммәд өммәти булгач.
Рәсүлулла пыраклары,
Зәгъфран тояклары,
Тәһлил әйтик, салават әйтик,
Без бу дөнья кунаклары.
Бу дөньяга торам вәйран,
Үз-үземә булам хәйран.
Гамәл кылмый, рәхәт күрми
Гомерләребез үтә вәйран.
Бу дөньялар бездән калыр,
Кара туфрак чорнап алыр.
Кара туфракның астында
Күзен ачып хәйран калыр.
Үләрмен, дип белмәдеңме?
Үлгәннәрне күрмәдеңме?
Җиңсез, якасыз күлмәкләр
Кигәннәрне күрмәдеңме?
Җәһәннәм төтене кара,
Гөнаһлы адәмнәр яна.
Үмеребез үтеп бара,
Биш вакыт намазлар кала.
Елан чыгар авызын ачып,
Илгә-күккә утлар чәчеп.
Рәсүлуллабыз булмаса,
Без котылалмабыз качып.
Тәһлил әйтик, салават әйтик,
Рәсүлулланың үзенә.
Мизан янына барганда
Карарбыз аның күзенә.
Тәһлил әйтик, салават әйтик
Фатыйма ананың үзенә.
Мизан янына барганда
Карарбыз аның күзенә.
Рәсүлулла дога кыла.
Яшел чалмалары белән.
Бер ходаем хөрмәтләсен
Җәннәт алмалары белән.
Рәхмәт сезнең мәҗлескә,
Утырабыз түрегездә,
Иман нуры йөзегездә,
Нур балкысын йөзегездә.

---

Прак – пырак – бурак – мифик ат.
Зәгъфран – хуш исле сары төстәге үсемлек, шафран.
Азраил – Газраил – үлем фәрештәсе.
Мизан – үлчәү.

Әҗәл суларын
Без бер эчәрбез.
Бу дөньялардан
Без бер китәрбез.
Әҗәлләр җитәр,
Тәннәребез бетәр.
Ясин укырга вакытлар җитәр.
Килер Азраил,
Җаныбызны алыр.
Нурлы йөзләребез
Саргаеп калыр.
Тактага салып,
Юа башларлар.
Кәфенлек алып,
Юли башларлар.
Үләрбездин
Алып китәрләр.
Салкын кабердә
Калдырып китәрләр.
Зифа буемны
Үлчәп алырлар.
Салкын кабергә
Илтеп салырлар.
Шатланыр идем,
Җомга көн үлсәм.
Җомгага кадәр
Гүремә керсәм.
Җанымны алдыр
Җомга кичендә.
Караңгы итмә
Кабрем эчендә.

Газиз кардәшләр,
Якын иптәшләр,
Дога кылыгыз,
Яхшы иптәшләр.
Кабер өстенә
Чардак корыгыз.
Агач утыртып,
Нурландырыгыз.
Яфраклар ярса,
Кошлар сайраса,
Рухым хушланыр
Догалар барса.
Нәзерләр кылыйк
Таңнар атканда.
Нихәл итәрбез
Кабергә ятканда.
Рәсүлулланың
Чыкмыйк юлындин.
Ширбәт суларын
Эчерер кулындин.
Намаз укымадым
Яшь вакытларда.
Нихәл итәрбез
Тар ләхетләрдә?
Үлем аера
Яхшы тормыштан.
Качып булмыйдыр
Азраил дустан.
Үлем шәйләми
Яшьне дә, картны.
Үлгәч, кабердән
Беркем дә кайтмый.

*Володар районы Юганец поселогында яшәүче*
*Әмир Яруллин язмасыннан («Туган як», 1992, 27 март)*
*А. Вәлиуллина язып алган. А.Х. Садыйкова күчерде*

---

Ясин – Коръәннең 36 нчы сүрәсе.
Юли – тегә.

## Мөнәҗәти Ибраһимә

Бисмиллаһи вә биллаһи,
Мөнәҗәт яза башладым.
Бу дөнья фикерен ташлап,
Ахирәтне уйлый башладым.

Мөнәҗәт яза башладым
Дәфтәр сызыклары буйлап,
Язам-язам да елыймын,
Ахирәт хәлләрен уйлап.

Гафил булмыйк, тәүбә кылыйк,
Кичен йокыга ятканда.
Куркынычлы хәлләр булыр,
Кыямәт таңы атканда.

Гафил булмыйк, туганкайлар,
Үткән гомер кире кайтмас,
Кыямәт көнне үкенсәң дә,
Үкенечтән файда булмас.

Кыямәт таңы атканда
Кабер өстенә чыгарбыз,
Сулар кибәр, күк кызарыр,
Ничек, туганнар, чыдарбыз?!.

Мәхшәр җиренә куярлар,
Гамәлләребездән сорарлар,
Авыр булыр шунда хәлләр,
Ни хәл итәрбез, туганнар?!

Кыямәт көне булганда,
Ходай үзе җавап алыр.
Җавап бирәлмәгән бәндә
Гаҗиз булып хәйран калыр.

Әй Иляһи, кадир мәүлам,
Синнән башка юктыр Алла.
Иманымны зарар кылма,
Җәһәннәм утына салма.

Әй Иляһи, кадир мәүлам,
Таянамын рәхмәтеңә.
Без фәкыйрьләрне ярлыка
Рәсүлулла хөрмәтенә.

Дуслар, безгә бик зур сөенеч –
Ходай биргән «мөэмин» атын.
Мөэмин булган бәндәләргә
Хәрам иткән тәмуг утын.

Сират күперен кичкәндә,
Аягымны тайдырмагыл,
Без Мөхәммәд өммәтләрен
Тәмугында яндырмагыл.

Сират күпере өстендә
Нәзер – корбаннарның эзе.
Хәзрәти – Фатыйма бит
Рәсүлуллабызның кызы.

---

Бисмилләһи – Аллаһның исеме белән.
Ахирәт – теге дөнья.
Гафил – игътибарсыз, гамьсез.
Кыямәт – үлгәннәр тереләчәк көн.
Мәхшәр – кыямәт көнендә барлык кешеләр җыелачак мәйдан.
Кадир – көчле, бөек көчкә ия булучы (Аллаһ Тәгалә).
Мәүла – галиҗәнаб, әфәнде.
Мөэмин – мөселман.
Сыйрат – сират – җәһәннәм өстенә корылган күпер.

Мөхәммәд өммәте булып,
Кәүсәр шәрәфләрен эчсәк,
Шунда булыр безгә шатлык
Сират күперендин кичсәк!

Әйтик микән менә Хакны,
Ходайдан сорыйк хаҗәтне.
Бер Ходаем насыйп итсен
Фирдәвес дигән җәннәтне.

*Бозлау авылы музеендагы язмадан*
*А.Х. Садыйкова күчерде. 2010 ел.*

**Моңлы ана мөнәҗәте**

Ялгыз ана, ялгыз ана,
Күзләреннән яшьләр ага.
Балалары үсеп җиткәч,
Аналары ялгыз кала.

Газиз ана балаларын
Бик тырышып үстерә ул,
Соңгы көндә ялгыз калып,
Башын бөгеп утыра ул.

Ялгыз ана – ялгыз йортта,
Аның эче яна утта.
Бала күңеле каты икән,
Карамый аны уйлап та.

Бала бәгъре каты икән,
Ананы ул ялгыз куя.
Үсеп җиткәч, кеше булгач,
Бала анасыннан туя.

Ялгыз ана буп-буш йортта
Һәр көн саен ярдәм көтә.
Ялгызлыкта гомере үтә,
Һәм бер көнне үлеп китә.

Ялгызлык ул бигрәк авыр,
Ялгызлык ул кабер йорты.

Йөзнең нурларын ала ул;
Ялгызлык ул хәсрәт йорты.

Ходайдан ул сыгынып сорый,
Үзе елый, үзе сорый.
Баласына ялгыз ана
Ходайдан бәхетләр сорый.

Бу дөньяда бармы икән
Татлы нәрсә балалардан?
Үсеп җиткәч, кеше булгач,
Бизә алар аналардан.

Бу дөньялар һичбер кемгә
Ике килми, беләсезме?
Кем – барлыкта, кем – тарлыкта
Гомер итә, күрәсезме?

Шәфкатьлек бир балаларга,
Сабырлык бир аналарга.
Сабырлыкның күркәме бар
Ялгыз калган аналарга.

Бала өчен янган йөрәк
Шулай янар ул гомергә,
Бала өчен янган йөрәк
Калдыра кара күмергә.

---

Кәүсәр – оҗмахтагы елга исеме.
Хак – Аллаһы Тәгалә.

Китканеңә күпме айлар,
Кайчан күрешербез тагын?
Ана күңеле – сынык күңел –
Хөрмәтләгез исән чагын!

*А.Х. Садыйкова кучерде*
*(«Туган як», 1994 ел, 6 август)*

**Сак-Сок бәете**

Әнкәем иртә торды,
Өендә кошлар күрде.
Бу нинди кошлар, диеп,
Хәйранга калып торды.
Әткәйгә сүләп бирде,
Рәнҗеде, дога кылды.
Күрәсең, туры килгән
Кабуллык сәгатенә.
Балалардан мәхрүм калып
Янарга кайгы утында.
Мине белгәннәр болай
Баланы каргамасын.
Баладан, каргыш каргап,
Гомергә мәхрүм калмасын.
Ходайдин микән язмыш,
Алабыз көн дә каргыш.
Һәркөнне рәнҗегәнгә
Барысы да бергә бармыш.
Сагышлыйбыз үле (өйле) көндә,
Куркабыз озын төндә.
Һавадагы ерткыч кошлар
Йөриләр җир өстендә.
Караңгы урман эче,
Күк күкри, яшен яшьни.
Давыл чыга, урман гөрли,
Кар, яңгыр ява башлый.

Бардым урманга, җиләкләр пешкәч,
Әнкәй елыйдыр, исенә төшкәч.
Әнкәй каргады, эткәй, белдеңме?
Турыңдин очтык, эткәй, күрдеңме?
Җыйган җиләгем калды яртысы,
Ике баламдин калмады берсе.
Кояш тулганда нур тула күзгә,
Кыямәт көнсез күрешү юк безгә.
Моңны моңларсың, сайрап сайрарсың,
Балаңны очырдың, кемгә еларсың?
Су буйларында диңгез камышы,
Тын урманнарда Сак-Сок тавышы.

*Сергач районы Камка авылында Сюбаева Фатыймадан*
*А.Х. Садыйкова язып алды. 1984*

## Өзелеп көтәм, балам, хатларыңны

Өзелеп көтәм, балам, хатларыңны.
Утырам, айга карап, йокламый...
Йөрәгемдә әрнү, ә күземнән
Кайнар яшем ага туктамый.

Ташладың бит әниеңне, балам,
Оныттың анаңның барлыгын.
Үстергәндә һич сизмәгән идем
Күңелеңнең шулай тарлыгын.

Үзең ана хәзер, аңлыйсыңдыр:
Бала анага нинди кадерле!
Балам, йөрәк парәм, әйт җылы сүз,
Өзмә, татлым, минем бәгырьне!

Синең белән аерылгачтын да
Бик күп еллар үтеп киттеләр.
Арык кулым белән хатым язам,
Тамырларым калкып беттеләр.

Бик сагынам сине, өзелеп сагынам,
Гүремәчә урының күңелемдә.
Беләм миңа җавап язмасыңны,
Ә мин язам, язам бүген дә.

Килмә, балам, вакыт табалмасаң,
Килмә, килмә, күңелең тартмаса.
Килмә инде, әгәр теләмәсәң,
Хат та язма, кирәк тапмасаң.

Гомер уза... Сизенәм – озакламый
Каберемә туфрак салырлар,
«Баласыннан шатлык күрмәде», – дип
Дус-ишләрем елап калырлар.

Хуш, исән бул, күрешмәбез кебек,
Хатым булыр сиңа истәлек.
Кулларыңа алып, бер укырсың,
Бәхетсез анаңны искә алып.

*Кызыл Октябрь районы Уразавылда Ф. Шакировадан*
*Л.Зиннәтуллина язып алган. Р. Ягъфәров күчергән*

## Ялгыз ана

Ялгыз ана уйлый-уйлый
Йөзенә сарылар төшкән.
Күкрәк сөтен имезеп үскән
Баланың шәфкате беткән.
Ялгыз ана, ялгыз ана,
Күзләрендин яше ага.
Балалар үсеп җиткәч,
Аналары ялгыз кала.
Ана йөрәге, башында
Кеше күрмәгән ут яна.
Төрле уйлар уйлый-уйлый
Сәламәтлеге югала.
Балалары үсеп җитә,
Бар да таралышып бетә.
Ананың нурлы йөзендә
Саргаеп, нурлары бетә.
Бала бәгъре каты икән,
Ана, мескен, ялгыз кала.
Ялгызлыгындин кайгырып
Ялкынлы утларда яна.
Ялгыз ана ялгыз, якта.
Ана йөрәге яна утта.
Кызганыч ул, ялгыз ана.
Ананың йөрәге яна.
Янган йөрәккә ул ана
Таба алмый һичбер дәва
Ана, мескен, баласындин
Һәркөн саен ярдәм көтә,
Шулай итеп үмере бетә,
Ахыры бер көн үлеп китә.
Ялгызлык бик авыр аңа,
Ялгызлык бит кабер йорты.
Йөзендәге нурын алган
Ялгызлыкның хасерәте.

*Сергач районы Камка авылында Сюбаева Фатыймадан*
*А.Х. Садыйкова язып алды. 1984*

## Үксез кыз бәете

Ай анам, назлы анам,
Моңлы анам, бәгърем анам.
Бу каберне күрсә күзем,
Өзелә үзәгем, янам.
Һич онытмыйм сөйгәнеңне,
Үпкәнеңне шатланып.
Балам, бәгърем, диеп мине,
Кил, иркәм, диеп алып.
Күзе нурлы, күңеле моңлы,
Кулы йомшак әнкәем.
Бер тавыш бир гүр эченнән,
Бәбкәем, дип әнкәем.
Бер генә дим, бер генә тик,
Әнкәй, ишетим сүзеңне.
Туймадым дөньяда күреп
Гөлчәчәктәй йөзеңне.
Мин ятим, моңлы ятим,
Бар кеше хурлый, кага.
Елый-елый моңланамын,
Йөрәгемнән кан тама.
Гүр караңгы, гүр караңгы,
Гүр кара, буш, әнкәем.
Миңа да шундый бу дөнья,
Әнкәем, газизкәем.
Син мине кызган, әнием,
Бәгърем, кулың суз миңа,
Мә, әнием, мә, тот кулым.
Суз кулың, гүргә керим.

Бергә ятыйк гүр эчендә,
Мин дә дөньяны сөймим.
Мин бу дөньяны сөймим.
Тыңла димен, тыңла безне,
Азраил, кил, ал җаным,
Ашыгамын, бул җитез.
Йә, әнием, тот кулымны,
Тартып ал, әнкәем.
Бергә ятыйк гүр эчендә,
Бергә булыйк мәңгегә.

*Шөбиле авылында*
*Сәмерханова Һаҗәр Шәрәфетдин кызыннан*
*А.Х. Садыйкова язып алды. 1984*

## Әниемә

Әнекәем, бәгырькәем,
Җиде бала китердең.
Гөлләргә су сипкән кебек
Безне сөеп үстердең.
Үсеп җиттек, таралыштык
Җидебез җиде якка.
Бәхетле булып яшәдек
Әти-әни бар чакта.
Җидәү идек без һәрвакыт,
Кайгы-хәсрәт белмәдек.
Өчебез дөнья ташлагач,
Сабырлыклар теләдек.
Гомер бит ул шундый нәрсә,
Бик тиз уза да китә.
Ата-анадан, туганнардан
Бик ерак алып китә.
Ата-ана хәлен сорап,
Телефоннан белешик.
Җир астыннан юллар булмас,
Исән чакта күрешик.
Балалар, туганнар киткәч,
Моңсулана күңелем.
Аларның кайтуын көтеп,
Үтә минем гомерем.
Балаларым, туганнарым,
Кайда гына йөрисез?
Йөрәгемнең өзелгәнен
Сез бит бер дә белмисез.
Бергә чакта бик күңелле,
Тик бергә торып булмый.
Аерылышу әрнүләрен
Кемгә дә сөйләп булмый.
Тауларга мин менәм инде,
Аякларым талса да.
Аерылышуга түзәм инде,
Йөрәккәем янса да.

*Садекова Рәхимә Билял кызы (Ыргу авылы)*
*язмасыннан («Туган як», 1992, 27 март).*
*А.Х. Садыйкова күчерде*

## Гасый булдым, Раббым Алла

Буйсынмадым нәбиләр сүзенә,
Гасый булдым, Раббым Алла, үзеңә.
Кылган хаталарыбызны гафу ит,
Ялварамын, Раббым Алла, үзеңә.

Ялварамын, Раббым Алла, гафу ит,
Теләгемне, Раббым Алла, кабул ит,
Иман нуры белән нурлап
Кыямәт көнне йөземне нурлы ит.
Вәси вәсүсине кыладыр,
Нәфсе аны тыңлап торадыр.
Нәфес әмерен тотып янә
Хакыйкага гасый буладыр.
Гасый вәсүсине тыңладык,
Нәфес теләвене куймадык,
Хак Тәгалә әмерен тотмадык,
Тәмуг газабыннан курыкмадык.
Вәси вәсвәсәне кылу белән
Гасый булдым, Раббым, үзеңә,
Ошбу хаталыктан котылырга
Нәсыйхәт биргел, Раббым, син миңа.
Ни кылсам да, Раббым, күрәсең,
Барча хаталарым беләсең.
Раббым Алла, үзең кадир син,
Теләсәң син носрат бирәсең.
Раббым Алла, гасый булдым үзеңә,
Карау белән нәфесем сүзенә.
Ялварып киләм хозурыңа,
Гафу рәхим дигән сүзеңә.
Гафу, рәхим, Раббым, син үзең,
Ишетәсеңме мин – колың сүзен?
Дөньяда да, ахирәттә дә
Рисвай кылма мине син үзең.
Мәгъбүдем син, Раббым, холкым син,
Син Раббым син минем.
Барамын, Раббым, хозурыңа,
Колың, Раббым, мин синең.
Йа Раббым, кадир син,
Гафу, рәхим бирерсең үзең.
Кара кылма, Раббым, мәхшәр көнендә
Мин бичара колың йөзен.

Йөземне җиргә куеп ялварамын,
Яд итәмен, Раббым, мин сине.
Миһербанлы Алла, дөреслә,
Гафу иткел, Раббым, син мине.

*Һәдия Юсипова (Бозлау авылы)*
*язмасыннан («Туган як», 1992)*
*А.Х. Садыйкова күчерде*

**Тугры юлдан, Раббым, яздым мин**

Тугры юлдан, Раббым, яздым мин,
Нәфсе әмере белән аздым мин.
Туры юлга, Раббым, үзең күндер,
Рәхимле мәгъбүдем, кадир син.
Бигрәк куркам, Раббым, ачуыңнан.
Зекер итәм, Раббым, мин сине.
Миһербанлы Раббым, рәхим кыйл,
Гафу кыйлгыл, Раббым, син безне.
Миһербанлы Раббым, гафу ит,
Теләгемне, Раббым, кабул ит.
Хәбибең Мөхәммәд хөрмәтенә
Дидарыңны, Раббым, насыйп ит.
Ничек итеп, Раббым, ялварсам да,
Кабул иткел минем теләгем.
Раббым, ачуыңнан курку белән
Тетеридер минем йөрәгем.
Ялварамын, Раббым, мин сиңа:
Миһербанлык, носрат кыйл миңа.
Гафу рәхим дөресен, Раббым Алла,
Рәхим кыйлгыл, Раббым, син миңа.
Салгыл, Раббым Алла, калебебезгә
Әмереңне, тугры юлыңны.

---

Хәбибең – сөеклең.
Дидарыңны – йөзеңне.
Носрат – җиңү, ярдәм.

Шулай итеп ихластан ялварам:
Гафу ит, диюем, колыңны.
Салгыл, Раббым Алла, күңелебезгә
Фазлың белән туры юлыңны.
Юк торырга өем, юктыр йортым,
Юктыр әзерләгән азыгым.
Ходай хозурына ничек барыйм,
Бигрәк күптер мине гөнаһым.
Инде озак тормый үләрбез дә,
Хәл-әхвәлне шунда белербез.
Тәмугкамы, әллә оҗмахкамы –
Кая насыйп – шунда керербез.
Олуглыймын сине, Раббым Алла,
Һаман яд итәмен мин сине.
Кызгангыл, мәгъбүдем, мин колыңны,
Җәһәннәмгә якма син мине.
Кимчелеккә килмәссең бит, Ходай,
Гөнаһымны гафу кылсаң да.
Тулмастыр ул җәһәннәм чокыры,
Мин колыңны утка салсаң да.
Калбебезгә салгыл, Иляһым,
Рәхмәтең тулы исемең.
Яндырма син, Раббым Алла,
Бу колыңның җанын, җисемен.
Бирмәгел шайтанның кулына,
Кызгангыл мине, фәкыйрь колыңны.
Миһербанлы Раббым Аллам,
Ярлыкагыл гафил колыңны.

*Һәдия Юсипова (Бозлау авылы)*
*язмасыннан («Туган як», 1992)*
*А.Х. Садыйкова күчерде*

---

Фазлың – рәхмәтең.
Гафил – ваемсыз.
Калеб – йөрәк.
Мәгъбүдем – кабул итүчем.

## Истәлек

Безнең яшьлекнең кадере булмады,
Өс-баш ялангач, тамак туймады.
Ачка үлмәстән кырдан килмәдек,
Ял күрмәсәк тә, аруны белмәдек.
Авыр димәдек, салкын димәдек,
Шөкер Аллага, ачка үлмәдек.
Ә хәзер инде яшьлегем үтте,
Әй син, картлыгым, ник иртә килдең?
Иртә торам да, кичләрне көтәм.
Үткән гомерем кайтмас һич бүтән.
Суларым беткәч, чыгам коега,
Көн үткән саен күңел боега.
Боегып йөрмәдем, рәхәт күрмәдем.
Картаюымны үзем сизмәдем.
Чәчләр агарды, йөзләр саргайды,
Картлык килгәнне йөрәк тә аңлады.
Картлык көчле бит, яшьлекне җиңде.
Әй син, яшьлегем, кайтмассың инде.
Яшьлек хисләре калды йөрәктә.
Иртә торам да карыйм көзгегә,
Гомер узганны аңлыйм үзем дә.
Яшь чакларымда һаман эш көтте,
Картайгач кына бар эш тә бетте.
Фани дөньяда кемнәр булмаган,
Пәйгамбәрләр дә мәңге тормаган.

*Ыргу авылында*
*М.Адиәтуллина язмасыннан*
*А.Х. Садыйкова күчерде. 2010*

# ЗИМӘ БУЕ АРЫМСАК...

## *Риваятьләрдә – халкыбыз тормышы*

*Илсөяр Закирова*

Бу җыр юллары хәзерге вакытта риваятькә әйләнеп калган «Җимчәчәк» (Зимцәцәк) дигән яшьләр уены җырыннан. Риваятьләрдә халыкның үткәне генә түгел, җырлары да саклана. Аерым сүзләрнең мәгънәсе дә әкренләп онытыла бара. **Камка** авылы өлкәннәре җырның аерым строфаларын гына искә төшерә алды. Су буйларында гөрләп торган яшьләр уеннары да, аулак өйләр дә әкренләп сөйләкләргә күчкән, алар турында әби-бабайлар риваять итеп оныкларына сөйли. Максатым халык җырлары турында язу булмаса да, бөтен оныкларның әбиләре яки дәү әниләре булмавын истә тотып, бу җыр турында язасы иттем. Яз көне Пьяна елгасында су тонгач, яшьләр «Җимчәчәк» әйтергә су буена яки мәчет янына җыелган. Егетләр кызлар белән танышкан. Бер-берсен ошатып йөргән яшьләр бер-берсен «челбәй» дип атаганнар. Ул яраткан кешең, сөйгәнең дигәнне аңлаткан. Уен барышында кара-каршы тезелешеп баскан егетләр һәм кызлар бер-берсенә багышлап җыр җырлаганнар.

Зимцәцәк, зимцәцәк,
Зимә буе арымсак, арымсак,
Арымсакка ни кирәк, ни кирәк?
Бүдер-бүдер бүз кирәк, бүз кирәк!

Зимцәцәк, зимцәцәк,
Зимә буе арымсак, арымсак,
Арымсакка ни кирәк, ни кирәк?
Бөдрә чәчле кыз кирәк, кыз кирәк!

*Зимцәцәк* сүзе *зим* сүзеннән. «Яз көне су өстенә чыккан юка боз», – дип аңлатты безгә бу сүзнең мәгънәсен Оркыя апа (Хөсәенова Оркыя Саттар кызы, 1927 елда туган). Арымсак су буенда үскән чәчәк булырга мөмкин. Галимнәр җимчәчәкне умырзая чәчәге, дип аңлаталар. «Җимчәчәк» уены борынгы мәҗүси ритуалйоланың бер элементы буларак формалашкан. Ул татарларда гына түгел, башка халыкларда, мәсәлән, таҗикларда, үзбәкләрдә «Бойчечәк» исеме белән мәгълүм булган. Төп эчтәлеге – язгы кояшны мактау, Җир-Ананы котлау, гаиләләргә ныклык, иминлек теләү.

1958 елда узган фольклор экспедициясе вакытында «Җимчәчәк» уены җыры Камка авылында галимнәр тарафыннан язып алынып, «Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары» томында урын алган. 1984 елда «Җимчәчәк» җырының бер версиясен фольклорчы галимә Айсылу Садыйкова да язып ала.

**Мәдәнә** авылының Шәрык мәчетләре стилендә төзелгән мәһабәт мәчетеерактан күренеп, авылга ямь биреп тора. Ул зур комплекс булып, биредә мәчеттән тыш, туган якны өйрәнү музее, килгән кунакларны урнаштыру өчен кунакханә дә каралган булып чыкты. Авыл ямьле – ике катлы кирпеч йортлар, төзек урамнар, татар авылларының визит карточкасы булган челтәрле тәрәзә йөзлекләре, өй кыеклары... Авыл исеме Мәдәнә елгасыннан алынган.

Халисә апа (Насыйбуллина Халисә Хөсәен кызы, 1915 елда туган) авылның үткәнен, халыкның йолаларын, гореф-гадәтләрен тәфсилләп искә төшерде. Бу якның туй йолалары – кыз багулар, башкода җибәрүләр, задатка бирүләр, чаршау печәргә барулар турында сөйләгәндә ул үзенең унбиш яшьтән кияүгә чыгуын да, тормышының төрле мизгелләрен дә искә төшерде. Сүз арасында Халисә апа үзенең тормышына шөкерана кылып, улы-килене, оныкларына рәхмәт укырга, безгә эшебездә уңышлар, үзебезгә бәхет-куанычлар теләргә дә онытмады. Мәдәнә авылының Ак әбие белән очрашу-танышу күңелебездә якты хисләр, матур тәэсирләр калдырды.

**Сафаҗай (Сабачай)** авылы бу яклардагы иң борынгы татар авылларының берсе. Риваятьләр буенча, авылга Алтын Урда дәверендә Әстерхан һәм Касыйм якларыннан килеп ур-

нашучылар нигез сала. Шул рәвешле, Сафаҗай авылының килеп чыгуы XIV–XV йөзләргә нисбәт ителә. Документаль чыганакларда авыл исеме беренче тапкыр 1630 елда, хезмәткә билгеләнеп, җир бирелгән кешеләр (служилые татары) турындагы мәгълүматка бәйле рәвештә искә алына.

Сафаҗай авылы һәрвакыт – барлыкка килгән көненнән алып бүгенгә кадәр – үзенең гыйлем ияләре белән мәгълүм авыл. Бу авылда туып-үскән мәгърифәтче галим Хөсәен Фәезхановның исеме бөтен татар дөньясына мәгълүм. Галим 1860 елларда Санкт-Петербург университетында гарәп теле һәм төрки телләр, каллиграфия һәм чагыштырма лингвистика фәннәрен укыта. Татар халкының этногенезын, тарихын, төрки халыклар тарихын өйрәнә. Хөсәен Фәезханов, бигрәк тә, белем бирү системасын үзгәртүгә, европалаштыруга, укыту программасына дөньяви фәннәр кертүгә багышланган хезмәтләре белән мәгълүм. Хөсәен Фәезхановның туганы Габделгалләм Фәезханов та тирән белемле, икътисад буенча фәнни хезмәтләр язган кеше буларак тарихка кергән.

Сафаҗай халкының иң яратып сөйли торган, күп санлы риваятьләренә кергән шәхесләре – Хәбибулла ишан яки шәех һәм аның уллары, оныклары, мөритләре. Хәбибулла Әлмөхәммәтов башта Бохарада, аннары Казанда укый. Казанда Ш.Мәрҗани һәм Х.Фәезхановлардан белем ала. Сафаҗайга кайткач, мәдрәсә сала. Балалар укытудан тыш, медицина белән кызыксына. Хәбибулла хәзрәткә төрле чирләрдән дәва эзләп бик ераклардан килгәннәр.

Хәзрәтнең төрле җимеш агачлары, чәчәкләр үстергән бакчасы да риваятьләргә кергән. Хәбибулла Әлмөхәммәтовның сигез баласы була, күбесе гомерләрен балаларга белем бирүгә багышлаган. Хәбибулла хәзрәтнең олы улы Мухсин (Мухисинәт) хәзрәт тә атасының эшен дәвам итүче була. Ул мәдрәсә җитәкли, җәдитчә белем бирүгә корылган сигезьеллык мәдрәсәгә нигез сала, кешеләрне дәвалый, биология белән кызыксына. Мухсин хәзрәт танылган селекционер И.Мичуриннан яңа сортлы җиләк-җимеш агачлары алдырып зур бакча үстерә, умартачылык белән шөгыльләнә. Хәзрәтнең әлифба төзүе һәм балалар өчен китаплар язуы да билгеле.

Хәбибуллиннар династиясеннән 40 тан артык укытучы, зур галимнәр чыккан.

Бүгенге көндә Сафаҗай – 2500 кеше яши торган заманча матур авыл. Авыл халкы үзеннән чыккан укымышлыларны җылы сүз белән, хөрмәтләп искә ала, алар белән горурланып яши. Үзе дә Мухсин хәзрәтләр нәселенең килене булган Фәимә апа (Муксенятова Фәимә Абдрахман кызы, 1947 елгы) безгә шактый гына риваятьләр сөйләде.

### *Авыл тарихыннан*

*Безнең авылда иске каберлек бар, ул авылга беренче булып килгәннәрнеке. Әстерхан ягыннан сигез баба килә. Биредә чуваш авыллары була. Чуваш кызларын ислам диненә кертеп аларга өйләнәләр. Бабаларның дүртесе өйләнгән, дүртесе өйләнмәгән була. Чувашлар бу җирдән күчеп китәләр.*

*Иске зиратны сукаларга телиләр, әмма сукалый алмыйлар, сука төрәннәре сына.*

### *Хәбибулла хәзрәт*

*Хәбибулла хәзрәт Казаннан укып кайта. Пароходта кайтканда аны суга аталар. Карасалар, ул батмаган, һава куыгы эчендә икән. Пароходка кире күтәрәләр. Бөтен кеше өстендәге киеме дә юешләнмәгәнен күрә. Хәбибулла хәзрәт үзен суга бәргәннәрен дә белми.*

*Хәбибулла хәзрәт гарәп хәрефләрен сөйли торган хәрефләр, дип атый торган була. Ул 15 яшендә хәреф танымаган. Аннары үзлегеннән укырга өйрәнгән. Аның үзлегеннән укырга өйрәнүен күреп, бурлаклар Казанга укырга бирергә алып китәләр. Казанда 12 ел укый. Мәрҗани хәзрәтнең китапханәсеннән китаплар алып укый. Аннары Бохарага укырга китә. Кайткач халыкны дәвалый.*

*Июльдә һәр елны ураган була. Ул юлында бөтенесен тетә. Ураган безнең авылга керми.*

*Халык хәзрәт янына килә. Хәзрәт халыкны җыеп тау башына китә. Болыт болар турысына килә. Ишелеп йөри. Халык тәкъбир әйтә. Болыт ыңгыраша. Хәзрәт камчы белән суга болытка. Болыт икегә аерыла. Шуннан соң Хәбибулла хәзрәт сырхаулый. Әйтә, һәр гаеттә тәкбир белән чыгыгыз, халык укысын, ди. Авылга пәри кермәсен, ди. Безнең авылга ураган бер дә керми.*

*Фәимә апа авылдагы тынычсыз нигез турында да сөйләде. Бу нигезне дога өмет иткән рух тынычсызлаган икән.*

### *Муксенят бабай*

*Киләләр, әйтәләр Муксенят бабайга: «Безнең кызыбыз үгә (өйгә) керә алмый, аңа кирпеч белән бәрә», – диләр. Ярый, Муксенят бабай ызбага килә, керә. Моңа бәрми. «Хәзер кызыгыз керсен», – дир. Өстәл төзиләр. Сумар (самавыр) куялар өстәлгә. Кыз керә. Өстәлгә шап итеп мичтән алынган кирпеч килеп төшә. Барысы да чыгып китә. Муксенят бабай гына кала. Ул утыра да, әй, дир, адәм баласы, дир, кил, дир, яныма утыр, дир. Янына кеше килми, Муксенят бабай җил килгәнне генә тоя. И сүләшәләр болар. «Син кем буласың?» – дир хәзрәт. «Мин бу урамда барысының да пицләрен (мич) салган кеше. Әмма мине беркем дә искә алмый. Шуңа күрә мин бик авыр хәлдә. Миңа дога кирәк. Миңа дога кылучы юк. Мине сагынучы булмаганлыктан минем җаным да бозылды», – дир бу. «Мин дога укысам, синең җаның тынычлык табармы? Моннан китәрсеңме?», – дип сорый хәзрәт. «Мин китәм, әмма башкалар бу йортны тутырып торырлар. Бу шундый урын», – ди. Кем генә тормасын, бу нигездә яши алмый. Ул урында йорт та бетә. Хәзер берәү дә йорт салмый.*

*1921 елда бик каты корылык, ачлык була. Хәзрәт урманга барып кизләү казый. Шуннан кайтканда яңгыр ява.*

### *Куй суы мулласы*

*Бервакыт Куй суы авылының мулла өен талаганнар. Көзгеләрне, самавырларны алып китәләр. Шул вакыт җил-давыл чыга, бөтен урланган әйберләрне алып кире урынына кайтарып куя.*

### *Су анасы*

*Бервакыт абзый кайтып килә икән. Караса, берәү судан сикереп чыга. Бер карасаң бүре кебек тә ди, шул ук вакытта хатын-кыз кебек тә икән. Нәрсә булды соң бу дип, яңадан әйләнеп килсә, су анасы чәчен тарап утыра икән.*

**Яңа Мочали.** Галимнәр авыл исеменең килеп чыгышын маҗар кабиләсе исеме белән бәйлиләр. Риваятьләргә караганда, Яңа Мочали авылын Касыйм ягыннан күчеп килүчеләр нигезләгән.

Хәнәфи абзый (Гыймранов Хәнәфи Абдулхак улы, 1944 елгы) үзләренең башка тирә-як авыллардан аерылып торуларын билгеләп үтте: «Без ак тәнлерәк, ямьлерәкләр без», – диде ул.

Авылның бүгенге көне, халкы, йола бәйрәмнәре турында Хәсәнова Роза Хәнәфи кызы (1975 елгы, мәктәп директоры) һәм Низаметдинова Рамилә Ярулла кызы (1974 елгы, китапханәче) эзлекле итеп сөйләп бирделәр. Информантлар, яшь булуларына карамастан, им-томнарны да, йолаларны, ышану-ырымнарны да яхшы беләләр.

### *Әүлияләр кабере*

*Безнең авыл янында «Әүлия кабере өсләре» дигән изге җир бар. Алар Иван Грозный узган вакытта аңа каршы, чукындырылуга каршы көрәшкәннәрнең кабере. Иван Грозный Мочалигә керә алмаган. Халкы мөселман булып калган. Халык әүлияләрне җиде булган дип тә сөйли. Хәзер кабер өстенә ташлар куелган. Бирегә ераклардан киләләр. Бер баласы булмаган кеше килеп өч куй суя, шуннан соң баласы туа. Теләк кабул булсын өчен әүлияләр каберен җиде тапкыр әйләнергә кирәк.*

### *Йорт анасы*

Йорт анасы һәр ызбада була. Яңа йортка күчкәндә Йорт анасын да күчерәләр. Йорт анасы күчсен өчен иске йорттан яңа йортка ухватка атланып барырга кирәк.

### *Мунча пәрие*

*Мунча пәрие дә һәр мунчада була. Аларның вакыты төн. Төнге уникедән соң мунча керергә ярамый. Мунча пәриенең зәхмәте тияргә мөмкин.*

**Краснай** авылы исеменең килеп чыгуын биредә үскән кызыл тал белән бәйләп аңлаттылар. Бу агачлар авылга кызыл төс биргән, ул бер утрау булып аерылып торган. Красный Островта бу якның фольклоры, йола-бәйрәмнәре турында укытучылар – Гүзәл

Әхәт кызы Азизова (1957 елгы) һәм Кадрия Сәяр кызы Армиханова (1959 елгы) сөйләде. Зөһрә ападан (Сөләйманова Зөһрә Билал кызы, 1937 елгы) авыл җырлары, түмә (төймә) такмаклары язып алдык. Татар халык җырларының сүзләре мәгънәле, көйләре матур, тагын бер тапкыр халыкның тапкырлыгына, татар теленең байлыгына, сыгылмалыгына сокланабыз.

*Агыйделкәй алкын, суы салкын,*
*Барма якын, дулкын какмасын.*
*Бер битеңдә кояш, берсендә ай,*
*Яман күздән Ходаем сакласын.*

Зөһрә апа бу якның үзенчәлекле туй йолалары, яшьләр һәм балалар уеннары турында сөйли.

**Чүмбәли** – Мәдәнә елгасы буенда урнашкан төзек, матур авыл. Авылда заманча яңа йортлар белән рәттән, революциягә кадәр салынган берничә борынгы йорт та сакланган. Чүмбәли – татар халкының мәшһүр җырчысы Хәйдәр Бигичевның туган авылы. Авыл атамасын бу авылга нигез салган Вәли исемле кеше белән бәйләп аңлаталар.

### ***Чүмбәли***

*Безнең Чүмбәли шуннан килә. Бер егет булган Чүмбәли* (Чын Вәли) *атлы. Ул Мәдәнә елгасы буенда яшәр өчен уңайлы урыннарны күреп биредә авыл корырга уйлаган. Авылга аның исемен бирәләр. Бу сүз картлардан килә.*

*Шәрәпов Мансур Мостафа улыннан (1929 елгы)*
*язып алынды*

Рәйхана апа (Мусина Рәйхана Аббас кызы, 1927 елгы) гомере буе укытучы булып эшләгән. Ул хәзер балалар аз булуга көенеп, 1952 елда Чүмбәли мәктәбендә меңнән артык бала укуын искә төшерә. Рәйхана апа халыкның йола-бәйрәмнәре, уеннары турында сөйләде. Туй йолалары «кыз күрендерү», «кияү күрендерү», «кыз бирнәсе», «кияү келәте», бала туу һәм бәби чәе, гает бәйрәмнәре белән бәйле йолалар, яшь киленне сынаулар турында мәгълүмат бирде, бәйрәмнәрдә нинди ризыклар әзерләнүен дә тәфсилләп сөйләде. Бу якларда һәрбер бәйрәм табынына умак (коймак), күптермә, төче күмәч куелган.

### ***Яшь киленне сынау***

*Киленнең һәрбер эшенә бик әһәмият бирәләр иде. Килен идән юганда ничек юганын карыйлар. Мунчаланы турымы йөртер, әллә болгапмы? Тактаны буйдан буйга юса, уңган килен булачак, диләр. Әгәр дә болгап эшләсә, идәнне дә юа белми, болгап бетерә, диләр.*

*Эл еккеләр икмәк бастырганнар. Зур куашняда икмәк басканнар. Килен беренче тапкыр икмәк пешергәндә шуның эченә сала булганнар көмеш акча. Баскан вакытта шул акчаны таба алса, димәк, килен уңган була, ул камырны баса белә. Камырны үзләтә. Әгәр таба алмаса, ул килен уңмаган булыр имеш. Камырны үзләтә алмады.*

*Килен кеше – ким кеше, дигәннәр. Кил ен килгәч, гел сынаганнар. Киленгә башкалар белән бер өстәлдә ашарга ярамый, кайнагасы алдында сүләргә ярамый, беләкләре күренмәсен, йөзен каплап торсын.*

### ***Күптермә***

*Күптермә белен кебек була. Тары ярмасын юып, сөттә бүрттерәсең. Ул бераз пешә, бүртә, үтә пешми. Аннан аны суытып, йомырка, май, шикәр комы, чүпрә, он, тоз салып болгатасың. Камыр куе түгел, коймак камыры кебек була. Ике сәгать ачый. Купы (аш чүмече, половник) белән майлы табага саласың, җәелеп китәргә тиеш. Элек мичтә, утка каршы пешерә идек. Хәзер духовкада пешерәбез.*

**Куй суы** атамасының килеп чыгуын галимнәр мордва теленнән кергән дип аңлаталар. Мордвалар авыл буендагы елгачыкны «кууси-ва» дип атаганнар. Татарлар бу атаманы татар теленә яраклаштырып һәм мәгънә бирергә омтылып Куй суы дип үзгәрткәннәр. Куй суы авылы бу төбәктә иң беренче ачылган мәчет-мәдрәсәләргә бәйле рәвештә мәгълүм авыл. Куй суы мәдрәсәсенә 1762 елларда (бу якынча дата, 1806 ел дигән версия дә бар) нигез салына. Аның беренче указлы имамы һәм мөдәррисе Абделҗәлил хәзрәт була. Мәдрәсәгә укырга башка авыллардан да киләләр. Дин нигезләре белән беррәттән гарәп һәм фарсы телләре, арифметика да укытыла. Куй суы халкы Абделҗәлил хәзрәтнең оныгы Садек абзый турында риваять-легендалар

сөйли. Садек абзыйның да төп эше мәдрәсәдә балаларга белем бирү була. Соңрак ул ишан була. Озак еллар узуга карамастан, авыл халкы бу кешеләрне онытмый, зур хөрмәт белән искә ала. Абзыйлар яшәгән нигезгә хәзер дә халык барып йөри. Бирегә нәзер әйтеп, төрле проблемаларны чишүдә ярдәм сорап, ераклардан киләләр. Садек абзый турындагы истәлекләрне һәм изге нигез турында шушы йортта яшәүче Зөбәйдә апа (Мирсияпова Зөбәйдә Җамалетдин кызы, 1936 елгы) сөйләде.

### *Садек абзый*

*Садек абзый бик изге кеше була. Ул кешеләрнең нинди уй белән килгәннәрен дә белеп торган. Ул үлгәндә әйткән, мин булмам дигән, ишегем бикләнгән булса, дигән, теләкләрегезне әйтеп туфрагыма килсәгез дә теләгегез кабул булыр, дигән. Ихлас күңел, яхшы уй белән сорасагыз, барысын да бирә. Мәскәүнең әүвәлге муллалары бу йортта укып чыкканнар. Үлгәненә ике йөз елдан артык. 41 яшендә үлгән. Ике баласы булган.*

*Ике тапкыр хаҗга барган. Беренчесендә ялгыз барган. Аннан әнисе әйтә, улым, ди, син хаҗда булдың, ди, мин, үләрмен озакламый, хаҗда булмадым, ди. Садек абзый әнисен аркасына асып икенче тапкыр хаҗга чыгып китә. Ике ел ярым барганнар.*

*Биредә аның караваты, өстәле, креслосы үзе ясаган. Дисбесе, сондыгы да үзенеке. Аларны хаҗдан китергән. Ул сондык белән китергән булган төрле үләннәр, шулар белән дәвалаган.*

*Балалары булмаганнар күп килә. Татарлар гына түгел, башка халыклар да килә. Балалары туа.*

*Нәрсә кирәк, караватына тотынып сорарга кирәк, ихлас күңел белән, кешеләр морадларына ирешә.*

Бу авылдагы икенче информантыбыз – Роза апа (Зиннәтова Роза Хәсән кызы, 1937 елгы). Ул хәзер Горький шәһәрендә яши, авылга җәйге ял вакытында һәм бәйрәмнәрдә генә кайта. Роза апа Су анасы, Әздака турында сөйләде. Ул башкарган җырны да без биредә беренче тапкыр ишеттек. Озын көйгә башкарыла торган бу җыр бәлки җырчылар репертуарында да урын табар дип ышанасы килә.

### ***Киндерләр җәйдем кибәргә genә***

*Киндерләр җәйдем кибәргә генә,*
*Яңгыр булмаса, кибәрләр генә,*
*Яңгыр булмаса, кибәрләр генә.*
*Бу хәсрәтләрдән үләргә генә,*
*Ходаем үзе бирмәсә ярдәм,*
*Ходаем үзе ярдәм бирмәсә.*

*Карай урманның урталарында*
*Кырау сукмасмы яшел мәләшне,*
*Кырау сукмасмы яшел мәләшне.*
*Үзебез яшьләр, йөрибез сәфәр,*
*Ятлар сөймәсме безнең кәләшне,*
*Ятлар сөймәсме безнең кәләшне.*

*Безнең асларда, түгәрәк күлләрдин*
*Сукмакларындин сары су ага,*
*Сукмакларындин сары су ага.*
*Безнең сөйгәннәр тәрәздин бага,*
*Маллар юклыктин ятларга кала.*
*Үзем егъламыйм, күздән яшь ага.*

### ***Әздака***

*Бер хатынның ире үлә. Ул көне-төне ирен уйлый, бик елый. Аңарга әздака ияләшә. Ул төнге сәгать уникедә елан булып трубадан төшә. Ире кыяфәтендә гостинцалар китерә, бага, анда гостинцалар түгел, куян тизәге. Синяклар белән йөри инде бу хатын. Бу түзми, иренең сеңлесенә сөйли. Шуннан теге тагын төшә. Суга бу хатынга. Шуннан бу хатын Коръән укыта. Теге китә бөтенләйгә.*

Бу якларда **Семочки** авылында булган фаҗигале хәлләрне белмәгән кеше юктыр. Ул вакыйгаларга гасырга якын вакыт үтсә дә, авыл хәтерендәге тирән яра әле дә төзәлмәгән, аннан һаман да кан-яшь саркый кебек. Шулай булмый мөмкин дә түгел. Бу фаҗига берәүне дә читләтеп узмаган, күп гаиләләр аталарын яки улларын югалткан. Продразверстка елларының канлы фаҗигасе дә авыл тарихына язылган.

### ***Шәһидләр кабере***

*51 кешене аталар ул көнне. Продразверстка отрядлары авылны талап йөриләр. Кемнең тавыгын, казын, сарыгын күрсәләр, әйтәләр, бүген без сездә ашыйбыз, диләр. Кешеләрнең киемнәрен, туннарын салдырып алалар, соңгы казаннарын яки самоварларын алып чыгалар. Авыл бай була. Волостной авыл.*

*Бер вакыт яшьләрне учебкага җыялар. Красная армия өчен. Шул яшьләр занятие беткәч таудан төшәләр. Шул вакыт отряд бер йортны талый. Яшьләр шуңа туры килә. Отрядтагы берәүне үтерәләр. Башкаларын кыйныйлар. Продразверстка отрядына ярдәм килеп җитә. Авылны чолгап алалар. Активный участникларны «без суда и сл едствия» шул көнне үк аталар. Январь аеның салкын көне була. Атылганнарны эчке киемгә калдырып чишендереп, урамга чыгарып ташлап баралар. Икенче көнне муллаларны, хәллерәк кешеләрне ату дәвам итә.*

*15 январьда мәрхүмнәрне авыл зиратыннан ерак түгел, юл буена, елга янындагы уйсу җиргә җирлиләр. Язын ташу вакытында бу кабер су астында калырга тиеш була. Әмма шул яз елга ярларыннан чыгып яңа юл яра, туганнар каберен урап уза. Бу урынны «40 мулла күмелгән җир» яки «шәһидләр кабере» дип атыйлар.*

### ***Хәйретдин мулла***

*Хәйретдин муллага әйтәләр: «Корәнне аяк астына салып таптасаң, без сине җибәрәбез», – диләр. Ул: «Семьям белән барып күрешим, сөйләшим», – ди. Җибәрәләр. Өенә кайта күрешергә. Өендә әйтә: «Юк, шәһид булам, таптамыйм», – ди, бәхилләшә. Кире бара, аталар аны.*

*Семочки авылында Абдуллина Хава*
*Абдулла кызыннан (1932 елгы) язып алынды*

**Бозлау** авылының «бәйрәм-сабантуйлары», халыкның йолагадәтләре турында, озак еллар шушы авылда колхоз рәисе булып эшләгән Салихҗанов Рамил Әхмәт улы мәгълүмат бирде. Авыл халкының элекке җитәкчесенә хөрмәте зур. «Безнең Рамил», «Безнең матур Рамилебез», – дип сөйлиләр аның турында. Үзе дә һәр әби-бабайның, һәр баланың хәлен сорап, һәр кешенең

шатлык-кайгысын белеп, уртаклашып яши ул. Рамил абый авылны яратып, авылдашлары белән горурланып сөйли. Горурланмаслык та түгел. Мәчет картларының мәчеткә җыелган хәерне шифаханәгә дарулар алырга, картлар йортына, авылга газ кертергә, Сабантуйлар уздырырга бирүләрен кайда күргәнегез бар?! Сабантуйны бу авылда һәр елны икешәр көн бәйрәм итүләре турында да яратып сөйләде ул. Сабантуйның беренче көнендә кунаклар кайта. Бу көн мәрхүмнәрне искә алу көне. Авыл халкы да, кайткан кунаклар да башта зиратка баралар. Зиратны, кабер өсләрен чистартып, хәтем укып кайталар. Нәзер корбаннары да шушы көнне суела. Икенче көн – кунак көне. Иртәнге уннан 3–4 ләргә кадәр кунакка йөрү башлана. Башта берсенә, аннары икенчесенә, туганнарга, дусларга, күршеләргә. Шулай туганлык җепләре яңартыла, яңалыклар сөйләшелә, алып кайткан күчтәнәчләр тапшырыла.

Дүртләрдә Сабантуй башлана. Көрәш сәгать тугызларга кадәр дәвам итә.

Бозлау авылының бу күркәм традицияләрен башка төбәкләр дә кабул итсен иде.

Түбән Новгород өлкәсендә бай һәм кызыклы фольклор материаллары җыеп гына түгел, кунакчыл, эшчән, күркәм халкы белән танышып кайттык. Халыкның телне саклавына соклandык. Мәскәүдән каникулга кайткан балаларның татарча сөйләшүләрен ишетү дә күңелгә хуш килде.

**Ыргу** авылында Рәхимә апа (Садекова Рәхимә Билал кызы, 1950 елгы) 1970–1971 елларда магнит тасмаларына яздырып калган бәет-мөнәҗәтләрен яздырганнан соң, Мәскәүдән кайткан кунак кызы Диләрә (Хәярова Диләрә Илдар кызы, 1998 елгы, 6 сыйныф укучысы) дә, безне сокландырып, балалар өчен язылган берничә татарча җыр башкарды.

**Актук** авылына кунакка кайткан балалар берсен-берсе уздырып авыл янындагы «Тораташ» турында сөйләделәр. Халык иҗаты яшәвен дәвам итә, традицияләрне сакларлык яшьләр үсеп килә.

# АУЛАК ӨЙЛӘРДӘН – САБАНТУЙ МӘЙДАННАРЫНА

## *Сергач татарларының йола һәм уен фольклоры*

*Илһам Шәрипов*

Һәр милләтнең үзенә генә хас бәйрәмнәре, йолалары, кабатланмас гореф-гадәтләре бар. Алар халыкта милли горурлык, милли хисләр культурасы тәрбияләргә ярдәм итә. Татар халкының бик күп йолалары халык хәтерендә, өлкән буын кешеләренең истәлекләрендә сакланып килә. Бу хәзинәнең зур өлеше инде, кызганыч, гадәти көнкүрештә кулланылмый да.

Халык иҗаты җәүһәрләре төрле экспедицияләр барышында халыкның үзеннән өйрәнеп, тел осталары һәм йола белгечләреннән, авыл хәтерен саклаган абруйлы кешеләрдән сөйләтеп теркәлә, фәнни әйләнешкә кертелә. Менә шул максат белән бик зур киңлекләргә сибелеп утырган татар халкының төрле төбәкләреннән халык йолаларына караган мәгълүматлар җыйнала. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан татарлар яшәгән төбәкләргә махсус план буенча, нәтиҗәле экспедицияләр оештырылу соңгы елларда аеруча активлашты. Татарлар күпләп яшәгән Түбән Новгород өлкәсендә булган шундый экспедицияләрнең берсендә катнашу минем үземдә дә онытылмас тәэсирләр калдырды.

Нижгар татарлары (ягъни сергач мишәрләре) өлкәнең көньяк-көнчыгыш өлкәсендә бергә тупланып яшиләр. Түбән Новгородта алар шактый зур диаспора тәшкил итәләр. Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, Мәскәүдә яшәүче татарларның

40 проценты «сергач мишәрләре». Әйтүләренә караганда, алар иҗтимагый тормышта бик актив катнашмасалар да, чит халык арасында югалмаска, милли йөзләрен сакларга тырышалар. Мәскәүдә тамыр җибәреп яшәгән икенче яки өченче буын Казан яки Уфа татарын күрү авыр, ә «сергач мишәрләре» шунда аяк терәп татар булып яшәргә тырыша. Чыннан да, Түбән Новгород якларында яшәүче милләттәшләребез Санкт-Петербург, Мәскәү кебек шәһәрләр хакында күршедә генә урнашкан авыллар турында сүз барган кебек сөйлиләр. Алар өчен, бигрәк тә Мәскәү, бакча башында урнашкан кала кебек кенә.

Түбән Новгород татарларында үз язмышларын, киләчәкләрен кайгырту бар. Үзләрен алар бирeдә «җирле халык» һәм «тирән тамырлы» дип саный. Мондагы һәр кешенең йорт-җиренә исең китәрлек! Бигрәк тә ишегаллары матур, футбол кыры кебек зур. Һәр авылны берничә мәчет бизи, алардан яңгыраган азан авыл халкының динилеген белдереп аваз сала. Ә менә мәктәп, китапханәләр (һәрхәлдә без булган авылларда) беркүпме ятим калган сыман...

Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче татарларның авыз иҗаты әсәрләрендә, гомумән, халкыбызга хас булган тормыш тәҗрибәсе, рухи хәзинә, акыл зирәклеге, күңел дөньясы һәм тел байлыгы чагылыш таба.

Халык йолалары белән бәйле шигъри иҗат әсәрләрен, дөнья мәдәнияте тарихын өйрәнү традицияләренә таянып, төп ике төркемгә бүлеп тикшерәләр: гаилә йолалары һәм календарь йолалар. Борынгыдан килгән йолалар һәрвакыт серле-тылсымлы такмаклар яки җырлар белән үрелеп баралар һәм шул йоланың аерылмас бер өлеше, аның төп бизәге булып торалар. Аларда халыкның борынгыдан килгән ышанулары, күзаллаулары чагыла. Сергач мишәрләре фольклорында әнә шундый бик борынгы чорларга караган ырымнар да сакланып калган.

Ырым, им-том – тылсымлы сүз формуласы. Кешегә авыру булып кергән явыз рухны хәрәкәт һәм сүз ярдәмендә куып чыгару – ырымнарның төп мотивы. Борынгы ышанулар буенча, кеше иң күп зыянны күз тиюдән күрә. Шуңа бәйле рәвештә күз тиюгә каршы төрле ырымнар, сүз тезмәләре кулланыла. Ләкин ырымнарны безгә төгәл сүзләре белән түгел, ә эчтәлекләрен

генә сөйләп бирә алдылар. Мәсәлән, Чүмбәли авылыннан Абдрахманова Сания (1958) сөйләгәннәрдән:

*– Бер күршемә кергән идем, балалары елый-елый. Алар тотындылар: «Күзекте, күзеккән-күзеккән!». Савытка су алды апа и суга мана уцын, өстәлләрнең цитләрен себереп цыкты, и ишек бавын барып юды, баланың битен юды шул су белән. Өшкерәләр, төкерәләр дип әйтәләр инде.*

Сафаҗай авылыннан Зөфәр (1942) һәм Мәгъсүмә (1948) Мөхәммәтовлар сөйләгәннәрдән:

*– Кемнең күзе тигәнен белсәләр, аның авызыннан су салдыралар иде, цайкап, вот су кабасын, цайкий да сала өц мәртәбә. Ул суны оланга эцерәләр иде. Или нәстәсендер кисеп алып тетәштерәләр иде. Минем дүрт айлык туганым күзегеп үлгән иде. Кемнең авызыннан су алырга катып йөрдек, килмәде таки, мәскәүче кыз. Сразу иртән күзекте, кичен үлде.*

Баланың теленә ак төшеп, ул сөйләшә алмый башласа, камыр басып аны икегә бөкләп кисемнәр кискәннәр һәм:

*Ни кисәм, гөмбә кисәм,*
*ни кисәм, гөмбә кисәм, –*

*дип кисәләр, и бала телендә була иде ак ниләр и шулар бетә иде. Ярдәме бар иде аларның,* – дип сөйләде Краснай авылыннан Әнисә Җаппарова (1935).

Ырымнарның иң зур күпчелеге төрле авырулардан дәвалау өчен кулланыла. Бала куркып калса, аны дәвалау өчен «курку коярга» кирәк булган. Моны махсус кешеләр генә башкара алган. Бу турыда безгә Рбишча авылыннан Җамалия Ибраһимова (1923) сөйләде:

*– Куркуны койганда алар кургашин эреткәннәр, аннан соң инде аның шул үзенең йоласы булган:*

*Эзлим эзләр җиреңнән,*
*Каян килгән җиреңнән,*
*Эзлим җирдән, эзлим җилдән,*
*Эзлим җирәннән...*

*Шул сыйфатың белән күз алдыма кил диеп, суга кургашын тамызганнар и аннан нинди сыйфат барлыкка килгән, ул*

*нәрсәдән курыккан, эт сыйфатымы, кеше сыйфатымы. Вот шул сыйфат буенца аны инде өшкереп дәваларга тырышканнар. Бозыклар бар, кеше адашып китә яисә кинәт үзен-үзе тотышы үзгәрә, дорфалана, вот аларга инде курку койдырганнар. Анда инде тоң китаптан файдаланганнар, алар төнге сәгать уникедә өч юл чатына укып өшкереп, тозлы суны коя торган булганнар.*

*Тимерәү, күзгә арпа цыкса, аның да йолалары бар. Аны кояш баеганда шуны өц тапкыр укып, бисмилла әйтеп басалар арпаны.*

Ырымнарның төп үзенчәлеге – сүзнең яки билгеле бер хәрәкәтнең, гамәлнең тылсымлы, мәгънәле, магик көченә ышану.

Календарь йолаларның татар халкы өчен, кайсы төбәктә генә яшәмәсен, иң таныш булганы һәм иң киң таралганы Сабантуй. Элек Сабантуй бәйрәме сабанга чыгу, тантаналы шартларда беренче бразна яру, чәчүне башлап җибәрү белән бәйләнгән булган, соңрак ул язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелә башлый. Хәзер исә махсус билгеләнгән, алдан ук мәдәни чаралар планында күрсәтелгән көндә, җәй башында үткәрелә. Безнең көннәрдә, күрәсең, авыл хуҗалыгы тармагындагы озакка сузылган кризис белән бәйле рәвештәдер, (ә «сергач мишәрләре» исә, гомумән, исәпчел халык) Сабантуй акрынлап үзенең борынгы үзенчәлекләрен югалта бара. Бүген Сабантуй мәйданында профессиональ артистлар билгеле бер сумма гонорар хисабына чыгыш ясый, профессиональ спортчылар спортның төрле төрләре буенча көч сынаша, кыйммәтле бүләкләр ала. Шулай итеп, элек-электән халыкныкы булган, нәкъ менә авыл кешеләренең моңын, көч-куәтен күрсәтергә тиеш булган милли бәйрәм – ясалма концерт, спорт ярышлары төсен ала бара. (Кызганыч, мондый «профессиональ Сабантуй» башка төбәкләргә дә керә инде).

Әлбәттә, авыл халкын бергә җыю, шәһәр халкын туган ягына тарту, өлкән буын белән яшь буынны, элекке дусларны, танышларны очраштыру өчен бу бик мөһим, әһәмиятле һәм кирәкле вакыйга. Халыкта ул шушы формада булса да яшәргә тиеш.

Татарлар яшәгән зур авылларда, мәсәлән, Рбишча (Рыбушкино), Сафаҗай (Красная Горка), Татар Моклокасы (Татарское Маклаково) авылларында бу бәйрәм зур тырышлык белән уздырыла, диделәр. Кызганыч, без анда катнаша алмадык.

Элек, кагыйдә буларак, җәйге кыр эшләре беткәч, көннәр кыскаргач, ягъни көзге һәм кышкы озын-озак кичләрдә татар авылларында аулак өйләр уздырылган. Сергач мишәрләрендә бу йоланы «вечер» дип йөртәләр.

Өлкән буын ул йоланы бүген дә сагынып, горурланып, яратып искә ала.

Петрякс авылыннан Сәяр Сабиров (1924):

*– Вечеркалар бар иде, Казанда аулак өй диләр. 1930 елда клуб та ацылды, ләкин халык анда йөрми иде, вечеркаларга йөри иделәр. Анда потому что кешеләр үзләрен иркен тоталар. Хозяин китә кунакка, аның кызымыдыр, малаемыдыр яшә кунакка, шулай кызлар да, малайлар да йырлашып утыралар иде. Ашсыз, чәйсез. Вечеркалар кыш көне дә, җәй көне дә булалар иде. Җырлап утыралар, аннан уеннар уйныйлар бүлмә эчендә, төймә такмаклары әйтәләр. Күз бәйләш, тычкан тагыш уеннары уйныйлар иде.*

Рбишча авылыннан Факия Ситдыйкова һәм Җамалия Ибраһимова (1923):

*– Аннан вечерлар була иде. Даже менә сугыш вакытында үткәрәләр иде, например, бүген миндә чират, сезгә җыелабыз, дияләр иде. Һәммәсе култык астына киемен кыстырган, туфлясын алган, әле күлмәкне кешедән дә алып торалар иде, монда килгәч тиз генә ышыкта киенә. Анда гармун тарталар, бииләр, җырлыйлар, егетләр булмаса да. Анда һәрбересе үзенең ашын китерә, ит кисәгеме, шикәренме. Ашлар пешереп шунда сәгать дүрткә кадәрле, төн буе шулай вечерда утыралар иде. Эштән соң үзләренә үзләре күңел ацканнар инде. Иртән укытырга барасың, йокламаган, гармун тавышы колагымда тора...*

Вечерларда җырлау, бию, кара-каршы җыр әйтешү, уеннар иң зур урынны алып торган. Мәсәлән, «Номер», «Ремень сугыш», «Байкал күле», «Күрше» уеннарын яратып уйнаганнар. Сафаҗай (Красная Горка) авылыннан Әлфия Исхакова (1959) безгә «Ремень сугыш» уены турында сөйләде:

*– ...Һәр кешегә айтәләр номер, мәсәлән ике, дүрт, алты и т.д. и бер урын буш кала. Вот шунда килеп ремень белән суга да һәм ике якта утырган кеше айтергә тиеш нинди дә булса номер, ә ул номердагы кеше тиз генә килеп утырырга тиеш, тиз генә килеп*

*утырса инде яхшы. Әгәр дә инде задержать ителсә, аны ремень белән сугалар, наказать итәләр.*

Иң кызыклы уеннарның берсе – «Байкал күле» (кайберәүләр аны «Бака түшәге» уены дип атады). Бу турыда безгә Рбишча авылыннан Факия Ситдыйкова белән Җамалия Ибраһимова (1923) сөйләде:

*– Бака түшәге уйный булганнар. Уртага кызны чыгаралар, утырталар урындыкка, аннан аны батыралар җырлар белән:*

*Баттыңмы, баттыңмы,*
*Баттыңмы, күмелдеңме?*
*Бака түшәгенә ятып*
*Торуы күңеллеме?*

*Аннан аның егете булса арада, ул егет җырлап аңарга, мәсәлән, анда «люблю тебя», «возьму себе», «не забуду никогда» диеп йырлый да ул кызны тартып чыгара, аның җырлары бар тагын:*

*Кулларымда, кулларымда,*
*Кулларымда чемодан;*
*Мин бит сине яратамын,*
*Бир бер кулың чыгарам.*

*Менә шундый җырлар, әгәр яратса; ә яратмаса – ул батырырга гына тырыша инде. Ул җырлар инде исемдә түгел. Әгәр инде тартып цыгармасалар, аны батыра гына баралар, аннан башкасы цыга, менә шулай уен дәвам итә.*

Бу уенның җырларын Яндавишча авылында Флера Ганеева (1938), Зәйтүнә Хәсәнова (1939), Рафия Сәлахова (1937) апалар җырлап күрсәтте:

Әле Байкал өсләрендә,
Төпкә киткәч, нишләрсең,
Кулларыңа кучарга алып,
Кочегарым эшләрсең.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр папирус,
Моны кем дә чыгара алмас,
Китерегез паравоз.

Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр семечка,
Байкал күленнән чыгарам,
Бир кулыңны, Сонечка.

Байкал күленең буенда
Балык тотып утырам,
Ике кулыңнан да тотып.
Тирәнерәк батырам.

*Атымны бәйләп куйдым*
*Азык юктан казыкка,*
*Без бу кызны батырабыз*
*Бакаларга азыкка.*

*Байкал күлләрендә төптә*
*Бакалар тотып аша,*
*Бака сүәкләрен җыеп,*
*Үзеңә салат яса.*

*Ерактан ук күренеп тора*
*Киноның афишасы,*
*Киттең, буй кыз, бакаларга,*
*Бакалар падишасы.*

*Галстук-костюм кияр булсаң,*
*Чалдырдатып сындыргач,*
*Байкаллардан тартып алам,*
*Бир кулыңны, сандугач.*

*Сәүдитләргә барсаң әгәр,*
*Ал кулыңа чемодан,*
*Табын чәеңә чакырсаң,*
*Үзем тартып чыгарам.*

Факия апа Ситдыйкова мәхәббәтне, егетлекне сыный торган «Күрше» уены турында да мәгълүмат бирде:

*– Парлап утыралар иде и сорыйлар «күршең белән яхшы торасыңмы?» Берәү инде каты гына кулына ремень тотып шартлатып йөри, әле берсе янга килә, күршең белән яхшы торасыңмы, яхшы торам, күршесен алырга тели, юк бирми, кулын суза, кулына шыпылдатып ремень белән сугалар, кыйныйлар, ул түзә, ярата, димәк кызны.*

Вечерларда уеннар ярдәмендә кызлар үз язмышларын да сынаганнар. Бу турыда безгә Камка авылыннан Зөһрә апа Абдюханова (1935) сөйләде:

*– Җанихәй – Камка авылы җыры. Аны әвәл вакытта әтиәниләр кунакка киткәч, кыз балалар шул ызбага җыелып җырлаган. Элек вакытта, бик борынгы заманда, кемгәдер күңел саласың, сиңа кемдер күңел сала, кемгәдер кемдер ошаган, и знаете бит, кемдер ошаса, особенно кыз кеше, уйлап торасың шул кешене, ә мине күрдеме икән, ә мине ярата микән. Алар шул җыелышып, өстәл артында утырып Җанихәй әйткәннәр. Аны бер кыз йырларга тотына да, бармаклары белән йөртә, нинди сүз туры килә, шул тормышка аша дип уйлаганнар, туры килсә, сөя дигән сүз, значит, ул аны сөя. Мондый җырлар:*

*Тәрәзә төбемдә юуыйм агым,*
*Алтын ука чорнап куймадым.*

*Уйладым да гына, әй уйладым,*
*Уйлаган, әй ярыма булмадым,*
*Уйлаган ярыма булалмагач,*
*Төнен уйанып йыладым.*
*Пьяна буеның, әй, яр башы,*
*Шунда юдым дөге ярмасы.*
*Теләгән яр гынам миңа булмас,*
*Үз яры бар алтын алмасы.*
*Үз яры бар, әй, алмасы,*
*Сизелә күңел миңа, әй, салмасы.*
*Сандугач моңая, әй, тугайда,*
*Мин моңаям нигә бу айда.*
*Моңаймас та идем мин бу айда,*
*Җанихаем минем син кайда?*
*Җанихаеңне ятлар алса,*
*Еглауларда гына ни файда.*

Рбишча авылыннан Факия Ситдыйкова безгә кызыклы уеннар турында сөйләде:

*– Агач буралар бар иде бит. Агач бурасының эченә керә дә идек цит алыш уйный идек. Анда, мәсәлән дүрт цитле бит ул, дүрт цитенә берәр кеше баса, ә берсе уртага баса һәм менә шулай нитәсең, кем цит алыр тизрәк...*

*Тукмакны куясың, түгәрәкләп басалар, ә уртага чыгып берсе тукмакны әйләндерә. Тукмакның башы кемгә эләгә, ул нәрсә булса да эшли, аны әйтәләр, мәсәлән, әтәц кебек кычкырсын или анда кемне булса да үпсен.*

Календарь йола бәйрәмнәрдән аермалы буларак, гаилә йолалары үз эченә кеше гомеренең иң җитди өч вакыйгасын ала: баланың дөньяга килүен, никах туен һәм үлгән кешене җирләүне.

Бала табу һәрвакыт, һәр гаиләдә зур бәхет дип саналган. Шуңа күрә бала туу вакыйгасы төрле гореф-гадәтләр, йолалар белән билгеләп үтелгәндер дә. Түбән Новгород өлкәсе Сеченов районы Краснай авылыннан Зәйнәп Хәбибуллина (1930) һәм Сания Сабитова (1932) апалар, балага мулла исем кушканнан соң, *«аны ястыкка куеп китерәләр дә, аннан соң шул ястыкны*

*йөретәләр шул цакырылган кешеләр алдында. Ул цакырылган кешеләр шул ястыкка үзләрең китерелгән бүләкләрен куялар и акца салалар»,* – дип искә алдылар.

Баланы беренче тапкыр мунчада юындыру зур әһәмияткә ия булган. Бу як халкы «баланы беренче тапкыр кайнана коендыра иде», – дип искә ала.

Сафаҗай авылынан Яхья Әббәс улы Сәлимов (1924) сөйләвенчә, балаларны сөннәткә утыртучыны абдалчы дип йөрткәннәр:

*– Баланы сөннәт утыртканда абдалчы дияләр иде. Аны специально кеше, әти-әниләр үзләре эшли алмыйлар. Ул килеп баланы сөннәткә утырта иде. Аннан соң утыртканнан соң инде, өц көнме тагы да килеп бага иде баланы, ничек анда үтә дия авыруы инде.*

*Абдалчы бабай килеп үз эшен башкаргач, аңа рәхмәт йөзеннән сәдака, бирнәләр дә инде, күлмәкме, шундый әйберләр бирәләр иде, акцасын да.*

Гаилә йолалары арасында иң күренекле һәм хөрмәтле урынны никах туе алып тора. Туй йоласы сергач мишәрләрендә искиткеч бай, катлаулы, күпкырлы музыкаль-драматик тамаша. «Иң беренче, егет ягыннан башкода килә», – дип башлыйлар бу турыда сөйләгәндә Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче татарлар. Хәзер егет белән кыз үзләре риза булып, өйләнешү инде хәл ителгән мәсьәлә булганда да, башкода җибәрү гадәте биредә әле азмы-күпме сакланган икән. Краснай (Красный Остров) авылыннан Зөһрә Сөләйманова (1937) сөйләвенчә:

*– Башкода итеп иң ышаныцлы кешеләрне генә йибәрәләр. Ул, өстәвенә, кицен караңгы төшкәч кенә, аниләр атмешли, кеше аягы чәлгәч кенә, диерләр иде, кайтыр. Башкоданы кем дә белмәсен. Кинәт бернәрсә кил еп цыкмаса, кыз риза булмасамы, сүләшәлмәсәләрме, кил ешәлмәсәләрме, башкодалар кайтканны авыл белмәсен өцен. Бу хәбәрне алар беркая таратмасыннар өцен бик ышаныцлы кешеләр генә йибәргәннәр.*

Бу йола уңышлы башкарылганнан соң килешү эшләре башлана, ягьни никах көне, ничә кунак буласы, никах уздыруда кайсы якның күпме чыгым тотасы, мәһәр хәл ителә.

*– Безнең заманда акцалата мәһәр бирү юк иде, – ди Зөһрә апа. Туй уздырырга нәрсә кирәк шул: ит, май, он, чәй, шикәр*

*бирәләр иде. Ярты куй ит. Акцага инде ул кайнатага, кайнанага подаркалар алалар.*

Рбишча авылыннан Җамалия Ибраһимова (1923) сөйләгәннәрдән без сер бирергә яратмаган мишәр халкының хәйләләрен дә белдек:

– *Бездә хәзер кыз өчен мәхәрне 100 дә 150 мең дә биргән дип сүләшәләр, бәлки алар бер тиен дә бирмәгәннәрдер, ләкин моны кеше белми кала инде, шулай бер-берсенең хакын күтәрәләр кодалар.*

Кыз ягыннан килешү алгач, бер яктан яшьләр, якын туганнар кыз котларга төшәләр. Яшь кияү кызларга кич утырырга күчтәнәчләр алып килә. Һәм яшьләр «вечер» оештыралар. Биредә төрле уеннар уйнала. Бу уеннарны без аулак өйләр турында сөйләгәндә искә алып киттек. Татар халкының төрле этник төркемнәрендә, бигрәк тә мишәрләрдә, киң таралган, гаять тирән эмоциональ көчкә ия кыз елату җырларын, кызганыч, искә төшерә алучылар булмады.

**Задатка**

Никах туй йоласының иң изге өлеше дип санала. Ул тыныч, салмак, шау-шусыз, җай гына барырга тиеш. Мәҗлескә махсус чакырылган мулла кияүнең һәм кәләшнең вазифалары, гомер буена бер-берсенә тугрылыклы булу, гаилә кору, бала тәрбияләп үстерүнең әһәмияте турында вәгазь сөйли һәм Коръәннең дүртенче сүрәсеннән аятьләр укый. Никах укылганнан соң, егет белән кыз өйләнешкән, ир белән хатын булу дәрәҗәсенә ирешкән, дип санала һәм егет килен куенына керү хокукына ия була. Кич белән кияү мунчасы ягыла.

Краснай (Красный Остров) авылыннан Зөһрә Сөләйманова (1937) сөйләвенчә:

– *Кияү йөри кызның үэнә кунарга. Өц көн рәттән обязательно мунца ягалар. Моны киленнәр яга. Өц көн рәттән тәрәзә төбенә кияү аларга акца куеп калдырырга тиеш.*

Яшь килен кияү йортына килгәч, туй йоласы белән бәйле башка күптөрле йолалар башкарыла. Мәсәлән, чаршау печү. Зөһрә апа әйткәнчә:

– *Егет белән кызның йоклый торган урынына чаршау печеп китәләр дә, кыз төшергәндә аны юләп китерәләр.*

Сафаҗай (Красная Горка) авылыннан Саимә апа Вилданова (1925) сөйләвенчә:

*– Эленгеләр китерәләр иде, чаршау эләләр шул көнне, нәрсә бар шуны китерәләр инде, эскәтерне, кленканы, пәрдәләр китерәләр.*

Сафаҗай авылыннан Әлфия Исхакова (1959) туй вакытында «Бал кычкырту» йоласы турында сөйләде:

*– Кыз төшкән көнне шундый вакыт килеп җитә, башта ашап-эчәләр, җырлыйлар и аннан бал кыцкырту башлана. Берәр ир кеше, алар инде специальный шундый сүзләр беләләр, баллап алыгыз ди, шундый ямьле сүзләр айталар алар и сорыйлар, бу егетне сорасагыз, бөтен Татарстанга карындаш, например, бөтен Сабацайга карындаш. Аннан яшь килен белән кияүне котлап бии иң беренче кайнана, ул тырышып-тырышып бии, анарга акца салалар, кем, допустим яшь килен инде, конечно, күбрәк сала, ул зурлый кайнанасын, ә калганнары могут әзрәк бирергә. Ул значит бии, хәленнән килгәнчә. Аннан артлы-арты, ул бию инде котлау була, кияү белән кызны. Самый якыннарын башта цыгаралар, аннан инде күрешләрдә барысы да и шул вакытта вот сүзләр атәләр.*

Ыргу авылыннан Нәгыйм абзый Бәдретдинов (1946) Сергач мишәрләрендә кызның өендә уйнатыла торган «Силәзән уены» турында сөйләде. Ләкин бу уенның төгәл сүзләрен искә төшерүче һәм мәгънәсен тулы итеп аңлатып бирүче кеше бүтән очрамады:

*– Менә Сергач районының Андреевка дигән татар авылында кызның өйендә силәзән уены уйнату бар иде. Ул кыз йортында, кыз керткән вакытта, бездә бөкмә диләр инде, пелмен пешерәләр, шул пелменне ясаган вакытта кызыклы сүзләр айтеп силәзән эшлиләр. Кызыклы сүзләр айтәләр, как-будто берсе кыз, берсе малай шикелле инде сүләшәләр, айтәләр. Анда сүзләре бар да, ул әдәпсез сүзләр, алар кияү белән кызга бәрелешле сүзләр, шулай-шулай дип айтәләр, уйнаталар-уйнаталар да аннан басыштыралар, шуның белән тәмамлана.*

Өлкән буын яшь килен булып төшкәч, үзләрен ничек сынап караулары турында да искә алырга ярата. Саимә апа Вилданова (1925):

*– Кайнанам камыр бастырып карады. Мин басам-басам инде, элек бит инде киҫен катлап куя идек тә, катыра идек камырны. Басам-басам да акҫа цыкты, мин бит инде белми идем, аннары кайнанама аттем инде, камырга акҫа төшкән, кайдан төшкән икән дип, көлде шылай дигәч, ул камыр эченә акҫа салдырып калдырган булган, көмеш акҫа. Алла боерса син уңган килен булырсын, акҫаны таба беләсен, акҫа кулыңа эләккән диде. Әлеге тапкан акҫаны кайнанама бирдем, ә ул аны үсә торган бер балага бирергә кушты, сәдака иттереп. Алдагы тормышы көмеш шикелле ялтырап торсын, үзеннең дә тормышын көмеш кебек ялтырап торсын диде. Икенҫе көнне иң беренҫе суга барырга иде. Килennең суны ничек итеп алуын да карап торырлар иде. Хәзер килен сынау, суга җибәрү дигән әйберләр юк. Ә элек инде суга җибәргәннәр, су юлын күрсәткәннәр, көянтә, ҫиләкләр бирәләр яшь киленгә, суга алып баралар. Ул су китерә. Анда әле мескеннең аяклары эләгә, сулары ҫәҫри, вот шул сынау булган. Иң беренҫе, кил ен төшкәч элек бутка болгаттырып сынаганнар. Цәҫрәтмәс микән дип, кайсы инде куркына-куркына калагы да төшеп киткән кулыннан. Үз дигәннәре инде карап торганнар уңганмы, ҫулакмы, пөхтә эшли аламы. Үзенә күрә бер яраклаштыру, ярарга тырышу.*

Мәкаләдә китерелгән үрнәкләрдән күренгәнчә, берничә көнлек экспедиция дәвамында гына да халык авыз иҗаты әсәрләре аша никадәр кызыклы, әһәмиятле байлык тупланган. Бу рухи мирас тапшырылмаган хатлар булып, өлкәннәр күңелендә генә калмасын, ә яшь буынга күчеп, ата-бабаларыбыз мирасы буларак озак еллар, гасырлар буе күңелләребезне баетып торсын иде.

# КОРАЛ ЭШЛӘР, ОСТА МАКТАЛЫР

## *Сергач мишәрләренең туку эшчәнлеге*

*Лариса Илтубаева*

Түбән Новгород өлкәсендә яшәүче татар-мишәрләр этник төркеменең мәдәнияте, катлаулы этник-тарихи вакыйгаларга бәйле рәвештә, үзенчәлекле төсмерләргә баеган. Әлеге бай милли-мәдәни мирасны өйрәнү максатыннан 2010 елның май аенда ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан бу якларга фәнни-тикшеренү экспедициясе оештырылган иде. Без бу өлкәнең Кызыл Октябрь, Пилнә, Сеченов районнары авылларында булып, аерым кешеләрдә, мәктәп музейларында сакланып калган декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштык, аларның эшләнешен өйрәндек.

Мишәрләр көнкүрешендә декоратив сәнгать эшләнмәләре киң таралыш алган. Алар матди культура һәм йола гадәтләре белән бәйле әйберләрдә аеруча еш очрый. Гадәттә, өй эчен бизәү һәм киемнәр тегү өчен бизәкләп сугылган (парчалы) тукымалар киң файдаланылган. Халык көнкүрешендә төрле төстәге сөлгеләр, өстәл һәм сәке җәймәләре, пәрдәләр һәм чаршау-чыбылдыклар зур урын алып торган. Димәк, бу якларда борынгыдан килгән һөнәрчелек төрләреннән тукучылыкка игътибар аеруча зур булган. Моны археологик табылдыклар һәм фольклор материаллары дәлилли.

Чигү һәм тукыманы бизәкләп сугу орнаментлары бик борынгы үрнәкләргә, археологик материалларга барып тоташа. Геометрик фигуралардан (ромб, хач, «Х» рәвешле фигуралар, квадрат,

свастика һ.б.) гыйбарәт булган орнамент мотивлары Идел һәм Урал буйларында яшәүче башка халыклар (башкортлар, чувашлар, фин-угор һәм руслар) өчен дә хас. Бу яклардагы мишәрләрнең күрше халыклар, аерым алганда, руслар һәм мордвалар белән бәйләнеш дәрәҗәсе, бу этник төркемнең декоратив-гамәли сәнгатенең үзенчәлекле булып формалашуына да йогынты ясаган.

Җирле халыкның сәнгать үрнәкләрендә бизәкләп туку борынгы алымнары һәм аларның үзләренә генә хас стиль ачык чагыла. Мишәрләрнең бизәкләп сугылган тукымалары нәфис, зәвыклы төсләр гаммасы белән аерылып тора, һәм бу – тукымага аерым бер декоративлык өсти. Мишәрләрдә чүпләмләп, өлешләп, күпертмәләп (чиккәнсыман итеп), чуптарлап һәм чуарлап сугу киң таралган булган. Тукучылар еш кына бу техник алымнарны катнаштырып та үзенчәлекле декоратив бизәкләргә бай сәнгать әсәрләре иҗат иткәннәр.

Экспедиция барышында безгә очраган тукылган кул эшләренең зур күпчелеген сөлгеләр тәшкил итә. Бу – татар көнкүрешендә аларның функциональ роле зур булу белән аңлатыла. Сөлгеләр көндәлек куллану һәм өй эчен бизәү предметы буларак кына түгел, ә гореф-гадәтләр һәм йолаларны (туй, мәет күмү, халык бәйрәмнәре һ.б.) үтәгәндә дә файдаланылалар. Өй эчен бизәү һәм йолалар үтәү өчен махсус тукылган сөлгеләр төсләргә, бизәкләргә аеруча бай булган. Аларның үлчәмнәре дә шактый зур, хәтта 2,5–3,5 метр озынлыктагылары да бар.

Чүпләмләп туку техникасы буенча сугылган сөлгеләр декоратив эшләнеше ягыннан аеруча бай һәм кызыклы. Бу техника нигезендә аркау җебе (ул гадәттә кызыл төстә була) тукыманың бөтен киңлеге буйлап, йә аның өслегеннән, йә аскы ягыннан бара һәм тукыманың тискәре ягына да бизәк рәсеменең чагылышын бирә. Шул рәвешле тигез чиратлашкан геометрик фигуралардан торган орнамент барлыкка килә. Бер үк рәсемне өске бизәк дип тә, төп фон-җирлек дип тә кабул итәргә мөмкин һәм еш кына тукыманың өслеге белән тискәре ягын аеру да кыен.

Чүпләмләп сукканда сөлгеләрнең урта өлеше еш кына җитен сүсеннән эрләнгән ак җептән, йә булмаса чуар җепләрдән эшләнә. Аларның традицион гаммасы, нигездә, ак белән кызылдан

гыйбарәт. Мондый сөлгеләрне тукыганда төп фон өчен аркауга ак (җитен) җеп куялар, ә икенче аркау белән (гадәттә, кызыл төстәге киҗе-мамык җеп) бизәкнең орнаментын тукыйлар.

Татар-мишәрләр арасында сөлгенең баш-башларын күпертмәләп, ягъни чиккәнсыман итеп эшләү техникасы киң таралган. Бу чүпләмләп сугу техникасының бер төре, әмма рәсемнәр төшерүдә аның үз аерымлыклары бар. Монда орнаментның һәр элементы аерым, бизәк төсендәге җеп белән эшләнә. Экспедиция вакытында без күбрәк нәкъ менә шул ысул белән тукылган сөлгеләргә тап булдык. Аларның кызыл (сирәк кенә ак) кыры буйлап өч яруска төрле төстәге геометрик бизәкләр төшерелгән. Сөлгеләрнең иң читенә, бөреп, киҗе-мамык тукыма кисәге тегелгән. Сөлгенең уртасы, еш кына, чуарлап (гадәттә, ак белән кызылдан шакмаклап) сугылган, яки ак җитен җептән тукылган. Кайвакытта мондый үзәк өлеш сатып алынган киҗе-мамык тукымадан булып, сөлгенең төп өлешенә ялгап тегелгән.

Чуар тукыма (аның нигезе дә төрле төстәге җепләрдән эшләнгән) сугу да бу якларда киң таралган була, аннан киемсалым, көндәлек куллану өчен сөлгеләр, өстәл җәймәсе, пәрдәләр һ.б. әйберләр дә тегәләр.

Чуптарлап туку бик үк киң таралыш алмаган булса да, җирле халыкта бу техника буенча эшләнгән әйберләр дә очрата алдык. Чуптарлап туку техникасының үзенчәлеге шунда – бизәк төшкән урыннарда нигез һәм аркау тукыма үрелеше белән үзара тоташып бара. Аркау җебе нигезнең бөтен иңенә түгел, ә шушы төс булган җиренә генә салына. Әлеге ысул туку осталарына тукыманы күптөсле рәсемнәр белән бизәкләргә мөмкинлек бирә.

Җитен һәм киҗе-мамык җепләрдән, тар-тар итеп тасмалап ертылган төрле төстәге чүпрәкләрдән тукылган идән җәймәләрен һәркайда очратырга була. Мондый әйберләрне XX гасырның 70–80 нче елларында һәр авыл өендә диярлек күрергә мөмкин иде.

Татар-мишәрләрдәге бизәкләп туку алымнары белән Идел буе халыклары тукучылыгы арасында уртаклыклар бик күп. Бу аларның бер территориядә яшәүләре һәм үзара тыгыз элемтәләре белән аңлатыла.

Шул ук вакытта Түбән Новгород оста кулларының иҗат җимешләрендә, төп төрки-татар ысул-алымнарыннан тыш, фин-угор (мордва) һәм рус компонентлары да ачык сизелә. Күп кенә шундый үзенчәлекле орнамент үрнәкләре, буыннан-буынга күчеп, композицион алымнарның сакланып калуына ярдәм иткәннәр.

XIX гасырда – XX гасыр башында өй шартларында бизәкләп туку өчен төп материал булып киндер һәм җитен, соңрак – мамык (киҗе-мамык) саналган. Бизәкләрне гадәт буенча йон җепләрдән эшләгәннәр. Ул вакытта рамсыз һәм арткы күшәсез, горизонталь урнаштырылган гади туку станын (ул толымсыман үрелгән нигезе белән тераккә беркетелә) һәр өйдә очратырга мөмкин булган. Археологик тикшеренүләр раслаганча, мондый станның элгәрләре бик ерактагы үткәннәргә барып тоташа. Иң гади саналган, бер-берсеннән әз генә аерылып торган бу станнарны удмуртлар да, мордва, мари, башкортлар да үзләренеке дип саныйлар[1]. XIX гасыр – XX гасыр башында рамлы һәм арткы күшәсез (аның урынына үргән толым рәвешендәге нигез җепләре беркетелгән таяк файдаланылган) туку станнары тарала. Соңрак русларныкы кебек рамлы һәм арткы күшәле станнар кулланыла башлый.

Кызганыч, XX гасырның 60–70 нче елларында, өй шартларында бизәкләп тукучылык һөнәре әкренләп юкка чыга бара. Моның объектив сәбәпләреннән, беренче чиратта, фабрикада җитештерелгән тукымаларның һәм көнкүреш кирәк-яракларының киң тарала башлавын атарга мөмкин. Җитмәсә, шул елларда авыл җирләрендә өйдә туку өчен чимал булган җитен белән киндерне игүдән бөтенләй туктаталар. Бүгенге көнкүрештә исә кулдан тукылган әйберләрне фабрика эшләнмәләре бөтенләй кысрыклап чыгарды диярлек. Шулай да әбиләребез сандыкларында элекке буын туку осталары эшләгән әйберләр кадерләп саклана әле.

*Русчадан Я.М. Абдулкадыйрова тәрҗемәсе*

[1] *Сафина Ф.Ш.* Ткачество татар Поволжья и Урала: Историко-этнографический атлас татарского народа. – Казань, 1996. – С. 44.

# УҢГАН КУЛДА УТ УЙНЫЙ

## *Традицион һөнәр-кәсепләр, гамәли сәнгать*

*Рауза Солтанова*

Татар-мишәрләрнең мәдәниятен өйрәнү бүгенге көндә аеруча зур әһәмияткә ия, чөнки заманча шартларда гореф-гадәтләребез көндәлек тормыштан юкка чыга бара. Ә бу өлкәдәге борынгыдан килгән традицияләребезне саклап калу, өйрәнү фәнни яктан гына түгел, гамәли яктан, ягъни, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать төрләрен үстерү, халкыбызны эстетик тәрбияләү җәһәтеннән дә гаять мөһимнәрдән санала.

Традицион мәдәният һәм сәнгатьне без комплексლы рәвештә карыйбыз, чөнки алар, беренчедән, тарих белән тыгыз бәйләнгән, икенчедән, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм, билгеле бер дәрәҗәдә, аларның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, йолаларын, ышануларын, яшь һәм социаль үзенчәлекләрен һ.б. чагылдыралар. Теге яки бу милләтнең сәнгатьчә фикерләве, зәвыгы аның архитектурасында, киемендә, декоратив эшләнмәләренең бизәлешендә, композицион алымнарында һ.б. ачык күренә.

Мәкаләдә татар-мишәр йортларының архитектур йөзе, эчке һәм тышкы бизәлеше (экстерьер һәм интерьеры), гамәли сәнгать, һөнәр һәм кәсеп төрләре, традицион киемнәре үзенчәлекләренә төп урын бирелә. Без бу юнәлештә XX йөз дәвамында барган үзгәрешләрне күзәтеп, кайбер сәнгать төрләренең юкка чыгуы яисә башка формалар белән алышынуы, шәһәр мәдәниятенең гадәти формаларны кысрыклап чыгаруы кебек күренешләргә игътибар итәргә тырыштык.

Мәкалә 2010 елның июнь аенда Нижгар төбәгенең Мәдәнә, Сафаҗай (Красная Горка), Краснай (Красный Остров), Чүмбәли, Петрякс, Рбишча, Куй суы, Семеновка, Пашат, Актук авылларында җыелган мәгълүматлар нигезендә әзерләнде. Экспедиция материалларын анализлау гамәли сәнгать осталарының исемнәрен ачыкларга, архитектура, йорт-җир, аерым һөнәр һәм кәсепләрнең җирле үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирде. Алар нигезендә һөнәрчелек һәм гамәли сәнгать үсешенең бүгенге торышын тасвирласак, борынгырак чорларны күзаллау өчен музей экспонатларына, шәхси йортларда саклана торган коллекцияләргә, җирле халыктан алган мәгълүматларга һәм үзебезнең күзәтүләребезгә таяндык. Кызганычка каршы, кайвакыт коллекцияләр очраклы рәвештә табылган кул эшләреннән гыйбарәт һәм тиешенчә тасвирланмаган, шәрехләнмәгән була. Мондый эшләнмәләрнең җитештерелү урыны, вакыты, эшләү техникасы һ.б. мәгълүматларны музей хезмәткәрләреннән һәм халыкның үзеннән сораштырулар нәтиҗәсендә генә ачыкларга мөмкин булды.

Аеруча әһәмиятле этнографик коллекцияләр (аларның һәммәсендә 1 меңнән алып 5 меңгә кадәр экспонат) «Рәшидә» мәчете каршындагы «Туган якны өйрәнү музее»нда (Мәдәнә авылы) һәм Чүмбәли авылы мәктәбенең халык музеенда, Сафаҗай, Краснай авылларындагы мәктәп музейларында саклана.

Экспонатларының күптөрле булуы белән Кызыл Октябрь районы Чүмбәли урта мәктәбендә урнашкан халык музее аерылып тора. Музейны оештыруда һәм материаллар туплауда, аның директоры – Шияпов Абдулвәдүт Хуҗа улына (1925) мәктәп укучылары һәм барлык авыл халкы ярдәм иткән. «Әйберләрне хәтта арбага төяп китерәләр иде», – ди Абдулвәдүт әфәнде, ул вакытларны искә төшереп. Биредәге милли киемнәрдән конкурсларда чыгыш ясыйлар, ә экспонатларын төрле мәдәни чаралар, фестивальләр уздырганда алып торалар икән.

Үзебез караган, өйрәнгән башка музейлардан Петрякс мәктәбе музеен да аерып атарга кирәк. Аның фондында тукылган кул эшләренең, костюм, көнкүреш кирәк-яракларының сирәк очрый торган үрнәкләре саклана.

Халык сәнгатен өйрәнүдә тел мәгълүматлары өстәмә чыганак ролен үтәде. Теге яки бу предмет һәм эшләнмәләрнең килеп чыгышын, үсеш-үзгәрешен, ягъни эволюциясен тулырак ачыкларга мөмкинлек биргәнлектән, без аерым үрнәкләрне аларның атамалары белән бәйләп өйрәндек. Халык авыз иҗаты, йола һәм ышануларга мөрәҗәгать итүебез дә нәтиҗәле булды.

Татар-мишәрләрнең көнкүрешенә, мәдәниятенә, халык сәнгатенә багышланган махсус хезмәтләрдән Р.Г. Мөхәммәдованың XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башында мишәрләрнең матди һәм рухи мәдәниятен анализлаган (гәрчә авторның күп кенә күзәтүләре бүгенге чорга да карый) китабы[1] зур әһәмияткә ия. Н.А. Халиковның[2] Идел буе татарларының кәсеп-һөнәрләренең милли, субэтник һәм этномәдәни үзенчәлекләрен ачыклауга юнәлтелгән тикшеренү нәтиҗәләре шулай ук безгә бик кызыклы.

Әлеге мәкаләне язу барышында без экспедиция дәвамында тупланган һәм бу өлкәгә кагылышлы барлык фәнни, әдәби һәм музей материалларын туплау, анализлау, гомуми нәтиҗә ясау максаты куйган идек. Бу җәһәттән 7 музей (мәктәп музейлары һәм бер клуб музее) фонды өйрәнелде, 45 респондент сораштырылды, архитектура объектлары һәм аларның элементлары (мәчет, өй, тәрәзә, капка, интерьер), тасвирый-гамәли сәнгать үрнәкләре (тукучылык, чигү, бәйләү һ.б.), агачтан һәм тимердән эшләнгән көнкүреш кирәк-яраклары, костюм комплектлары (аяк, өс киемнәре), бизәнү әйберләре, шәмаилләрнең меңгә якын фоторәсеме тупланды.

Галимнәр фикеренчә, бу төбәктә яшәүче мишәрләрнең этномәдәни үсеш үзенчәлекләренә Түбән Новгород тирәсендә татар авыллары оешу процессы да тәэсир итмичә калмаган. Бу, үз чиратында, аларның Казан һ.б. татарлардан күпмедер дәрәҗәдә аерылып торуына китергән. С.Б. Сенюткин[3] язганча, XVI гасырларда читтән күчеп килгән, шактый төрле төрки элементлар (йомышлы

---

[1] *Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари: историко-этнографическое исследование. – Казань: Магариф, 2010.

[2] *Халиков Н.А.* Промыслы и ремесла татар Поволжья и Урала (середина XIX – начало XX веков). – Казань, 1998.

[3] *Сенюткин С.Б.* История татар Нижегородского Поволжья с последней трети XVI до начала XX вв. (историческая судьба мишарей Нижегородского края). – М.; Нижний Новгород: «Медина», 2009. – С. 393.

татарлар сыйфатында Касыйм, Кадимово, Темников, Барашев һ.б. җирләрдән килүчеләр) башка этник төркемнәр – мордва, чуваш, руслар белән тыгыз элемтәдә булганнар.

Региондагы һөнәр һәм кәсеп төрләренең үсеше, нигездә, авыл хуҗалыгының төп тармаклары булган иген игү һәм терлекчелек белән бәйле. Моны шул вакытлардан калган күп санлы эш кораллары дәлилли. Мәсәлән, суканың киң таралган һәм кулланылыш алган булуы Чүмбәли музее экспонатларыннан ачык күренә. Музей өчен сука макетын ясаучы мулла Айса Сабиров хәтта 1970–1980 елларда мәктәпкә килеп укучыларга сука белән җирне ничек сөрүләре турында сөйли торган булган[1].

Пашат (Пошатово) авылыннан Хәерниса Җәфар кызы Алиәкбәрова (1929) хатын-кызларның игенне урак белән урып, аны көлтәләргә җыюлары турында сөйләде («урак урдык, алаша белән көлтә ташыдык»). Он яки ярма ясау өчен бөртекле ашлыкны кул тегермәннәрендә («тирмән») тарттырганнар яисә киледә төйгәннәр. Төйгечне халык *кисап, киле сабы* дип йөрткән.

Башка авыл хуҗалыгы коралларыннан музейда тешләре төрле зурлыктагы *тырма, агач соскы* («сулька») һәм агач көрәк (1878–1958 елларда яшәгән Хәдичә Әсфәндияр кызы Шияпованыкы) һәм ашлык суга торган *чабагач* («цеп») саклана. Ашлыкны иләү, киптерү һәм хуҗалыкта куллану өчен осталар үзләре металлдан кырып иләкләр ясаганнар, юкә, усак, имәннән савыт-саба җитештергәннәр. Сафаҗай, Краснай, Чүмбәли мәктәп музейларындагы металлдан кырып эшләнгән савыт-саба һәм хуҗалык кирәк-яраклары – *җилпуч*, камыр атлый торган савыт – *балаяк* (1910 елгы, Сафаҗай) һ.б. әлеге һөнәрнең биредә киң таралган булуы хакында сөйли. Петрякс авылында XVIII гасыр ахырына караган зур чүмеч (1881 ел дигән язуы да бар), «куашня» (Краснай авылы), *изгеч* һәм *агач купы* үзенчәлекле борынгы экспонатлардан санала.

Мәдәнә авылындагы музейда агачтан һәм таштан ясалган тегермәннәр (*агач тирмән, таш тирмән*), Куй суы авылында *агач кисмәк* һ.б. күрергә мөмкин. Төрле зурлыктагы бәләкләр, кер

[1] Мәгълүмат бирүче – А.Х. Шияпов (1925 елгы).

бәләкли торган тукмаклар (*каталка бәләк*) күп авылларда очрады. Мәдәнә авылыннан Нәсимә Осман кызы Хәлилуллина (1935 елгы) «без менә шулай каталкалый идек», – дип, бәләк белән эшләп тә күрсәтте. Язулар һәм төрле бизәкләр төшерелгәннәрен дә күрдек. Мәсәлән, Чүмбәли авылындагы бер *каталка бәләк*кә дата һәм соляр билге төшерелгән. Хәдичә Андиржанованыкы булган әлеге бәләкне музейга 1974 елда тапшырганнар. Имәннән ясалган икенче *бәләк* – Хәлимә Баһаутдинованыкы.

Җирле вак һөнәрчеләр туку җиһазлары – *соса* (челнок), *тарак* (берда), *орчык* (веретено) һ.б. да җитештергәннәр.

Чүмбәли авылының мәктәп музеенда туку станогы детальләренең чагыштырмача тулы комплектын күрергә мөмкин. Алар арасында – төрле зурлыктагы өч тарак, сосалар бар. 1967 елда аларны Айниҗан Арибжанова тапшырган булган. «Үзе исән вакытта ул аларны җыймакчы иде, әмма өлгерә алмады», – ди А.Х. Шияпов. Бер таракка – 1869 ел дип сырланган. Сафаҗай авылы музеенда саклана торган *каба* (пряслице) белән *җеп әйләндергеч* әлеге коллекцияне тагын да тулырак күзалларга ярдәм итә.

Мәдәнә авылында С.Ф. Хәлилуллинаның (1930) әнисе – Мәликә Хәбибуллина (1982 елда вафат булган) өендә Бөек Ватан сугышына кадәр үк инде туку станогы булган. Мәскәүгә китәр алдыннан ул кызына истәлек итеп үзе тукыган берничә сөлге калдырган. Күрәсең, алар йола вакытында куллану өчен махсус эшләнгәннәрдер, чөнки бик озыннар (105 см чиста бизәктән генә тора), һәм очлары киртләнгән.

Нәсимә Осман кызы Хәлилуллина (1935) кайнанасы Зәйнәп Хәлилуллинаның йола сөлгесен кадерләп саклый. Сөлгенең уртасы – 128 см, очы – 25 см. «Гает бәйрәмнәрендә ямь өчен стенага дүрт читкә берәрне элеп куялар иде. Аның «заты» әйбер саклап тора», – дип сөйләде ул бу хакта.

Вәсимә Кәбир кызы (1943) әнисе Җамалетдинова Хәлимә Җамалетдин кызының (Биляллованың) (1912–2000) йола вакытында тотыла торган «алмалы сөлге»сен күрсәтте (тукырга әнисе – Мәрьям Абзерахим кызы Хәмидуллина өйрәткән булган). Гадәт буенча, бу якларда мондый сөлгеләрне тәрәзәләргә, ат

дугаларына әлә торган булганнар. Кеше үлгәч тә, кырык көн буена диварларда сөлгеләр эленеп торырга тиеш[1].

Балта осталары өй җиһазлары (өстәлләр, эскәмияләр, утыргычлар, савыт-саба шкафлары, сандыклар, кабык бишекләр) ясаганнар. Чүмбәли авылында безнең игътибарны авыл осталары тарафыннан юкәдән ясалган өстәл (зурлыгы 120×160×70 см) җәлеп итте. Өстәлнең аякларына уеп бизәкләр төшерелгән. Моннан зуррак өстәлне (145×83×79 см) Куй суы (Овечий Овраг) авылында Садыйк хәзрәт йортында очраттык. Биредә ат койрыгы тутырылган һәм дермантин белән тышланган биек утыргычлы кулдан ясалган борынгы кәнәфи дә саклана.

Башка вак-төяк көнкүреш эшләнмәләрдән яктырту вазифасын үтәүче төрле формадагы фонарьларга игътибар иттек. Болар – Чүмбәли авылындагы чырасыман – *шәндек–шапалдык* һәм «Рәшидә» мәчете музеендагы чыра формасындагы яктырткыч.

Хуҗалыкта һәм көнкүрештә юкә кабыгы, тал чыбыгы, каен тузыннан ясалган төрле әйберләр – шешә салыр өчен үреп ясалган савыт, балалар сумкасы (Сафаҗай), кәрҗин-сумка (Мәдәнә), сөзгеч – дуршлаг, кәрҗин (Краснай) киң кулланылышта булган.

Чүмбәли авылында Якуб Тәүлиханов (XIX г. ахыры) үргән кәрзин (*кәрҗин*), хуҗалык сумкасы буларак, кырга ашамлык салып бару өчен кулланылган[2]. Берсе эченә берсе кертеп куела торган һәм куллану өчен җиңел, уңайлы булган көтүче сумкалары аеруча нәфис, матур күренә (Чүмбәли, Петрякс авыллары). Мәдәнә авылында хуҗалыкта әле дә печән һәм салам ташу өчен махсус кәрҗиннәр (*кызау*) кулланыла. Гаяр Хәмзә улы Вәлитов (1957) сөйләвенчә, әле 1970 елларда монда тал (өянке) чыбыкларыннан төрле зурлыктагы кәрҗиннәр ясаганнар.

Һәр өйдә диярлек бүгенге көндә дә чыршы, нарат агачларыннан ясалган һәм фанер, калай белән тышланган сандыклар күрергә мөмкин. Сафаҗай мәктәбе директоры Р.Х. Мусин әбисе М.И. Шаһиморатованың (1870–1972) 1940–1950 елларда ясалган сандыгын бүгенге көнгә кадәр саклаган. Мәдәнә авылында

[1] Мәгълүмат бирүче – В.К. Билалова.
[2] Мәгълүмат бирүче – А.Х. Шияпов.

С.С. Фәйзуллина (Вәлитова; 1922–1996) өендә ике сандыкка тап булдык. Берсе бик зур (озынлыгы – 120, киңлеге – 65, биеклеге – 54 см), бикләвечле һәм чүкеп ясалган toткычлы; сырлы калай белән тышланган. Икенчесе аннан кечкенәрәк, почмаклары һәм капкачы калай белән тышланган, тоткычлары – шулай ук чүкеп ясалган; бикләвече кулдан эшләнгән. Куй суы авылы клубындагы сандык (документлар саклау өчен) 1930 нчы елларда *кызыл агач* – нараттан эшләнгән (зурлыгы – 51×30×24 см). Сафаҗай авылында Рәвдә Сәмигулла кызы Сөләйманова (1937 елгы) безгә әнисе Зәйтүнә Идрис кызы Сәләхетдинованың (1911–1982) чемоданын күрсәтте. Зәйтүнә апа 1980 елларда әлеге чемодан белән Мәскәүгә бара торган булган.

Экспедиция материаллары төбәктә сыер һәм сарык асрау киң таралуын раслый. Моны музейлардагы күп санлы чүлмәкләр һәм эрләү, туку белән бәйле эшләнмәләр һ.б. дәлилли.

Этнограф Р.Г. Мөхәммәдова[1] мишәрләр элек-электән үк атларга мөкиббән булганнар, дигән фикер җиткерә. Моны төрле ышану һәм йолалар белән дә аңлатып булыр иде. Ат культы коймакапкаларны һәм башка торак корылмаларны буяуда, бизәүдә дә күренә һәм күпсанлы музей экспонатларында чагыла. Мәсәлән, Сафаҗай авылы музеенда *ияр* («сидельцә»), Петрякс авылында юкәдән эшләнгән арба тәгәрмәче – шуларның кайберләре.

Краснай һәм Сафаҗай авылларында сөтчелек тармагы алга китүне күрсәткән балчыктан ясалган бик күп савыт-саба үрнәкләре саклана. Мәсәлән, кырыйларында дулкынлы бизәкләре һәм уртасында сырлары булган муенлы чүлмәкләр, глазурьлы тар муенлы чүлмәкләр (кувшиннар), урта өлешенә чокырлатып 2 рәт квадрат бизәкләр төшерелгән кувшин, кайнатылган сөт – *кызыл каймак* сала торган чирәп (*цирәп*) савыт (биеклеге 6 см, гәүдә өлешенең диаметры – 19 см, төбенең диаметры – 9 см) һ.б.

Чүмбәли авылындагы тар муенлы ике чүлмәк (кувшин) дулкынлы һәм туры сызыкчалар белән бизәкләнгән. Аларның берсе чагыштырмача борынгы, 1870 елга карый (биеклеге – 30 см, башының диаметры – 19 см, түп өлешенеке – 26, төбенеке – 11 см).

[1] *Мухамедова Р.Г.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 67.

Р.Г. Мөхәммәдованың[1] кошчылыкның мишәрләр хуҗалыгы өчен зур ярдәм булып торуын ассызыклаган фикерен безнең күзәтүләребез дә дәлилли. Чүмбәли авылы музеенда гаять үзенчәлекле экспонатлар – йорт кошларына азык салу өчен кулдан эшләнгән *тигәнә*, тавык-чебешләргә агач *су салгыч*ны күрергә мөмкин.

Бай тарихлы Сафаҗай авылы һөнәрчеләр саны буенча башкалардан аерылып тора. Монда әле дә «касыйм» һәм «әстерхан» якларына бүленеш яшәп килә. «Касыйм ягында кешеләр баерак яши»[2] дигән фикер дә нигезсез түгелдер. Бу авылда төп хуҗалык тармагы булып терлекчелек санала. Халык сыер, сарык, ат һәм файдалы сөте өчен кәҗә асрый.

Туган ягы тарихын өйрәнүче В.А. Камалетдинов (1949) сүзләренә караганда, биредә элек-электән савыт-саба ясау, өс һәм аяк киемнәре тегү, киез басу, металл эшкәртү белән шөгыльләнгәннәр. Йон эшкәртү кәсебе аеруча киң таралган булган. Киез басу белән шөгыльләнүче осталар династиясе бар (Әнәс Нуриманов, Абделхак Исхаков, Хәмзә Сәламов, Зөфәр Мөхәмmәтов, Сәнәт Нуриманов). Киез итекләрне биредә *церге итек* дип, кыска итекләрне *калош* дип йөртәләр[3].

15 ел киез басу белән шөгыльләнгән авыл мулласы Искәндәр Гыйльман улы Гыйльманов (1938 елгы) безгә киез итекләр җитештерү вакытында кулланыла торган бөтен эш коралларын – йонны кысу, пресслау һәм кәтәләтү җайланмасы, киез итек калыплары һ.б. күрсәтте. Ул бу һөнәргә руслардан өйрәнгән. Кешеләр соравы буенча, ягъни, заказга эшләгән, итекләрне Петрякс базарында саткан. Улы Хәлил (1967 елгы) дә берара бу кәсеп белән шөгыльләнгән. Итек тегүчеләрне биредә *юләүче* дип атыйлар. Шундый осталарның берсе – Шәйхулла бабай кунычлы итекләр (сапогилар) теккән.

Тегүчеләр гадәттә өйләрендә эшләгәннәр: шапкалар, бияләйләр, бишмәтләр, күлмәкләр теккәннәр. Шунысы кызык, тегү

---

[1] *Мухамедова Р.Г.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 67.

[2] Мәгълүмат бирүче – В.А. Камалетдинов (1949 елгы).

[3] Мәгълүмат бирүче – В.А. Камалетдинов.

эше белән, нигездә, ир-атлар шөгыльләнгән, ә хатын-кызлар сирәгрәк булган (мәсәлән, Таира Низамова). Мансур Ибраһимов тире туннар теккән. Мәгълүмат бирүчеләр фикеренчә, авылларда элек-электән тире иләп, мех әйберләр тегүче осталар булган. Мәдәнә авылыннан Н.О. Хәлилуллина хәбәр итүенчә, аның әтисе ягыннан бабасы авылларда тире җыеп йөргән.

Татар-мишәрләрдә металл җыю һәм эшкәртү эше дә зур урын алып тора. Төбәктә тимерчелек һөнәренең үсеше хакында «Рәшидә» мәчетендәге музей экспонатларыннан чыгып та фикер йөртергә мөмкин. Сугыш кораллары, сөңгеләр, көнкүреш кирәк-яраклары (*урак, сука көрәге, капкын, бизмән*) – җирле тимерчеләрнең хезмәт җимешләре.

Музейларда (Петрякс, Чүмбәли, Мәдәнә авыллары) бакыр һәм алюминийдан ясалган күпсанлы савыт-сабалар (кружка, чәйнек, комганнар) урын алган. Сафаҗай авылында калайчылар династиясе билгеле. Харис, Хасип, Хәбип Хөсәеновлар түбә ябу, йортларны бизәү – «*чәчәкләү*» белән шөгыльләнгәннәр, калайдан самавыр торбалары, *сосма* (соскыч), капкач, чиләкләр ясаганнар. Бөек җиңүгә багышланган обелискны да алюминий белән 1975 елда алар тышлаганнар икән. Шул ук авылдан Сафиулла Сабитов (кушаматы – Сапи) самавырлар төзәтү белән шөгыльләнгән.

Зәркән һөнәре, ягъни, ювелирлык эше дә бу регион өчен ят түгел. Чүмбәли авылының «Туган якны өйрәнү музее»нда төбәк осталары тарафыннан ясалган бик күп ювелир эшләнмәләр тупланмасын күрергә мөмкин. Габидуллиннар нәселе көмешчеләре (Бәдретдин, Гаязетдин, Сөләйман) заказга эшләп XIX йөз ахыры – XX йөз башында тирә-як халкының бизәнү әйберләренә ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә алганнар, совет хакимияте елларында Сергачка «качканнар»[1]. Нигездә, кою (литье), чүкү (чеканка), чоку (гравировка), каралту (чернение), бөтерү (скань) техникаларын кулланып эшләгәннәр, шулай ук, эмаль белән дә каплаганнар, инкрустация ясаганнар. Иң күп очраган ювелир бизәнү әйберләре – чүкеп ясалган һәм лалә

[1] Мәгълүмат бирүче – А.Х. Шияпов.

чәчәкләре, боргаланган бизәкләр төшерелгән, ташлар белән бизәлгән беләзекләр. Кайбер беләзекләрдә йолдыз һәм ярымай сурәтләре дә күрергә мөмкин. Бер авыл баеның килене – Афия Галәветдинованың шундый дүрт беләзеге 1971 елда музейга бүләк ителгән. Беләзекләрнең берсенә – бормалы гарәп язуы төшерелгән, урта өлешендә – чәчәк рәвешендәге йолдыз һәм чокып язылган 1915 датасы тора. Икенчесендә шулай ук эпиграфика һәм 1917 ел датасы, өслегендә – модерн стилендә башкарылган үлән, үсемлек бизәкләре, композициянең үзәгендә – чәчәк. Гаять үзенчәлекле балалар беләзеге бик сокландырды. Үтә нәфис әлеге беләзек калын көмештән (күк, яшел, ак түрткеле фирүзә төсендәге эмаль) коелган. Халидә Сибгатуллинаның бу беләзеген музейга 1976 елда Мостафина тапшырган. Бөтерү техникасында башкарылган чулпылар (көмеш, пыяла, тәңкә) искиткеч матур.

Моннан тыш, түбән пробалы металлдан ясалган бизәнү әйберләре дә очрый. Мәсәлән, Краснай авылы мәктәп музеенда 21 см озынлыктагы шундый чулпылар саклана. Аларны 1930–1940 елларда Рәйхана Аллаяр кызы Шакирова (1905–1998) тагып йөргән[1].

Киң таралган һөнәр төрләренең тагын берсе – кирпеч җитештерү (мич чыгару һәм төзелеш өчен). Сафаҗай авылында бу кәсеп сәнәгать характерын алган (биредә үзләренең кирпеч заводлары булган, аннан тирә-як авыллар өчен дә, Казанга да атлар белән кирпеч ташыганнар). Миччеләр күрше авылларга да хезмәт күрсәткәннәр. Сафаҗайның күпләргә мәгълүм миччеләр династиясе – Хәмзә Хәбибуллиннар (Хәйдәр Хәмзин, Малик Хөсәенов, Абделхак Хөсәенов) – нәселләре белән башка авылларга барып, мич чыгарып йөргәннәр.

Авыр матди хәл кешеләрне төрле җирләргә барып эшләп кайтуга этәргән. «Якка китү» дип аталган бу күренеш күп авылларда төп яшәү чыганагына әверелгән.

Түбән Новгород губернасы чиновниклары билгеләвенчә, Сергач өязе татарлары, үзләрендә вак һөнәрчелек промыселлары

[1] Мәгълүмат бирүче – К.С. Армиханова (1959 елгы).

булмау сәбәпле, төрле якларга, шул исәптән Киев губернасы заводларына, Себернең алтын приискаларына эшкә юнәлгәннәр[1].

Пашат авылында, мәсәлән, тукучылык һәм итек басу артык киң таралыш алмаган булган. Х.Җ. Алиәкбәрова (1929) бу турыда: «Тукучылар юк иде, тукыган әйберләрне сатып ала идек», – ди. Монда яшәүчеләр рус авылларына агач эшләренә киткәннәр, төзелештә эшләгәннәр. А.Ш. Алиәкбәров (1930) йорт яки караltылар салу белән шөгыльләнгән.

Сәүдә бу якларда киң таралган. Мәсәлән, Пашат авылында куй (сарык), сыер тиреләре сатканнар. Петрякс авылында Халидә Сәетованың (1939) каенатасы Нурулла Садретдин улы сату-алу белән мәшгуль булган: «тауар тоткан», ашамлык кибете ачкан. Кәлимулла Туктаровның үз пекарнясы һәм ике катлы кирпеч йорты булган[2].

Шунысын да билгеләп үтик, бу якта хәлле кешеләр йортларын, кибетләрен гел таштан салганнар. Еш кына аста кибет тотып, өске катта үзләре яшәгәннәр. Шундый йортларның берсе Чүмбәли авылында сакланып калган. Ул Абдулла Нуриев йорты, 1910 елда салынган: йортның асты – кирпеч, өсте агач.

Актук авылында элеккеге кибетнең икенче катында 1980 елга кадәр мәктәп эшләгән[3].

Саман кирпеч һәм балчыктан өеп, балчык һәм ком катыштырылган измә белән салынган йортлар да очрый. Сөйләмдә сылау – «штукатурка» кебек сүзләрнең булуы шуны дәлилли[4].

Мәдәнә авылындагы Мәгъсум Фәйзрахман улы Нивретдинов (1906–1988) йорты 1984 елда дранкадан (дранча) салынган. Балчык белән сыланган йорт сары төскә буялган, тәрәзә йөзлекләре һәм коридоры аксыл-зәңгәр төстә.

Р.Г. Мөхәммәдова тикшеренүләреннән күренгәнчә[5], татар-мишәр йорты формалашуга рус ызбаларының тәэсире зур

---

[1] *Халиков Н.А.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 17.

[2] Мәгълүмат бирүче – Х.И. Сәетова (1935 елгы).

[3] Мәгълүмат бирүче – Р.Ш. Зәйнетдинова (Яруллина; 1956 елгы).

[4] Мәгълүмат бирүче – Х.Җ. Алиәкбәрова (1929 елгы).

[5] Мухамедова Р.Г. Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 92.

булган. Бу төзелеш үзенчәлекләрендә, атамаларда һәм төрле конструкцияләрдә чагылыш тапкан.

Сафаҗай авылында яшәүче Равил Вилданов Щукино дигән рус авылыннан йорт алып кайтып утырткан, бизәкләрен дә шул килеш саклаган.

Элегрәк йортларны (ызбаларны) күбесенчә агачтан (чыршы, нарат) салганнар[1]. Пашат авылы – моның бер мисалы.

Архитектурада йортларның тышкы бизәлешенә зур игътибар бирелә. Нигездә, уеп ясалган бизәкләр бик күп очрый. Йорт-каралтылар татар милли сәнгатенә хас булганча, төрле-төрле төскә буялган, шул ук вакытта, монда рус агач архитектурасы йогынтысы да сизелә, бу күренеш мордваларга да хас.

Йортларны (өскорма-балконнарны, тәрәзәләрне һ.б.) бизәүдә пычкы белән кисеп бизәк ясауның рельефлы яки контурлы төрләре кулланыла. Мондый бизәкләр яссы өслеккә беркетелеп рельефлы нәкыш хасил итәләр. Контурлы кисеп ясау белән фронтон кәрнизләренең каймалары һәм тәрәзә йөзлекләре бизәлә.

Кисеп ясалган бизәкләр йә яссы өслеккә тегелә, йә шул килеш калдырылып, хикмәтле челтәрле рәсем барлыкка китерә. Мондый нәкыш фронтоннарны, кәрнизләрне, йөзлекләрне һәм йортның башка өлешләрен бизәгәндә дә файдаланыла.

Уеп ясалган бизәкләр арасында («резьба»ны бу якларда «бизәк» дип атыйлар) геометрик (квадрат, турыпочмаклык, түгәрәк, ярымтүгәрәк, ромб) һәм үсемлек мотивлары (өчьяфрак, лалә, кыңгырау), шулай ук кәкре сызыклар, спиральләр, ярымспиральләр бар (алардан төрле-төрле чәчәкләр, яфраклар һ.б. ясала). Тәрәзә йөзлекләрендә зооморф мотивлар – стильләштерелгән күгәрченнәр, еланнар һәм башка хайван фигуралары очрый (Пашат авылы). Гади генә кебек тоелган йортлар да кисеп ясалган нәкышләр белән бизәлү хисабына сокланып туялмаслык матур күренә.

Җете төсләргә буялган орнаментлар белән бизәлгән балконнар йортларның тышкы күренешенә үзенчәлекле төсмер өсти. Аллы-гөлле (ал, ак, зәңгәр, аксыл-көрән) буяуларга буялган

---

[1] Мәгълүмат бирүче – Х.Ж. Алиәкбәрова (1929 елгы).

челтәрле бизәкләре белән бигрәк тә Чүмбәли авылы балконнары аерылып тора. Бер яки ике тәрәзәле балконнар ешрак очрый. Шулай ук тәрәзәләре түгәрәк формада булган балконнар да бар (Сафаҗай). Бизәкләрнең төп мотивлары йолдыз, ярымай, сигез почмаклы яфраксыман нәкыш (розетка) һәм төрле геометрик фигуралардан (ромбик, киртләчләп ясалган квадрат) гыйбарәт.

Йортларны бизәүдә, кисеп рәсем, сурәт ясау белән беррәттән, төрле төсләргә буяу һәм тышлау аерым роль уйный. Матурлап тышлау алымы бигрәк тә XX гасырның икенче яртысында ясалган йортларга, капкаларга хас. Гадәттә, такта белән чыршысыман яки мозаика рәвешендә фронтонның яссы өслеге тышлана[1]. Тышланган өслекне буяганда ак, яшел, зәңгәрсу, зәңгәр, сары төсләр күп кулланыла.

Йортларның тышкы кыяфәтенә алгы һәм арткы якта урнашкан аерым балконнар (мезонин) декоративлык төсмере бирә. Төбәк халкы моны мөселманлык билгесе дип саный. «Мөселман ызбалары балконлы булырга тиеш», – ди Әлфия Хәлил кызы Сәйфетдинова[2].

Йорт һәм балкон түбәләрендә, баскычларның алгы ягында агачтан, калайдан кисеп ясалган ярымай яки ярымайлы манарачыклар (аларның саны 7–9 га җитәргә мөмкин) очрый (Семеновка, Мәдәнә авыллары).

Пашат авылы балта остасы Абдулбарый Сәмиуллин (1932–2010) калайдан чәчәкләр ясап, аларны йортка да, түбәгә дә бик матур итеп урнаштырган (Коммунистлар урамы, 76 нчы йорт). Актук авылының үз балта остасы бар – Әнвәр Хамматов. Рбишча авылында исә агачтан кисеп бизәк ясау белән Хәйдәр Хәлиуллин шөгыльләнгән (хәзерге вакытта мулла вазифаларын үти). Татар Моклокасы авылы кешеләре балта эшенә осталыклары белән аеруча аерылып торалар. Мәдәнә авылындагы төрледән-төрле бизәкләп ясалган Харис Үмәр улы Ситдыйков (1934), Гаяз Абдрахман улы Хәсәнов (1946), Абдулкадыйр Җиһангир улы Әшрәфетдиновларның (1928) йортлары – шушы осталарның эше.

[1] *Мухамедова Р.Г.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 96.
[2] Мәгълүмат бирүче – Ә.Х. Сәйфетдинова (1969 елгы).

1985–1990 елларда кайбер йортларны чуваш осталары да бизәгән (мәсәлән, Хәсибә Абдулла кызы Үмәрова (1938) йорты).

XX гасырның икенче яртысындагы икътисади үзгәрешләр нәтиҗәсендә йорт салу һәм бизәү өлкәсендә дә яңа тенденцияләр барлыкка килә. Мәсәлән, Пашат (1960 елдан) һәм Рбишча (1970 елдан) авылларында йортларны башлыча кирпечтән сала башлыйлар, өй эчен тагын да иркенәйтү максатыннан янкормалар төзиләр.

Пашат авылында яшәүче А.Ш. Алиәкбәров йортын 1963 елда кирпечтән салган була. Ун елдан аңа Горький шәһәреннән агач янкорма алып кайтып өстәп куя. Өенең үзәк өлешендә – зал, йокы бүлмәсе, ә янкормада аш бүлмәсе урнашкан. Мәдәнә авылындагы Г.А. Хәсәнов (1946) йортында, киресенчә, яңа корылган өлеш алгы һәм йокы бүлмәләреннән тора. Йортның подвалында мунча урнашкан, бәдрәф 1970 елдан ук инде өй эчендә икән.

Ә менә Рбишча авылында мунчаны йорттан читтәрәк төзергә тырышалар. Йортта «шайтан базы» ясарга кирәкми, диләр.

Кайчакта өй һәм веранда бер түбә астына кертелә. Аларны гармоник рәвештә яраштырып төрле төсләргә буйыйлар (Семеновка авылы). Мәсәлән, тәрәзәләр зәңгәрсу төстә, ә аларның йөзлекләрендәге кояш билгеләре кызыл төстә, йорт үзе сары төскә буялган. Кирпеч йортлар бизәлешендә агач йорт декоры кабатлана. Аларга шулай ук тукучылыкта кулланыла торган орнамент та төшерелергә мөмкин. Мәсәлән, Мәдәнә авылындагы Х.А. Үмәрова (1938) йорты кызыл һәм ак кирпеч белән бизәкләнгән, ә ак кирпеч урыны-урыны белән зәңгәрсу һәм кызыл төскә буялган. Кирпечтән ясалган тәрәзә йөзлекләре дә зәңгәрсу төстә.

Сафаҗай авылы йортларының бизәлеше гаять кызыклы. Биредә йорт хәтта тукылган келәмне хәтерләтергә мөмкин. Кайчакта йортның алгы ягындагы кәрниз астындагы орнамент сөлге бизәген хәтерләтә. Бер үк йортның агач һәм кирпеч өлешләргә бүленүе дә кызыклы. Түбәндәге кирпеч катта һәм йөзлекләрдә бизәкләр (ромблар, өчпочмаклар) – тукылган сөлгедәге кебек. Алгы стенасында өч кызыл лалә чәчәге урнаштырылган агачтан эшләнгән өске кат коңгырт-сары төскә буялган.

Петрякс авылында бөтен яклап геометрик бизәкләрдән (ромблар, линейкасыман бизәкләр яки ак-кызыл кирпеч кисәкләреннән төрле сурәтләр) торган йортлар да очрый. Аксыл фонда кызыл кирпечтән ясалган ярымайлы манарачык хуҗаларның дингә карашын күрсәтә. Түбәдәге манарачык шулай ук ислам дине билгесе.

Кайбер хуҗалыкларда элеккеге гореф-гадәтләр белән яңа тенденцияләр үзара үрелеп бара. Монда яшәүчеләр хәзерге заман технологияләрен һәм материалларын кулланып, борынгы бизәлеш үрнәкләрен яңарталар.

Пашат авылында яшәүче Шәмсетдин Шияфетдин улы Шияфетдинов (1935) ДСП белән тышланып, зәңгәр төскә буялган иске йорты (1964) янына ике катлы яңа йорт салып куйган (Коммунистлар урамы, 77 нче йорт). Беренче каты саргылт-ак төскә буялган кирпечтән булса, икенче кат сайдинг белән тышланган, түбәсе чирәп (черепица) белән ябылган. Балкон шулай ук сайдинг белән тышланган һәм өстенә ярымай куелган. Тәрәзә йөзлекләре иске йортыныкы кебек бизәлгән, бүрәнәсе эчтән зәңгәргә буялган.

Рбишча һәм Куй суы авылларында йортлар кирпечтән төзелсә дә, биредә бизәлгән балконлы түбәнең традицион формасын саклап калырга тырышалар. Фронтонда татарларга хас төсләр төрлелеге (полихромия) һәм буй-буй бизәк төшерү саклана.

Капка (кабак) – корылмаларның бер өлеше буларак шулай ук традицион: гадәттә ике яклы «кәлиткә»ләр. Аларын «кече кабак» дип атыйлар. «Түбәле» агач капка да сакланып калган.

Соңгы вакытта тимер капкалар модага керде. Элек капка һәм койма баганалары буларак агач бүрәнәләр файдаланылса, хәзер алар урынына төрле юанлыктагы торбалар кулланыла. Капкаларны төрлечә бизәкләргә тырышалар. Мәсәлән геометрик бизәкләр (ромблар), бөгелгән полосалар, уртада берәр төрле орнамент очрый. Чәчәк (тюльпан), зооморф (пар аккош) мотивлары киң таралган. Сафаҗай авылыннан А.Сөләйманов (1947) капка бизәкләрен үзе уйлап тапкан, уллары аны тормышка ашырган. Койманың бер өлешен йорт архитектурасыннан чыгып кирпечтән ясыйлар, үзләренчә бизиләр. Агач коймалар йорт белән бер төскә буялган. Зәңгәрле-яшелле буй-буй бизәкләр очрый.

Региональ үзенчәлек буларак, бизәкле утыргычларны («скамейка») билгеләп үтәргә кирәк. Кайбер авылларда утыргычлар утыру урыны гына түгел, ә ял итү, ялгызлыкта калу урыны булып хезмәт итә. Мәдәнә авылында аларны терәлеп утырырга уңайлы булсын өчен, биек артлы һәм түбәле итеп ясыйлар; койма белән бер үк төскә буйыйлар һәм агачтан уеп ясалган орнамент белән бизиләр.

Безгә шушы авылда балаларның «өйле» уйнауларын күзәтергә насыйп булды. Өйдән мендәрләр, юрганнар алып чыгып куышларын коралар.

Төбәктә коеларга ихтирам зур: алар ишегалдында (Мәдәнә, Пашат), бакчада (Сафаҗай) урнашырга мөмкин. Өлкән буын кешеләрендә агачтан, яңа «мәскәүчә» йортларда (хуҗалары җәйгә генә торырга кайта) һәм хәлле кешеләрдә кирпечтән ясалган. Чүмбәли авылында бер кое (1990) ярым ай һәм дага («Алла су китер» диләр) белән бизәлгән.

Шундый ышану яши: «Җир астында су юллары бар, һәм өскә чыкмаса, поток кешеләрне йоклата». Монда бераз элегрәк иске коены күмгәннәр һәм юл һәлакәтләре (аварияләр) башланган. «Кире казыгач, аварияләр бетте», – дип сөйлиләр.

Авылларда капкачлы тәрәзәләр очрый (Актук авылы). Соңгы вакытта халык рамнарга бүленмәгән пластик тәрәзәләр куя башласа да, тәрәзә рамы ясаучы осталар хәзер дә бар (Гаяр Хәйдәр улы Имаметдинов, Мәдәнә авылы).

Гадәттә тәрәзәләр зур түгел. Әмма Пашат авылында яшәүчеләр үз тәрәзәләрен зур дип саныйлар. «Коргыч»ларны (пәрдә) ике катлы итеп («эчке коргыч», «тышкы коргыч») итеп тегәләр. «Элек-электән ике катлы иде», – ди А. Алиәкбәрова.

Өй эчендә төп урынны мич алып тора, ул бүгенге көндә зур үзгәрешләргә дучар булган. Кайбер йортларда, бигрәк тә өлкән буын хуҗаларныкында, әле үзенең төп функциясен башкарса да, күп авылларда инде ул юкка чыккан. Моңа сәбәпче, әлбәттә, – йортларга газ кертелә башлау. Кирпеч йортларда мич пар белән җылыту өчен генә кулланыла[1]. Пашат авылының ике катлы

[1] Мәгълүмат бирүче – Г.А. Хәсәнов (1946 елгы).

йортларында, «ис өскә китсен» өчен, мич икенче катта урнашкан. Без су җылыту баклары һәм «утын куярга уемы» булган мичләрне күрдек (А.М. Сөләйманов (1937) йорты; Сафаҗай авылы). Бөтен җирдә дә мич акшарланган.

Мишәр йортлары интерьерында күренекле урынны көзге бизи. Сафаҗай авылы мәктәп музеенда 1930–1940 нчы елларга караган ике көзге (уеп бизәлгән, юкә, имәннән эшләнгән) бар. Берсендә хуҗасының исеме дә язылган: Абдрахман Мөксинов.

Петрякс авылындагы көзгенең (биеклеге – 133 см, киңлеге – 52 см) бизәкләре уеп ясау техникасы белән эшләнгән, шулай ук өстәмә орнамент та бар. Монда шулай ук кулдан ясалган сәгать тә урын алган (материалы – юкә; кара төскә буялган).

Олы яшьтәге кешеләрнең аш бүлмәсендә хәзерге вакытта да кулдан ясалган шкафлар, буфетлар, комодлар очратырга була. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, сатып алынган мебельне дә монда үзенчә бизәргә тырышалар. Мәсәлән, Пашат авылында 1930 нчы елларда Түбән Новгородта алынган савыт-саба шкафын «агачтан роза чәчәген кисеп, бояп, „сырмалык"», – диләр.

Мишәр йортлары интерьеры шәһәрнекенә охшаш, мебельнең төп өлеше сатып алынган (диваннар, креслолар, шифоньерлар).

Сәкене без Садыйк хәзрәт йортында гына очраттык. Ул, элекке вакыттагы кебек үк, алгы стена буенда («түрдә»), абыстайның кунаклар каршылый торган төшендә.

Казан татарларында һәм шулай ук башка төрки халыкларда өй эчен бизәүдә төп урынны тукымадан (материал) ясалган әйберләр алган: чыбылдыклар, кашага, сөлгеләр (тукылган һәм чигелгән), һәртөрле чигү (панно).

Киленнең бирнәсенә урын-җир кирәк-яраклары гына түгел, төрле савыт-саба да кергән. «Әни кияүгә килгәндә сандыкка түшәк, ике ястык, чаршау, кашага, биш пар чәшкә, пар тәлинкә алып килгән», – ди Н.О. Хәлилуллина (1935).

Пашат һәм Мәдәнә авылларында чаршауны «коргыч», «тәрәзә коргычлары», «ишек коргычлары», «караваt коргычы», бишектәгене – «чыбылдык» дип атыйлар.

Чаршауның өске өлешен кашага – «мич кашагасы», «ишек кашагасы» диләр (Сафаҗай авылы). Чаршау өчен ачык чәчәкле

тукымаларны сайлыйлар. Кайбер йортларда хәзер дә йокы урыны янына чыбылдык коралар.

Мишәрләрдә туй вакытында киленнең бирнәсен элү йоласы бар. Яшь буын да әле бу йоланың үзенчәлекләрен белә. Мәсәлән, Ф.Х. Сәйфетдинова (1969; Петрякс авылы) сөйләве буенча, «кыз килгәч, өйне чаршаулаганнар». Пашат авылыннан Х.Җ. Алиәкбәрова бу турыда менә нәрсәләр сөйләде:

«Кызның туганнары (җиңгиләр) кияү йортына чаршау үлчәргә баралар. Аннары чаршауны «дүлиләр», кияү өендә туй көнне коралар. «Бусага йоласы» буенча, ишек алдыннан кергәндә, килен «бисмилла» әйтеп, бусагага бүләк («подарка») куя. Каенана «бисмилла» әйтеп ала. Тәрәзә «коргычлары», сандык, өстәл япмаларын «бисмилла» әйтеп җәя, өстәлгә «хәер» куя, аны егетнең анасы ала. Чиккән, тукылган сөлгеләрне түргә эләләр инде. Туй сөлгесенең биле кызыл, очы ак, «ямь» өчен телгәләнә. Көндәлек сөлгенең очы телгәләнми. Элек стенада берни дә юк иде, әүвәл обой да сыламыйлар иде...»

Бу төбәктә «матурлык» төшенчәсен белдерү өчен «ямь» сүзен кулланалар. Авыр заманда да халыкны матурлыкны тоя белү хисе, өй эчләрен бизәү теләге ташламаган. «Газетадан клей урынына картуштан (бәрәңгедән) тәрәзәгә «чилтәр» ясадык. Буш йомырка кабыгына кәгазьдән канатлар куеп, кошлар ясый идек һәм аларны матурлык өчен җеп белән тәрәзәгә элеп куясың», – дип искә ала Н.О. Хәлилуллина (1935; Мәдәнә авылы).

Хатын-кызлар төрле төсле тукыма кисәкләреннән тегелгән (корама) сандык, утыргыч япмалары тегеп өй эчен бизәгән. Чүмбәли мәктәбе музеенда Фатыйма Фазлуллинаның (1908–1980) – «кыртмыш Фатыйма»ның – бик матур өстәл япмасы саклана. Япма катнаш ысул белән тегелгән: өйдә тукылган материяга (настильная техника) төсле чүпрәктән бөрмәләр, алар арасына фабрикада эшләнгән челтәрләр («кыржава» – «кружево») тегелгән. Әле XX гасырның 30–40 нчы елларында гына хатын-кызлар, борынгы заманнардагы кебек үк, юка җитен һәм киҗе-мамык җепләрдән челтәр бәйләгәннәр, бу искиткеч нәфис эшләнмәләре белән өй эчләрен бизәгәннәр.

Без челтәр бәйләүче осталарның исемнәрен дә ачыкладык: Сафаҗай авылыннан К.С. Асадуллина, Р.С. Сөләйманова (1937); Мәдәнә авылыннан Ф.В. Баутдинова (1942), Ф.А. Җамалетдинова (1954), К.Г. Измайлова (1933), С.С. Фәйзуллина (Вәлитова) һ.б. Кул эшләнмәләре арасында «караватт челтәре», «караватт башы», өстәл, радио, самовар («самавыр кыржава»), тегү машинасы япмалары, «зеркало кругына челтәр» киң таралган. Бизәкләрнең күпчелеге яңа уйлап чыгарылган булмаса да, аларның урнаштырылу рәвеше (комбинациясе) чиксез күптөрле һәм иҗади күңел аларның яңадан-яңа формаларын уйлап таба.

Фантазияне бераз эшкә җиксәң, кием-салымга яңа сулыш өреп була. Өрфиядәй челтәрдән бәйләнгән яка, бизәлгән шәл һәм киемнәр заманча яңгырый башлый. Ф. Миниатуллина бәйләгән бик нәфис кара косынка (1955 елда тапшырылган), Х. Низамованың искиткеч матур күлмәге (1967 елда тапшырылган) Чүмбәли мәктәбе музее коллекциясендә саклана. Мәдәнә авылында яшәүче С.С. Фәйзуллина (Вәлитова) бәйләгән челтәр яка киемне бөтенләй ачып җибәрә, ямьләндерә (1950 нче еллар ахыры – 1960 нчы еллар башы).

Бәйләгән әйберләр хуҗаларының кул җылысын, мәхәббәтен үзендә саклый. С.С. Фәйзуллина (Вәлитова) акрил, йон, кижемамык җепләрдән төрледән-төрле бизәкләр бәйли, күңелендәге матурлык хисен свитерлар, жилетлар, япмалар өстенә төшерә. Сания Фәйзрахман кызы Хәлиуллинаның да бәйләгән әйберләре бик күп: оекбашлар, бияләйләр (Петрякс авылында аны «барига» диләр), кофталар, свитерлар, жилетлар һ.б.

Орнаментлы сәнгатьнең борынгы төрләреннән булган чигү бу төбәктә бик аз очрый. Хәзерге йортларда ул бөтенләй юк дисәң дә була. Безгә аның үрнәкләрен мәктәп музейларында гына күрергә насыйп булды (Сафаҗай, Краснай, Чүмбәли). «Татар-мишәр хатын-кызлары базар белән артык бәйләнеш тотмаганлыктан, профессиональ рәвештә чигү белән шөгыльләнмәгәннәр. Шул сәбәптән, аларга яңа бизәк төрләре дә бик аз үтеп кергән», – дип яза Р.Г. Мөхәммәдова.

Информантлар биргән мәгълүмат буенча, осталар чигүнең бөтен төрләрен дә белгәннәр: шома чигү («суздырып чигү» –

Мәдәнә авылы), тамбурлы (элмә) чигү («арттан алып чигү»), шома, сабаксыман чигү («атландырып чигү»), тапкырлап чигү (Сафаҗай авылы).

Чигү осталарының уртача яше 60 ка туры килә. Мәдәнә авылыннан З.Т. Айнетдинова (1950) яшь вакытында тапкырлап чигү белән мавыккан, бүләккә сөлгеләр чиккән; Краснай авылыннан Р.А. Нәҗметдинова (1951), К.С. Армиханова (1959) шома чигү белән мәшгуль булганнар, шулай ук тапкырлап сөлгеләр чиккәннәр.

Сафаҗай авылында элегрәк тәрәзә «коргыч»ларына күгәрченнәр (кошлар), чәчәкләр чиккәннәр. Ә мендәр тышлары һәм «чәшке япмалары»нда җиләк-җимеш сурәтләре очрый. «Ястык япмаларын катушка җебе белән чигәләр иде», – ди Х.Ж. Алиәкбәрова (1929; Пашат авылы).

Диварлардагы чигү үрнәкләрендә чәчәк-үсемлек мотивлары киң урын алган. Канәфер, роза һәм болын чәчәкләре композициясе бөтеркәләнеп гирляндалар хасил иткән, натюрмортларны хәтерләтүче кәрҗин яки куак кебек үсеп чыккан чәчәк бәйләмнәре сюжеты да еш очрый.

Шома чигү үрнәкләреннән спиральсыман бөтеркә бизәк, яфрак-чәчәксыман бизәк һәм «тормыш агачы» мотивы (намазлык; Мәдәнә авылы), дулкынсыман бизәкне күрсәтеп үтәргә мөмин.

«Рәшидә» мәчете музеенда саклана торган сөлге үрнәге дә тикшеренүчеләрнең игътибарын җәлеп итәрлек: шома чигү техникасында эшләнгән, өстенә бөрчек-бөрчек кара төшкән кызыл чәчәк рәсеме шакмаксыман бизәкләр хасил итә.

Кайбер сөлгеләрнең башларында гарәп хәрефләре белән бизәлгән истәлек язуларын да очратырга туры килде (Актук авылы). Бер тукылган сөлгенең башына шома чигү белән «Хөсәен» исеме язылган (Сафаҗай мәктәбе музее). Бу язу, бәлки, бүләккә лаек кешенең исемедер.

Чүмбәли авылындагы борынгы кул эшләнмәләре үзләренең байлыгы, төрлелеге белән башкалардан аерылып тора. Бәрхет, ефәк тукымаларга алтын, көмеш, укалы җепләр белән төшерелгән бизәкләр күз явын алырлык (төп өлешне түбәтәйләр, калфаклар, тасмалар тәшкил итә). Лалә чәчәкләре, өчьяфраклар, чәчәкле, яфраклы, җимешле үсемлек ботаклары баш киемнәренең

кырыйларында һәм уртасының бер өлешендә урын алганнар. Бу бизәкләр Казан татарлары орнаменты белән охшаш.

Музейларда сәйлән яки энҗе белән чигелгән бәрхет калфакларның төрле төсләре сакланып калган (яшел, куе кызыл, шәмәхә, зәңгәр һ.б.).

Ир-ат баш киемнәреннән түбәтәй («кәпәч») һәм каракүл бүрекләрне очратырга була. Плюш һәм бәрхеттән тегелгән түбәтәйләрнең җирлекләре бертөсле, аерым өлешләре сәйлән, укалы чигү белән бизәлгән. Сафаҗай авылындагы экспедиция вакытында В.М. Измайлова безгә бабасының абыйсыннан – Кәрим Мөхәммәтхановтан (1910–2000; Зур Рбишча авылыннан) калган тамбурлы тоташ чигү белән эшләнгән бик матур түбәтәй күрсәтте. Монда шулай ук «тус-тупи» дип аталган үзбәк түбәтәйләрен дә кияргә яратканнар. Бу түбәтәйләр сәнгати яктан бик үзенчәлекле: аның һәрбер өлешендә (долька) кара фонга ак традицион бизәк («кыяр») чигелгән (Чүмбәли, Актук).

Чүмбәли авылында без тоташ каракүлдән тегелгән бүрекләрне күрдек. Хатын-кызлар хәзерге вакытта да төрле төстәге (ак, шәмәхә, яшкельт) шәлләрне бик яратып бәйлиләр (яулык-шәлләрне «җәеп» бәйлибез, диләр).

«Әнинең ак чуклы өрпәге бар иде. Өрпәкне яшь килен, кызлар кигән» – дип искә ала Н.О. Хәлилуллина (1935; Мәдәнә).

1930 нчы елларда Мәдәнәдә озын чуклы зур ак шәл булган. Аны киленнәр кияүгә чыкканда ябынганнар. Ул авылда бер генә һәм мөһим ритуаллардан саналган.

Чүмбәли авылындагы мәктәп музеенда «кияү бишмәте» саклана[1]. Урта Азиядән китерелгән кыйммәтле ачык тукымадан, җиңнәре терсәккә кадәр генә җитәрлек итеп тегелгән казаки Ходайбирде Бигичевныкы булган (музейга Зәйнәп Бигичева 1967 елда тапшырган). Кыз ярәшкән көнне, кәләш белән беренче очрашуга кияр өчен кияүләр бу казакины аннан алып торганнар. Мәрьям Деникова «кыз туны»н (бишмәт) кунакка барганда гына кигән. Тун дүрт өлештән торган бизәкле атластан тегелгән (күтәрмә яка, чабулары зигзагсыман ромблар белән тегелгән).

---

[1] Мәгълүмат бирүче – А.Х. Шияпов (1925 елгы).

Алты өлештән тегелгән бишмәтләр дә очрый. Мәсәлән: яшькелт төстәге плюш хатын-кыз бишмәте (шәлсыман яка, сырылган эчлек, кесә һәм каптырма – уң якта).

Чүмбәли авылы мәктәп музеенда XX гасыр башына караган хатын-кыз өс киеменең уникаль коллекциясе мишәр хатын-кызларының модасы һәм зәвыгы турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Хәлимә Низамованың яшел төстәге кыйммәтле күлмәге шакмаксыман бизәкле ефәктән тегелгән: җиңнәре аска таба киңәя бара, бөтеркәле; бизәлеше – челтәрле яка һәм ефәк чукмар. Итәк очы вак-вак чуклы зәңгәр тасма белән бизәлгән, эчлеге дә бар. Арткы ягында пелерина формасында киң яка. Итәгендә төймәләр (4 данә) белән бизәлгән декоратив гипюр ялгау (вставка) да бар. Яка челтәр белән бизәлгән. Шома чигү белән тоташ чигелгән чәчәкле киҗе-мамык тукымадан күкрәкчә «изү»не хәтерләтә. Җиңнәре челтәрдән бәйләнгән бөрмәләр белән бизәлгән.

Фирүзә Арслpraнованың кара атлас күлмәге дә игътибарга лаек (музейга 1970 елда тапшырганнар). Ул ике өлештән тора, сатин эчке күлмәге дә бар. Декоратив бизәлеше – ришелье, гипюр ялгауларга эре күбәләкләр, чәчәк-үсемлек мотивлары төшерелгән. Җиңнәре киң итеп, манжет белән эшләнгән. Яшерен каптырмалары бар, якасы түгәрәк, челтәр белән бизәлгән (ришелье). Арткы өлеше дә бизәкле. Элгечкә элеп куяр өчен махсус элмәкләре бар.

Хатын-кыз изүен бизи торган әйберләр арасында безнең игътибарны Ф. Фазлуллина күкрәкчәсе җәлеп итте. Ул төрле зурлыктагы перламутр төймәләр һәм тәңкәләр белән бизәлгән. «Яшь килен күкрәгеН һәрвакыт ябарга тиеш» – ди А. Шияпов. Мәдәнә авылыннан Камалетдинова Фәрзәнә сөйләвенчә, элек күлмәкләрне тәңкәләр белән бизәгәннәр. Чәч «үреләренә» чулпы («кыстынка») такканнар.

Элекке заманнарда бу төбәктә агач кайрысыннан ясалган «шакмаклы» чабаталар (күтәртмәле) һәм төпле башмаклар кигәннәр. Укытучы Әнисә Вәсил кызы Сәетова (1925) үзенең укучыларына күренекле татар язучысы Кави Нәҗминең дә «шакмаклы» чабатадан йөргәнен сөйли торган булган[1].

---

[1] Мәгълүмат бирүче – К.С. Армиханова (1959 елгы).

Төбәкнең резина аяк киеме ясаучы үз осталары булган. Мәсәлән, Чүмбәли авылында (1940 нчы еллар) Аббас Низамов олыларга һәм бала-чагага галошлар ясаган. Хатын-кызлар шулай ук үкчәле резин туфлиләр дә кигәннәр. (Мәрьям Азизова туфлие; 1920–1930 нчы еллар).

Читек-кәвешләрне («бәбец», – «бәбеч») Казаннан кайтарткannar һәм көндәлеккә кигәннәр, шуңа күрә аларны «Казан тапочкалары» дип тә атыйлар. «Читек-кәвешне Казан ягыннан китерәләр иде. Кешелеккә генә, мәчеткә барганда бик кадерләп хәзер дә кияләр» – ди З.М. Айнетдинов. *(Мәдәнә)*

Мәкаләгә йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: Нижгар татарлары ислам традицияләрен саклап, хөрмәтләп яшиләр. Һәрбер авылда мәчетләр салынган, һәрбер йортның эчке һәм тышкы бизәлешендә дини символикалар урын алган. Йортның һәрбер бүлмәсендә (аш бүлмәсе, керү бүлмәсе, йокы бүлмәсе, зал) сатып алынган яки кулдан ясалган шәмаилләр эленеп тора. Кайчакта бер йорт эчендә аларның саны 7–8 гә җитәргә мөмкин. Бу төбәк халкында «шәмаил» сүзе кулланылмый, аларны «катымлык» («хәтем» – дога), «аятелкөрси», «дога» дип атыйлар.

Безнең тарафтан 20 шәмаил тикшерелде һәм язып алынды. Аларның төп өлешен төрле эчтәлекле каллиграфик язулар белән архитектура күренешләре алып тора. Алар чәчәк-үсемлекле яки орнаментлы каймалар белән әйләндереп алынган. Каллиграфик композицияләрдән генә торган шәмаилләр дә очрый (Садыйк хәзрәт йортында).

Шәмаилләр күбесенчә үзешчән осталар тарафыннан пыялага ясалганнар (фольга яки хәзерге ялтыравык кәгазьләр кыстырыла). Профессиональ каллиграфия юк диярлек. Казан татарларында очрамый торган ачык, контраст төсләр кулланыла (ал, алсу, шәмәхә төсләр өстенлек итә). Рәсемнәре дә примитив характерда. Кайбер шәмаилләрдә мәчет архитектурасын, манаралы мәчетләрнең примитив рәвештә ясалган рәсемнәрен реа0листик ысул белән язылган пейзажларда күрсәтү очрый. Күк йөзе фонына «Басмала»[1]

[1] «Басмала» – бисмиллаһи-р-рахмани-р-рәхим.

һәм «Хәмдала»[1] язылган була (Краснай авылындагы кызыл мәчетле һәм бакчалы шәмаил; Сафаҗай авылындагы дүрт манаралы мәчет).

Гадәттә, фольга белән яктыртылган композиция уртасына манаралы мәчет ясалган, почмакларга эре чәчәкле, яфраклы бизәкләр төшерелгән (Күгелҗем-соры төстәге фонда мәчет рәсеме ясалган шәмаил. Күк гөмбәзенә «Аятел-көрси» дип язылган. Аятьтән соң шәһәдә, аннан соң дүрт изге хәлифәгә мөрәҗәгать урнаштырылган: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали (пыяла, туш, фольга, майлы буяу 50×38; А.М. Сөләйманов йорты, Сафаҗай авылы). Бу шәмаилне Казан татарларыннан сатып алганнар.

Садыйк хәзрәт йортында төрле техник ысул белән, борынгы һәм хәзерге көндә эшләнгән шәмаилләр коллекциясе бар (пыялада, фанерда, чүкеп ясалган). Шулай ук кәгазьгә ясалып, пыяла рам эченә урнаштырылган шәмаилләр дә очрый (Куй суы).

А.Җ. Алиәкбәров йортындагы (Пашат) шәмаил фотокәгазьдә ясалган: кара фонда ак мәчет силуэты, өстә текст (21×29).

Пашат авылында безгә шәмаилләр ясаучы оста Мөнир Фазлулла улы Фазлуллин ((1906–?), кушаматы «Мөнир шәкерт») турында сөйләделәр. Заманында ул Петрякс авылы мәдрәсәсендә укыган. Бертуган кардәшенең улы Шәмсетдин Шиафетдин улы Шиафетдиновның (1935) сөйләвенчә, ул Мәскәүгә киткән һәм, шунда яшәп, сатуга шәмаилләр иҗат иткән. Аларның йортында сеңлесе Сәлимәгә бүләк иткән шәмаил саклана.

Композиция уртасында зәңгәр фонга өч биек манаралы ак таш мәчет төшерелгән. Мәчетнең нигезе, гөмбәзләре кызыл төстә. Күктә ак болытлар йөзә, тирә-якта биек агачлар, алгы планда мәчеткә илтүче чирәмгә һәм чәчәкләргә күмелгән юл күренә. Мәчетнең төрле ягында кызгылт-сары, фирәзә, зәңгәр фондагы турыпочмаклы һәм ярымтүгәрәк композицияләр эченә Коръән сүрәләре язылган.

Түбән Новгород татарлары көнкүрешен, мәдәниятен, гамәли-тасвирый сәнгать төрләренең торышын күзәткәннән соң, йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: элекке заманнарда татар-мишәрләр

---

[1] «Хәмдала» – әл-әлхәмдули-л-ләһи-рабби-л-галәмин.

арасында халык сәнгатенең бөтен төрләре дә үсеш алганнар. Чигү, тукучылык, бәйләм бәйләү, тегү, агачтан кисеп бизәк ясау, чүлмәкчелек – болар барысы да без китергән төрле үрнәкләрдә күренә. Бүгенге көндә инде аларның кайберләре бөтенләй юкка чыккан (тукучылык, чүлмәкчелек), кайсылары һаман үсешен туктатмый (бәйләм бәйләү, агачтан кисеп бизәк ясау һ.б.).

Авыл тормышына көннән-көн шәһәр культурасының, яңа технологияләрнең керүе яшәешне нык үзгәртә: көндәлек тормышта, өй эче бизәлешендә, архитектурада чагылыш таба. Шулай итеп, традицион сәнгать төрләренең бүгенге көндә кулланышы заманча төсмер ала. Мәсәлән, сөлгеләр бүген тукылмаса да, чигелмәсә дә, үзләренең йола функцияләрен югалтмаганнар[1].

Тарихи-мәдәни шартларда формалашкан татар-мишәр рухи мәдәниятенең үзенчәлеге бүгенге көнгә кадәр саклanган. Безнең тарафтан ачыкланган гамәли сәнгать материаллары шуны күрсәтә.

*Русчадан Э.И. Сафина һәм А.В. Әбдриева тәрҗемәсе*

[1] «Элек кеше вафатыннан соң түргә тукылган сөлгеләр элсәләр, хәзер мәетнең йөзенә япкан сөлгеләрне 40 кичәсе узганчы, аның төсе итеп тоталар» (З.М. Айнетдинова (1950 елгы)).

КУШЫМТА

## Музейлар

***«Рәшидә» мәчете каршындагы музей («Мәдәнә» дини-мәдәни үзәге).***

2001 елда оештырылган. Директоры Беляев Фәрит Абдрахман улы. Музей фондында 5 меңгә якын экспонат исәпләнә.

***Х. Фәезханов исемендәге Сафаҗай урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган якны өйрәнү музее (Пилнә районы Сафаҗай авылы).***

Музей 1978 елда оештырылган. Беренче директоры – Таҗуризин Камил Таҗуриз улы (1927 елгы).

Төрле елларда музей директорлары: Сабиров Сәяр Вафа улы (1923 елгы; мәктәп директоры – бүгенге музейга нигез салучы. Аңа немец теле укытучысы Кәримов Ринат Кәрим улы (1937) булышкан), Кәбирова Ләйлә Әнвәр кызы.

Хәзерге көндә музей белән инглиз теле укытучысы Измайлова Венера Максут кызы (1960) җитәкчелек итә.

Мәктәп директоры Мусин Рамил Хәбип улы (1959).

***Петрякс авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее.***

Музей 1983 елда оештырылган. Директоры – Алимова Йолдыз Сәүбән кызы (1925–2009). Музей бүгенге көндә мәктәп директоры Билялова Клара Абдулхаковна (1954) карамагында.

***Краснай авылы мәктәбенең туган якны өйрәнү музее.***

Мәктәп директоры Ибраһимов Абдулбарый Абдул улы (1932–2010). Директоры Армиханова Кадрия Сәяр кызы – татар һәм немец телләре укытучысы (1959 елгы).

***«Куй суы» авылы клубындагы туган якны өйрәнү музее.***

***Р. Ваһапов исемендәге Актук мәктәбе.***

Музей җитәкчесе Алиева Рушания Әхмәт кызы.

***Халык музее**. (Чүмбәли)*

Чүмбәли тулы урта мәктәбе (Кызыл Октябрь районы).

Директор, музейга нигез салучы – Шияпов Абдулвәдүт Хуҗа улы (1925), Халык мәгарифе отличнигы, «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены

кавалеры, К.Нәҗми исемендәге премия лауреаты, районның почетлы гражданины.

Музей 1967 елда оештырылган. Музей фондында 5 мең экспонат бар.

## Осталар

### *Мәдәнә авылы*

Фәйзуллина (Вәлитова) Сара Сафа кызы (1922–1996) – бәйләү остасы (челтәр бәйләүче).

Хөсәенова Мөнирә Бәдретдин кызы (1933) – чигү һәм бәйләү остасы.

Җамалетдинова (Билялова) Хәлимә Җамал кызы (1912–2000) – тукучы.

Хәмидуллина Мәрьям Абдерәхим кызы (18 ?) – тукучы.

Хәбибуллина Мәликә (? –1982) – тукучы.

Хәлилуллина Сания Фәйзрахман кызы (1930) – бәйләү остасы.

Хәлилуллина Зәйнәп – тукучы. (Аның сөлгеләре килене Нәсимә Осман кызында (1935) сакланган.)

### *Сафаҗай (Красная Горка) авылы*

Гыйльманов Искәндәр Гыйльман улы (1933) – киез кату, киез итек басу остасы.

Хәбибуллин Хәмзә, Хәмзин Хәйдәр, Хөсәенов Мәлик, Хөсәенов Абдулхак – мич салучылар династиясе.

Асадуллина Кафия Сәмиулла кызы (1935) – челтәр бәйләүче.

Сөләйманова Рауза Сәмиулла кызы (1937) – чигүче, челтәр бәйләүче.

Ибраһимова Зафәрә Якуб кызы (1910–1989) – тукучы.

### *Краснай (Красный Остров) авылы*

Баутдинова Факия Вәдүт кызы (1942) – челтәр бәйләүче.

Җамалетдинова Фәймә Әхмәт кызы (1954).

Җәләева Әминә Сафа кызы (1927) – челтәр бәйләү остасы.

Нәҗметдинова Рафия Абдулкадыйр кызы (1951) – чигүче.

Измайлова Клара Таҗетдин кызы (1932) – челтәр бәйләүче.

### *Чүмбәли авылы*

Низамов Аббас – резин галошлар ясау остасы.

Габидуллин Бәдретдин (1820–?), Бәдретдинов Гаязетдин, Гаязетдинов Сөләйман (1880 елларда эшләгәннәр) – көмешчеләр династиясе.

### *Рбишча авылы*

Хәлиуллин Хәйдәр – агачтан кисеп ясаучы.

### *Пашат авылы*

Фазлуллин Мөнир Фазлулла улы (1906–?) – (кушаматы «Шәкерт Мөнир») шәмаилләр ясау остасы.

Шәрәфетдинова Мөнәвәрә Мөхәммәдьяр кызы (1912–1983) – тукучы.

Сәмиуллин Абдулбарый (1932–2010) – балта остасы, тимерче.

### *Актук авылы*

Хамматов Әнвәр – балта остасы.

### *Петрякс авылы*

Низаметдинова Садия Әсәт кызы (1938 елгы) – тукучы.

# ИБЕН БЕЛСӘҢ, КӨЕ КИЛӘ

## *Музыкаль фольклор һәм уен кораллары*

*Эльмира Каюмова*

*Җыр булса – икмәк тә була.*
Халык әйтеме (Зур Рбишча)

*Приведи-ка, матушка, Татарина с скрыпкою,*
*Мордвина с волынкою.*
А.С. Пушкин язмаларыннан (Болдино)

2010 елның 30 май – 11 июнь көннәрендә Түбән Новгород өлкәсенә юнәлтелгән комплекслы экспедиция кысаларында мин, музыка белгече буларак, этномузыкаль тикшеренүләр алып бардым. Барлыгы 15 авыл өйрәнелде: Княгинин районы – Ыргу (Урга); Кызыл Октябрь районы – Актук (Актуково), Зур Рбишча (Большое Рыбушкино), Куй суы (Овечий Овраг), Мәдәнә (Медяны), Пашат (Пошатово), Чүмбәли (Чембилей), Яндавишча (Ендовищи); Пилнә районы – Петрякс (Петряксы), Сафаҗай (Красная Горка)[1]; Сергач районы – Камка (Камкино), Кучкай Пожары (Кочко-Пожарки); Сеченов районы – Краснай (Красный Остров); Спас районы – Бозлау (Базлово), Татар Моклокасы (Татарское Маклаково). Кылган сәяхәтебез дәвамында 1919–1984 еллар арасында туган 80 нән артык кешедән күп төрле мәгълүматлар

[1] Сафаҗай һәм Красная Горка исемнәре күптән түгел генә кулланыла башлаган. Халык элек тә, хәзер дә бу авылны Сабачы, Сабацы,Сабацай дип атый, шуннан русча – Собачий Остров килеп чыккан.

тупланды (халык музыкасы һәм авыз иҗаты үрнәкләре, гореф-гадәтләр, авыллар тарихына кагылышлы материаллар һ.б.).

Тәэсирләргә килгәндә, Түбән Новгород якларында яшәүче татарлар (галимнәр аларны сергач мишәрләре дип атыйлар) бик ачык, кунакчыл халык, шуңа күрә үземне Татарстаннан читкә китмәгән дә шикелле, ягъни үз өемдәге кебек хис иттем. Сүз уңаеннан, эшебез белән кызыксынып, аның асылын аңлап, ярдәм иткән авыл башлыклары, дин әһелләре, мәгариф һәм мәдәният хезмәткәрләренә, шулай ук барлык халык башкаручыларына күңелләрендә йөрткән иҗат җимешләрен тапшырган өчен ихластан рәхмәтемне белдерәсем килә.

Нижгар татарлары бай, мул тормыш алып баралар. Урынҗирләре иркен, урамнары киң, йортлары зур. Авылларында ике катлы йортлар шактый, хәтта өч катлылар да очрый. Чагыштырмача «кечкенә» – бер этажлы өйләрендә дә 4–5 бүлмә бар. Шунысы кызык: кеше саны 500–600 дән артмаган авыл бетә торганнардан исәпләнә, ә инде халкы 3 меңгә якын булса (мәсәлән – Зур Рбишча) – әйбәт, ныклы булып санала.

Биредә яшәүчеләр – эшчән, тырыш һәм максатчан. Һәрбер йортта диярлек төзү, яңарту эшләре гөрләп тора. Шунлыктан, өлкән буын вәкилләрен дә еш кына эшләреннән аерырга туры килде.

Тагын бер сокланырлык сыйфатны аерып үтәсем килә. Мишәр татарлары үзләренең тарихын, динен, мәдәниятен саклауга күп көч куялар. Мәсәлән, Түбән Новгород шәһәрендә махсус газеталар («Туган як», «Мишәр дөньясы»), журналлар («Ислам на Нижегородчине») чыгалар, «Мәдинә» нәшрияте бар, «Маһинур» мәдрәсәсе эшләп килә һ.б. Ә инде ислам символикасына зур әһәмият бирүләре – башка милләтләр арасында югалып калмау чарасы.

Музыка сәнгатенә якын килсәк, әлеге төбәк – Рәшит Ваһапов һәм Хәйдәр Бигичев кебек мәшһүр җырчыларның туган ягы. Безгә алар туып үскән Актук (икенче исеме – Яңапар) һәм Чүмбәли (Цүмбәли) авылларын күрү насыйп булды. Җыеп алганда, мишәр халкы бик музыкаль. Билгеле ки, бүгенге көндә күп кенә фольклор әсәрләре юкка чыгу дәрәҗәсенә җиткәннәр (XXI гасырда, өченче меңьеллыкта яшәгәнебезне онытмаска кирәк). Ләкин шуңа

да карамастан, тамчылап, бөртекләп туплый торгач, 2010 елгы экспедиция нәтиҗәсендә бик кызыклы һәм үзенчәлекле материаллар язып алынды. Яңадан барсаң – тагын шуның хәтле җыркөй табылыр сыман, чөнки, вакыт чикле булганга күрә, кайчакта тиз-тиз генә урап кайтырга туры килде (югарыда авылларның күпсанлы икәнлеген искәртеп узган идек, шунлыктан һәрберсен җентекләп йөреп чыгар өчен бер атна вакыт та җитмәс).

Элегрәк бу якларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих (сәнгать) институты, Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе (академиясе), Татар фольклоры дәүләт үзәге тарафыннан оештырылган экспедицияләр эшләп килгәннәр.

1962 елда нижгар мишәрләренең җыр-көйләрен күренекле музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов язып кайткан булган. Бер ай дәвамында (7 июньнән алып 6 июльгә кадәр) 12 авылны тикшереп, 54 информанттан (1860–1940 елгылар) 228 халык музыка үрнәкләре җыелган[1]. Аларның дүрттән бер өлеше (59 мисал) 1970, 1976 һәм 1984 нче елларда басылган ноталы җыентыкларда дөнья күргән[2]. Шунысын ди билгеләп үтик, Түбән Новгород өлкәсенә килүебезнең бер сәбәбе бүгенге музыкаль фольклор хәзинәсен әлеге язмалар белән чагыштыру иде.

Әлбәттә, 50 елга якын вакыт эчендә шактый күп үзгәрешләр барлыкка килгән. Мәсәлән, М. Нигъмәтҗанов туплаган «Ташкай бәете», «Әхсән бәете», «Киндерләр җәйдем», «Зәлифәкәй», «Далаларда егет печән чаба», «Анай кәбәй» (кыз елату) кебек әсәрләр

---

[1] Отчет музыкально-фольклорной экспедиции ИЯЛИ КФАН СССР в Горьковскую область 1962 г. // Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге, 74 ф., 1 тасвир., 2 сак. бер., 2 б.

[2] *Нигмедзянов М.Н.*Татарские народные песни. – М.: Сов. композитор, 1970. – №№ 37, 39, 40, 40а, 40б, 42, 49, 50, 61–64, 70, 72, 76, 79, 83–89, 95, 108, 117–119, 125–127, 130, 130а, 131, 135, 145, 152, 165, 176, 177, 183, 187, 193, 194, 196, 199, 205; *Нигъмәтҗанов М.Н.* Татар халык җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – №№ 83, 109, 114, 117, 208, 249; Нигмедзянов М.Н.Татарские народные песни. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – №№ 66, 107, 117, 152, 160, 231. Шул исемлеккә чыгышы буенча Кызыл Октябрь районыннан Мәскәүдә яшәүче башкаручылардан язып алынган үрнәкләрен дә кертеп җибәрдек.

безгә бөтенләй очрамады. Традицион бәетләр һәм лирик озын көйләр – сирәк очрый торган жанрлардан. Хәзерге чорда күбрәк кыска көйләр кулланыла, аеруча – «Картош көе» бик популяр, аның дистәләгән вариантларын язып алдым. Шунысы сөендерде: сергач этнографик төркеменә генә хас булган «Түмә такмаклары»н («Түмә бәетләре») хәтерләүчеләр әле дә бар. Шул ук вакытта, яңа әсәрләр, моңарчы яктыртылмаган яклар ачыкланды.

Алдагы елларда мөселман музыкаль традициясенә игътибар аз булган. 2010 елгы фәнни сәфәрдә исә күп кенә көйләп әйтелә торган мөнәҗәтләр, Коръән сүрәләре, салаватлар, азаннар тупланды. Борынгы туй җырлары, үзенчәлекле «Җимчәчәк», «Байкалга батыру», «Бармак уены» көйләре язылды. Өстәвенә, мандолина һәм скрипкада уйнаучыларны табарга туры килде. Болар турында тәфсилләп язарбыз.

Казан белән Мәскәү арасында урнашуы музыкаль-шигъри иҗатта да чагылыш таба. Нижгар татарларының музыкаль фольклоры өч катламнан гыйбарәт: 1) мишәр компоненты (төрки һәм фин-угыр этник элементларның берләшүе нигезендә барлыкка килгән); 2) гомумтатар культурасы (уртак җырлар, дини көйләр); 3) рус мәдәнияте йогынтысы (репертуарда һәм башкару манерасында сизелә).

Җирле үзенчәлекләрне тасвирлауны иң элек кыска көй рәтенә кергән «Картош», «Баламишкин» (халык телендә – «Маламишкин») исемнәре белән мәгълүм көйдән башларга кирәк.

Яндавища илебез,
Ик[е] очында күлебез,
Ик[е] очында күлебез.
Кайсы күйгә йырласак та
Килә «Картош» көебез.
(Яндавишча авылы)

Куй суы дигән җиребез,
Уртасында күлебез,
Уртасында күлебез.
Җырласак та матур чыга
«Маламишкин» көебез.
(Куй суы авылы)

Аның төп атамалары – авыл күе, урам күе. Башкаручылар фикеренчә, бу көй – барыннан да өстен, ягъни беренче урында тора. Бергә җыелган чакларда (туйларда, егетләрне солдатка озатканда, бәбәй бәйрәмнәрендә һ.б.) җырлашуны шуннан башлыйлар, анда йөзләгән куплетлар кереп китә («сыптырталар гына», «вичерларда берсенең артыңнан ялгый гына барасың»),

аннары гына башка көйләргә күчәләр. Элегрәк уен җырлары да шул көйгә башкарылган.

Еш кулланыла торган «Картош» исеменең килеп чыгышын болайрак аңлаттылар. Беренчедән, әлеге көй бәрәңге кебек киң таралган. Икенчедән, «түгәрәк булгангамы, по кругу шулай йырлап йөриләр». *(Петрякс)* Өченчедән, «Картош шылдырдыймы салганда? Шуның шикелле бит, менә дырылдаттырып җырлап бетерәләр дә – булды». *(Мәдәнә)*

Авыл халкы аның аермасын тоеп, «безнең мишәр көе» дип горурланып торалар. Шигъри ягын билгеләгәндә, нижгар такмаклары, частушкалар дигән төшенчәләр кулланышта йөри.

Шулай итеп, Татарстанда яшәүче казан татарларының «Алмагачы» кебек, сергач мишәрләренең «Картош»ы («Баламишкин») көйләр патшасы булып тора.

Биредә танылган «Сарман», «Арча», «Шахта», «Рамай», «Галиябану», «Сибелә чәчем», «Урманнарда йөрдем» һ.б. аеруча яратып җырланган. «Тәфтиләү», «Вәсфи Камиләкәй», «Мәрфуга», «Агыйдел буйлары», «Ык буйлары», «Сакмар буйлары» җырларының аерым мисаллары язылды. Композиторлар әсәрләреннән «Утыр әле яннарыма» (И. Хисамов муз., Ш. Галиев сүз.), «Керим әле урманнарга» (Р. Яхин муз., Г. Мөхәммәтшин сүз.), «Китмә, сандугач» (Р. Яхин муз., Г. Зәйнашева сүз.), «Җидегән чишмә» (С. Садыйкова муз., Г. Бәширов сүз.), «Чыгарсыңмы каршы алырга?» (В. Әхмәтшин муз., Д. Гарифуллин сүз.), «Кыр казлары киткәндә» (Ә. Бакиров муз., Р. Гәрәй сүз.), «Әйтмә син авыр сүз» (Р. Хәкимов муз., Р. Чурагулов сүз.) һ.б. таралыш алган.

Түбән Новгород төбәге авылларында **йола фольклорының** саклануы төрлечә. Мәсәлән, Татар Моклокасы, Бозлауда борынгы туй җырлары хәзерге көнгә хәтле килеп җиткәннәр. Биредә оригиналь «Силәзән җырлары»[1] башкарылган. Өйләнмәгән егетләр төрле төстәге тасмалардан ясалган бәйләмнәрен шешә башларына куеп, эротик эчтәлекле текстларын җырлап (кияүнең ир булуын аңлатып), театраль тамаша күрсәткәннәр. Әүвәле «Силәзән җырлары»н Ыргу авылында да уйнатканнар. Әлеге авыл-

---

[1] Силәзән – селезень (рус.)

да сирәк очрый торган «Абау, бәгърем» кушымталы сүзләр белән башкарыла торган бик матур көй язып алынды.

2010 елгы экспедиция барышында «Җимчәчәк» җырлары (белгечләрнең күбесе аларны ел фасылы белән бәйле йола иҗатына кертәләр)[1] фәкать Камка авылында гына табылды. Әйтергә кирәк, шундый исемдәге язгы уеннар Рязань өлкәсенең Әҗе авылында, Башкортстанның Ык буенда урнашкан авылларында (элекке Бәләбәй өязе), Татарстанның Лаеш районы Ташкирмән авылында да булган[2]. Камкада язылган үрнәктә түбәндәге юллар бар:

Зимцәцәк, зимцәцәк,
Зима буе сарымсак, сарымсак,
Сарымсакка ни кирәк?
Энә белә[н] йеп кирәк.

Әһәмияте шунда ки, алданрак теркәп куелган язмаларда сарымсак сүзе урынына нарымсак диелгән:

Зимә буе нарымсак, нарымсак,
Нарымсакка ни кирәк, ни кирәк,
Ярма-ярма бүз кирәк, бүз кирәк,
Ул бүзләрне тегәргә, тегәргә
Инә белән җеп кирәк, җеп кирәк...[3]

Борынгы сүзнең мәгънәсе аңлашылмаганга күрәдер, тора-бара ул үзгәртелеп әйтелә башлаган. Керәшен татарларының җырларында исә (Ташкирмән авылы) нарыймдҗан сүзе кулланыла:

Джем тчәтчәк, джем тчәтчәк,
Нарыймдҗанга ни кирәк, ни кирәк,

---

[1] *Мухамедова Р.Г.* Татары-мишари: Историко-этнографическое исследование. – М.: Наука, 1972. – С. 198; *Сарварова Л.И.* Этнический компонент песенной культуры татар-мишарей: Вопросы звуковысотной и фактурной организации: автореф. дис. ... канд. искусствоведения. – Казань, 2006. – С. 6. Р.К.Уразманова уйлавынча, «Җимчәчәк»не йола итеп түгел, ә язгы ташу вакытындагы яшьләр уены дип расларга кирәк: *Уразманова Р.К.* Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX – нач. XX вв.). – Казань: Дом печати, 2001. – С. 88.

[2] *Уразманова Р.К.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 88.

[3] Татар халкының җырлы-биюле уеннары / төз. Х. Гатина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – Б. 55.

Ак калпаклы кыз кирәк, кыз кирәк,
Джемрә-джемрә джем тчәтчәк...[1]

Нижгар якларында иң таралган **уеннар** арасында «Байкалга батыру» (исемнең вариантлары: «Суга батыру», «Бака төшәге») һәм «Бармак уены»н атарга мөмкин. Беренчесенең тәртибе болай: яшьләр түгәрәкләнеп утыралар, уртада берәү түндәктә (артсыз урындыкта) утыра. Аны башта җыр белән «батыралар», аннары кем дә булса «чыгара». Чыгарган кеше үзе түндәктә кала. Уен шулай дәвам итә.

«Бармак уены»н өйләрдә дә, ә күпчелек кырда (чөгендер утаганда), эштән арып ял итәргә җыенгач, оештырганнар. Еш кына җиргә йөзтүбән ятканнар һәм һәр кеше (катнашучы санына карап) бер, ике (берсе – егет, берсе – кыз имеш), дүрт, яки биш бармагын куя торган булган. Бармакларга чиратлашып басып, мәхәббәт җырларын (ашыйк йырлары) башкарганнар. Җыр кемдә тукталса, аның эчтәлеге шул кешегә кагылган дип саналган. Шул рәвешле сөйгән ярларын юраганнар[2]. Шунысын да искәртик, әлеге уеннар 1954–1958 нче елларда туган буын вәкилләренә инде эләкмәгән, ә кайбер авылларда хәтта алардан олыраклар (мәсәлән, Ыргуда 1947 нче елгылар) да аны уйнаудан туктаган.

Кызыл Октябрь районы Өчкүл авылы яшьләре июнь урталарыннан алып сентябрьгә кадәр кич саен Катлама күле янына җыела торган булганнар. Кара-каршы чирәмгә тезелешеп (уртада – баянист була), бер-берсен төрттереп «Чиртеш җырлары»н башкарганнар. Җыр аша ярышу формасында узган бу кызыклы уен турындагы мәгълүматларны Актук авылында яшәүче Яруллина Рафия Җәфәр кызы (1956 елда Өчкүл авылында туган) тапшырды.

Санап киткән уеннарның җыр текстлары «Картош» көенә яңгыраганнар. Шулай ук татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә популяр

---

[1] *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр: Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. – Казан: Матбугат йорты, 1997. – Б. 197.

[2] «Бармак уены» пермь татарларында да таралган булса кирәк. III Бөтенроссия «Түгәрәк уен» фестивалендә (Екатеринбург, 2010) Барда районыннан килгән фольклор коллективының бу уенны сәхнәдә күрсәтүе шулай фикерләргә нигез бирә.

булган «Йөзә үрдәк, йөзә каз» («Күпер чыгыш», «Күпер алыш» уены), «Сара сибә», «Суда, суда», «Челтәр элдем читәнгә», «Талы бөгелеп тора» һ.б. җырлар да таралыш алган.

Уеннар белән бәйле җирле төшенчәләр дә игътибарга лаеклы. Мисал өчен, Княгинин районындагы бердәнбер татар авылы булган Ыргуда уеннарны куерту дип йөрткәннәр. Түгәрәккә басу халык телендә – мәрәгә басу дип атала (Куй суы, Пошат һ.б.).

**Бию көйләре** җыелмасы «Әпипә» («Афифә»), «Бишле бию», «Краковяк», «Яблочко», «Цыганка» («Цыганочка»), «Барыня» («Русский») кебек үрнәкләрне үз эченә ала. Сергач мишәрләренең кычкыртып бию (Зур Рбишча), бал кычкырту (Краснай) гадәтенә тукталып китик. Информантларның сөйләве буенча, аны мунча сые көнне (кыз ягына кияүнең туганнары җыелгач) үткәрергә яратканнар. Гармунчы янында кем дә булса кепка тотып басып торган, биергә теләгән кеше шунда вак акча салып биегән. Шул чакта «Бер тиен генә салды!» дип кычкырсалар – аңа гармунчы уйнамый инде (әз биргән дип). Яисә: «Ун тиен салды!» (ул заманнарда зур акча!) – ул кеше инде озаграк бии. Шулай итеп кычкыртып-кычкыртып биегәннәр.

Башкалардан үзгә булган **«Төймә такмаклары»** (халыкчан әйтелеше – «Түймә такмаклары», «Түмә такмагы», «Түмә бәете») Мәдәнә, Чүмбәли, Краснай, Сафаҗай, Куй суы авылларында теркәлде. Олы яшьтәге җырчылар аларны яшь чактан ук картлардан ишетеп, отып алганнар. Әлеге мисаллар М.Нигъмәтҗанов язып калдырган көйгә башкарылды[1].

**Бишек җырлары** һәм балаларны кулда сикертеп уйнатканда әйтелгән әсәрләр арасында «вәттүри-вәлбизә, юка бии төнтәнә», «сендибалы, сендибалы, сендибалы сендигач», «томарушка, тымарка, томарушки, тимарка» кебек аңлашылмый торган сүзләргә корылган үрнәкләр бар. Хөсәенова Мөнирә (1933 елда Мәдәнә авылында туган) истәлеге буенча, аның әнисе «сандугачым минеке, былбыл ... минеке» җыр текстын нигәдер үзгәртеп, сүзләрен алыштырып, «сәсү сәсем минетте, быбыт нәсем ми-

[1] *Нигмедзянов М.Н.* Татарские народные песни. – М.: Сов. композитор, 1970. – № 64.

нетте...» дип көйли-көйли сабыйларын йоклата торган булган. Әлеге күренешнең очраклы булмавы бәхәссез. Әмма бу – гади аваз иялртемнәре, иҗекләрне көйгә салып «телдән» җырлаумы, әллә инде борынгылыкның бер калдыгымы? Чын мәгънәсен әле чишәсе бар. Өстәп тагын бишек җырларының **кеше үлгәч елау** үрнәкләре белән бәйләнешен билгеләп үтәргә кирәк (чагыштырып карагыз: Кушымта II, № 8 һәм № 18). Китерелгән мисалларда баланы тирбәткәндә һәм баласын югалтып өзгәләнеп елаганда бер үк сөйләм әйләнмәләре файдаланыла.

Җыелган **бәетләрне** ике төркемгә бүләргә мөмкин. Беренчесен традицион әсәрләр тәшкил итә: «Сак-Сок» (Мәдәнә, Сафаҗай – 3 данә), «Кыз сату бәете» (Мәдәнә, Пашат – 2 данә), «Рамазан бабай бәете» (Сафаҗай), «Марзыя бәете», «Алданган кыз бәете», «Качкыннар бәете» (өчесе дә – Яндавишчада). Икенче төркем хәзерге заман иҗат җимешләреннән гыйбарәт: «Рөстәм бәете» (Зур Рбишча), «Абдулхамит бәете» (Зур Рбишча), «Рамилә бәете» (Яндавишча) һ.б.

Бу якларда әйләнештә йөргән традицион бәетләрнең музыкаль ягына күз салсак, аларда, нигездә, рус җырлары белән охшашлык сизелә. «Сак-Сок» бәетенең язылган үрнәкләре барысы да татарлар арасында киң таралган көйнең вариантлары булып торалар. Белгечләр бу көйнең «Хасбулат удалой» исемле рус балладасы белән уртаклыгы бар дип саныйлар[1]. «Марзыя бәете»[2], «Кыз сату бәете»[3] данлыклы «Кирпичики» көенә якын торалар. Әлеге әсәрнең сүзләрен П. Герман, музыкасын В. Кручинин (С. Бейлейзонның «Две собачки» вальсына таянып) 1924 елда иҗат иткәннәр. Башка мисаллар да шул ук фикерне дәлилли.

---

[1] «Сак-Сок» бәете / төз. Ш.К. Шәрифуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – Б. 3. – (Татар халык иҗаты музыкаль җәүһәрләре).

[2] Ганеева Флюра Ибраһим кызы тапшырды, ул 1938 елда Краснай авылында туган, Яндавишчада яши. Бәетне аның әтисе – 1903 елгы Мансуров Ибраһим Фатыйх улы – ире тарафыннан үтерелгән кыз туганына багышлап чыгарган.

[3] Пашат авылында 1921 елгы Җәләлова Нәфисә Җәләлетдин кызыннан язып алынды. 1903 елгы Мансуров Ибраһим Фатыйх улы – ире тарафыннан үтерелгән кыз туганына багышлап чыгарган.

Безнең чорда иҗат ителгән бәетләр, кагыйдә буларак, көйләнмичә укылалар, ягъни шигъри әсәр буларак яшиләр. Аерым шәхесләрнең фаҗигале язмышына карата чыгарылган үрнәкләр нижгар мишәрләренең «Туган як» газетасы битләрендә басыла килә. Бүгенге авторлар авылдашлары соравы буенча бәетләр, шигырьләр, җырлар уйлап чыгаралар. Андый сүз осталарының кайберләрен атап китик. Яндавишча авылында – Ибраһимова Зәйнәп Юсып кызы (1939 елда Карга авылында дөньяга килгән). Ул үзенең авылдашы, озак вакыт югалып торган Рамилә исемле кыз турында 1995 елларда «Рамилә бәете»н язган. Зәйнәп апа югарыда телгә алынган «Алданган кыз бәете»н һәм «Качкыннар бәете»н көйләп башкарды (ул аларны әнисеннән отып калган). Зур Рбишча авылында яшәүче Ситдыйкова Факия Сәяр кызының (1958 елгы) иҗат сандыгында төрле темаларга багышланган әсәрләр байтак. Мәсәлән, ул 2004 елда җәберләп үтерелгән егетенең әнисе үтенече буенча «Рөстәм бәете»н чыгарган. Шулай ук «Абдулхамит бәете»н карагыз (Кушымта I, № 9).

**Ислам дине белән бәйле халык традициясенә** тукталып үтик. Мөнәҗәтләргә килгәндә, биредә «Мусә мөнәҗәте», «Менә шундый заман җитәр», «Әминә ханым Мөхәммәт анасы», «Рәсүлулла ятим үзе», «Үлем дигән ачы агу», «Газиз гомерләрнең кадерен белмәдем», «Сөйлим әле, балам, сөйлим әле», «Мәҗлесегез күркәм булсын», «Вәйселкарани» (бала йоклатканда да кулланыла) һ.б. таралган. Безнең дәвернең үзенчәлеге шунда ки, башкаручылар текстларны, гадәттә, Казанда нәшер ителгән китаплардан алалар. Шуңа күрә бер үк әсәрләр төрле төбәкләрдә кабатлана. Көйләре исә, күпчелек очракта, якын даирәдән үзләштерелә, димәк, җирле була. Шунысын да әйтергә кирәк, яшь муллаларның мәкамнәрендә гарәп музыкасының йогынтысы сизелә. Китап көйләү мисаллары сирәк очрады: «Бәдәвам» (Мәдәнә), «Йосыф китабы» («Юсип китабы» – Краснай). Чүмбәли авылында Сибгатуллин Мәсум Мусә улыннан (1930 елгы) «Мәүлит-ән-нәби» тулаем язып алынды (ул аны апасыннан калган кулъязма дәфтәрдән укып көйләде).

Хәзерге вакытта төбәктә **музыка коралларында уйнау традицияләре** зур үсеш алган дип әйтеп булмый. Һичшиксез,

җитди нәтиҗәләр ясар өчен барлык буын вәкилләре арасында махсус социологик сораштырулар үткәрергә кирәк. Без, әлбәттә, гасырлар тирәнлегеннән күчеп килгән мирасны барлау максатыннан чыгып, өлкәннәрдән җыеп алган мәгълүматларга таянып фикер йөртәбез. Шулай да, әүвәлге еллар белән чагыштырганда (Петрякста – 100 гармунчы булган, һәр йорт аша диярлек; Бозлауда XX гасырның 60 нчы елларында – 27 кеше), зур мишәр авылларында гармунчылар бармак белән генә санарлык.

Моталлапов Хәлим Хәлиулла улының (Сафаҗай авылыннан, 1933 елгы) ике төрле баяны бар: берсе Германиядә, икенчесе – Россиядә (Тула шәһәрендә) эшләнелгән. Ул Уразавылда яшәгән чакта Вениамин дигән мордва кешесеннән баянда уйнарга өйрәнгән, соңыннан нота билгеләрен үзләштергән. Репертуарында – «Урам күэ», «Идел» («Су буйлап»), «Яшьлек» җырларының инструменталь версияләре, бию көйләре – «Әпипә», «Әнисә», «Цыганочка», «Яблочко», вальслар, маршлар. Яшь вакытта популяр татар җырларын («Сарман», «Зәңгәр шәл», «Шахта», «Галиябану», «Өй артында шомыртым», «Гөлҗамал») яратып башкарган. Аның әйтүе буенча, «Гөлҗамал» җыры Ә. Афзалова концерт куеп киткәннән соң халык арасында бик таралган.

Садеков Рәшит Үмәр улы (1949 елда Чүмбәли авылында туган) 6 яшьтән үк уйный башлаган. Хафиз абзыйсы (1936 елгы) эшкә киткән арада, аның бер рәтле гармунында уйнарга өйрәнгән. Хәзер «Royal standard» баяны (Мәскәүдә сатып алган), «Solo» аккордеонында зур осталык белән уйный. Малае да әтисенең һөнәрен дәвам итә.

Рәшит әфәнде Хәйдәр Бигичевның якын дусты булган, алар бергә үскәннәр. Атаклы якташы җырларга яраткан «Тәфтиләү», «Китмә, сандугач», «Керим әле урманнарга» һ.б. башкарып күрсәтте. Репертуарында бик кызыклы «Пасяк көе» бар. Элек авылда Пасяк кушаматлы көтүче булган, ул бу көйгә кырда җырлап йөргән, үзе тальянда да уйнаган. Туйларда картлар шул көйне сузып, җырлап утырганнар. Шулай ук Р. Садековтан «Урам күе» (биредә «Картош» дип әйтмиләр), «Ык буйлары» (Хафиз абзыйсының яраткан көе), «Шахта», төрле бию көйләре («Әпипә», «Цыганочка»), «Чыгарсыңмы каршы алырга?»

(армияга озатканда җырлаганнар), «Ак каен» (З. Сафиуллин муз., Ә. Зәйни сүз.), «Беренче мәхәббәт» (С. Садыйкова муз., Ә. Рәшит сүз.) һ.б. әсәрләр язылды. Ул уйнаганда, хатыны – Садекова Халидә Мәксүд кызы (1957 елгы) һәм мине авыл буйлап йөрткән Фатехова Гөлнара Осман кызы (1967 елда Кучкай Пожары авылында туган, китапханәче) баянга кушылып җырладылар.

Яруллин Максут Мансур улы (1954 елда Актук авылында туган) – гармунчылар нәселеннән. Башта заказ буенча эшләнгән гармунда уйнаган. Өендә музыка кораллары коллекциясе саклана. Көйләр исемлеген бу як өчен хас булган үрнәкләр тәшкил итә: «Картош күэ», «Сарман», «Әпипә», «Утыр әле яннарыма», «Сагыну җыры» (Р. Хәсәнов муз., Г. Идрисов сүз.) һ.б. Музыка сәләте балаларына да күчкән, алар Мәскәүдә «Яшьлек» ансамблендә җырлыйлар һәм уйныйлар.

Ыргу авылында Җамалов Салих Хөсәен улы (1951 елда туган) «Чайка» хромка гармунында һәм «Тембр» баянында «Кыска кү» («Картош»), «Колхоз күе» («Шахта», биредә озын урам көе функциясен үти), «Агыйдел буйлары», «Ай-ли, чияләр», «Әпипә», «Бишле бию» һ.б. уйнады. Композиторлар иҗат иткән әсәрләрдән иң яратканы – «Юксындырсаң, нишләрмен» (М. Макаров муз., Х. Туфан сүз.). Яздырган вакытта гармунчыга кушылып, 4 кеше күмәкләшеп җырлады: Салихова Хадичә Таһир кызы (1934), Баһаутдинова Наимә Таһир кызы (1941), Җамалова Галия Җәфәр кызы (1952), Җамалова Зөһрә Мирхатип кызы (1958).

Пашат авылында гомер кичерүче Алиәкбәров Абдулла Алиәкбәр улы (1941 елгы) хромкасын Сергач кибетеннән сатып алган, уйнарга күршесеннән өйрәнгән. Башкаручы сүзләренә караганда, әүвәлрәк «Кара урман», «Сарман»ны җырлаганнар, ә аның яшь чагында – И. Шакиров, Г. Рәхимкулов, Р. Ваһапов репертуарындагы көйләр популяр булган.

Үзләре белән очрашып өлгермәсәк тә, халык арасында уйнаулары белән танылган башка гармунчыларның исемнәрен дә биредә атап үтик. Болар: Мәдәнәдә – Айнуллин Наил, Билялов Ханнән, Җәббаров Фәрит, Уразавылда – Башаров Мөнир һ.б. Шунысы куанычлы, алар арасында яшьләр дә бар.

Бүгенге көндә ешрак хромка, баян һәм аккордеон кулланылса, элек заманда тальян, саратов гармуны киң таралган булган. Мисал өчен, Яндавишча авылында тальянчы Сабирова Халисә Исмаил кызы (1918 елгы) турында мәгълүматлар теркәлде. Әббәсов Абделмәлик Әббәс улы (1930 елда Сафаҗайда туган) саратов һәм «Казан» гармуннарында уйнаган.

Нижгар якларында гармун-баяннарны орган, органнар дип атау игътибарга лаеклы.

Скрипка һәм мандолинада уйнау традицияләре аеруча сүнеп бара торганнардан.

Исән скрипкачылардан Бозлау авылында яшәүче Садыйков Шамил абзыйны атарга кирәк. Инструментын кибеттән сатып алып, үзлегеннән өйрәнгән. Олы яшендә булганлыктан, скрипкасын күптән кулына алганы юк икән инде. Шулай да, сәламәтлеге бик яхшылардан булмаса да, ул безгә берничә көй башкарып күрсәтте («Шахта», «Сарман» һ.б.). Заманында (армиягә хәтле) ул Измайлов Абдулла белән бергә урамнарда, вечерларда уйнап йөргән.

Измайлов Абдулла Измаил улы (якынча 1922–1923 елларда туган) исә музыка коралларын ясау һәм төзәтү эше белән шөгыльләнгән. Скрипканың төп өлешен фанердан, башын – каен агачыннан, аерым детальләрен – юкәдән ясап, лаклап, мич башында катырган, ат койрыгыннан кыллар куйган. Үзе «Тәфтиләү»не уйнарга яраткан. Әлеге кыйммәтле истәлекләр белән аның кызы – Юнисова Роза Абдулла кызы (1946 елгы) уртаклашты. Роза ханым үзе дә талантлы шәхес – оста халык җырчысы, шагыйрә, төбәкне өйрәнүче һәвәскәр галим.

Мәдәнә авылында скрипкачы Әнвәр Фәхретдинов (1936 елгы, баянда да уйный, укытучы булып эшләгән) яши дигән хәбәр ишеткәч, аның янына юл алдым. Кызганычка, өендә булмаганлыктан (Мәскәүгә кунакка киткән иде) аны яздырырга насыйп булмады.

Элек булган скрипкачылар турында шактый белешмәләр җыелды. Сеченов районы Краснай авылында гомер итүче Җаббарова Әнисә Усман кызының (1935 елда туган) әтисе – [Әх]мәтов Усман Муса улы (1910 елгы) туйларда уйнап йөргән.

Ире Мәнсур (1932) һәм иренең абыйлары – Ирфан (1929) белән Абдулла әбзи (1929) дә скрипкада башкарганнар.

Петрякста яшәгән Абянов Ибраһим (1885 елгы чамасы) инструментларын чыршыдан ясаган булган. Скрипкада «Түмә такмагы» һ.б. әсәрләрне уйнаган. Барыннан да артыграк «Комаринская» исемле рус көен яратып башкарганлыктан, аңа Камрун кушаматы такканнар.

Скрипкачылар бигрәк тә Мочалидә (1930 нчы елларда туйларда уйнаганнар) һәм Ыргуда булганнар (үзләре ясап уйный торган булганнар). Бу һәм алдагы мәгълүматны Сабиров Сәяр Вафа улы тапшырды.

Рәшит Ваһаповның дусты – Мостафа Салахетдинов, Куй суы авылында тирә-якка дан тоткан Абдуллин Сафа Абдулла улы (1924 елда туган, укытучы булып эшләгән) скрипкада төрле татар халык көйләрен башкарганнар.

Кыллы музыка коралларында уйнау традициясенең биредә ныклы урнашуын исбатлаучы бер кызык мисал китерәсем килә. Бөек рус шагыйре А.С. Пушкин 1830 нчы еллар тирәсендә Болдино авылында (Уразавылдан 50 чакрым чамасы) язып алган «Калина-малина!» уен җырында мондый сүзләр бар: «Приведи-ка, матушка, Татарина с скрыпкою, Мордвина с волынкою»[1].

Мандолиначыларга килгәндә, әлеге инструментта бердәнбер уйнаучы Петрякс авылында табылды. Ул да булса – Сабиров Сәяр Вафа улы (1924 елгы), РСФСРның атказанган укытучысы, Ломоносов исемендәге премия лауреаты, туган якны өйрәнүгә күп көч куйган кеше (мәкаләләр һәм китаплар авторы) булып чыкты. Кучкай Пожары педагогик училищесында укыганда, мандолина, скрипка, думбыра, пианино, корнет кебек уен коралларын үзләштергән. Ноталарны белә. Туган авылы кибетеннән 1947 елларда 8 сумга сатып алган мандолинасында татар һәм рус халык көйләрен, И. Дунаевский, М. Блантер («Катюша») җырларын яратып башкарган. Аннан күптөрле бәһале материаллар язып алынды.

---

[1] *Соймонов А.Д.* П.В.Киреевский и его собрание народных песен. – Л., 1971. – С. 126.

Алдагы елларда Түбән Новгород өлкәсе авылларында яшәгән мандолиначыларны санап китик. Н.М. Сөләйманова (1924 елда Петрякста туган, Сафаҗай авылында яши) хәтерләвенчә, аның әтисе – Аймалетдинов Мөҗип Аймалетдин улы (1901) мандолинада уйнарга яраткан. Әнисенең энесе – Билялов Абделхак Билял улы (чама белән 1906–1908 елгы, Петрякста туган) да скрипкачы булган, башкарган әсәрләре арасында «Башмагым» көе дә булган. «Мин кечкенә идем ул вакытта... Безгә килә иде Абделхак абый скрипкасын тотып... Әтием мандолинада, икәү кара-каршы уйнадылар... икәү утырып», – дип искә алды Назифә ханым.

Пашат авылында – Бөек Ватан сугышы ветераны, Вафин Нурмөхәммәт Нурмөхәммәт улы (авылдашлар аңа Нурулла дип эндәшкәннәр) клуб сәхнәсендә, туйларда «Кара урман», «Сарман», «Авыл күе» кебек әүвәлге көйләрне уйнап торган.

Яндавишча авылында гомер кичерүче Ибраһимова Зәйнәп Юсып кызы хатирәләре буенча, аның кайнатасы – Мансуров Ибраһим Фатыйх улы («Марзыя бәете»нең авторы), ире – Ибраһимов Мансур Ибраһим улы (1934 елгы) һәм улы Рәшит – барысы да мандолина кылларын чиртеп уйнаганнар. Репертуарларында – «Кара урман», «Әллүки», «Алмагачлар» кебек үрнәкләр булган.

Шунысын да билгелик: гади халык арасында скрипка белән мандолинаны бутау очраклары күзәтелә.

Элекке заманнарда көтүчеләрнең үсемлектән, агачтан яисә тимердән ясалган өреп уйный торган кораллары булган. Шуларны кычкыртып, сызгыртып, бөтен авылга ишетелерлек тавыш чыгарганнар. Мәсәлән, Петрякс авылында 1930 нчы елларга хәтле көтү көткән Әмин (Әминдәй) исемле кешенең камыштан яисә агачтан үзе ясаган 4 тишекле коралында уйнавы мәгълүм. Краснай авылы көтүчесенең инструменты калын тимер (калай) труба формасында булып, аның нәзегәеп киткән очында агач сыбызгысы, ике яклатып тишеге булган.

Пашат авылында күңел ачу вечерларында конфет фольгасын («конфет печатын») авызларына кабып (мөгаен, кубызга яки каен тузына охшатып) кызларның көй чыгарып утырулары билгеле.

Тупланган материаллар күрсәткәнчә, нижгар якларында курай, кубыз шикелле халык уен кораллары таралмаган булса кирәк.

Тагын берничә мәсьәләгә тукталып үтәсем килә. Казан татарлары культурасыннан аермалы буларак, җирле терминологиясендә моң, моңлы дигән эпитетлар сирәгрәк кулланыла. Халык телендә «ямьле күй», «бик ямьле йырлыйлар иде», «бик ямьле күле гармун иде» кебек сүзтезмәләр әйләнештә йөри. Шуның белән бергә, «моңаебрак йырлау» («сузыбрак җырлау» мәгънәсендә), «моңлы караш» («сагышлы караш») дигән төшенчәләр дә хас.

Элек-электән халыкның тормышы җыр-көй белән үрелеп барган. Ата-бабалар «Җыр – кешенең юлдашы» дип юкка гына әйтмәгәннәр. «Без, яхшым, колхузда иллешәр тунна цөгендер өзә идек. Ашарга яхшы итеп юк иде, ацлы-туклы. Көңелләребез көр... Җырларга тотынсак – ашны да онытабыз, эшне дә онытабыз. Машина тиз генә үйгә килеп туктамасын диеп, җырлап бетерик диеп, җырлый идек без... Эш белән җыр бергә барган» (Даутова Назыймә Насретдин кызы, 1943 елгы, Зур Рбишча авылы). Шул ук вакытта, халыкта күп җырлаган кешенең бәхете аз була, җырлый-җырлый бәхете кими дигән ышану да яши (Ыргу авылы).

Соңгы еллардагы тикшеренүләр мишәрләрдә **күп тавышка җырлау традициясе** булуын исбатлыйлар[1]. Чынлап та, 2010 елгы экспедиция дәвамында ике, өч, дүрт кешенең бергә җырлау үрнәкләре шактый язылды. Әмма алар, әйтик, керәшеннәрнең гетерофон типтагы күмәкләшеп башкаруыннан нык аерылып торалар. Моннан тыш, мәҗлесләрдә ике-өч кешенең бергә кушылып җырлау гадәте Бөек Ватан сугышыннан соң гына барлыкка килгән (шуңа кадәр ялгыз башкарганнар) дигән фикерләр дә очрады. *(Мәдәнә)* Бу тамырда булганмы, әллә күптән түгел генә калкып чыккан күренешме? Безнең карашыбызча, бүгенге көндә мондый җитди сорауларга кистереп, төгәл җавап бирү әле иртәрәк.

Әлеге җыентыкта экспедиция материалларының уннан бер өлеше генә урын алды. Түбән Новгород өлкәсе татар-мишәрләренең музыкаль фольклорын тирәнтен өйрәнү һәм бастыру эше алга таба да дәвам ителәчәк дигән өметтә калабыз.

---

[1] *Сарварова Л.И.* Күрсәтелгән хезмәт. – Б. 18 –22.

## *КУШЫМТА*

Фольклор әсәрләрен матбугатка әзерләгәндә чын халыкчан башкару үзенчәлекләрен мөмкин булганча чагылдырырга тырыштык. Шул исәптән, сүзләрнең әйтелеше: фәни (фани), хазер (хәзер), кияш (кояш), нихак (никах), чыгыб алыгыз (чыгып алыгыз) һ.б. – үзгәртелмичә, әдәби нормаларга туры китерелмичә бирелә. Шуның белән бергә, транскрипцияләү гамәлдә булган алфавит нигезендә (телчеләрнең махсус билгеләрен файдаланмыйча) эшләнелде.

Әлеге хезмәттә өстәмә сузыклар түгәрәк җәяләр, төшеп калган авазлар – квадрат җәяләр белән күрсәтелә. Мәкалә авторы тарафыннан өстәлгән яки реконструкцияләнгән сүзләр шулай ук квадрат җәяләр эчендә бирелә.

Җырлаган вакытта барлыкка килгән үзгәрешләр ноталар астындагы текстта тулы килеш китерелә. Калган очракларда исә шигырь ритмы (үлчәме) өчен мөһим булган өстәмә һәм кыскартылган сузык авазлар гына теркәлә.

Биредә, кагыйдә буларак, әсәрләрнең беренче строфасы нотага салып бирелә. Көйләрне юллап (ягъни шигырь юлына туры китереп) урнаштыру тәртибе кулланыла. Өстәмә нота сызыкларында музыкаль өзекнең башкача яңгырау варианты күрсәтелә. Ачкыч янына реаль очраган альтерация билгеләре куелды. Башкару ягын истә тотып, аларны нота юллары эчендә (биш сызыктан чыкмыйча) килеш язылуын уңай дип таптык.

Шартлы билгеләр

1. 𝄞 (8) – көйнең бер октавага түбән яңгырашы
2. V – башкару сулышы билгесе
3. ⟍ – глиссандо
4. > – акцент
5. (𝄽) – метрга кермәгән башкару паузасы
6. ⌒ – аваз дәвамлыгын аз гына озайту
7. ◡ – аваз дәвамлыгын аз гына кыскарту
8. → – аваз югарылыгының зур булмаган (ярты тоннан азрак) күтәрелеше
9. 𝅘𝅥𝅮 (x) – сөйләп көйләү (сөйләп җырлау)
10. (◇) – беренче авазның чын (реаль булган) югарылыгы

## I. НОТА ЯЗМАЛАРЫ

### 1. Җимчәчәк




Зимцәцәк, зимцәцәк,
Зимә буе сарымсак,
Сарымсакка ни кирәк?
Зим, зим, зимцәцәк,
Зима буе сарымсак,
Сарымсакка ни кирәк?
Егет белән кыз кирәк.

Зимцәцәк, зимцәцәк,
Зимцәцәккә ни кирәк?
Бүдер-бүдер бүз кирәк,
Егет белә[н] кыз кирәк.
Зимә буе сарымсак, сарымсак.

Зимцәцәк, зимцәцәк,
Зимә буе сарымсак, сарымсак,
Сарымсакка ни кирәк?
Энә белә[н] йеп кирәк.

Камка авылында Юханова Мөсфирә Мөхәммәтша кызыннан (1933 елгы) язып алынды. Башкаручы хәтерләвенчә, «Җимчәчәк»не кызлар, яз башында Пьяна елгасы җәелгәч, су буенда төшеп әйтә торган булганнар. «Кызлар төшәләр иде, буй кызлар, без әле дә оланнар идек, шунда тыңнадык. Аннан инде безнең кебекләр айтмадылар... Суга багып йырлыйлар иде».

## 2. Уен җыры




Егетләр:
Бакчагызга бәрәңге чәчтек без, чәчтек без.

Кызлар:
Без аларны таптарбыз, таптарбыз, таптарбыз.

Егетләр:
Ниләр бирде таптарсыз, таптарсыз...

Актук авылында Яруллин Максут Мансур улыннан (1954 елгы) язып алынды. Бу уен урамда уйналган. Кызлар һәм егетләр каракаршы ике рәткә басалар, аннары алга-артка йөрешеп җырлыйлар (дөресрәге – кычкырып әйтәләр).

### 3. Суга батыру уены




– Кызлар утыра идек... минем егетем бата, әле миңа айталар иде:

Кияш бата, ай калка,  
Зәйнәп, ни багып торасың?  
Әхмәт бит суга бата  
(Егетең суга бата).

– И анарга мин инде, имештер, йырлыйм цыгарып:

Корзинка үреп кенә,  
Суз кулыңны, чыгарамын  
Якын дус күреп кенә.

Камка авылында Салькина Зәйнәп Хәлил кызыннан (1938 елгы) язып алынды. «Утыра идек кицен... үдә, ызбаларда, вечер була иде... Егет бата, батырабыз инде, ул менә... түндәккә утыра иде... [Калганнары] круглы утырган, ә ул идән уртасында... [Башта] егет бата иде, аның артыннан – кыз». Әлеге уен җырлары «Картош» көе белән башкарыла.

## 4. Петрякс авылы көе




Югар[ы] очтан түбәнг[ә] ага
Пит(е)ряк(ы)с елгасы.
Уйнап-көлеп күңел ачик,
Шауласын бар дөньясы.

Пит(е)ряк(ы)с илебез,
Очыбызда күлебез.
Язгы сабантуйларында
Кунак булып килегез.

Пит(е)ряк(ы)с кырлары
Шаулый т(ы)рактырлары.
Зур уңышлар яулаб алды
Егетләре, кызлары.

Петрякс авылында Сабирова Кадрия Котдус кызыннан язып алынды. Ул 1923 елда Уразавылда туган. «Мин моны кыз вакытында инде 80 ел элек ишеткән идем. Мәдәнәдә эшләдем, анда Петряксныкы бер кыз кемнеңдер балаларын карап җыйды, ул җырлап йөри [иде] шул күгә…» Сабиров Сәяр Вафа улы (1924 елгы) әйтүе буенча, бу көй Петрякста гына таралган, аны элек яшьләр урамда башкарганнар.

## 5. Түймә такмаклары




Тәрәзә төбендә, әй, кеше бар,
Кулларында тутый кошы бар.
Тутый кошын бирми, сүзен әйтми,
Әллә нинди хаҗәт йомышы бар.

Краснай (Красный остров) авылында Җаббарова Әнисә Усман кызыннан (1935 елгы) язып алынды.

«Кайчан шундый авыр вахытың була, ... кайчан яңгыз каласың, эч поша, «Түймә такмаклары»н айтасың берсәк... Аруга болай урамда без йырлый идек аларны... Аларны бик күп айталар иде. Аннары тотындылар үзгә йырларны кушып та, «Түймә такмаклары»на кушарга... [Картлар да] беләләр иде, йырлыйлар иде. Моңаебрак йырланыла иде бу йырлар».

Текст һәм көй ярты гасыр элек Петрякс авылында М.Нигъмәтҗанов тарафыннан язып алынган вариантка туры килә. Карагыз: Нигмедзянов М.Н. Татарские народные песни. – М.: Сов. композитор, 1970. – № 64.

## 6. Кыз сату бәете

А) 1 вариант




Б) 2 вариант




1) Кайдадыр шунда гөл бакчасында
Яшь кыз булып йөри идем мин.
Дус кызлар белә[н] җыйнаулап бергә
Әл[е] дә дөнья белми идем мин.

2) Чыктым сахрага, кистем яшь таллар,
Уйнарга дип камчы үрергә.
Бу җырым минем алдау түгел
Кайтып күрдем үз күзем белән.

3) Көннәрдән бер көн татар илендә
Очрадым мин шундый бер өйгә,
Туй туйлаганда кыз егълаганда
Утырдым да калдым бер өйгә.

4) Әнкәсе сорый, кыз бала егълый
Нигә мине картка бирәсез?
Мин кыз баланы, яшь бичараны
Картка биреп әрәм итәсез?

5) Елама, кызым, нигә егълыйсың?
Йорты юк бит ул яшь малайның,
Шуңардан бирәм ул карт бабайга
Акчасы күп ул карт бабайның.

6) Яхшы атларда ефәк эчендә
Кыр багарга чыгып китәрсез,
Сакалын тарап, акчасын санап,
Шулай бергә гомер итәрсез.

7) Бетсен лә малы, чыксын ла җаны,
Барасым килми ул карт бабайга,
Лучше бир мине, газиз әнкәем,
Теләнчегә, яшь бер малайга.

8) Ишек ябылды, халык тын калды,
Муллалар нихакка[1] керделәр.
Кызның елавын шуннан белдем мин
Яшь бичараны картка бирделәр.

9) Сукыр әткәсе кулларын сузып
Карт кияүдән мәһәр алырга.
Бармыймын, әткәй, барасым килми,
Риза түгел аңа барырга.

---

[1] Нихак – никах.

10) Әүвәл заманда безнең кырларда
Йөри иде байның куйлары.
Озак та үтми, кыз кайтып килә,
Юкка үтте бабай туйлары.

11) Кирпечләр ягып мичкә ыргытсаң,
Алар кызыгышып яналар.
Янган кирпечтәй бездә кызларны
Акчага сокланып саталар.

12) Кырга чыксагыз атакларга
Пулегызны юкка атмагыз,
Кыз балагыз булса карт бабайларга
Акчага сокланып сатмагыз.

Пашат авылында Җәләлова Нәфисә Җәләлетдин кызыннан (1921 елгы) язып алынды. Башкаручы беренче строфасын гына көйләде, калган текстын латин язулы дәфтәреннән укыды. Көе һәм тексты үз заманында атаклы рус җыры «Кирпичики» белән аваздаш (бәетнең 11 нче строфасын карагыз).

**7. [Кыз сату бәете]**



Яхшы атларда ефәк эчендә
Кыр багарга икәү китәрсез.
Сакалын тарап, чәчләрен сыйпап,
К[в]артир белән гомер итәрсез.

Мәдәнә авылында Мөхәммәтҗанова Әнисә Хәйрулла кызыннан (1938 елгы) язып алынды. Үги әнисеннән ишеткән бу бәетне башкаручы «Зөлхабирә» дип атый. Көендә шулай ук рус җырлары белән охшашлык бар.

8. **Абдулхамит бәете**




1) Тарих мең дә тугыз йөздә
Туксан җиденең көзендә
Синең үлү хәбәрләрең
Килде җомга төнендә.

2) Тилифоннар шалтырагач,
Тордым: кем соң икән дип.
Дөрес ишеттемме икән,
Абдулхамит үлгән бит.

3) Туганың Халит, дустың Сәит
Сине алырга киттеләр.
Үле гәүдәңне ничек кенә,
Улым, алып килерләр?

4) Егерме ел эчләрендә
Ике баламны җыйдым.
Сабыр бирче, Алла Тә[га]ләм,
Сабырлыгымны җуйдым.

5) Әллә нинди булды тормыш,
Көн дә хәбәр, яңа хәл.
Әй, улкаем, син китәсең,
Яшь гомерең бигрәк җәл.

6) Ялан аяк уйнап узган
Сукмакларны сагындың.
Бер көнгә генә булса да
Авылыңа ашкындың.

7) Соңгы кабат килүеңдә
Тыкрык буенда йөрдең.
Әллә инде үләсеңне
Алданмы, улым, белдең?

8) Кем уйлаган утыз биштә
Каберләргә керем дип,
Соңгы кабат бу дөньяны,
Дусларымны күрем дип.

9) Әти-әни, туганнарым,
Хатыным, бала-чагам,
Кичерегез инде мине,
Сезне кайгыга салам.

10) Алсу, синең күзләреңнән
Яшьләр мәңге кипмәсләр,
Әлфиям белән Сылуым
Мине гаеп итмәсләр.

11) Гомерләрем кыска булган,
Рәсемдә генә калдым.
Әти-әни, туганнарым,
Сезне кайгыга салдым.

12) Кайгылы күзләрегездән
Ирфан яше дә бит кипмәде.
Дошман пулясы алып китте мине,
Нигә яшә димәде?

13) Җеназа намазыңа
Картлар-яшьләр килделәр.
Абдулхамит сине, улым,
Салкын җиргә күмделәр.

14) Мәскәүләрдән, Гүрькийлардан
Күп дусларың төштеләр.
Сине күтәреп алып киткәч,
Кайнар яшьләр түктеләр.

15) Синең кебек шәфкатьлене
Беркайда да күрмәдем.
Үлү хәбәрләрең килгәч,
Кычкырмыйча түзмәдем.

16) Яхшылыклар бик күп кылдың
Дошманга да, дуска да.
Синең ис[е]мең мәңге яшәр
Күңелләрдә һаман да.

17) Синең салкын кабереңне
Җылытадыр ап-ак кар.
Син уйлаган һәр эшләрнең
Дәвам итүчесе бар.

18) Син(е)сез үтә җәйләр, көзләр,
Син(е)сез үтә кышларым.
Ничек кенә [ана] сабыр итсен
Бу кайгыга, дусларым?

19) Аккан сулар кебек китеп бардың
Юлларыңда эзләр калдырып.
Күтәрбез без сине, әле кайтырсың дип,
Яшьле күзләребез талдырып.
Ник соң киттең, улым, мәңгегә
Кайгы-сагышларда яндырып?

20) Авылыбызның күрке булып,
Үсеп чыкты мәчетең.
Һәр карт кереп сиңа дога кыла,
Яшь булсаң да, күп хезмәт иттең.

21) Олы юлның башларыннан
Күренә бер манара.
Кызганчылар[1] бик күбәйде,
Авыр килде замана.

Зур Рбишча авылында татар теле һәм әдәбияты укытучысы Ситдыйкова Факия Сәяр кызыннан (1958 елда туган) язып алынды. Бу бәетне ул 1997 елда чыгарган. Садеков Абдулхамит – аның дусты («күршедә бергә уйнап үстек»), бик яхшы кеше булган. Мәскәүдә Б. Ельцин тирәсендә эшләсә дә, авылдашларына күп ярдәм күрсәткән. Мәсәлән, мәктәпкә иң беренче тапкыр компьютерлар китерүче ул һ.б. Авыл мәктәбе бүгенге көндә аның исемен йөртә. Башкаручының әйтүенчә, бәет калыбына китерер өчен, үрнәкләрен ул «Татар халык иҗаты: Бәетләр» (Казан, 1983) китабыннан караган. Көйгә килгәндә, бу – элеккедән, әбиләрдән ишетеп алган көй. Әсәрнең соңгы өч строфасы (№ 19 – 21) көйләнмичә, шигырь формасында укылды.

### 9. Мөнәҗәт




1) Әбиләрем, дускайларым,
Нурлар балкый йөзегездә.
Җаннарыма дәва табам
Һәр сөйләгән сүзегездән.

2) Барыбызга да үлем килә
Килгән кебек караңгы төн.
Якты дөнья вәйран булып
Кала бер көн, кала бер көн.

---

[1] Кызганчылар – көнләшеп караучылар, көнче кешеләр (кеше байлыгына, уңышына кызыгып, көнләшеп йөрүчеләр).

3) Анда өз бөтен[1], тамак тук,
Фәни дөнья хафасы юк,
Мәңге кияр күлмәгеңнең
Җиңе белән ягасы юк[2].

Зур Рбишча авылында Даутова Назыймә Насретдин кызыннан (1943 елгы) язып алынды. Мөнәҗәт мәет (үдер) янында укыла. Башкаручы тарафыннан язылган көйдә («Күлгә үзем салам») җыр интонацияләре яңгырый. Назыймә ханым, элек үзе җырчы булган кеше, җыр материалын үзенчә үзгәртә, иҗади эшкәртә.

## II. ШИГЪРИ ТЕКСТЛАР

### 1. Туй җырлары

***Кияү йортына килен төшерү [«Картош» көе]***

Каршы ява карыгыз,
Кил[е]негезне китерәбез,
Каршы чыгыб алыгыз.
Кил[е]негезне китерәбез,
Каршы чыгыб алыгыз.

***Хуҗа кунакларга хөрмәтен (рәхмәтен) белдерә (туй башы, элеккеге озын көй)***

Айлар көткәннәрем бар шунда,
Еллар көткәннәрем бар шунда.
Айлар, еллар көткән дусишләрем,
Хазер утырасыз каршымда.
Айлар, еллар көткән туганнарым,
Хазер утырасыз каршымда.

***Яшь килennнең әнисе җырлый кияү әнисенә [«Шахта»]***

– Кызын биргән инде, ...сезнең шундый бәхетле, ялтыравыклы тормышыгыз булсын.

Ундыр минем бармагым,
Ундыр минем балдагым.

---

[1] Өз бөтен – өс бөтен.
[2] Ягасы юк – якасы юк.

Берсен салып, сезгә бирдем,
Ялтырасын бармагың.
Берсен салып, сезгә бирдем,
Ялтырасын бармагың.

***Кияүнең әнисе каршы җырлый (элеккеге озын көй)***

Челтәрлекәй күпер, ай, тар булмас,
Уник[е] алашага, һой, юл булмас.
Күтәрелеб әйтмим бу сүземне,
Безгә килгән ярлар хур булмас.
Күтәрелеп әйтмим бу сүземне,
Безгә килгән ярлар хур булмас.

***Кодалар җыры (элеккеге озын көй)***

– Бу инде кодалар үзара макташып җырлашалар бер-берләренә яхшы җырларны, йә булмаса – яшьләргә дә җырлыйлар инде. Бу менә шундый озынрак күйгә сузып йырлый торган күләребез.

Казан сөлгеләре матур була
Бәйрәм көннәрендә эләргә.
Безнең теләгебез шулдыр сезгә –
Бергә яшәп, бергә үләргә.
Безнең теләгебез шулдыр сезгә –
Бергә яшәп, бергә үләргә.

*Татар Моклокасы авылында*
*Юнисова Зәкия Салих кызыннан язып алынды*

***Бер як кодалары икенче як кодаларга җырлыйлар (туйның озын көе) [«Шахта»]***

Их, җир шары, их, җир шары,
Их, җир шары түгәрәк.
Шул түгәрәк җир шарында
Яшик дуслар бергәләп.
Шул түгәрәк җир шарында
Яшик дуслар бергәләп.

***Нижгар такмаклары (туйның кыска көе) [«Картош»]***

– Бу күләргә күбрәк инде яшьләр җырлыйлар, үзләренең такмаклары аларның бар.
– Кодалар йырлашалар шулай.

1) Бодай таратканымны,
Бер Ходаем гына белә
Сезне яратканымны.

2) Гармуныңны тартып уйна,
Бик матур уйнатасың,
Бик матур уйнатасың.
Он[ы]тылып беткән, югалган
Уемны уйлатасың.

3) Сездә кызыл гөлләр бармы?
Бездә кызыл гөл генә,
Бездә кызыл гөл генә.
Сездә сагыну көннәр бармы?
Бездә сагыну көн генә.
Сездә сагыну көннәр бармы?
Бездә сагыну көн генә.

4) Кепка киям, кепка киям,
Кепканың яшелләрен,
Кепканың яшелләрен.
Тагын берне сөяр идем
Шуларның нәселләрен.
Тагы[н] берне сөяр идем
Шуларның нәселләрен.

5) Җыен дуслар җыелыштык,
Таң атмый таралмабыз,
Таң атмый таралмабыз.
Иртәгә шушы вакытны
Кайтарыб ал[а] алмабыз.
Иртәгә шушы вакытны
Кайтарыб ал[а] алмабыз.

6) Күбәләгем сайлап алды
Роза дигән гөлемне,
Роза дигән гөлемне.
Кемнәр дә белми телемне,
Кемгә сөйлим серемне?
Кемнәр дә белми телемне,
Кемгә сөйлим серемне?

***«Сарман» көенә***

Аткынаең куркак, тапкан малың уртак,
Сөйгән ярың уртак булмасын.
Аткынаең куркак, тапкан малың уртак,
Сөйгән ярың уртак булмасын.

***Силәзән җырлары***

– Силәзәнне йөртәләр кыз керткән көнне, ... берсе йырлый кыз ягыннан, берсе йырлый – егет ягыннан... Өйләнмәгән егетләр йырлый.

1) Хазер эләктең кулыма,
Өзәмен каколыңны[1],
Өзәмен каколыңны.

2) Белтерендә нумеры,
Белтерендә нумеры.
Ике матур кавышканнар,
Айрылмаслар гомергә,
Айрылмаслар гомергә.

***Кунаклар чыгып баралар рәхмәт әйтеп (туй ахырында) [«Картош» яки «Шахта» көенә]***

1) Кар яуган эзегезгә,
Ашыгыз бар, суыгыз бар,
Биг рәхмәт үзегезгә.
Ашыгыз бар, суыгыз бар,
Биг рәхмәт үзегезгә.

---

[1] Какол – хохол (рус.).

2) I вариант:

Суда йөзгән үрдәкне,
Гомерем булса онытмамын
Сездә булган хурмәтне.

II вариант:

Суда йөзгән үрдәкне,
Гомерем булса онытмамын
Сездә күргән хурмәтне.
Гомерем булса онытмамын
Сездә күргән хурмәтне.

*Татар Моклокасы авылында*
*Юнисова Зәкия Салих кызы һәм*
*Салихова Афия Якуп кызыннан (1953 елгы)*
*язып алынды*

**2. [«Ак тирәк, күк тирәк»] уены**

Кызлар:
Ак тирәк, күк тирәк,
Сезгә тагын кем кирәк?

Егетләр:
Ак тирәк, күк тирәк,
Үзе ямьле, үзе матур
Алсу атлы[1] кыз кирәк.

Зур Рбишча авылында Ситдыйкова Факия Сәяр кызыннан (1958 елда туган) язып алынды. Яшьләр ике якка тезелеп басалар (кызлар бер якта, егетләр – икенче якта), кулларын каты гына тотып торалар. Кемнең исемен әйтәләр (безнең очракта – Алсу исемле кыз), шул кеше йөгерә. Әгәр дә кулларын өзсә – берсен үз ягына алып китә, киресенчә булса – каршы рәтендә кала. Күпчелек малайлар җиңә торган булганнар. Без үскән чагында андый уен Казанда «Цепи» дип аталган.

[1] Атлы – исемле (Алсу атлы – Алсу исемле).

### 3. Суга батыру уены

Колидоры, колидоры,
Колидоры тәрәзле.
Иң беренче кыз колхозда –
Батырабыз э-разве?

Ыргу авылында Үмәрова Алия Мөбин кызыннан (1928 елгы) язып алынды. «Түндәккә утырталар иде, идәнгә цыгарып, ... батыралар иде йырлап... Батыргац, алды мине йырлап Хамзә. Мин цыга алмадым үзем, ул йырлап алды».

### 4. Суга батыру уены [«Картош» көенә]

Кечерәк кенә, матур гына
Эрәктен[1] күренәсең.
Яшь вакытың – тиле вакыт,
Яр өчен өзеләсең.

Ыргу авылында Әхтәмова Халимә Сәмиулла кызыннан (1924 елгы) язып алынды. Информант әйтүенчә, бу куплетны «кечерәк кешегә йырлыйлар иде».

### 5. Байкалга батыру уены [«Картош» көенә]

Батыру җырлары:

1) Байкал өсләрендә
Төпкә киткәч нишләрсең,
Төпкә киткәч нишләрсең?
Тот кулыңа кучарканны,
Кычегарым[2] эшләрсең.
Кулларыңа кучарк[а] алып
Кычегарым эшләрсең.

2) Әнә килә афтымабиль,
Төягәннәр папирос,
Төягәннәр папирос.
Моны кем дә чагар[а] алмый,
Китерегез паравоз.

---

[1] Эрәктен – ерактан.
[2] Кычегар – кочегар (рус.).

3) Байкал күленең уенда
Балык тотыб утырам,
Балык тотыб утырам.
Ике колагыңнан тотып,
Тирәнлерәк батырам.

4) Тур[ы] атыңны бәйләп куйдым
Азык юктан казыкка,
Азык юктан казыкка.
Без буй кызны батырабыз
Бакаларга азыкка.

5) Әле Байкал күлләрендә
Бакалар тотып аша,
Бакалар тотып аша.
Бака сүякләрен җыеп,
Үзеңә салаш[1] (шалаш) яса.

6) Ерактан ут күренеп тора –
Кинонынң афишасы,
Кинонынң афишасы.
Киттең, буй кыз, Байкалларга,
Бакалар Падишасы.

7) Төшеп киттең Байкалларга,
Чыг[а] алмасаң нишләрсең,
Чыг[а] алмасаң нишләрсең?
Кулларыңа метла тотып
Дэворникым эшләрсең.

Чыгару җырлары:

8) Мәскәүләргә барсаң әгәр,
Тот кулыңа чемодан,
Тот кулыңа чемодан.
Үземнең дустым буласың,
Бир кулыңны, чыгарам.

[1] Салаш – шалаш (рус.).

9) Бостон костюм кияр булсаң
Шалдырдатып сындыг ач[1],
Шалтырдатып сындыг ач.
Байкаллардан тартып алам,
Бир кулыңны, сандугач.

10) [Сәбитләргә] Сәрдитләргә барсаң әгәр,
Ал кулыңа чемодан,
Ал кулыңа чемодан,
Табыш чәеңә чакырсаң,
Үзем тартып чыгарам.

11) Әнә килә автымабиль,
Төягәннәр симычка,
Төягәннәр симычка.
Байкал күленнән чыгарам,
Бир кулыңны, Синычка (Сонечка).

12) Моны Байкалдан чыгарып
Нинди файдалар таптың,
Нинди файдалар таптың?
Юк-бар сүзләргә ошанып[2],
Үзең Байкалга баттың.

Яндавишча авылында элек фольклор ансамбленә (җитәкчесе – Сәйфетдинова Надирә Хәммәт кызы) йөргән башкаручылардан язып алынды. Күмәкләшеп җырладылар: Ибраһимова Зәйнәп Юсып кызы (1939 елда Карга авылында туган), Ганеева Флюра Ибраһим кызы (1938 елда Краснай авылында туган), Хәсәнова Зәйтүнә Садек кызы (1928 елгы), Салахова Рафия Исхак кызы (1937 елгы).

### 6. Бармак уены [«Картош» көенә]

1) Сөя идем элек тә,
Сөямен хазер дә дә,
Сөямен хазер дә дә.
Шул сөюләр аркасында
Керәмен кабергә дә.

---

[1] Сындыг ач – сандык ач.

[2] Ошанып – ышанып.

2) Сөя идем бер чәчәкне,
Өзелеп ярата идем,
Өзелеп ярата идем.
Эчемдәге серләремне
Аңа тарата идем.

*Сафаҗай (Красная Горка) авылында*
*Аблясова Хадичә Фәйзрахман кызыннан (1954 елгы)*
*язып алынды*

### 7. Бармак уены [«Картош» көенә]

Сандугачым, син сайрап тор,
Күгәрченем, син гөрлә.
Үзем монда, күңелләрем
Гел синең белән бергә.

Алмалар өзәсеңме,
Йеплəргә тезәсеңме?
Өзелгән алмалар булдык,
Шуларны сизәсеңме?

Аклы ситса күлмәгеңне
Үзем юләгән идем.
Сезнең белән утырырга
Күптин теләгән идем.

Син, син генә, син бер генә,
Минем күңелләремдә.
Синең гайры чәчәк атмый
Сөйкемле гөлләрем дә.

Пашат авылында Фатыхова Миңлегөл Нәзибулла (Нәсибулла) кызыннан (1939 елгы) язып алынды. «Үдә шулай дус кызлар җыела да идек, шунда уйный идек. Һәрбер кеше (кызлар) берәр бармак куялар иде и аларга егетләр айталар иде... Җыйнау җырлыйлар иде». «Кемгә нинди йыр цыга инде... мөхаббәт җырлары җырлыйлар иде инде».

### 8. Бишек җыры

1) Алү-балү итәрсең,
Балам, син йокыга китәрсең.
Ак йомырка(й) ашаган,
Әнисенә(й) о[х]шаган.

2) Балам, балам, бәгърем, балам,
Ике күземнең нуры,
Ике кашымның арасы,
Баламның баласы,
Йөрәгемә дару салмасы.

*Чүмбәли авылында Аляутдинова Рахимә*
*Ширмөхәммәт кызыннан (1923 елгы)*
*язып алынды*

### 9. Бишек җыры

1) Йокла, балам, йом күзең,
Йом-йом күзең, йолдызым.
Ил каршында нур булып,
Матур булыб үс, улым.

2) Йокла, йокла, йоклачы,
Мине эшсез тотмачы.
Йортым тулы эшләрем,
Эшемне калдырмачы.

*Сафаҗай авылында*
*Аббясова Разия Сәмиулла кызыннан (1939 елгы)*
*язып алынды*

### 10. Бишек җырлары

1) Вәттүри-вәлбизә,
Юка бии төнтәнә,
Баю-бай...

2) Сәсү сәсем минетте,
Быбыт нәсем минетте,
Сәсү сәсем быбыт нәсем
Хетте-хетте минете.

Мәдәнә авылында Хөсәенова Мөнирә Бәдретдин кызыннан (1933 елгы) язып алынды. «Шулайлап-шулайлап тезә иде... әни минем селкетеп бишекне, көйләп, айтып җырлый иде, ... йокласын өцен».

### 11. Баланы сикертү

Сендибалы, сендибалы,
Сендибалы сендигач,
Помарок, помарок,
Помарок та самарок.

Сафаҗай авылында Аббясова Разия Сәмиулла кызыннан (1939 елгы) язып алынды. Күршедә торган Рахимә Юсып кызыннан (1925 елгы чамасы) ишетеп калган. «Шундыйларны айтып сикертә иде... Безгә керә иде, әни минем өц ызба аша гына, әниләргә барам, әнинең дусты иде ул, керә анда – оланын ала, сикертә, елый торганны туктата».

### 12. Түмә такмагы

Агыйделкәйләрдән агып килә
Голаныский[1] казның каколы.
Сөеб алу белә[н] сөеп бару –
Юсеп–Зөлейханың законы.

Сафаҗай авылында Аббясова Разия Сәмиулла кызыннан (1939 елгы) язып алынды. «Аны йырлый идек без... Карцыклар йырлый иде, без аны отып алган идек. Мин дә шулай әле туйда йырлаклый идем».

[1] Голаныский – голландский.

## 13. Түмә бәете

I вариант:

Ындыр артларында, әй, зур тана
Бодай богылларын акдара[1].
Үзе дә генә карсак, дөмбер корсак
Кыз аламын диеп мактана.

II вариант:

Богы артларында, әй, ак тана
Бодай быгылларын акдара.
Үзе дә генә(й) карсак, дөмбер корсак
Ярлар сөям диеп мактана.

Чүмбәли авылында Алеева Рауза Үмәр кызыннан (1939 елгы) язып алынды. «Түмә бәете»н картлардан ишетеп калган. Текстның икенче вариантын көйгә салып башкарды. Көй вариантын карагыз: Кушымта I, № 6.

## 14. Түймә такмаклары (Түмә бәетләре)

1) Ындыр артларында, әй, биш милчә
Әйләнәләр җилләр исмичә.
Болай сөюләреңә риза түгел
Элмәк бауларымны тишмичә.

2) Ындыр артларында, әй, ак тана
Богыл бозам диеп мактана.
Үзе дә генә(й) карсак, дөмбер корсак
Кыз аламын диеп мактана.
Үзе дә генә(й) карсак, дөмбер корсак
Кыз аламын диеп мактана.

Мәдәнә авылында Мөхәммәтҗанова Әнисә Хәйрулла кызыннан (1938 елгы) язып алынды. «Картлар, әүвәлгеләр инде йырлыйлар иде... Әүвәл бит тукыганнар: сөлгеләрне анда шулай, урын өстенә җәя торган җәймәләр тукыганнар... Шул тукыган вакытларда «Түймә такмаклары» да булган, башка такмаклар да, бар да булган». «Әүвәл бит җыелышып утырганнар кицен картлар, сүләшеп инде... куыклы лампаларда, бишле лампа, җиделе лампа, унлы лампа шул кысып кына ягып. Вот шулай

[1] Акдара – актара.

күршеләр җыелышып, бөтен «Түмә бәетләре»н дә, шул такмакларны да, шуларны йырлап утырганнар».

Көе шул ук: Кушымта I, № 6.

### 15. Әни җыры

1) Олы юлкайларның, әй, тузаны[н]
Белми дә генә калдым тузганын.
Белми дә генә калдым, сизми калдым
Яшь гомеркәемнең узганын.
Белми дә генә калдым, сизми калдым
Яшь гомеркәемнең узганын.

2) Баярлар җигәләр яхш[ы] алаша,
Башлары күренә дуг[а] аша.
Егет сөйгән ярын ал[а] алмаса –
Йөргән юлларыннан адаша.
Егет сөйгән ярын ал[а] алмаса –
Йөргән юлларыннан адаша.

Куй суы авылында Рауза Хөсәен кызы (1941 елгы) һәм Әнвәр Ибраһим улы (1934 елгы) Мостафиннардан язып алынды. Бу җырны Әнвәр абыйның әнисе (Сәйдә Хөсәен кызы, 1915 елгы) яратып башкарган. «Сугыш вахытында эшләп кайталар иде, ирләре сугышта булган. Менә лампа да ул вахытларда булмаган, пәзәкәй диләр ... Шул мамык яктысында берничә хатын җыелганнар да, шуны җырлаганнар».

Көе – «Түймә такмаклары»ның (Кушымта I, № 6) сузыбрак җырлана торган варианты.

### 16. Рамазан бабай бәете

1) Коритага су саламын
Күлмәгемне юарга.
Бәгърем исемә төшә дә
Тотынамын еларга.

2) Өстемдә бер күлмәгем,
Юып җилгә элмәдем.
Ун ел яттың түшәктә,
Кадереңне белмәдем.

Сафаҗай авылында Аббясова Разия Сәмиулла кызыннан (1939 елгы) язып алынды. «Бер бабай бар иде безнең күрештә..., ул бәет язган үзенә, Рамазан бабай. Аның катыны сурхау иде. Миңа гына яздырган иде, мин дә оныттым инде, бер-икесен генә беләмен».

### 17. Мәетне елап озату

Каберлеклар юлы ерактыр,
Уртасында тимер йозактыр.
Ул тимер йозакларны мин үтәлмим,
Артларыннан барып җитәлмим
(Әбекәем, артларыннан җитәлмим).

Чүмбәли авылында Арсланова Маһидә (Магидә) Якуп кызыннан (1925 елда Мәдәнәдә туган) язып алынды. Башкаручы әйтүенчә, ул бәләкәй чагында үдерләрдә әбиләр шулай көйли торган булганнар. Бер куплеты гына истә калган.

### 18. Баласы үлгәч, елау

Балам, балам, бәгърем, балам,
Нәк мине калдырып киттең?
Нәк мине калдырып киттең?
Әй, баламның баласы,
Ике күземнең карасы,
Йөрәгемә яра салма [санә].
Нәк мине калдырып киттең, балам?
Балам, балам...

Чүмбәли авылында Аляутдинова Рахимә Ширмөхәммәт кызыннан (1923 елгы) язып алынды. Рахимә апа 11 бала тапкан булган, шуларның сигезе бәләкәй чагында ук үлеп киткән.

### 19. Кыска җырлар

1) Агыйделдә күп үрдәкләр,
Санадым барысын да.
Дусларым да дошман икән,
Сынадым барысын да.

2) Агыйделне буйладым,
Буйладым, йөзә алмадым.
Сандугачның сайравына
Еламый түзә алмадым.

3) Аерылсак та, их, дускаем,
Син генә исләремдә.
Былбыл булып гөлгә кунып
Керәсең төшләремә.

4) Ай нурлары якты диеп
Ташка басып су алма.
Бәгърем еракларда диеп
Ятлар белән чуалма.

5) Ай яктысы бер ялгызым
Сулар алам агымнан.
Серле күзең мәҗбүр иткәч
Сөйдем бала чагымнан.

6) Айрым тудык, бергә үстек,
Безнең серләр бер булды.
Үсә-үсә кайгы басты,
Бу дөньяга ни булды?

7) Ак күбәләгем дә син,
Күк күбәләгем дә син.
СССРда син булмасаң,
Ничек яшәр идем мин?

8) Ак та була, күк тә була
Алмагачның чәчәге.
Белмим инде ничек булыр
Тормышның киләчәге.

9) Аклы ситса күлмәгемне
Кидем тузсынга гына.
Мин бит синең белән йөрдем
Көнем узсынга гына.

10) Аклы ситса күлмәгемне
Тегүчеләр юләгән.
Бер сүземне унбиш итеп
Кешеләргә сөйләгән.

11) Аклы ситса күлмәгемнең
Итәк очлары атлас.
Яшь вакытлар кире кайтмас,
Кайтса да – чәчәк атмас.

12) Ал чиләгем, гөл чиләгем
Сулар белән тулмады.
Ул теләде танышырга,
Минем теләк булмады.

13) Аллар өзеп гөлләр тезәм,
Дустым, баскан эзеңә.
Бакчада үскән гөлләр кебек
Күренәсең күземә.

14) Аллы-гөлле чәчәк ата
Бакчада алмагачым.
Дошманнар белән кушылып
Сайрама, сандугачым.

15) Алсу чәчәк бир, бәгерем,
Күкрәгемә кадармын.
Китеп югалсаң кош кебек,
Кайдан эзләп табармын?

16) Алтмыш градус салкыннар
Салкын якта, тайгада.
Ай-һай, кызганыч гомерләр
Үтеп бара кайгыда.

17) Артларыңнан барыр идем,
Юлларымда каен бар.
Шат яшәргә ирек бирми,
Башларымда кайгым бар.

18) Асыл кошның канатының
Җилләр ала сынганын.
Күрмәмен дә, күрмәмен дә
Җаннарымның тынганын.

19) Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр багана.
Кеше ярын тартып алып
Сөя торган замана.

20) Әнә килә машина,
Утыр да кит башына.
Исемеңне язар идем
Алтын йөзек кашына.

21) Базардан килгән атларга
Салкын су эчермәгез.
Болай да йөрәгем яна,
Исемә төшермәгез.

22) Батис кульяулыгым юдым,
Кибәр, болыт килмәсә.
Мин күптән саргаер идем,
Әгәр хатың килмәсә.

23) Башларымны әйләндерден,
Сепарат диденме әллә?
Янмый торган йөрәгемә
Шул кирәк, диденме әллә?

24) Бәгеремнән аерылганда
Бигрәк авыр суладым.
Ялгыз үскән ак каенга
Кочакланып еладым.

25) Без бит әллә кемнәр түгел
Бостон костюм кияргә.
Әллә нәрсә түгел инде
Сиңа бәгърем дияргә.

26) Безнең авыл уртасында
Яшел башлы манара.
Чын күңелдән сөяр булсаң,
Юк-бар сүзгә карама.

27) Безнең артта салкын чишмә,
Сулары көмеш кебек.
Әкрен искән җилләр белән
Тавышың килә кебек.

28) Безнең өйнең түбәсендә
Шыпырдап ява яңгыр.
Утыз җирдә аның күңеле,
Унбиш челбәе[1] бардыр.

29) Беләкләрең болай да ак,
Сабын кирәкмәс инде.
Вәгъдәләшкән ярың түгел,
Сагыну кирәкмәс инде.

30) Берне, икене, өчне сөйдем,
Өчесен дә ташладым.
Хәзер таптым саф күңелне,
Өзелеп сөя башладым.

31) Биек тауны менгән чакта
Береткам тиде ташка.
Күңелләрем синең белән,
Тормышым синнән башка.

32) Биек тауның башларында
Трактор белән сабан.
Бер савытта гөлләр кебек
Торган идек бер заман.

33) Бишле лампа начар яна,
Безгә кирәк унлысы.
Таң алдында моңлы сайра,
Сандугачның моңлысы.

34) Брошкаңны җибәрдеңме
Алтынга мандырырга?
Ашыйк тотып уйладыңмы
Ятларга калдырырга?

35) Бу дөньяда бармы икән
Чын мәхәббәт, саф күңел?
Эзләдем, таптым, югалттым,
Хәзер табылачак түгел.

36) Виноград пешкән диләр,
Алып өләшер идем.
Бик сагынган көннәремдә
Күреп сөйләшер идем.

37) Гармонь кечкенә булса да,
Әйтә ни кирәкләрен.
Сикер дә төш агым суга
Янса яшь йөрәкләрең.

38) Гармонь кечкенә булса да,
Әйтеп бирә кирәген.
Кайчанга басылыр икән
Яна торган йөрәгем?

[1] Челбәй – сөйгән яр.

39) Гармонь теле, гармонь теле,
Гармонь теле ун гына.
Сиңа ошаган чәчәк ата
Бакчада лимон гына.

40) Дошман сиңа каршы килсә,
Син аңарга кылыч бул.
Ташламам сине, ташламам,
Син ул яктан тыныч бул.

41) Дошманнарның алдый торган
Сүзләренә ышанма.
Алар белән бергә булып
Яшь башыңны ашама.

42) Җәй башында яңгыр яуса
Тигез җирләр казыла.
Аккан яшем җиргә тамып
Синең исемең языла.

43) Җәйгә чыккач, әй, дускаем,
Күлләрдә юынырбыз.
Мәхәббәтем бигрәк көчле,
Ничек соң суытырбыз?

44) Җәйгә чыккач, их, дускаем,
Мин киямен ак юбка.
Сине уйлап ак йөземне
Саргайттым ару юкка.

45) Җәйнең матур көннәрендә
Ник асыл кидем икән?
Күкрәгемнең саф җиренә
Ник басып сөйдем икән?

46) Иртә торып тышка чыктым,
Ай төште беләгемә.
Ай төшмәде беләгемә,
Ут капты йөрәгемә.

47) Исеңдәме, их, дускаем,
Рояльдә уйнаганнар?
Йөзләреңдә кояш нуры,
Ай гына куймаганнар.

48) Их, бу немец солдатлары
Кия кызыл ыштаннар.
Серне бирмик, дус булыйк без,
Әрнесеннәр дошманнар.

49) Их, дускаем, кавышырбыз,
Килер бер көн безгә дә.
Гыйшыкка чыдаган йөрәк
Түзәр нахак сүзгә дә.

50) Их, дускаем, теләк телим
Иртәсен дә, кичен дә.
Күрмә хәсрәт, түкмә күз яшь,
Яшә рәхәт эчендә.

51) Их, минем роза чәчәгем,
Их, минем зәйтүн гөлем.
Ышанычсыз мәхәббәткә
Алданды яшь күңелем.

52) Их, таң җиле, ни сөйләдең
Нечкә тал яфрагына?
Бир кулыңны, юлдашым бул
Киләчәк тормышыма.

53) Кара костюмнарны кимә
Сатин эчле булмаса.
Өзелеп сөймә матурларын
Сознательный булмаса.

54) Кара матур күзләреңә
Бер карадым, туймадым.
Мин бит сине ай нурыннан
Яралган дип уйладым.

55) Кара сатиннан да кара
Дошманнырның йөзләре.
Дошман икәнен сиздереп
Косой карый күзләре.

56) Кичә төшләремдә күрдем
Карасу кара урман.
Шул карасу кара урман
Без аерылырга булган.

57) Костюм кесәләрендә
Ватылган көзгеләрем.
Сине уйлап үтә минем
Төннәрем, көндезләрем.

58) Костюм салып пальто киден,
Туңармын дип белдеңме?
Мине ташлап ятны сөйдең,
Уңармын дип белдеңме?

59) Көтмәгәндә очрашулар
Таныштырды бит безне.
Гомерем буйларына, бәгърем,
Оныта алмамын сине.

60) Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Гөлхәйдәр.
Бер кавышсак – аерылмабыз
Кыямәт көнгә кадәр.

61) Куян йөгерә, куян йөгерә,
Куян йөгерә – тимәгез.
Җырым юктан гына җырлыйм,
Чиртеп җырлый димәгез.

62) Күзләрен кыйгачлап ала,
Дошман бит явыз була.
Чага торган елан кебек
Аяк аста чуала.

63) Күкрәгемдә алсу чәчәк,
Кемнәр кадады икән?
Янам гыйшык утларында,
Кемнәр каргады икән?

64) Күпме генә йөк булса да,
Паровоз тарта гына.
Сиңа булган мәхәббәтем
Көннән-көн арта гына.

65) Кызыл лента, кызыл лента,
Кызыл лента ялгаулы.
Бар мәхәббәт чын күңелдән,
Бар мәхәббәт алдаулы.

66) Кышның юеш көннәрендә
Калошыңны ки, маем.
Танышың булмаса – отказ ит,
Танышыңны сөй, маем.

67) Матур гөлләр арасыннан
Ал чәчәкләр эзләдем.
Эзләдем, таптым, шулай да
Бер чәчәк тә өзмәдем.

68) Матур чәчәкләр атадыр
Безнең бакчаның гөле.
Матурдан матурга куна
Дускаемның күңеле.

69) Мәскәү бульварына ошаган
Сезнең йөргән юлыгыз.
Хатларымны тәмам итәм,
Хуш, исән-сау булыгыз.

70) Мәскәүләргә барган чакта
Күрдем урман агачын.
Гармонеңны матур уйнап
Күңелемне ачасың.

71) Мәскәүләргә барыр идем,
Анда тимер юл икән.
Ауруларга дарулар бар,
Сагынуларга юк икән.

72) Мендем тауга, салдым тамга
Имәнгә түгел – талга.
Безнең бергә очрашулар
Сагынып сөйләргә кала.

73) Мин танышам, их, дускаем,
Бүтән ярың булмаса.
Ал чәчәктән гөл чәчәккә
Күңел кошың кунмаса.

74) Минем бәгърем эшли икән
Телефон заводында.
Неужели бер без генә
Дошманның авызында.

75) Мочалей, Рбишча,
Ерак түгел Кадымка.
Аруга челбәем юктыр,
Сөймисез ару юкка.

76) Нигә күрдем, ник таныштым,
Нигә тормадым тыныч?
Төштем ашыйк[1] утларына,
Хәзер чыгу куркыныч.

77) Нигә томан каплады икән
Караңгы күгебезне?
Нигә аерым тота икән
Бу фани дөнья безне?

78) Нигә яңгыр ява икән
Нәфисә күлләренә?
Хәлләрен яман сөйлиләр,
Авыр күңелләремә.

79) Өстәлләрдә ике лимон,
Берсе тора ике сум.
Синнән миңа, миннән сиңа
Булса иде телефон.

80) Роза гөлем, роза гөлем,
Роза гөлем, алтыным.
Үлсәм, каберемнән чыгар
Сине сөйгән ялкыным.

81) Роза гөлем, ышандырдың,
Вәгъдә бирдең көтәргә.
Уең юкмы башларымны
Мәңгегә хур итәргә?

82) Роза гөлнең тармагына
Элдем кулъяулыгымны.
Очырдым сандугачымны,
Югалттым саулыгымны.

83) Салкын чишмә, салкын чишмә,
Салкын чишмә басуда.
Кычкырып җырлап җибәрсәң,
Янган йөрәк басыла.

84) Сандугач басып сындырган
Таянган тәхетемне.
Кайлардан эзләп табармын
Югалган бәхетемне?

85) Сандугачлар басмада,
Басмага басмаса да.
Алар күңелемне ача,
Кайгымны басмаса да.

86) Сандугачлар күккә менә
Киң тасмага тезелеп.
Хәзер сөям һәм сөярмен
Киләчәктә өзелеп.

[1] Ашыйк – гашыйк.

87) Сикерә-сикерә алга атлый
Күгәрчендәй яшь йөрәк.
Рәхәт яшә җир йөзендә,
Миннән сиңа шул теләк.

88) Сирень исенә буялган
Сиреньнәр утыртучы.
Элек болай түгел идең,
Бар сине котыртучы.

89) Сөйгәнемнең бөдрә чәче
Маңгаена салынган.
Гөл яфрагы селкенсә дә,
Мин булырмын сагынган.

90) Сөярсең яр, сөярсең яр,
Исеме дә матур булыр.
Сөярсең туксан тугызны,
Ләкин файдасыз булыр.

91) Станцияда машиналар
Кычкыралар туктарга.
Уйламыйча яшь башымны
Салдым янган утларга.

92) Сура суы ишелеп ага,
Төбе тирәнгә микән?
Исләремнән бер чыкмыйсың,
Өзелеп сөйгәнгә микән?

93) Ташласаң да яр табармын,
СССР күләме зур.
Дошман сүзләренә карап
Ярны ташлау бит позор.

94) Тәрәзә төпләребез
Үрмәле гөлләребез.
Күп дошманның йөрәгенә
Ут салган көннәребез.

95) Тәрәзәмнең наличнигы
Виноград агачы.
Виноград гел яфырак,
Син сандугач баласы.

96) Телеграф чыбыклары
Барысы да кыл кебек.
Синнән башка үткән көннәр
Минуты да ел кебек.

97) Утырам да буш вакытта
Сепарат әйләндерәм.
Үзем бармыйм, ятка бирмим,
Башларын әйләндерәм.

98) Энҗе бетү – энҗе-мәрҗән,
Энҗүләрне элмәгез.
Алдыбызда чәчәк булып
Артыбызда көлмәгез.

99) Эчеңдәге серләреңне
Сөйләмә беркемгә дә.
Эчең пошса – ятып йокла
Бер караңгы бүлмәдә.

100) Ялт-йолт итеп утлар яна
Театр залларында.
Җибәрмичә тотар идем
Бәгерем яннарымда.

101) Яңа өемнең шкафында
Калды сәгать чылбырым.
Хатымны алгач, укып чыккач,
Каршы хат яз, былбылым.

102) Яшь күңелем никтер курка
Алда киләчәгемнән.
Дошманнар аерма кели[1]
Син роза чәчәгемнән.

[1] Аерма кели – аерырга тели.

Сафаҗай авылында яшәүче Бакеева Рәйсә Ярулла кызының (1929 елда Петрякста туган) дәфтәреннән күчерелде. «Ишетә дә идем бик якшы йырларны, мин сразу язып ала идем аларны» – ди Рәйсә апа. Шулай итеп җыелган 327 дүртьюллыклар арасыннан кайберләрен генә тәкъдим итәбез. Шигырьләр, нигездә, автор ничек язган, шулай китерелә.

Мондый кулъязма җыр дәфтәрләре халык тормышын аңлау өчен искиткеч кыйммәтле чыганак. Аларда көнкүреш әйберләре, техник яңалыклар, географик атамалар гына түгел, ә бәлки халыкның яшәү фәлсәфәсе, рухи кыйммәтләр системасы чагылыш таба.

# ӘЛЛҮ-БӘЛЛҮ БӘБКӘСЕ...

## *Кучкай Пожары авылындагы бишек җырлары*

*Гүзәл Юнысова*

Бишек җыры – фольклорның иң борынгы жанры. Язма истәлекләрдә (христиан истәлеге «Волхвлар баш июе», «Алтын ярук» будда сутрасы, Мәхмүт Кашгарый сүзлеге) «бишек» дигән борынгы төрки термин «бәллү, бала караваты»[1] мәгънәсендә китерелә. Бу жанр үрнәкләре татар халкының бөтен төркем вәкилләрендә дә, шул исәптән мишәрләрдә дә, еш очрый. 1987 һәм 1989 еллардагы экспедиция вакытында Сергач районы Кучкай Пожары (Кочко-Пожарки) авылы кешеләреннән берничә бишек җыры үрнәге язып алырга насыйп булды. Алардан тыш М. Нигъмәтҗанов төзегән «Татар халык җырлары»[2] җыентыгында китерелгән тагын бер үрнәк (Уразавылда язып алынган бишек җыры) бу мәкаләне язуга этәргеч бирде.

Бишек җырының төп башкаручылары – өлкәннәр. Барыннан да элек бу җыр халыкның дөньяга карашын, бигрәк тә хатын-кызның күңел торышын, рухи дөньясын чагылдыра. Шунлыктан балалар фольклорын өйрәнүнең башлангыч этабында ук, бишек җырларын балалар фольклорына кертеп өйрәнү турындагы мәсьәлә калкып чыкты. Дөрес, этномузыкологлар бу мәсьәлә буенча төрле позициядә торалар. Бишек җырларын балалар фольклорына кертүгә ышанычлы нигез – балаларның үзләренең бу

[1] Древнетюркский словарь. – Л.: Ленинградское отделение изд-ва «Наука», 1969. – С. 97.

[2] Татарские народные песни. – М., 1970. – № 40. – С. 50–51.

жанр үрнәкләрен башкарулары һәм саклаулары (бигрәк тә үткән гасырларда). Мәсәлән, Я. Ханбиков «Татар халык педагогикасы»[1] дигән мәкаләсендә өлкәнрәк балаларның кечкенәләрне караганда бишек җырларын җырлауларын билгеләп үтә. Кучкай Пожары авылында язып алынган җырларның беренче юллары ук (мәсәлән: «Әллү-бәллү бәбкәсе, кайда моның әнкәсе?» яки «Әлли-бәлли бәбкәсе, кая киткән әнкәсе?») башкаручының, һәрхәлдә, ана кеше түгел икәнен күрсәтә[2]. Кайбер фольклорчылар, бу фикер белән килешсәләр дә, балалар халык авыз иҗатына бала дөньясын чагылдырган бишек җырларын гына кертергә киңәш итәләр. Бүгенге көндә бишек җырларын (шул исәптән татар халык иҗатын өйрәнүчеләрдә дә) балалар фольклорының «Бала багу поэзиясе» дип аталган беренче бүлегенә кертеп карау өстенлек итә. Монда шулай ук түбәндәге юаткычлар һәм үртәвечләр дә кертелә: 1) йоклату («Әлли-бәлли», «Әлли-бәлли бәй», «Бәй, бәй итәр»); 2) әнисе кая киткән дигән сорау һәм аңа җавап (балага бүләк алырга); 3) йокы теләү; 4) йокламаса, нәрсә буласын аңлату (аю килеп баланы алып китү белән куркыту һ.б.); 5) сабыйны мактау.

Башка төрки халыкларның бишек җырларын өйрәнүче галимнәр «бәй-бәй», «балам бәй» сүзләрен бала йоклатыр өчен уңай булган синсематик иҗекләр (слоглар) дип атыйлар[3].

Кайбер бишек җырларында Г. Тукайның «Бишек җыруы», «Авыл хатынының бала тирбәткәндә өмидләре» шигырьләренең текстлары очрый. Икенче шигырьдә Тукайга хас сатирик төсмер сакланмаган. Шагыйрьләр үз әсәрләрендә сабыйның исемен атамый, ә авылдагы башкаручылар бишек җырын җырлаганда, гадәттә, тәгаен исем әйтәләр, күңеле булсын өчен, язып алучы фольклорчының исемен дә кушып җибәрәләр. Җыр эчендә берничә исем искә алынырга мөмкин:

«1. Әлли-бәлли бәбкәсе, кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка, җиләккә, Гүзәлгә бүләккә;

---

[1] *Ханбиков Я.* Татарская народная педагогика // Из истории педагогической мысли. – Казань, 1967. – С. 3–147.

[2] 1987 елда Казанда Насыйбуллина Рабигадан (1915; тумышы белән Кучкай Пожары авылыннан) язып алынды.

[3] *Кондратьева Н.М.* Колыбельные теленгитов // Музыкальная этнография Северной Азии. – Новосибирск, 1988. – С. 187.

2. Баю, баю, Бәхтеяр. Бар да сине мактыйлар.
Икмәге бар, тозы бар; Сөя торган кызы бар».

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фонархивы фондларында бишек җырларының аерым кызга яки малайга багышланган үрнәкләре саклана[1].

Бишек җырларының көенә килгәндә, аларда башка җырларда сузыла торган көйләр дә очрый, аерым алганда бик популяр «Бәдәвам» китабы көе. Бу көй белән информант бишек җырларын башкарды һәм балаларга багышланган дидактик әдәбияттан «Көйле иман» дигән бер өзек җырлап күрсәтте (1, 2 нче үрнәкләр).

Бишек җырларының көе итеп башка җыр вариантлары да кулланыла. Мәсәлән: Кучкай Пожары авылында язып алынган «Аппак куян утыра» (3, 4 нче үрнәкләр), «Без, без, без идек» дигән лирик җыр, шулай ук М. Нигъмәтҗанов җыентыгыннан алынган «Нарасый бала» уен җырлары. «Аппак куян утыра» җырындагы тәрбияченең хәрәкәтләрен кабатлауга корылган уен тибы – бик кечкенә балаларга багышлана. Ритмик үзгәрешләр кергән саен бер үк көй төрле жанрга карый башлый. Шулай ук бер көйнең рус бишек җырлары белән дә уртаклыгы бар. Әйтергә кирәк, татар һәм рус балалар фольклорының үзара багланышлары хакында да биредә шактый мәгълүмат тупланды.

Бишек җырларының көй үзенчәлеге булып аларның музыкаль терция (ешрак кече терция) алымыннан башлануы тора. Бала йоклатканда (яки йоклый алмый борсаланганда), ана нарасыен кулына алып тирбәтүе, бәллүнең (бишекнең) җай гына чайкалып торуы – болар барысы терциянең (беренче һәм өченче гамманың баскычлары арасындагы интервал) интонациясен тәшкил итә. Бүгенге көндә бала тирбәтүнең физиологик аспектын өйрәнүгә аеруча зур игътибар бирелә. Бу хәрәкәтнең сабыйларга бик ошавы мәгълүм. Шуңа күрә, тез өстендә, аякта сикертү, тирбәтү еш кына уйнауның бер элементы булып тора.

Нәкъ шушы авылда безгә тирбәтү көенә уеннарның бик күп төрен язып алырга насыйп булды. Алар күбесенчә шушы интонациядән башлана. Еш кына башкарыла торган бишек

---

[1] Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ фонархивы. Фонд 66 (№№ 2, 3).

көйләрендә олы һәм кече терцияләр чиратлаша. Тагын шундый үзенчәлеккә игътибар итәргә кирәк: мишәрләрнең бишек һәм гомумән балалар җырларында Казан татарларының борынгы көйләренә хас булмаган өчаваз буенча хәрәкәт (трезвучие) очрый.

Күренекле фольклорчы И. Земцовский жанрлардагы өч төп сыйфатка басым ясый: сүз, максат, көй. Аларның барысы бергә булуы яки берәр компонентының төшеп калуы төрле жанрларның әйдәп бару үзенчәлеген тәшкил итә. Бишек җырларында әһәмиятлелеге буенча аларның чиратлашу тәртибе түбәндәгечә: максат, көй һәм сүз. Төп бурычы – баланы йоклату һәм тәрбияләү. Ә кайбер тикшеренүчеләр бишек җырларының тәрбияви функциясенә ышанмый. Сабый бала сүзләрне аңламый, шуңа күрә бишек җырларының төп элементлары – ритм һәм көй, дигән караш хөкем сөрә. Сүзсез бишек көйләренең дә булуы – алар өчен төп дәлил. Татар халкындагы бу төр көйләрне В. Шнитников[1] һәм М. Нигъмәтҗанов[2] теркәгән. Бишек җырларының ике-өч яшькә кадәрге балаларга җырлануын исәпкә алсак, күбесе инде бу яшьтә сөйләшә, димәк сүзләрне дә аңлый дигән сүз. Шунысын әйтергә кирәк, сүзсез бишек җырлары бик аз язып алынган.

Бишек җырын бала йоклап киткәнче җырлыйлар. Кайбер чагында сүзләр дә бетә, ана да арый һәм бертөрле (монотон) көй генә яңгырый башлый, шуңа күрә аларның интонациясе дә үзенчәлекле. Кучкай Пожары авылындагы кайбер башкаручылар (көй тапшырган кешеләр) үзләре башкарган бишек җырлары турында сөйләгәндә: «Бу җыр түгел, бу такмак», – диләр. Шул рәвешле, алар аның ритмлы сөйләм табигатенә игътибарны юнәлтәләр. Бу бигрәк тә «Сәлендерү» тибындагы балалар уены өчен характерлы.

Бишек җырларының метро-ритмик төзелеше турында берничә сүз әйтеп үтәргә кирәк. Аларның музыкаль үлчәве күбрәк ике чирекле була. Җырларда, күбесенчә, түбәндәге иҗек ритмы кулла-

---

[1] *Шнитников Всев.* Материалы по киргизской и татарской музыке // Живая старина. – 1913. – Г. XXII. – Вып. III–IV. – С. 400–416.

[2] *Нигмедзянов М.* Народные песни волжских татар. – М.: Советский композитор, 1982. – № 48. – С. 103.

нылган: ♪♪♪♪♪♪♩. Фольклорчы Н. Әлмиева[1] тарафыннан ул керәшен татарларындагы бишек көйләренең шундый ритмик калыбы (үрнәге) буларак та аерып күрсәтелә. Ләкин шунысын әйтергә кирәк, мишәрләрдә һәм казан татарларында бу иҗек ритмы кайбер җырларга гына хас. Тукай шигырьләренә таянып, яки бүтән китап көйләрен башкарганда, башка ритмик төзелеш өстенлек итә. Бу шулай ук гаруз белән бәйләнгән булырга да мөмкин: ♪♪♪♩

*Русчадан А.В. Әбдриева тәрҗемәсе*

*КУШЫМТА*

## Бишек җыры

I




Бай, бай итәр, бай итәр,
Бала йокыга китәр.
Бала тиздән йокламаса,
Аюлар алып китәр.

*Казанда Бадьян Садыйковадан (1904 елда туган) язылды.*
*Ул Кучкай Пожары авылында туып үскән. 1987.*

## Көйле иман

II




---

[1] *Альмеева Н.Ю.* Ритмические клише и мелодическая заменяемость в песнях татар-кряшен // Народная музыка: история и типология. – Л., 1989. – С. 162.

1. Белем истә һәркемдә,
Ирләргә һәм кызларга.
Фарыз да бар чамызга,
Сабагыңы бел, бала.

2. Сабак уку фарыздыр.
Яза белү фарыздыр,
Язу ярты илемдер,
Язуны да бел, бала.

*Бадьян Садыйковадан язып алынды. 1987*




1. Әлли-бәлли бәбкәсе,
Кая киткән әнкәсе?
Каенлыкка җиләккә, } 2
Гүзәлгә бүләккә.

2. Баю, баю, Бәхтеяр,
Бар да сине мактыйлар.
Икмәге бар, тозы бар, } 2
Сөйли торган кызы бар.

*Кучкай Пожары авылында*
*Маһирә Ситдыйковадан язып алынды*

## Уен җыры

IV



1. Ап-пак куян утыра,
Колакларны селкетә,
Менә шулай, менә шулай } 2
Колакларны селкетә.

2. Тик торганда бик суык,
Без кулларны җылытыйк.
Тра-ля-ля, тра-ля-ля, } 2
Без кулларны җылытыйк.

3. Тик торганда бик суык,
Аякларны җылытыйк.
Тра-ля-ля, тра-ля-ля, } 2
Аякларны җылытыйк.

4. Кемдер куянны куркытты,
Сикереп качты, әй качты.
Әй качты, качты, качты, } 2
Куян сикереп качты.

## Бишек җыры

V




Әллү-бәллү бәбкәсе,
Кайда моның әнкәсе?
Тирән юлга җиләккә
Киткән аның әнкәсе.

*Кучкай Пожары авылында*
*Сания Мостафинадан (1900 елда туган)*
*язып алынды*

## Бишек җыры

VI




Әлли-бәлли бәбкәсе,  
Кая киткән әнкәсе?  
Каенлыкка җиләккә,  
Бәбкәсенә бүләккә. } 2

*Кучкай Пожары авылында*  
*Сөләйман Курамшиннан (1920 елда туган)*  
*язып алынды*

## Бишек җыры

VII




1. Әллү-бәллү, бай балам,  
Сине бишеккә салам.

Син йокыга киткәндә,
Үзем янында калам.

2. Йокла, балам, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Төнлә йокың калганга,
Егълап үтә көндезең.

*Равия Насыйбуллинадан (1915 елда туган)*
*язып алынды. Ул Кучкай Пожары авылында*
*туып үскән. 1987*

## Бишек җыры

VIII




1. Әллү-бәллү итәр бу,
Бохарага китәр бу;
Бохара иштәр иштән,
Мулла булып кайтыр бу.

2. «Остабикә кирәк», – дип,
Бер бай кызын сорар бу.
Сүз дә әйтмәсләр бирерләр,
Кодачалар килерләр.

3. Кодачалар кайтырлар,
Кызны алып китәрләр.

*Равия Насыйбуллинадан язып алынды.*
*Текстта Г. Тукай сүзләре кулланылган.*
*1987*

## Бишекне ничек ясаганнар

Бер бишекне дүрт агачтан озынча итеп эшлиләр иде рамка кебек. Аның төбенә капчык чүпрәген тегеп куялар иде. Дүрт почмактан җеп бәйлиләр дә иде, түшәнгә колчә кебек эшләгән иде анда. Шул ыргак бәйлиләр җепләрнең очына. Шул ыргак белән бишекне асып куялар иде. Әнисенең кровать янына куялар иде асып.

Бер төрлечә озынча ящик эшли иде. Шул ящикның дүрт почмагына җепләр бәйләп, төбенә капчыклар сугып, чүпрәк капчыклар төзелеп. Шулай итеп асып куялар иде.

Өченче төрлесе юкә бишеге була иде. Юкәне киң итеп сугып, шуңы бөкләп, аның бер-ике ягына дуга куялар иде калын чыбыктан бөгеп. Ә бер башыннан бәйлиләр җеп. Шул җепне дугага бәйлиләр иде. Шул дугадан җеп бәйләп ыргак белән түшәмгә аны да асып куялар иде.

*Равия Насыйбуллинадан*
*язып алынды. 1987*

# ТАКМАК – ЯНЧЫКТА, ҖЫР – КАПЧЫКТА

## *Халык җырларының төзелеше һәм эчтәлеге*

*Ләйлә Мөхәмәтшина*

Түбән Новгород өлкәсе – халык авыз иҗаты әсәрләренә бай төбәкләрнең берсе. Моны әлеге төбәккә берничә тапкыр оештырылган экспедиция материаллары да раслый.

Бу өлкәдә язып алынган җырлар, нигездә, түбәндәге жанрларга карый: йола җырлары, уен һәм бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар һәм лирик дүртьюллыклар.

Җырларның башкарылу формалары һәм вазифаларына килгәндә, алар төрлечә: кешеләрнең күңел халәтен, моңлану, кайгыру, сагыну, сагышлануны белдерүче лирик җырлар; төрле мөнәсәбәтләрне чагылдыручы, хатын-кызның моңлы-зарлы тормышын сурәтләүче лирик җырлар; мәҗлесләрдә җырлана торган табын җырлары; егетләрне армиягә озатканда җырлана торган җырлар; кешенең эчке халәтен чагылдыручы кыска җырлар; туй йолаларын яки башка төр йолаларны үтәгәндә ялгыз яки парлап, кара-каршы, шулай ук күмәкләшеп тә башкарыла торган җырлар.

Йола җырлары татар халык иҗатының иң борынгы төрләреннән санала. И. Надиров әлеге җырларны өч төркемгә бүлеп карый: мәҗүсилек һәм борынгы чорлардан калган шигъри сүз үрнәкләре, ырымнар; ел фасылы (календарь) белән бәйле поэтик иҗат үрнәкләре; туй йоласына караган җырлар[1].

---

[1] Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары / төз. И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 485 б.

Бу китапның исеме алга таба кыскартылып (ТХИ. Йола һәм уен җырлары), файдаланылган бите күрсәтелеп, текст эчендә биреләчәк.

Түбән Новгород өлкәсенә моңа кадәр оештырылган экспедицияләрдә тупланган материалларга карап фикер йөрткәндә, биредә халык җырларының иң зур күпчелеген туй йоласына багышланган җырлар тәшкил итә.

Туй йоласы үзе берничә өлештән тора. Килешү йоласы үтәлгәннән соң, китәчәк кызны иптәшләре-тиңдәшләре озатырга килә. Шул чагында махсус җырлар – кыз елату җырлары башкарыла. Кыз елату җырлары мишәрләр яшәгән җирләрдә аеруча киң таралган була. Кыз елату йоласы нигезендә борынгы ышанулар төсмерләнә. Кызның елап китүе аның язмышы юлында торган серле көчләрне җиңү, явыз рухларны йомшарту өчен кирәк, дип саналган (ТХИ. Йола һәм уен җырлары. Б. 12). Кыз елату җырларында кызның яшьлеге үткән ата-ана йорты якты буяулар белән сурәтләнә, кыз килен булып төшәчәк кайнана-кайната йорты исә караңгы төсләрдә бирелә.

«Бәхил дә булыгыз һәр барчагыз» җырын 1958 елда Горький (хәзер Түбән Новгород) өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Камка авылында Хәбирә Имаевадан И.Надиров язып алган.

Хәбирә апа 1900 елда туган. Ул яшь вакытта инде кыз озату җырлары бик сирәк җырлана торган булган. Бу җырларны ул үзенең туе алдыннан җырлаган. «Мин яраткан кешемә бардым. Еламаска да була иде. Тик, гадәтен китереп, әти-әнигә рәхмәт әйтеп, елап аерылышырга куштылар», дип искә ала ул (ТХИ. Йола һәм уен җырлары. Б. 277).

**Бәхил дә булыгыз һәр барчагыз**

Әнекәем генә, елашыйк,
Сандугачлар кебек сайрашыйк;
Сандугачлар кебек сайраштык,
Былбыл кошлар кебек адаштык.

Анай кәбәм, кушә[1] коргансың,
Анда бөгелеп ниләр тукырсың?
Сау бул, анай кәбәм, китәмен,
Ничек миннән башка торырсың?

[1] Кушә — туку станогы.

Сандугачлар оча җил көндә,
Җил көндә лә түгел, иркендә;
Китәм, анай кәбәм, каласың,
Сиңа кереп бакмас беркем дә.

Тәрәзә төбендә йомырка,
Күчер, анай кәбәм, онытма;
Каршымда балалар калды, дип,
Мине дә, анай кәбәм, онытма.

Алтын сәгать бирим кулыңа,
Чылбырларын элим муеныңа;
Алтын сәгатьләрнең яктысы
Ялтырап торсын барган урыныңда.

Мамык шәлең, кызым, җылымы?
Җылы булса, катлап урама;
Буласы гына эш булмый калмас,
Күз яшеңне түгеп елама.

Әтекәем, бирнә бирием,
Уң кул белән генә алсана;
Әтекәем, китеп барамын,
Хәер-догаң белән калсана.

Көмеш энә генәм, җеп кенәм
Сандык төпләрендә каладыр;
Уйнаганым гына, көлгәнем,
Әтием, синең өйдә каладыр.

Ары да гына элмә, бире эл,
Әтекәем, камыт-дугаңны;
Әти кәбәм, китеп барамын,
Бирәмсең хәер-догаңны?

Ишек алдындагы карларны
Көри торырмысыз, туганнар?
Туганкаегызның хәлләрен
Сорый торырмысыз, туганнар?

Олы агакаем – ак яка,
Тарелкада калган бал сиңа;

Мине бик хөрмәтләп озатасың,
Өч оҗмахта урын бар сиңа.

Кече туганкаем – ак итек,
Басып пычратма балчыкка;
Кил яныма, куллар бирешик,
Күрешә алмабыз, бәлки тансыкка.

Сылу сеңлем, белеп кайт әле,
Талның тамырлары бар микән?
Талның тамырлары таралган,
Без таралыр өчен яралган.

Ике дә генә келәт янәшә,
Бастырыклар салдым юл аша;
Барып та гына юлым уңмаса,
Килеп елармын ла көн аша.

Алачалы чаршау, әй, комач бау,
Кор, дисәгез дә кормамын;
Китәр вакытларым җитте инде,
Тор, дисәгез дә тормамын.

Идәнебез сары балавыз,
Икәү бер тактадан барабыз;
Бәхил дә булыгыз һәр барчагыз,
Аерылып китә балагыз!

(ТХИ. Йола һәм уен җырлары. Б. 77–79)

Моннан тыш, әлеге өлкәдә халык телендә «бал кыцкырту», «килен төшерү», «япма будыру» дип атала торган йолалар да бар. 2010 елда уздырылган экспедиция вакытында Түбән Новгород өлкәсе Сафаҗай (Красная Горка) авылында Мөхәммәтов Зөфәр Мөхәммәт улыннан (1942 елгы) бал кычкырту такмаклары язып алынды:

«...кыз төшкән көнне кияү ягында опять бәйрәм. Элек бит парлылар парлап утырмыйлар иде, яшьләр генә иде тәмам вечерда, әле бит хатын-кыз да инде, картлар да утыра, эцәләр, ә ул вакытта яшьләр генә, кызлар-егетләр утыралар иде. Яшь килен

килгән көнне опять анда вечер була инде, шылай ашап-эцәләр дә и вечер. Опять шул ук уеннарны уйныйлар, аннан давай бал кыцкырталар. Кодагидан башлыйлар, башта биетәләр кода белән кодагины, бер кеше кыцкырта, акца җыя бара котлап, эшләпәсе бар иде, котлап такмак атяләр, акца бирәләр. Бер шапка яки кепкасын ала идек тә тотына инде, бал кыцкыртабыз, акца җыябыз. Такмагы бар иде:

Әй, егетләр,
Алдап алыгыз, шалдап алыгыз,
Бал кабыгыз, дир,
Бал тиң дәрья булыгыз, дир,
Кем дә атер, дир (кодагины атяләр инде анда),
Равия тутай атядер, дир,
Кызым белән киявемнең туен күркәм иттереп
Юк-бар акцам да бер тәңкә,
100 тәңкәлек белән, имештер кыцкыртадыр, дир.

Аны әле биергә цыгаралар, давай-давай кодаги бие, диеп. Әле икенце кодаги кыцкырта, теге кодаги биер, дип атядер, дир, миннек белән кыцкыртадыр, дир:

Ат бирсәм узар,
Тун бирсәм тузар, дир,
Кәзә бирсәм, бары сөзәр, дип атядер, дир,
Бу кодагины сорасагыз, дир,
Россиягә карендәш, дир,
Бөтен Татарстанга карендәш, дип атядер, дир.

Шылай итеп, бөтен кеше цыкканда шылай такмак атеп торалар иде. Аннан тагын инде үзгәләр тотына инде биергә. Аннан тагы шушы ук такмакларны атяләр, бу ирне сорасалар, бөтен Россиягә карендәш, дир. Аннан тагын атүчеләр бардыр, дир. Кем дә атмидер, дир, әнә кияү белән килен дусты бирер, дип атядер, дир. Кияү белән кыцкыртсалар, биш йөзлек белән имештер кыцкыра. Аның ике тәңкә генә акцасы бар инде, мактап кыцкырталар шылай. Кеше исеме белән атяләр:

Кемнәрнеңдер бакцасында
Сайрыйдыр ла сандугач,

Бу егетне сорасагыз,
Бөтен Россиягә карендәш, дип атяләр, –

дип йырлыйлар иде. Вот шылай кыцкырталар иде. Кыз төшкән көнне шылай бииләр иде, кызык була иде. Акцаны җыештыралар да акца аннан яшьләргә була иде. Вот шуның белән туй бетә иде». (Л. Мөхәммәтшина белән И. Шәрипов язып алды.)

Түбән Новгород өлкәсенә моңа кадәр оештырылган экспедицияләр вакытында туй мәҗлесендә башкарыла торган мактау-макташу җырлары да очраган. Шундый җырларның берсен – «Безнең кызыл алмабыз»ны – 1962 елгы экспедиция вакытында, Горький өлкәсе Кучкай Пожары авылында Рокыя Сабировадан (1919 елгы) Т. Галиуллин язып алган.

**Безнең кызыл алмабыз**

Кыз ягы: Безнең кызыл алмабыз,
Сезнең кызыл алмагыз;
Безнең кызыл алмабызны
Саргайтырга алмагыз.

Егет ягы: Сезнең кызыл алмагыз,
Безнең кызыл алмабыз;
Сезнең кызыл алмагызны
Саргайтырга алмабыз.

Кыз ягы: Алмалары өзелгәндә,
Агачы кала тирбәлеп;
Багалмадай кызыбызны
Сөярсезме кинәнеп?

Егет ягы: Алмалары өзелгәндә,
Агачы кала тирбәлеп;
Багалмадай кызыгызны
Без сөярбез кинәнеп.

2010 елгы фәнни сәяхәтебез вакытында уен һәм бию җырларын башкарып күрсәтүче булмады. Шунлыктан, биредә элеккеге елларда уздырылган экспедиция вакытында шушы өлкәнең Кучкай Пожары авылы яшьләреннән И. Надиров тарафыннан язып алынган уен җырын тәкъдим итәбез.

## «Өч тәрәзә» уены

Уен башлануга, бер егетне яки кызны өйдән чыгарып торалар. Өйдәгеләр тарафыннан өч тәрәзәгә өч исем кушыла. Тышта кыз булса, тәрәзәләргә шул кызга күзен төшереп йөрүче егетләр исемен яки, киресенчә, тышта егет булса, тәрәзәгә кызлар исеме кушалар. Өйалдына чыккан егет яки кыз керә дә, өч тәрәзәнең берсе янына туктап җыр җырлый:

*Мәсәлән, егет җыры:*

Алмагачлар арасында
Сандугач юллары бар;
Дускаемның йөзләрендә
Ай-кояш нурлары бар.

Ахырдан әлеге тәрәзәгә кушылган исемне әйтәләр. Егет (яки кыз) шул исем янына барып утыра. Шуннан соң өйалдына яңа кеше чыгарыла:

*Кызлар җырыннан бер мисал:*

Станцада исем китте
Казан чияләренә;
Кирәкми кеше ярлары,
Булсын ияләренә.

Фант җыю һәм һөнәр күрсәтү белән бәйле уеннарның тагын берсен – «Җыр әйтешү» уенын шул ук елдагы экспедиция вакытында (1962 елда) Петрякс авылында Х. Гатина язып алган.

## «Җыр әйтешү» уены

Уенга катнашучылар тезелеп утыралар, арадан берәү уйнатучы-җиңги булып кала. Җиңги бер егетне өйдән чыгарып җибәрә дә, утыручылар белән киңәшеп, өч кызны билгеләп куя. Ул арада тыштагы егет, үз урынына бер иптәшен чакырып чыгара да, үзе өйгә керә. Аңа билгеләнгән өч кызның да исемнәрен әйтәләр. Ул шулар арасыннан берсен сайлап, шуның белән каршы-каршы җыр әйтешә. Җырларның бер мисалы:

Сөям сине, ал чәчәгем,
Синдә мәхәббәтем бар;
Күп эзләдем, таба алмадым
Синнән мәхәббәтле яр.

Җавап:

Сөяр идем син чәчәкне
Сүрелмәс булсаң гына;
Ал чәчәктән тигәнәккә
Үрелмәс булсаң гына.

Бу пар җырлап бетергәннән соң, уйнатучы-җиңги яңадан өч кызны билгеләп куя да, тыштагы егетне чакырып, аңа да билгеләнгән кызларның исемнәрен әйтә, кабат кара-каршы җырлашу башлана. Уен вакытында чәнечкеле, шаян җырлар да башкарыла (ТХИ. Йола һәм уен җырлары. Б.171).

Кара-каршы сафларга тезелеп, парлашучы уеннарга керүче «Җимчәчәк» уены, килеп чыгышы ягыннан, борынгы туй йолаларына бәйләп карала. Уен барышында егет ягының кыз сайлавы, ә кыз ягының булачак «кияү»не хурлавы – аерым төбәкләрдәге гадәтләрне искә төшерә. Уен, тора-бара йолалык билгеләрен югалтып, яшьләрнең күңел ачу уенына әверелгән. Әлеге җыр 1958 елда Кызыл Октябрь районындагы Камка һәм Сафаҗай авылларында Х. Ярми, И. Надиров, Р. Башкуров һәм Х. Гатина тарафыннан язып алынган (ТХИ. Йола һәм уен җырлары. Б. 291).

**«Җимчәчәк» уены**

Кызлар, егетләр, кара-каршы ике сафка тезелеп, җыр әйтешәләр. Гадәттә, кызлар – егетләрне, егетләр кызларны үчекләп, шаян җырлар башкаралар.

Уен язгы ташу вакытында атна-ун көн буена (су килгән көннән алып су киткәнче) һәр көнне кич беләп көтү кайткач уйналган.

Җырлары:

Җимчәчәк, җимчәчәк,
Зимә буе нарымсак, нарымсак,
Нарымсакка ни кирәк, ни кирәк?
Ярма-ярма бүз кирәк, бүз кирәк.
Ул бүзләрне тегәргә, тегәргә
Инә белән җеп кирәк, җеп кирәк;
Ул инәне тотарга, тотарга
Оста куллы кыз кирәк, кыз кирәк.

Вак-вак кына тарелка, тарелка,
Җиргә төшсә уала, уала;
Сезки саяк-сандуракка[1], сандуракка
Кыз бирсәң дә югала, югала.

Пичкә салдым алты үпмәк[2], алты үпмәк,
Алтысы да ябышкан, ябышкан;
Сезки саяк-сандураклар, сандураклар,
Кайдин бергә табышкан, табышкан.

Ызба алдында садыгыз, садыгыз,
Коямысыз, юкмысыз, юкмысыз;
Кызыгыз безгә чыгып килә, чыгып килә,
Тоямысыз, юкмысыз, юкмысыз.

Аргы якта ак тана, ак тана,
Бирге якта ак тана, ак тана;
Улыгызны ник мактыйсыз, ник мактыйсыз,
Келәнгәнен[3] мактана, мактана.
Озын касар[4] буенда, буенда
Чалгы кайрый йөрисез, йөрисез;
Аздакадай[5] улыгызга, улыгызга
Кызлар сайлый йөрисез, йөрисез.

2010 елда Түбән Новгород өлкәсе Рбишча авылында Ситдыйкова Факия Сәяр кызыннан (1958 елгы) «Бака түшәге» уены язып алынды.

### «Бака түшәге» уены

Уртага бер кызны чыгаралар, урындыкка утырталар, ул батучы була. Аннан аны җырлар белән батыралар. Уен кагыйдәсе буенча аны җыр әйтеп коткарырга тиеш булалар. Батыручы батучыга әйтә:

---

[1] Саяк-сандурак – вак-төяк.
[2] Үпмәк – икмәк.
[3] Келәнгәнен – сораганын.
[4] Касар – болын.
[5] Аздакадай– аждаһадай

Баттыңмы, баттыңмы,
Баттыңмы, күмелдеңме?
Бака түшәгенә ятып
Торуы күңеллеме?

Аннан, арада аның егете булса, ул егет, җырлап чыгып, аны коткара да, үзе батучы була. Коткаручы егет болай дип җырлый:

Бер кулымда, бер кулымда,
Бер кулымда чемодан,
Сине сөям көне-төне,
Бир кулыңны, чыгарам.

Шулай җырлый да, кызны коткара, үзе шул кыз урынына кереп баса, хәзер инде аны батыра башлыйлар.

Ә инде батучы кеше егет булганда, аңа түбәндәге җыр җырлана:

Батасың, егет, батасың,
Ниләр килә уеңа?
Бир кулыңны, чыгараем,
Чакырырсың туеңа.

Әгәр инде тартып чыгармасалар, аны батыра гына баралар, аннан башкасы чыга, менә шулай уен дәвам итә (Л. Мөхәмәтшина белән И. Шәрипов язып алды).

2010 елда оештырылган экспедициядә тарихи җырлар язып алынмаса да, моңа кадәр әлеге өлкәне өйрәнүгә багышланган 1958, 1962 елларда узган экспедиция вакытында Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать (ул елларда – тарих) институты галимнәре тарафыннан ике дистәгә якын тарихи җыр һәм җыр вариантлары язып алынган. Аларның берсе – Казан ханлыгы чорына, ә калганнары – качкыннар һәм тоткыннар тематикасына карыйлар.

**Качкынның михнәте бигрәк зур**

*(Тали җырлары)*

Серый да гына зыбын, арты бөргән,
Кигезделәр бәнем өстемә;
Агай, бер угълыңны солдатка бир,
Шунда бән төшәрмен исеңә.

Шылдыр да гына шылдыр сулар ага
Елга буйларында ташлыкта;
Яшь тә баш кынаем югаладыр,
Көтмим патшалардан шатлык та.
    Бармагымны киссәм, агырта...
    Мизан мулла салды тәмугка.

Уң кулымда агыр мылтыгымны
Ничек өйрәнермен атарга;
Приемда Коръән үптергәндә,
Ният кылып үптем качарга.

Ачы да гына буран, нечкә җилдә,
Анай кәбәм, тышта кунармын;
Кәсәй белән писер Сәйпулланы
Очыратсам, терели тунармын.
    Ай-һай, туганнарым, агыр хәл,
    Әнкәй генәм кала бигрәк жәл.

Мендем биек тауның, әй, башына,
Ияремне куйдым башыма;
Әллә күрешәбез, әллә дә юк,
Килсәнә, анай кәбәм, каршыма.

Көрән аткаема менгән чакта
Камчы сабым калды каерылып;
Камчы сабым калу берни түгел,
Әнкәй кәбәм калды аерылып.
    Егълама, анай кәбәм, көн сәтә[1],
    Дөнья төрле хәлне күрсәтә.

Быел гына чәчкән игенемне
Җыр гынамны җырлап урырсыз;
    Ай-һай, Фәйзулла гынам, балакаем,
    Кайсы губернада булырсың.

Аяктагы тимер богавымны
Себер кузнеслары эшләде;

---

[1] Көн сәтә – көн саен.

Артларымнан фискал[1] куган чакта
Иярләгән атым кешнәде.
	Ай-һай көннәремнең үтүе,
	Авыр булыр үмер итүе.

Мәскәү губернасы зур губерна,
Өч сутка[2] әйләндем кругын[3];
Сорамагыз, дуслар, сорамагыз
Качкын егетләрнең торуын.

Елга буйларында утлап йөри
Ратник[4] Талиеның атлары;
Тугай елгасында качып кунам,
Рәнҗемәгез, авыл картлары.
	Булмагыз, егетләр, болай хур,
	Качкынның михнәте бигрәк зур.

Очып кына барган асыл кошның
Авызында яшел яфрак;
Качып йөргән чакта вафат булсам,
Кем өстемә салыр туфрак?

Зиләдер[5] дә болыт, әй зиләдер,
Җилгә дә генә каршы киләдер;
Чык, анай кәбәм, ач ишегең,
Көтмәгән кунагың киләдер.
	Егълама, анай кәбәм, бетәрсең,
	Качкын угълың кайдан көтәрсең.

Аерыкай нөгез[6], болан дигән,
Ашап кына туймый нүектән[7];

---

[1] Фискал – әләкче. Биредә бу сүз Талине тотарга йөргән авыл куштаннарына карата әйтелә.

[2] Сутка – тәүлек.

[3] Круг – әйләнә, түгәрәк.

[4] Ратник – элек солдатны, сугышчыны шулай дип тә йөрткәннәр.

[5] Зиләдер – җиләдер.

[6] Нөгез – мөгез.

[7] Нүектән – мүктән.

Себер җирләрендә күп йөредем,
Асла чыга алмадым күектән[1].

Һавалардан очкан асыл кошның
Кагырчынын[2] алдым каләмгә;
Бүләк җибәрергә һич хәлем юк,
Риза бул, анай кәбәм, сәламгә.
    Йоклар идем ятып төн ката,
    Кеше күрсә, атым уйгата[3].

Очыгыз ла, казлар, әй очыгыз,
Очалмаганыгыз кайтыгыз!
Безнең туган җиргә җитә алсагыз,
Туганнарга сәлам әйтегез!

Кыйгак та гына кыйгак каз кычкыра –
Адашкан киек казның баласы;
Тугай буйларында егълап йөри
Ратник Талиеның анасы,
    Егълама, анай кәбәм, бетмәгел,
    Якын җирдә түгел, көтмәгел!

Бер дустыма кердем кунак булып,
Атым бәйләп куйдым имәнгә;
Фискаллар киләдер мине алырга,
Хатын булып[4] киттем кибәнгә.

Җәй дә башларында, кызу көндә,
Кортлар бал ташыйдыр муртага;
Печән кибәненә качып кердем,
Илле фискал алды уртага.
    Егълама, анай кәбәм, көн сәтә,
    Дөнья төрле хәлне күрсәтә.

Казаннардан алган ияремнең
Зәңгеләрен ничек ачармын;

[1] Күектән – көектән, кайгыдан.
[2] Кагырчынын – кавырсынын, каурыен.
[3] Уйгата – уята.
[4] Хатын булып – хатыннар киеме киенеп дигән мәгънәдә.

Йөрмәгез, фискаллар, әй артымдин,
Тотсагыз да тагын качармын.

Суык та гына кизләү өсләрендә
Ашап йөри Тали атлары;
Печән кибәнендә бән тотылдым,
Рәнҗемәгез, авыл картлары.
Булмагыз, егетләр, болай хур,
Качкынның михнәте бигрәк зур.

Алдыма карасам, әй, тау кебек,
Артыма карасам – туй кебек;
Галанский кырның уртасында
Бәйләп салдылар ла куй кебек.

Тугай буйларында, япь эчендә,
Ашап йөри Тали атлары;
Сарысаз түбәсендә мин тотылдым,
Аепләмәгез, авыл картлары!
Егълама, анай кәбәм, доган кыл,
Бигрәк озын качкын йөргән юл.

Себерләрдин алган ак күлмәгем,
Итәгендин озын җиңләрем;
Үземә үзем генә җыр чыгардым,
Сагынып бер җырларсыз, тиңнәрем![1]

«Качкынның михнәте бигрәк зур» (*Тали җырлары*) – 1941 елның 12 гыйнварында «Октябрь коммунасы» газетасында басылып чыккан. Әлеге газета үз вакытында Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь районында чыгып килгән. Текст шул район укытучысы Х. Абдуллин тарафыннан 1940 елда Актук авылының олы яшьтәге кешеләре Хәлил Рамазанов, Басыйр Рәхмәтуллин һәм Атыйп Ситдыйковтан язып алынган. Әсәр «Тали беглый бәете» дигән исем астында басылган. Әмма аны бәет дип атау белән килешәсе

[1] Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар / төз. И.Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – Б. 48–51.

Алга таба бу чыганак кыскартылып (ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар), файдаланылган бите күрсәтелеп, текст эчендә биреләчәк.

килми. Ул тулысы белән җыр традицияләренә нигезләнгән һәм поэтикасы белән җырлар рәтендә торучы әсәр. Текстның үзендә үк аның җыр булуын раслаган юллар бар. Бер урында, мәсәлән, Тали үз исеменнән:

Быел гына чәчкән игенемне
Җыр гынамны җырлап урырсыз, –

дигән үтенеч белдерә. Соңгы строфада исә:

Үземә генә җыр чыгардым,
Сагынып бер җырларсыз, тиңнәрем –

дигән теләк белдерелә.

Х. Абдуллин шул ук газетада бу әсәрнең иҗат ителүе өчен нигез булган тарихи сәбәпләрне һәм Талинең гомер юлына караган кайбер белешмәләрне дә китерә (өзек газетада басылганча бирелә):

«Талиның исеме – Фәйзулла. «Тали» – кушаматы, фамилиясе – Сәйфетдинов.

Тали үзе Актук авылында 1833–1835 еллар тирәсендә туган. Яшь вакытларын ярлылыкта үткәргән. Аның энесе Фәтхулла да, шулай ук, байларга ялланып эшләп йөргән. Тали әнисе, энесе һәм сеңлесе белән бергәлектә яшәгәннәр.

1855 елда, ягъни лашманчылык бетерелгән һәм 25 еллык солдат хезмәте булган заманнарда, Актук авылыннан 6 кеше солдатка китәргә тиеш була. Шуларның берсе Мизан мулла була. Шул вакытта авылның түрә, бай куштаннары Талины Мизан мулла урынына солдатка җибәрәләр. Ләкин Тали солдат хезмәтеннән качып кайта. Шуннан соң Тали беглый булып китә.

Актүк авылы картлары сөйләвенчә, Тали Беглый 25 еллап качкынлыкта йөргән. Берничә тапкыр тотылган, ләкин тагын да качкан булган. Бер тапкыр ул Себердән дә качкан. Ахырда, 25 еллар вакыт үткәч, Тали авылда урнашырга уйлый. Ләкин моңа авылның байлары каршы булалар. Нәтиҗәдә, Тали беглый Себергә сөрелә һәм Себердә үк үлә дә» (ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 384).

«**Әхсән голова**». Әлеге җыр Түбән Новгород өлкәсенең Камка авылында Фәхретдин Сәиновтан (1896 елгы) 1958 елда язып алынган. Язып алучылар Р. Башкуров, И. Надиров.

Җырлаучының сөйләве буенча, Әхсән Камка авылында туып-үскән. Ул XIX гасыр урталарында яшәгән. Әтисе мәзин булган. Тора-бара Әхсән бик баеп китә, авыл күләмендәге түрәгә әйләнә. Шуңа күрә аңа «Голова» дип кушамат бирәләр. Дошманнары аның баюын күралмый. Алар көнләшәләр. Ниндидер нахак сәбәпләр табып (мәсәлән, аны хөкүмәт акчасын үзләштерүдә гаепләп), Себергә озаттыралар. Җыр шул вакыйгадан соң туа (ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 389).

**Әхсән голова**

Ялтыр да гына ялтыр ни ялтырый? –
Камка[1] илләренең плугы[2];
Урламыйча Себер югаладыр
Осман азанчының олы улы.

Голова да идем, зур да идем,
Көн дә йөри идем пар атта;
Әхсән голованы сорасагыз,
Иске Макарида[3] ятапта[4].

Голова да идем, зур да идем,
Көмеш койдыра идем таякка;
Сокланмагыз бу дөнья малына,
Богау кидертәдер аякка.

Шауыл да гына шауыл ни шауылдый? –
Пьяна[5] буйларының камышы;
Татлы йокыларны качырадыр
Нахак Себер китү сагышы.

Мәкәрҗәдән алган туры атымны
Чыгарып бәйләгез, җил каксын;

---

[1] Камка – Камкино, Түбән Новгород өлкәсенә керүче авыл исеме. Халык сөйләвенә караганда, җыр герое Әхсән шушы авылныкы.

[2] Плуг – сабан.

[3] Макари (Макарьев) – Мәкәрҗә ярминкәсе уза торган урын.

[4] Ятап – этап (тоткыннарны конвой белән озату).

[5] Пьяна – Камка авылы янынннан ага торган елга.

Башкынамны йолар юллар булса,
Әнкәй ике ызбамны тиң сатсын.

Шылтыр да гына шылтыр ни шылтырый? –
Аргы як кибетенең ачкычы;
Болай буласымны белгән булсам,
Булыр идем бер бай ялчысы.

Шыпыр да гына шыпыр яңгыр ява
Острог[1] түбәсе калайга;
Богауда торсам да хат язамын
Яшь хәләлем белән анайга.

Чылтыр да гына чылтыр сулар ага
Острог янындагы канауга;
Җибәргән хатымны тапшырыгыз
Яшь хәләлем белән анайга.

Шауыл да гына шауыл ни шауылдый? –
Камка илләренең камышы;
Күздән югалганчы ишетеләдер
Хәләл Фатихамның тавышы.

Җилләр ачкан арткы җил капканы,
Җил капканы гына кем япсын?
Миндин генә калган өч ятимне
Усман абзый бакмый кем баксын.

Әхсән голованың чемоданы,
Унике икән аның бүлкәсе;
Әхсән голованы сорасагыз,
Караңгы икән аның төрмәсе.

Камка илләрендә ызба салдым
Камка илләренә тамга өчен;
Җырымны җырлагыз, мин түзәрмен,
Яманат сатмагыз, Алла өчен.
(ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 63–64).

[1] Острог – төрмә, зиндан.

«Канҗафәр» тарихи җыры Түбән Новгород өлкәсенең Татар Моклокасы авылында Харрас Хафизовтан (1895 елгы) һәм Тәнзилә Закировадан (1899 елгы) 1962 елда Т. Галиуллин тарафыннан язып алынган. Җырга карата шундый искәрмә бирелгән:

«Үткән гасырның урталарында Оваленский дигән бер алпавыт управляющие (җырда ул „бурмис" диелә) Канҗафәрнең җирен тартып ала. Канҗафәр жалоба белән барса да, аны кыйнап җибәрәләр. Шуннан ул энесе Алины ияртеп, мылтык алып, бурмистрга китә. Күрәсең, атышу да була.

Соңыннан Канҗафәр белән энесен кулга алалар, берничә көн караңгы подвалда тоталар. Канҗафәрне качуда гаепләгән булып, атып үтерәләр, Алины, яшь булуы сәбәпле, иреккә чыгаралар. Җыр әнә шул вакыйгага багышлап чыгарылган».

### Канҗафәр

Күк кырыйлары, әй, күгәргән,
Кара урман буйлары, әй, каралган;
Беләмсез, дусларым, хәлемне,
Яшь тә йөрәгемне кан алган.
Икәү буш урында, караңгыда,
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

Канҗафәркәй мылтык атадыр,
Төтене генә җиргә ятадыр;
Энем Гали, әйдә, тор, сугышыйк,
Бурмис[1] үтерергә әйтәдер.
Икәү буш урында, караңгыда
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

Сандугачлар кунып кайда сайрый?
Озын елгаларның башында.
Гали дә Канҗафәр тилмерәдер
Батрас бурмисы каршында.
Икәү буш урында, караңгыда
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

---

[1] Бурмис – җырга бирелгән искәрмәгә караганда, бурмис дип бер алпавытның управляющие аталган.

Гали дә Канҗафәр ничә яшәр,
Матур сукно бүрке башында;
Гали дә Канҗафәр допрос бирә
Батрас бурмисы каршында.
Икәү буш урында, караңгыда
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

Сандугачлар кунып кайда сайрый? –
Озын елгаларның буенда;
Нихәтле еласагыз да, мин булмамын
Кече энекәшем туенда.
Икәү буш урында, караңгыда
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

Быел гына куйган ызба башын
Нинди сырлар белән сырлатыйм?
Кеше дә җырларын күп җырладым,
Үз җырымны кемнән җырлатыйм?
Икәү буш урында, караңгыда
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

Җыелмагыз, ятлар, әй, яныма,
Качкан да гына купкан түгел мин;
Еламагыз, дуслар, минем өчен,
Бушка үлгән кеше түгел мин.
Икәү буш урында, караңгыда
Нишләрбез генә икән, Канҗафәр?

Лирик җырларның ике зур төркеме бар. Фольклорчы галим К.М. Миңнуллин әлеге җырларны лирик озын җырлар һәм лирик дүртьюллыклар дип атый. Лирик җырларның һәр ике төренең дә таралу, яшәү даирәсе бик киң һәм шуннан чыгып инде сурәтләнгән темалар да күп төрле. Алар адәм баласының бар кайгыларын, хәсрәтле кичерешләрен, шатлыкларын, ара-тирә була торган шаян-шуклыкларын чагылдыра. Кыскасы, лирик җырларда һәркемнең күңеленә якын булган уйланулар, эчке кичерешләр урын тапкан[1].

[1] *Миңнуллин К.М.* Һәр чорның үз җыры. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 62.

Озын лирик җырлар һәм җыр вариантлары, моңа кадәр оештырылган экспедицияләр вакытында, Түбән Новгород өлкәсендә күпләп тупланган. Аларның күпчелеге чит җирләрдә бәхет эзләүчеләр моңы, хатын-кыз язмышы, мәхәббәт тематикаларына карый.

Хатын-кыз язмышы тематикасына караган «Кайгырмыйк ла юк малларга» җырын, 1958 елгы экспедиция вакытында Түбән Новгород өлкәсенең Камка авылында Фәхретдин Сәиновтан (1896 елгы) И. Надиров, Р. Башкуров язып алган.

**Кайгырмыйк ла юк малларга**

Тугайларда сынды көмеш чалгым,
Печәннәрен шуңа чапмадым,
Газизәкәй кыз,
Печәннәрен шуңа чапмадым;

Кайгыра-кайгыра маллар өчен
Үтә инде арыслан чакларым,
Газизәкәй кыз,
Үтә инде арыслан чакларым.

Агыйделнең суы кая ага?
Бәреләсугыла ап-ак тауларга.
Газизәкәй кыз,
Бәреләсугыла ап-ак тауларга.

Кайгырмыйк, дуслар, юк малларга,
Мал җитәдер газиз башларга,
Газизәкәй кыз,
Мал җитәдер газиз башларга.

Нинди шәһәрләрдә табыла икән
Янган-көйгән йөрәкнең дарусы?
Газизәкәй кыз,
Янган-көйгән йөрәкнең дарусы.

Янган йөрәк дарусын эзли-эзли,
Ак йөзләргә чыкты ла сарысы,
Газизәкәй кыз,
Ак йөзләргә чыкты ла сарысы.

(ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 151–152).

### Бодай межасы

Агыйделкәйләрне кичәр идем,
Ак мамыктан салган сал булса;
Күргән нужаларымны сөйләр идем,
Элек сөйгән яр гынам сау булса.
Борылып киткән бодай межасы,
Ай-һай авыр дөнья нужасы.

Мижгород[1] ла дигән зур губерна,
Уртасына җыела сәүдәсе;
Чит илләрдә йөргән егетләрнең
Иленә кайта коры гәүдәсе.
Борылып кына ага агым су,
Малсыз, ярсыз калсаң, ямансу.

Мәскәү юлларында таш пулатта
Солылар ла салдым туры атка;
Сәфәрләрдә йөреп гомер уза,
Ирешермен микән морадка?
Борылып, сарылып үсә алмагач,
Ни кыйлаем бәхетем булмагач.
(ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 166).

Әлеге җырны 1962 елгы экспедиция вакытында Т. Галиуллин һәм И. Надиров Түбән Новгород өлкәсе Андреевка авылында Абдулла Хәсәновтан (1894 елгы) язып алганнар.

Җырлар арасында иң күп таралганнары – хатын-кыз язмышына багышланган әсәрләр. Аларның күпчелегендә яшь килеш ирексезләп, үзе белмәгән, хәтта күрмәгән, яратмаган егеткә кияүгә бирелгән, хәтта сатылган кызлар авызыннан сөйләнә. Алар үтә бер моң, күз яше белән сугарылган.

«Сатылачак кыз җыры» 1962 елгы экспедиция вакытында Андреевка авылында Осман Хәмидуллиннан (1883 елда туган) И. Надиров тарафыннан язып алынган. Әлеге җыр кыз сату белән бәйле ямьсез гадәтне фаш итү, аңа протест белдерү хисе белән сугарылган.

[1] Мижгород – хәзерге Түбән Новгород (Нижний Новгород) шәһәре.

## Сатылачак кыз җыры

Таң алдыннан торып тышка чыктым,
Агач яфракларын коядыр;
Бу хәсрәттән башлар азмаса да,
Елап күздән яшьләр коядыр.

Тор, балакай, инде таң-таң ата,
Нинди төшләр күрдең син бүген?
Сискәнеп китәсең йокы арaңда,
Сиздеңме әллә – бүген нинди көн?

Төшләреңдә, балам, ниләр күрдең?
Сөйләсәнә миңа, бәбкәем.
Кол базарларына сатар өчен
Чәчең үрде синең әнкәең.

Нидән, анай кәбәм, син елыйсың,
Әллә миндәй авыр төш күрдең?
Сатылачак бала әллә минме,
Кара чәчкенәемне ник үрдең?

Җылы сөтләреңне ник имездең,
Ник асрадың мине бала итеп?
Нарасый бичара мин баланы
Ник сатасың, әнкәй, кол итеп?

Кисеп алчы, әнкәй, чәчләремне,
Пыяла шкафыңа куярсың.
Адашкан казлар моңайгандай,
Чәчләремне алып карарсың.

Кол базарларында сатар өчен,
Әнкәй, буяу буя битемә.
Базарга илтергә эткәй атын җигә,
Карасам, кан тула күземә.

Байлар бал эчәләр, бик татулап,
Башымны йөриләр сатулап.
Байлар кул астында яшәгәнче,
Җан бирәсем килә агулап.

(ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 206–207).

Лирик җырларның төп өлешен мәхәббәт җырлары били. Мәхәббәт җырлары, кагыйдә буларак, яшьләр тарафыннан иҗат ителә һәм егет белән кызның хис-кичерешләрен, поэтик картиналар аша, бөтен нечкәлеге, нәфислеге белән сурәтли. Бу җырларны буеннан-буена саф, керсез, кайнар мәхәббәткә омтылу хисе сугара. 1962 елгы экспедиция вакытында Бозлау авылында Алимҗан Җаббаровтан (1891 елгы) И. Надиров, Т. Галиуллин язып алган «Җанашым» җыры шуның ачык бер мисалы булып тора.

**Җанашым**

Икәүләп бергә чыгыйк йөрергә,
Барыйк урманга, әйдә, җанашым.

Яшел үләннәр, агадыр сулар,
Сайрыйлар кошлар моңлы, җанашым.

Әйдә суларга, йөрик көймәдә,
Күңел ачарбыз, утыр, җанашым.

Әүвәлдә күрдем нурлы йөзеңне,
Ишеттем сүзеңне, моңлы җанашым.

Күзләрең кара, мәхәббәт сала
Дәртле күңелгә, матур, җанашым.

Кашларың кыйгач, йөзләрең кояш,
Күңлем яктыра, күрсәм, җанашым.

Йөзегең алмаз, кими ярамас,
Йөзек тик ярат мине, җанашым.

Сандугач сайрар яшел урманда,
Без дә сайрашыйк, әйдә, җанашым.

(ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 227).

Әлеге теманы дәвам итеп, мисал рәвешендә 1962 елгы экспедиция вакытында Х. Гатина тарафыннан Түбән Новгород өлкәсе, Яңа Мочали авылында Кәбир Шәрәфетдиновтан (1984 елгы) язып алынган «Гөлкәй», шул өлкәнең Пица авылында Садыйк Сабировтан (1896 елгы) язып алынган «Әсмабибкәй, Маһисәрвәр» җырларын китерергә мөмкин.

2010 елгы экспедиция вакытында Камка авылында яшәүче Абдюханова Зөһрә Мортаза кызыннан (1935 елгы) бер генә озын лирик җыр – «Җанихәй» язып алынды.

«Җанихәй – чиста Камка авылы җыры. Аны әүвәл вакытта эти-әниләр кунакка киткәч, кыз балалар шул ызбага җыелып башкарганнар. Элекке вакытта, бик борынгы заманда, кемгәдер күңел саласың, синә кемдер күңел сала, кемгәдер кемдер ошаган, ә бит кемдер ошаса, бигрәк тә кыз кеше, уйлап торасың шул кешене, ул мине күрдеме икән, ул мине ярата микән, дип. Алар шул җыелышып, өстәл артында утырып «Җанихәй» әйткәннәр. Аны бер кыз йырларга тотына да, бармаклары белән йөртә, нинди сүз туры килә, шул тормышка аша дип уйлаганнар, туры килсә, – сөя дигән сүз, значит, ул аны сөя».

Әлеге җырны Зөһрә апа озын көйгә салып башкарды.

**Җанихәй**

Тәрәзә төбемдә, әй, уймагым;
Алтын ука чорнап куймадым.
Уйладым да гына, әй, уйладым
Уйлаган, әй, ярыма булмадым.
Уйлаган ярыма булалмагач,
Төнен уянып егъладым.

Пьяна буеның, әй, яр башы,
Шунда юдым дөге ярмасы.
Теләгән яр гынам миңа булмас,
Үз яры бар – алтын алмасы,
Үз яры бар, әй, алмасы,
Сизелә күңел миңа салмасы.

Сандугач моңая, әй, тугайда,
Мин моңаям нигә бу айда?
Моңаймас та идем мин бу айда,
Җанихаем минем, син кайда?
Җанихаеңне ятлар алса,
Егълаулардан гына ни файда.

Яшьлек һәм мәхәббәт турындагы җырлар төркеменә кергән лирик җыр – «Җаныкаем» җырының бер варианты булып тора.

«Җаныкаем» җырын 1958 елда Камка авылында Сания Сәинова (1933 елгы) һәм Рәшидә Абдюхановалардан (1928 елгы) И. Надиров язып алган булган (ТХИ. Тарихи һәм лирик җырлар. Б. 260).

Экспедицияләрнең моңа кадәр оештырылганнарында да, соңгысында да, кыска җырлар күпләп тупланды. Әлеге төр җырлар үзләренең кыска формалы булулары, гади һәм отып алырга уңай көйгә башкарылулары сәбәпле, һәркемгә якын, таныш. Шунлыктан алар иң популяр, халык арасында киң таралган һәм яратылып башкарыла торган җырлардан санала. Авыл урамында да, аулак өйдә дә, клубта да, эш вакытында да, мәҗлестә дә еш яңгырый торган бу җырлар ярдәмендә тиз үтүчән кайгышатлыкны да, тирән кичереш һәм фәлсәфи уйлануларны да җиткерергә мөмкин. Кыска җыр, гадәттә, авыл, урам көйләренә, кыска көйгә, уен коралларында уйнап та, уен коралларыннан тыш та башкарыла. Әлеге төбәктә аны «картуш көе» дип атыйлар. Петрякс авылында яшәүче Сабиров Сәяр Вафа улы аңлатуынча, «әлеге җырлар картуф, картуш көе, дип атала, чөнки ул бәрәңге кебек таралган, аны бөтен кеше җырлап йөри».

2010 елда без 450 гә якын дүртьюллык кыска җыр һәм җыр вариантлары язып алдык. Аларның бер өлешен, тематикаларга бүлеп, сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. «Татар халык иҗаты. Кыска җырлар» китабына нигезләнеп, әлеге кыска җырларны халыкның тормыш-көнкүреш турындагы уйлануларын, иҗтимагый һәм шәхси моң-зарын, өмет-ышанычларын гәүдәләндергән җырлар һ.б. төркемнәргә бүлдек[1].

Кыска көйгә йырлыйм әле,
Озын көйгә сузалмыйм.
Аякларым тышаулана,
Турыгыздан узалмыйм.

*Петрякс авылында Зәйнуллина Кәримә*
*Сәяр кызыннан (1950 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

[1] Татар халык иҗаты: Кыска җырлар (дүртьюллыклар) / төз. И.Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр. 1976. – Б. 15.

Алга таба китапның исеме кыскартылып (ТХИ. Кыска җырлар), файдаланылган бите күрсәтелеп, текст эчендә биреләчәк.

Агыйделгә төшеп китте
Таянган таш кынаем,
Кайгыларга төшеп чумды
Бәхетсез башкынаем.

Агыйделнең буйларында
Басып су алган ташым,
Таштан авыр кайгыларны
Күтәрә ялгыз башым.

Агыйделдә керләр юдым,
Юдым, чәчрәтмәдем,
Агыйдел ярыннан биек
Күргән хәсрәтләрем.

Агыйделдә ат эчерттем
Атларым сусаганга,
Күзләремнең нуры бетте
Күңелем бушаганга.

Агыйделдән үтә-үтә
Аягына су үтә.
Балалардан хатлар көтеп,
Йөзем саргаеп бетә.

Агыйдел исемнәре бар
Пичәтләгән сабында.
Сабыр итүләре авыр
Исәпләгән чагында.

Агыйделнең суы таша,
Күпере китәр инде.
Бирмә кайгы башларыма,
Биргәне җитәр инде.

Агыйделнең күпере,
Челтер-челтер итүе,
Сызылып киткән таңнар сыман
Яшь гомернең үтүе.

Агыйделдәге салларның
Ак каен ишкәкләре,
Иртә саргайган гөлләрнең
Мин булам иптәшләре.

Агыйделгә төшим микән,
Төшеп су алыйм микән?
Су алганчы су төбенә
Төшеп югалыйм микән?

Агыйделләргә төшмәдем,
Ятып суын эчмәдем.
Кеше балалары кебек
Рәхәт күреп үсмәдем.

*Краснай авылында Җаппарова Әнисә*
*Усман кызыннан (1935 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Сандугачым, сайрамыйсың,
Талды мәллә телләрең?
Синең дәме, минем кебек
Кайгылы үтә көннәрең?

*Краснай авылында Хәбибуллина Зәйнәп*
*Шәрипҗан кызы (1930 елгы) һәм*
*Сабитова Сания Исхак кызыннан (1932 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина белән И. Шәрипов язып алды. 2010*

Утырдым көймәнең, әй, түренә,
Карадым суларның төбенә,
Су төпләрендә һич кара юк,
Ходай язмышына чара юк.

Утыр, анай кәбәм,
Кил яныма, әй, күлим күэңә
Синең күләреңне күли-күли
Керермен караңгы гүремә.

*Бозлау авылында Хәйруллина Айшуктан*
*Л.Мөхәмәтшина һәм И.Шәрипов язып алды. 2010*

Сандугачлар сайрый икән
Өй алдында, шомыртта;
Төрле көннәр була икән
Көн иткәндә тормышта.

Сандугачым очып йөри,
Канатлары ак икән;
Эх, дусларым, бу дөньяда
Тыныч адәм бар микән.

Сандугачым һәр көн иртән
Моңлы көйләргә сайрый,
Минем ялгыз яшәгәнне
Ул соң кайлардан аңлый.

Сандугачым, китмә очып,
Мине ялгыз калдырып,
Көтмәгәндә ялгыз калдым,
Ходай бирсен саулыгым.

Ялгызлыкка сокланмагыз,
Ялгызның күңеле боек,
Юлдашыгыз белән яшәгез,
Тормышның ямен тоеп.

Йөрәккәем, янасың,
Янасың да көясең.
Авырлыкны бик күп күрдең,
Йөрәк, ничек түзәсең.

Йөрәккәем, чыда инде,
Авырлыкларга батма.
Дөньяда торасым килә,
Гүмеремне кыскартма.

Йөрәккәем, әле безгә
Яшәргә дә йөрергә.
Салкын караңгы кабергә
Өлгерербез керергә.

*Ыргу авылында Билялова Хәдичә*
*Сәйфетдин кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Егетләрне солдат хезмәтенә озаткан вакытта башкарыла торган җырларда туган җирне, якыннарны калдырып китәсе килмәү, калдырып киткәнгә үкенү кебек хисләр чагыла. Әлеге җырларның күпчелеге армиягә китәсе егетләр тарафыннан җырлана.

«Солдатка озатканда, авыл яшьләре, егетләр җыелып шушы никрутка китәсе малайны, авыл буйлап, гармуннар тартып, озатулар бар иде. Гармун тартканда шундыйрак сүзләр әйтәләр иде, авыл көенә җырлыйлар иде», – дип искә алды Яхъя абый:

Без авылдан киткән чакта
Күтәрелде тузаннар.
Алла кушса, без кайтырбыз,
Кайгырмагыз, туганнар.

*Сафаҗай авылында Сәлимов*
*Яхъя Әббәс улыннан (1924 елгы)*
*Л.Мөхәмәтшина һәм И.Шәрипов язып алды. 2010.*

Армиядә яхшы булса,
Безне алмаслар иде,
Әти-әни һәм туганнар
Елап калмаслар иде.

Сау бул, Сабачай каласы,
Акъяр тауларың белән.
Сау бул, әнкәй, сау бул, әткәй,
Калган балаларың белән.

Армиягә китәм, дисең,
Казанга туктарсыңмы?
Бергә утырган минутларны
Исеңдә тотарсыңмы?

*Сафаҗай авылында Сабитова*
*Зифа Рәшит кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Армиягә алырлар да
Буырмын билләремне.
Өч елга, дип алсалар да,
Тутырмам көннәремне.

Армиягә барыр булсаң,
Нечкәләнер билләрең.
Минуты да авыр узгач,
Ничек үтәр көннәрең.

Армиягә алдылар,
Билгә каеш салдылар.
Өйгә кайтыр вакытында
Кайгыларга салдылар.

Армиягә мин бармадым,
Дусларым гына барды.
Дусларымның, сау бул, дигән,
Сүзләре генә калды.

*Сафаҗай авылында Зөфәр*
*Мөхәммәт улы (1942 елгы) һәм*
*Мәгъсүмә Мәлик кызы (1948 елгы) Мөхәммәтовлардан*
*Л. Мөхәмәтшина белән И. Шәрипов язып алды. 2010*

Шулай ук егетләрне армиягә озаткан вакытта, китәсе малайларның күңелен күтәрү өчен, бераз шаян җырлар да җырлаганнар.

Телефоннар булса иде,
Звонить итәр идем.
Мөмкин булса бер елыңны
Служить итәр идем.

*Ыргу авылында*
*Юнисова Фәридәдән (1928 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Армиягә алдылар,
Билгә каеш салдылар.
Дальний Востокка озатып
Челбәйсез[1] калдырдылар.

Аклы ситса күлмәгемне
Кисәм, каралыр микән?
Әкрен искән җилгә хәбәр әйтсәм,
Алып баралыр микән?

*Яндавишча авылында Хәсәнов Ринат*
*Абдуләхәт улыннан (1968 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Армиягә егетләр һәрвакытта да үз теләкләре белән китмәгәннәр. Бу очракта армиягә китәсе егет ата-анасына да үпкә белдереп җырлар җырлый торган булган:

Әнкәй, мине ник таптың,
Ник асрадың, ник бактың?
Унсигез яшь тулган көнне
Армиягә озаттың.

*Сафаҗай авылында Исхакова Әлфия*
*Харис кызыннан (1959 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

2010 елда язып алынган җырларның бер өлешен хатын-кыз язмышына багышланган җырлар алып тора. Аларның да

[1] Челбәй – сөйгән яр, яраткан кеше.

кайберләре туган йорттан, туган илдән, әти-әниләрдән аерылу, сагыну-сагыш хисләре белән сугарылган. Күпчелек җырларда хатын-кызның бәхетсез язмышы чагылыш таба.

Алдыр урам буйлары,
Гөлдер урам буйлары;
Ал булса да, гөл булса да
Кала урам буйлары.

*Сафаҗай авылында Исхакова Әлфия*
*Харис кызыннан (1959 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Сагына да белми идем,
Саргая да башладым.
Башларымның моңлы икәнен
Хәзер аңлый башладым.

*Сафаҗай авылында Вахитова Сара*
*Нәҗип кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Ике савыт гөл утырттым
Бәхетемне сынарга.
Сынды гөлем, юк бәхетем,
Агыйм микән суларга.

*Яндавишча авылында Камалова*
*Әсмабикә Исхак кызы (1930 елгы) һәм*
*Камалова Наилә Әхмәт кызыннан (1979 елгы)*
*А. Садыйкова һәм И. Закирова язып алды. 2010*

Агыйдел буен буйладым,
Буйладым тугайдыр дип;
Күп уйладым, инде уйламыйм,
Язмышым шулайдыр, дип.

Агыйделнең аръягында
Күлләр диңгез түгел ул;
Бере моңлы, бере моңсыз,
Дөнья тигез түгел ул.

*Краснай авылында Җаппарова Әнисә*
*Усман кызыннан (1935 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Язып алынган җырлар арасында аерым бер төркемне дуслык, туганлык турындагы җырлар алып тора. Әлеге җырлар, гадәттә, кунак табынында, якыннарны бергә җыйган аш-су мәҗлесендә яисә туй вакытларында башкарылганнар.

Мәҗлесләрдә кара-каршы җырлашып утырган вакытта күп кенә кыска җырлар җырланган һәм бер җыр икенче тапкыр кабатланса, аны сүз белән әйтмәгәннәр, ә кисәтүле җыр җырлаганнар:

Петрякс алма кели
Бүленгән кырларны;
Икенче кат йырламыйлар
Бер йырлаган йырларны.

*Сафаҗай авылында Вахитова Сара*
*Нәҗип кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Дуслык турындагы җырларда дуслар белән яшәүнең җиңелрәк, күңеллерәк булуы, ә аерым торуның сагынулы, сагышлы икәнлеге искәртелә.

Сайрый былбыл, сайрый былбыл,
Сайрый былбыл гөлләрдә;
Дуслар, бергә булсак иде
Без алдагы көннәрдә.

Эх, дусларым, беләсезме,
Җир шары бит түгәрәк,
Шул түгәрәк җир шарында,
Йөрсәк иде бергәләп.

*Краснай авылында Хәбибуллина Зәйнәп*
*Шәрипҗан кызы (1930 елгы) белән*
*Сабитова Сания Исхак кызыннан (1932 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Тау менәргә, тау төшәргә,
Таймас дага булса иде.
Якын күргән дус-ишләрдән
Аерылмаска булса иде.

*Пашат авылында*
*Бәдретдинов Таһирдан (1932 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Эх, дусларым, сезнең кебек
Булыр микән тагын да.
Сезгә охшаган кошлар сайрый
Алмагач ботагында.

*Ыргу авылында Билялова Хадичә*
*Сәйфетдин кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Дусларым күп, дусларым күп,
Бер дә күңелем теләми,
Сез дусларым арасыннан
Аерылгым киләми.

*Яндавишча авылында Хәсәнов*
*Ринат Абдуләхәт улыннан (1968 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Гөлләремә су сибәләр
Наил белән Наилә.
Сез дусларны охшатамын
Гөлчәчәк бәйләменә.

*Сафаҗай авылында Аймалетдинова*
*Фаилә Яхъя кызыннан (1951 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кыска җырлар арасында аерым зур бер урынны туй җырлары алып тора. Аларны туй мәҗлесе вакытында, өстәл артында кара-каршы җырлап та, кумәкләшеп тә башкарганнар, яшьләргә теләкне җыр аша белдергәннәр:

Самоварны тиз кайната
Чыршы, нарат күмере.
Кияү белән кызыбызның
Озын булсын гомере.

Бигрәк матур йөрешегез,
Бик пар килгән буегыз.
Кайлардан соң табыштыгыз,
Тату гына торыгыз.

Әй, тавыгым кыткылдыйдыр
Йомыркасын салырга.
Әй, кодагый, аеплама,
Килдек кызыңны алырга.

Мәскәүдән килгән поездның
Саныйм кондукторларын.
Кияү белән кызыбызның
Сорыйм татулыкларын.

Вакыт җитте, балдак кидең
Бармак буыннарыңа.
Рәхәт яшә, тыныч яшә
Килгән урыннарыңда.

Икегез дә ак күлмәктән,
Тәннәрегез күренә.
Бездән сезгә шушы теләк:
Гомер итегез бергә!

Алтын балдак, бриллиант каш
Бармак буыннарыңда.
Туганкаем, рәхәт яшә
Барган урыннарыңда.

Стенада калын көзге
Нурлы күрсәтә йөзне.
Икегез дә пар килгәнсез,
Кем кавыштырды сезне.

Биек тауга менгән чакта
Авыр килә тезләргә.
Киләчәктә тыныч тормыш
Теләп калам сезләргә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Мирхәйдәр.
Кавыштыгыз, аерылмагыз
Кыямәт көнгә кадәр.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Николай.
Теге елга шул вакытта
Сездә булсын бер малай.

*Яндавишча авылында Камалова*
*Әсмабикә Исхак кызы (1930 елгы) белән*
*Камалова Наилә Әхмәт кызыннан (1979 елгы)*
*А. Садыйкова һәм И. Закирова язып алды. 2010*

Гомергә бергә булырга
Алтын балдаклар кидегез.
Бер-берегезнең холкын белеп,
Бергә гомер итегез!

Кияү белән яшь киленне
Сугалар карточкага.
Нинди теләкләр телим икән
Шул матур парочкага.

*Ыргу авылында Мулюкова*
*Рабия Җамал кызыннан (1937 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Тәрәз төбендә гөлләрем,
Санадым, сигез генә.
Яфрак ярып, чәчәк атып
Яшәгез тигез генә.

Матур күлмәкләрегез,
Күренә беләкләрегез.
Тыныч тормыш, саф мәхәббәт
Безнең теләкләребез.

Котлы булсын туегыз!
Күпкә үрнәк булыгыз!
Озын булсын, тыныч булсын
Сезнең йөргән юлыгыз!

*Сафаҗай авылында Сабитова*
*Зифа Рәшит кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Яңгыр ява, тамчы тама,
Көтәм чиләк тулганын.
Яңа тормышка күчәсең,
Бәхетле бул, туганым.

*Сафаҗай авылында Исхакова*
*Әлфия Харис кызыннан (1959 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Лимон сары, лимон сары,
Салабыз чашкаларга.
Бер-берегезнең мәхәббәтен
Бирмәгез башкаларга.

Син дә утырдың түндәккә,
Мин дә утырдым түндәккә.
Нинди соң йыр йырлыйм икән
Син матур күбәләккә.

Әлеге җырларны туй вакытында җырлаганнар. Аннан соң туй беткәндә, сый-хөрмәт өчен рәхмәтне дә шулай ук җыр ярдәмендә җиткергәннәр.

Рәхмәт, тутай, ашыңа,
Саулык бирсен башыңа,
Йомырка кебек тәгәрәп
Дәүләт килсен каршыңа.

*Сафаҗай авылында Зөфәр*
*Мөхәммәт улы (1942 елгы) һәм*
*Мәгъсүмә Мәлик кызы (1948 елгы) Мөхәммәтовлардан*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кыска җырлар арасында кеше гомере, яшәү кадере турындагы җырлар да бар. Аларның асылында яшәү һәм үлем, яшьлек һәм картлык, гомернең мәгънәсе турында шигъри уйланулар ята.

Өз гөлләрне чәчәк аткан чакта,
Узар китәр алтын көннәрең;
Өзми калсаң, үкенерсең бер көн,
Чәчәкләре шиңәр гөлләрнең.

*Яндавишча авылында Камалова*
*Әсмабикә Исхак кызы (1930 елгы) белән*
*Камалова Наилә Әхмәт кызыннан (1979 елгы)*
*А. Садыйкова һәм И. Закирова язып алды. 2010*

Тау башында зәңгәр чәчәк,
Кемнәр менеп чәчте икән.
Яшь гомерне, чәчәк, диләр,
Чыннан да чәчәк икән.

*Сафаҗай авылында Вилданова*
*Саимә Абдулла кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Быел җәен печән чаптым,
Кара куйларга гына.
Безнең болай утырулар
Калыр уйларга гына.

*Сафаҗай авылында Аймалетдинова*
*Фаилә Яхъя кызыннан (1951 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Ике иде кульяулыгым,
Берсе суларга акты.
Икебезне ике якка
Тормыш дулкыны какты.

Каен ул, каен ул,
Каен урман саен ул,
Кайгы бездә генә түгел,
Кайгы кеше саен ул.

*Сафаҗай авылында Вахитова*
*Сара Нәҗип кызыннан (1948 елгы)*
*Л.Мөхәмәтшина һәм И.Шәрипов язып алды. 2010*

Йырлыйк, дуслар, йырлыйк, дуслар,
Йыр сатылмый акчага.
Яшь вакытлар кире килми,
Канлы яшьләр акса да.

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар, нәк болай,
Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай.

Яшь вакытта күкрәгемә
Чәчкәләр кадамадым.
Чөнки яшьлегемнән матур
Чәчәкләр табалмадым.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Чәчем сибелеп бетте инде шул.
Чәчем сибелеп, яши-яши
Яшь гүмерем үтте инде.

*Краснай авылында Хәбибуллина Зәйнәп*
*Шәрипҗан кызы (1930 елгы) белән*
*Сабитова Сания Исхак кызыннан (1932 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Тормыш юлларын үткәндә
Таймаска булса иде,
Туганнардан, туган илдән
Аерылмаска булса иде.

*Чүмбәли авылында Абдрахманова*
*Сания Абдрахман кызыннан (1930 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Яшәү кадере турындагы җырларның кайберләрендә яшь гомернең бик тиз үтүе, аның кадерен белергә кирәклеге искәртелә.

Яшь вакытта яшьнәргә дә,
Күкрәргә дә көч җитә.
Ләкин кадерен белү кирәк,
Яшь вакытлар тиз үтә.

Алай да үтә гүмерләр дә,
Болай да үтә гүмерләр.
Сандугачлар сайраса да
Күтәрелми күңелләр.

*Камка авылында Абдюханова Зөһрә*
*Мортаза кызыннан (1935 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Сандугачым һәркөн иртән
Моңлы көйләргә сайрый.
Минем ялгыз яшәгәнне
Ул соң кайлардан аңлый.

Ыргу авылы урамын
Кабат-кабат узалмыйм,
Яшьлегемне искә төшерсәм,
Егъламыйча түзалмыйм.

*Камка авылында Билялова*
*Хәдичә Сәйфетдин кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Аклы ситса күлмәгемнең
Итәге кара атлас;
Киткән гомер кире кайтмас,
Кайтса да чәчәк атмас.

*Ыргу авылында Усманова Равилә*
*Усман кызыннан (1929 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кыска җырлар арасында шактый урынны мәхәббәт турындагы җырлар алып тора. Мәхәббәт җырларында күптөрле хискичерешләр чагылыш тапса да, әйтергә теләгән хис-фикер дүрт юлга сыеп бетә. Биредә төрле чагыштырулар аша лирик геройның тышкы матурлыгына дан җырлана, гашыйкларның рухи халәте бик оста итеп сурәтләнә.

Безнең авыл түбән таба,
Су җыела уена;
Кисәң, киемнәр килешә,
Синең зифа буеңа.

Кашлары, күзләре
Каләм каралары бит;
Нәсел-ырулары белән
Былбыл балалары бит.

Әйдә, үзеңне алып барыйм
Чемодан сырлатырга;
Нигә мондый матур булдың
Йөрәкне сызлатырга.

Мәхәббәт бит иске нәрсә,
Белегез кадерләрен.
Тормыш мәшәкате белән
Өзмәгез садәпләрен.

*Сафаҗай авылында Сабитова Зифа*
*Рәшит кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кашың кара, күзең күк,
Сиңа сөйләр сүзем күп.
Сөйләр идем сүземне,
Күреп булмый үзеңне.

Йөрәгемнең януына
Кирәк күгәрчен ите.
Күгәрчен ите дә басмый,
Янып чыга бер чите.

Кайбер җырларда сөйгән ярның матурлыгын тасвирлау өчен төрле чагыштырулар кулланыла.

Гөлләремнең арасында
Яратамын кынаны.
Яратмас идем кынаны –
Охшатамын сиңа аны.

Сөйгән ярлар белән кавыша алмау мәхәббәт җырларында зур фаҗига буларак сурәтләнә.

Гашыйк тоту – бик авыр,
Янадыр йөрәк-бавыр.
Гашыйк тотып, кавышмасак,
Улсы нидән дә авыр.

*Сафаҗай авылында Исхакова Әлфия*
*Харис кызыннан (1959 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Биек тауның башларында
Ике яхшы нәрсә бар:
Беренчесе – саф мәхәббәт,
Икенчесе – сөйгән яр.

Батист яулыклар бәйлимен,
Батист яулык кигәнгә.
Ерак юлны якын итеп,
Килдем сине сөйгәнгә.

Җырларда «үз сөйгәнеңне ятка бирмә» һәм «сөймәгән кешеңә барма» дигән сүзләр дә еш кабатлана.

Атка атлансаң, сикереп атлан,
Йүгәнлегең селкенсен.
Сүгәнеңне ятка бирмә,
Күргәндә үкенерсең.

Сүгәнеңә әйттереп бар,
Сүмәгәнгә баргыйнча.
Аның гәүдәсенә карап,
Яшь йөрәгең янгыйнча.

*Сафаҗай авылында Вахитова*
*Сара Нәҗип кызынан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Бер дә исләремнән китми
Өзелеп сөйгәннәрем.
Төннәр буе йоклый алмыйм,
Көтәмен килгәннәрен.

*Пашат авылында Бәдретдинов Таһир (1932 елгы)*
*белән Бәдретдинова Фрунзалина Билял кызы (1932 елгы)*
*һәм Хәлиуллина Гүзәл Билял кызыннан (1938 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина белән И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кайбер мәхәббәт җырларында гашыйкларга «сөйгән яры белән кавышсын иде» дигән изге теләк тә әйтелә.

Алма бакчасына кереп,
Өзеп алма өләшәм.
Кавыш сөйгән ярың белән,
Мин дә теләк теләшәм.

*Камка авылында Абдюханова Зөһрә*
*Мортаза кызыннан (1935 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, белмисең.
Бик өзелеп сөйгәнгәме,
Исемә дә кермисең.

*Ыргу авылында Усманова Равилә*
*Усман кызыннан (1929 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Гармуннары, гармуннары,
Ай-һай, барабаннары.
Гомер үткәрергә яхшы
Ярның яраганнары.

*Яндавишча авылында Хәсәнов Ринат*
*Абдуләхәт улыннан (1968 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Ай кояшка, кояш айга
Нурларын бирешәләр.
Алар да бездән бәхетле,
Көнгә бер күрешәләр.

Роза гөле сына, диләр,
Сынмый да, бөгелми дә.
Сиңа булган мәхәббәтем,
Сүнми дә, сүрелми дә.

Кар бит ак бит, кар бит ак бит,
Карны ашамыйлар бит.
Яр бит җан бит, җан бит җәл бит,
Ярны ташламыйлар бит.

*Яндавишча авылында Камалова Әсмабикә*
*Исхак кызы (1930 елгы) белән*
*Камалова Наилә Әхмәт кызыннан (1979 елгы)*
*А. Садыйкова һәм И. Закирова язып алды. 2010*

Мәхәббәтнең шатлыклы да, газаплы да кичерешләр, аерылышулар, кавышулар белән бәйле булуын күрсәтү өчен җырларда Таһир-Зөһрә образлары мисалга алына.

Өстәлләрдә ике алма,
Берсен ал, берсен алма;
Таһир – Зөһрә мәхәббәтен
Сезгә дә бирсен Алла.

Чәчтем бодай, бирсен Ходай,
Бер бодайга мең бодай;
Таһир – Зөһрә мәхәббәтен
Сезгә дә бирсен Ходай.

*Сафаҗай авылында Сабитова*
*Зифа Рәшит кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кыска җырлар арасында шаян, көлкеле җырлар шактый. Аларга елмаю хисе уята торган көлкеле күренешләр, кешеләрдәге кимчелекләрне, начар гадәтләрне тәнкыйть итү хас.

Бандит, диләр, хулиган, диләр,
Амбарлар баскан, диләр.
Заббаровның[1] төрмәсеннән
Кыз урлап качкан, диләр.

Уразовка кечкенә булса да,
Сигез генә милинчә.
Заббар кергән конюшнига,
Флягадан сөт эчә.

*Сафаҗай авылында Вахитова Сара*
*Нәҗип кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Кайвакыт шаян җырларга җиткерергә теләгән фикерне турыдан-туры түгел, ә читләтеп әйтү вазифасы йөкләнә.

Көчегем бәйләнмәгән,
Үзем өйләнмәгән;
Алты авылда җиде хатын,
Әле дә үзем өйләнмәгән.

*Сафаҗай авылында Аймалетдинова*
*Фаилә Яхъя кызыннан (1951 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010.*

[1] Заббаров – район эчке эшләр бүлегендә эшләүче, тәртип сакчысы.

Уразовка, Уразовка,
Уразовка кайдарак?
Хәзер инде мин занято,
Ник әйтмәдең баштарак.

*Сафаҗай авылында Вахитова Сара*
*Нәҗип кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Шаян җырларга билгеле бер ситуацияне, комик сурәтне кыска һәм үтемле итеп тасвирлап бирү хас. Юмор тудыру өчен, күптөрле стилистик чаралар: ирония, киная, рус теленнән кергән сүзләрне катыштырып җибәрү һәм башка комик алымнар файдаланыла.

Охотниклар ак куянны
Тотсалар да атмыйлар,
Сезнең кебек пар килгәнне
Магазинда сатмыйлар.

*Сафаҗай авылында Сабитова Зифа*
*Рәшит кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Мәскәүский Маруськалар
Кычкыралар «уй» да «уй»;
Минем челбәй бигрәк матур,
Аның чәче кудрявой.

*Петрякс авылында Зәйнуллина*
*Кәримә Сәяр кызыннан (1950 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Ай яктысы бигрәк якты,
Челбәйләргә йөрергә.
Нинди хәйлә табыйм икән
Өйләренә керергә?

Айрылышу, айрылышу,
Айрылышу – ерунда.
Син дә уйлама, мин дә уйламыйм
Айрылышу турында.

Әнә килә машина,
Ник юләмәс, күзләсәң?
Берне түгел, биш-алтыны
Яр табармын, эзләсәм.

Түбән Новгород өлкәсендә үзенчәлекле бер шаян җыр очрады. Җырны башкаручы – Исхакова Әлфия – аңа түбәндәге аңлатманы бирде: «...Сугыш вакытында халыкның бердәнбер ашы бәрәңге булган. Аны кырганнар, төйгәннәр, бөтен итеп пешергәннәр. Ул арыган имеш, туйган...»:

Картош барган сельсоветка
Справка сорарга.
Барыбер моннан китәмен:
Невозможно чыдарга.

*Сафаҗай авылында Исхакова Әлфия*
*Харис кызыннан (1959 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар арыктан;
Кызын озатырга баргач,
Куркып качкан сарыктан.

Бездә хәзер шундый мода,
Кызлар кия фуражка.
Иреннәренә сылыйлар
Кило ярым краска.

Биек тауның башларында,
ДТ буксовать итә;
Безнең авыл егетләре
Кыз сортировать итә.

Исемнәре, исемнәре,
Исемнәре Габдулла;
Ярны сөйсәң – икене сөй,
Берсе кандидат була.

Кызлар карый, кызлар карый,
Кызлар карый ярыктан.
Карамас иде ярыктан,
Бер күрергә зарыккан.

Стенага шип суктым,
Кастюмымны эләргә.
Авызыма конфет каптым
Челбәемне үбәргә.

Минем иркәм армиядә,
Атлар эчерәм, дигән.
Төпсез чиләк, сапсыз көрәк
Минем кулымда, дигән.

Синең иркәң армиядә,
Ташкында атам, дигән.
Алучы булса, бара тор,
Өйләнеп кайтам, дигән.

Кыйблакайдан болыт килә,
Туктат тракторыңны.
Эч серемне сөйләр идем
Белмим характерыңны.

*Зур Рбишча авылында*
*Ситдыйкова Факия Сәяр кызынан (1958 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Алма битем, ни хәл итим,
Кемгә калдырып китим.
Кемгә калдырсам да жалко,
Калдырмый ни хәл итим.

*Камка авылында Абдюханова Зөһрә*
*Мортаза кызыннан (1935 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды*

Солдат ашы, балык башы,
Капкан саен кикертә.
Ике потлы мылтык асып,
Ярдан ярга сикертә.

*Яндавишча авылында*
*Хәсәнов Ринат Абдуләхәт улыннан (1968 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды*

Тапочкасы, тапочкасы,
Тапочкасы сызыклы.
Кеше ярларыннан алып,
Ярлар сөю кызыклы.

Суда йөзә балык кына,
Күренә сырты гына.
Әле инде кызларның бит
Третий сорты гына.

Әйдә, маем, алып барыйм,
Вечерга киендереп.
Ташлыйм, диеп сүз чыгарма
Дошманны сөендереп.

Өстемдәге костюмымның
Ялтырый якалары.
Неужели кабул булыр
Дошманның догалары.

*Яндавишча авылында Камалова Әсмабикә*
*Исхак кызы (1930 елгы) һәм*
*Камалова Наилә Әхмәт кызыннан (1979 елгы)*
*А. Садыйкова һәм И. Закирова язып алды. 2010.*

Югарыда мисал итеп күрсәтелгән җырларның барысын да, Түбән Новгород өлкәсенә генә хас дип әйтеп булмый, аларның күпчелеге татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә җырлана, анда

да яратып башкарыла. Чөнки алар халыкның тормыш-көнкүреше, төрле бәйрәмнәр, йолалар, гореф-гадәтләр, уеннар, күңел ачулар белән тыгыз бәйләнгән. Кайбер җырларда Түбән Новгород өлкәсендәге авыл исемнәре, топонимик атамалар искә алына. Әлеге күренеш бу җырларның шул өлкәдә генә яшәвен күрсәтә.

Әллә каян күренеп тора
Сафаҗай калалары.
Мәңге рәхәттә яшәгез,
Сандугач балалары.

*Сафаҗай авылында Сабитова*
*Зифа Рәшит кызыннан (1952 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Мучалиның өйләре –
Бар да салам түбәле.
Мучалида кызлар бетсә,
Сабачайда күп әле.

*Сафаҗай авылында Исхакова*
*Әлфия Харис кызыннан (1959 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Уразовка базарында
Бер кыз белән таныштым,
Танышуым шушы булды –
Тапочкасын сатыштым.

*Сафаҗай авылында Вахитова*
*Сара Нәҗип кызынан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Югары очтан түбәнгә ага
Петрякс елгасы.
Уйнап-көлеп күңел ачыйк,
Шауласын бар дөньясы.

Петрякс илебез,
Очыбызда күлебез.
Язгы Сабантуйларында
Кунак булып килегез.

*Петрякс авылында Сабирова*
*Кадрия Котдус кызыннан (1924 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Әлеге җырга «бу көй бары Петрякста гына, ул аның үз авыл көе, халык аны авыл урамында җырлап йөри иде, элек яшьләр дә җырлап йөриләр иде», – дип искәрмә бирде Сабирова Кадрия Котдус кызы.

Рбишчаның өйләре,
Бар да калай түбәле.
Рбишчада кызлар бетсә,
Мучалида бар әле.

Без Рбишча, Рбишча,
Без Рбишча яшьләре.
Моңлы сайраган кошларның
Булырбыз иптәшләре.

Әллә каян күренеп тора,
Мәдәнә калалары.
Кая болай таныштыгыз,
Сандугач балалары?

*Зур Рбишча авылында*
*Ситдыйкова Факия Сәяр кызыннан (1958 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Ыргу мәчетенең ае,
Ерактан балкып тора.
Ыргуның урман-кырлары
Үзенә тартып тора.

Ыргуның бит
Һавасы да сафландыра.
Кай җирләрдә яшәсәк тә,
Туган ил сагындыра.

Матур чәчәкләр үсәдер,
Ыргу болыннарында.
Бала чагым гөрләп үтте
Авылым урамында.

Беркайчан да үкенмимен
Ыргуда туып-үскәнгә.
Карурман, чишмә янына
Килегез ял итәргә.

Ыргу авылы урамын
Кабат-кабат узалмыйм.
Яшьлегемне искә төшерсәм,
Егъламыйча түзалмыйм.

Карурманның аланында
Чишмәсе агып тора.
Карурманның матурлыгы,
Үзенә тартып тора.

Матур җәйләр җиту белән
Ял итәргә кайтасыз.
Йөрәкләргә шифа була,
Ыргу чишмәсе суын эчсәгез.

Ыргу дигән авылым бит
Бер авылга тиң түгел.
Асфальт юлы, газ кертелгән,
Шәһәрдән бит ким түгел.

*Ыргу авылында Билялова Хәдичә*
*Сәйфетдин кызыннан (1948 елгы)*
*Л. Мөхәмәтшина һәм И. Шәрипов язып алды. 2010*

Җырларны башкаручы кешеләргә, килгәндә алар арасында төрле буын вәкилләрен очратырга мөмкин. Бүгенге көндә халык авыз иҗаты әсәрләре, аерым очракларны исәпкә алмаганда, 45–50 яшьтән өлкәнрәк кешеләр хәтерендә яхшырак сакланган.

Түбән Новгород өлкәсендә җырга-моңга бай халык яши. 2008 елда Петрякс авылыннан Ләйлә Алимова-Альмушева «Нижгар такмаклары» дигән китап чыгарган. Әлеге китапта аның төрле елларда җыйган, иҗат иткән такмаклары (кыска көйләр), шигырьләре тупланган.

Түбән Новгород өлкәсеннән чыккан мәшһүр җырчылар да бар. Алар – Чүмбәли авылыннан Хәйдәр Бигичев, Актук авылыннан – Рәшит Ваһапов. Туып-үскән авылларында халык аларны яратып искә ала, биредә җырчыларның тормыш юлын, иҗатын сурәтләгән документлар, фоторәсемнәр сакланган музей да эшли. Актук авылында туып-үскән Рәшит Ваһаповның җырчы булып китүе бик табигый, чөнки монда талантлы халык яши. Шушы ук авылдан Тәнзилә апа үзе башкарган тарихи җырлардан диск та чыгарган.

Камка авылында яшәүче Зөһрә Абдюханова да үзе җырлар яза, үзе шуларны башкара. 1992 елда ул «Туган як моңнары» дигән ансамбль оештырып җибәргән. Әлеге ансамбль үзенең эшчәнлеген бүгенге көндә дә уңышлы дәвам иттерә. Зөһрә Абдюханова да үзенең җырларыннан торган диск чыгарган. Ул иҗат иткән җырлар туган авылы Камкага, әнисенә, беренче мәхәббәтенә, хатын-кыз язмышына, шулай ук үз язмышына багышланган.

«Кайбер җырларны мин үз язмышыма багышлап язам, кешеләр моны тыңлаганда елыйлар да», – дип искә алды Зөһрә апа.

**Авылкаем**

*(Камка авылы җыры)*

Ал чәчәкләр, гөл чәчәкләр,
Камка кырында үсә,
Тигез урамнары буйлап,
Җылы йомшак җил исә.

*Кушымта:*
Әй, Камка өйләре,
Чәчәкләре, гөлләре,
Үзе йомшак, үзе назлы
Иртән искән җилләре.

Матурланып шаулап үсә
Пьянаның камышы.
Мәчетләрдән ишетелә
Моңлы азан тавышы.

*Кушымта.*

Дүрт йөз еллар яшәгәннәр,
Әби-бабакайларым.
Киләчәгең озын булсын,
Мең яшә, авылкаем.

*Кушымта.*

**Газиз әнкәем**

Сагынамын газиз әнкәемне,
Күз карашын һәм елмаюын.
Йомшак кулы белән чәчләремнән сыйпап
Иртә йокыдан уятуын.

Бәйрәмнәрдә изге теләк теләп,
Чәчләремә үрде тасмасын:
«Зур үс, балакаем, бул ризыклы,
Ходай Тәгалә сине сакласын».

Газиз әнкәем, сагынам сине,
Бәхиллек биреп, гафу ит мине.

Үсеп җиткәч, әнкәйләрнең
Кадерен белеп җитми икән балалар.
Кош баласы сыман бала очып китә,
Ялгыз кала газиз аналар.

Син дә ялгыз калдың, әнекәем,
Калган гомерең ялгыз үтәсең,
Тәрәзәдән карап, күзеңне алмыйча,
Балам кайтыр, диеп көтәсең.

**Бәхетл е бул, кыз бала**

Бала дөньяга килгәч,
Куанадыр әткәсе.
Балам, бәхетле, бул, диеп
Теләк тели әнкәсе.

Яшә рәхәт, күрмә хәсрәт,
Бул бәхетле, бәбкәем.
Изге теләкләр телидер
Сиңа газиз әнкәең.

Бала бәхетсез булса,
Гомере буена елый.
Язмышына чагыштырып,
Моңлы җырларны җырлый.

Йөрәгенә ял буладыр,
Моңлы җыр җырлаганда.
Күзләреннән яшь коела,
Язмышын уйлаганда.

Түбән Новгород өлкәсенә оештырылган экспедиция нәтиҗәләре шуны күрсәтә: башка жанрлар фән-техника казанышлары тарафыннан кысрыкланган заманда, халык җырлары һаман да иң популяр һәм яратып башкарыла торган жанр булып кала бирә. Моны җырларның халык тормышына, көнкүрешенә, аның уйкичерешләренә үтә якын торуы белән аңлатырга мөмкин. Дөрес, бүгенге көндә жанрның тарихи һәм лирик төрендә иҗат итеп, шул җырларны башкаручылар сирәк, әмма биредә кыска җырларның популярлыгы әле дә бик зур. Аларны дәфтәрләргә теркәп саклаучылар, сүзләрен күңелләрендә йөртүчеләр һәм төрле уен коралларында уйнап башкаручылар бихисап. Бу – куанычлы күренеш. Өлкән яшьтәгеләр белән бергә мондый төр иҗатка яшьләр дә битараф түгел. Информантлар арасында төрле буын кешеләренең булуы шуны күрсәтә. Димәк, җыр жанрына мөнәсәбәттә халыкның рухы нык, халкыбыз иҗаты саекмас чишмә булып яшәвен дәвам итә. Бу исә – әлеге төбәктә яшәүче халыкның үз теленә, милли җәүһәрләренә кадер-хөрмәт белән каравына шактый зур дәлил.

## ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

***Институт мирасханәсеннән***

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Түбән Новгород өлкәсенә караган күп кенә фольклор, музыкаль, археографик материаллар саклана. Алар, нигездә, төрле елларда оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында халыктан җыелган. Түбән Новгород өлкәсенең татар авылларына 1958 елның май-июнь айларында фольклор экспедициясе оештырыла. Аны күренекле галим Хәмит Ярми җитәкли. Алар Кызыл Октябрь районының Камка, Актук авылларыннан һәм Спас районының Тукай (Парша) авылыннан шактый гына материаллар җыеп (барлыгы: 252 кыска җыр, 26 сюжетлы җыр, 8 бәет, 2 уен) кайталар.

1962 елның июнь-июль айларында тагын бик зур фәнни экспедиция оештырыла. Алар ике отрядка бүленәләр. Беренче отрядны Илбарис Надиров җитәкли. Алар Кызыл Октябрь, Сергач, Спас районнарында, төгәлрәк әйткәндә, Кучкай Пожары, Андреевка, Бозлау, Ишавыл, Татар Моклокасы авылларында булалар.

Барлыгы 5 әкият, 6 бәет, 30 лирик җыр, 882 кыска җыр, 3 җырлы уен, 10 җырсыз уен, 1 мәкаль-әйтем һәм табышмаклар, 6 йолалар һәм истәлекләр, 7 авыл тарихын язып алу бәхетенә ирешәләр.

Икенче отряд җитәкчесе итеп Халидә Гатинаны билгелиләр. Алар Кызыл Октябрь районының Петрякс, Сафаҗай, Краснай, Иске Мочали, Яңа Мочали, Чүмбәли, Рбишча, Суыксу, Пецә (Пица) авылларында булалар һәм барлыгы 7 әкият, 17 бәет,

64 сюжетлы җыр, 2421 кыска җыр, 107 мәкаль-әйтем, 32 табышмак, 38 уен, 3 мәзәк, 2 истәлек алып кайталар.

Бу зур фәнни экспедиция составында музыка белгечләре дә була. Алар төбәктәге татар халкының музыкаль мирасын җыю максатын куялар. Авылдан авылга йөреп, ягъни Уразавыл, Куй суы, Петрякс, Сафаҗай, Краснай, Чүмбәли, Яндавишча, Мәдәнә, Суыксу, Семеновка, Андреевка, Кучкай Пожары авылларыннан магнитофонга яздырылган 228 музыкаль язма алып кайталар.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә әле тагын төрле кешеләр тарафыннан җибәрелгән фольклор материаллары да саклана. Фольклорчы галимнәр һәрвакыт газеталар, радио аша халыкка мөрәҗәгать итеп, үзләре белгән яисә үзләрендә сакланган халык авыз иҗаты үрнәкләрен Институтка җибәрүләрен үтенәләр. Шул сәбәпле, нигездә, хатлар аркылы илнең төрле почмакларыннан күп кенә материаллар җибәрелә башлый. Алар арасында Сергач районы Суыксу авылыннан җибәрелгән 1 әкият, Кызыл Октябрь районы Зур Рбишча авылыннан 1 сюжетлы җыр, Кызыл Октябрь районы Суыксу авылыннан 97 кыска җыр, 4 бәет язылган 1958 елга караган дәфтәр бар.

Алда әйтелеп узган барлык материаллар да Мирасханәдә бик кадерләп саклана. Чөнки, беренчедән, алар татар халкының кыйммәтле мирасын тәшкил итә, икенчедән, бу материаллар Институт хезмәткәрләре тарафыннан бик күп авырлыклар, тырышлыклар белән, тир түгеп җыелган. Теләгән кеше бу байлыкны безгә килеп тә карый ала.

Китап өчен архив материалларын Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә эшләүче фәнни хезмәткәрләр Айдар Гайнетдинов, Салават Галимов һәм Алсу Хасавнех әзерләде.







1929 елның җәендә 12 яшьлек Абдулкадыйр Дәүләтбаевтан язып алынган мәкаль-әйтемнәр (Кызыл Октябрь районы).
(63 колл.,1 тасв., 4 сакл. бер.)







1958 елгы экспедиция. Горький өлкәсендә Х.Ярми язып алган «Ташкай бәете».
(63 колл., 1 тасв., 3 сакл. бер.)



«Япон сугышы бәете»
Х. Бәдигый варианты
17/XI-58 Х. Я.

Имамеддинов
Гайса
Горький өлкәсе
Кызыл Октябрь
районы
Суыксу авылы
1933 ел





«Япон сугышы бәете». Х. Бәдигый язып алган вариант (45 бит). 17.11.1958.
(1 колл.,1 тасв., 1 сакл. бер.)

СССР Фәннәр Академи[...]
Тел, әдәбият һәм тарих инсти[...]
Горький өлкәсендәге татар авыл[...]
музыкаль мирасны җыючы
экспедициянең 1 отряды тараф[...]
стационардагы өйрә[...]
экспеди[...]

| Өлкә, район, авыл советының исеме | Авылның халкы - кузаллы саны | Авылда кайсы вакытта булынды | № № | Исемлектәге кешеләрнең язып алынды. фамилиясе, исеме. |
|---|---|---|---|---|
| Горький өлкәсе, Кызыл-Октябрь районы, Кочко-Пожарка авылы, Кочко-Пожарка авыл советы, «Авангард» колхозы. | 317 | 7-июнь 12-июнь. | 1. | Юнесов Фәрехма |
| | | | 2. | Ниязбаев Валит |
| | | | 3. | Фатыйхова Рәвилә |
| | | | 4. | Кадырова Афия |
| | | | 5 | Курамшин Сөләйман |
| | | | 6 | Курамшина Фәриха |
| | | | 7 | Зобәерова Фания |
| | | | 8 | Хөсеншин Рафик |
| | | | 9 | Ильясова Сара |
| | | | 10 | Шәмилова Рәхимә |
| | | | 11 | Галяутдинова Халисә |
| | | | 12 | Бәдретдинова Алия |
| | | | 13 | Әхмәдиев Гафар |
| | | | 14 | Хасанова Мәфтуха |
| | | | 15 | Ахсанов Курамша |
| | | | 16 | Абдулкадырова Зәйнәп |
| | | | 17 | Бәдретдинова Нәдирә |
| | | | 18 | Сабирова Рәхия |
| | | | 19 | Габитова Сария |


...1962 ел июнь аенда...

...1 отряд җитәкчесе И. Надиров

отряд члены Т. Галиуллин.

| Туган елы | Белеме | Профессиясе | Язып алынган материаллар: Җыр | Бәет | [illegible] | [illegible] | Кыска җыр | [illegible] | [illegible] | [illegible] | [illegible] | Авыл тарихы | Истәлек |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1886 | урта | укытучы-пенсион. | - | - | - | - | - | - | - | - | 2 | 1 | |
| 1884 | мәдрәсә | пенсион. | - | 1 | - | - | - | - | - | - | - | 1 | |
| 1943 | урта | гаскәри хезмәттә | - | - | 2 | - | - | 2 | 3 | - | - | - | |
| 1944 | урта | колхозчы | - | - | 1 | - | 32 | 1 | 2 | - | - | - | |
| 1920 | югары | укытучы | - | - | 4 | 1 | - | - | - | - | - | - | |
| 1926 | урта | укытучы | - | - | 1 | - | - | - | - | - | - | - | |
| 1945 | 8 кл. | укучы | - | - | - | 1 | 8 | - | - | - | - | - | |
| 1934 | IX | тракторчы | - | - | - | 1 | - | - | - | - | - | - | |
| 1915 | III | колхозчы | - | - | 2 | - | - | - | - | - | - | - | |
| 1906 | III | —"— | - | - | 1 | - | 3 | - | - | - | - | - | |
| 1940 | IX | —"— | - | 1 | - | 2 | - | - | - | - | - | - | |
| 1946 | VIII | укучы | - | - | - | 4 | 24 | - | - | - | - | - | |
| 1902 | высш. | укытучы | - | - | - | 1 | - | - | - | - | - | - | |
| 1901 | н/г | колхозчы | - | - | - | 1 | 4 | - | - | - | - | - | |
| 1888 | н/г | пенсион. | - | - | - | - | - | - | - | - | - | 1 | |
| 1946 | VIII | укучы | - | - | - | - | 20 | - | - | - | - | - | |
| 1945 | VIII | —"— | - | - | - | - | 35 | - | - | - | - | - | |
| 1916 | башл. | колхоз. | - | - | - | 2 | 7 | - | - | - | 1 | - | |
| 1945 | VIII | укучы | - | - | - | - | 10 | - | - | - | - | - | |
| Всего | | | - | 2 | 11 | 13 | 143 | 3 | 5 | - | 2 | 3 | - |

Горький өлкәсендәге татар авылларына оештырылган
фәнни экспедициянең (1962) 1 нче отряды башкарган эш турында хисап.
Экспедициянең җитәкчесе – И. Надиров, отряд әгъзасы – Т. Галиуллин.
(74 колл., 1 тасв., 1 сакл. бер.)

| [Өлкә], район, авыл һәм колхоз исеме | Авылның күрелгән хуҗалык саны. | Авылда кай вакытта булынды. | № | Материал кемнәрдән язып алынды. Фамилиясе, исеме |
|---|---|---|---|---|
| Горький өлкәсе, Сергач районы, Андреевка авылы, «Алга» колхозы. | 420 | 13-21 = июнь | 1 | Бугров Мөхәммәт |
| | | | 2 | Садыков Осман |
| | | | 3 | Соколов Котдус |
| | | | 4 | Хәмидуллин Осман |
| | | | 5 | Сабиров Мостафа |
| | | | 6 | Хәеретдинова Хәдичә |
| | | | 7 | Соколова Сания |
| | | | 8 | Абдуллина Роза |
| | | | 9 | Берендеева Фатыйма |
| | | | 10 | Иштирякова Амия |
| | | | 11 | Бугров Давыт |
| | | | 12 | Соколова Рәшидә |
| | | | 13 | Бәдретдинова Венера |
| | | | 14 | Авилева Фатыйма |
| | | | 15 | Дашкаев Аббас |
| | | | 16 | Хәертов Абдулла |
| | | | 17 | Хәеретдинова Венера |
| | | | 18 | Мухаметов Абдулазиз |
| [Горький] өлкәсе, Спасский районы, Базлово авылы, «Карл Маркс» исемен. колхоз. | 220 | 22-24 = июнь | 1 | Зәйнетдинов Бәдретдин |
| | | | 2 | Җаббаров Әминҗан |
| | | | 3 | Имаева Хамидә |
| | | | 4 | Исхакова Хамидә |
| | | | 5 | Хикмәтова Амидә |
| | | | 6 | Салихҗанова Флёра |
| | | | 7 | Мөхәммәтҗанов Вәфи[illegible] |
| | | | 8 | Исхакова Хәдичә |



Язып алынган материаллар (2

| Туган елы | Белеме | Профессиясе | Әкият | Бәет | Сюжетлы, көйле җырлар: Көй б-н мон. | Сюжетлы, көйле җырлар: Тексты гына | Кыска җырлар | Уеннар: Җырлы | Уеннар: Җырсыз | Мәкаль, әйтем, табышмак | Йолалар, ышанулар | Авыл тарихы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1888 | н/г | пенсион. | - | 1 | — | 1 | - | - | - | — | — | — | |
| 1891 | —"— | —"— | - | - | - | 1 | — | - | - | - | - | - | |
| 1891 | башл. | —"— | 3 | — | - | — | - | - | — | — | — | - | |
| 1892 | —"— | —"— | - | - | 1 | 2 | - | - | - | - | - | 1 | |
| 1890 | —"— | пред. к/х | - | - | - | 2 | — | - | — | — | — | - | |
| 1815 | югары | укытучы | - | - | - | - | 4 | - | - | - | 1 | - | |
| 1940 | урта | колхозчы | - | - | - | - | 6 | - | - | - | - | - | |
| 1944 | 8 | —"— | - | - | - | 1 | — | - | - | - | - | - | |
| 1901 | башл. | пенсион. | - | - | - | 1 | — | - | - | - | - | - | |
| 1939 | урта | колхозчы | - | - | - | 1 | 64 | - | - | - | - | - | |
| 1932 | 7 | тракторч. | - | - | - | - | 37 | - | - | - | - | - | |
| 1940 | 8 | эшче | - | - | - | - | 35 | - | - | - | - | - | |
| 1943 | 7 | колхозчы | - | - | - | - | 17 | - | - | - | - | - | |
| 1933 | 8 | пекарь | - | - | - | - | 67 | - | - | - | - | - | |
| 1915 | 4 | плотн. | - | - | - | - | — | - | - | - | 1 | - | |
| 1894 | —"— | пенсион. | - | - | 1 | — | - | - | - | - | - | - | |
| 1937 | 10 | пионервож. | - | - | - | - | - | - | 4 | - | - | - | |
| 1890 | н/г | пенсион. | - | - | - | - | 4 | - | - | - | - | - | |
| | | Всего: | 3 | 1 | 2 | 9 | 234 | - | 4 | - | - | 1 | - |
| 1879 | н/г | пенсион. | 2 | - | - | - | 14 | - | - | - | 1 | - | |
| 1891 | мәдрж. | —"— | - | - | 2 | 1 | 16 | — | - | - | 1 | - | |
| 1942 | урта | хисапчы | - | - | - | - | 45 | - | - | - | - | - | |
| 1947 | 8 | укучы | - | - | - | - | 8 | - | - | - | - | - | |
| 1940 | 8 | колхозчы | - | - | - | - | 20 | - | - | - | - | - | |
| 1944 | 5 | —"— | - | - | - | - | 25 | - | - | - | - | - | |
| 1901 | 4 | —"— | - | - | - | - | — | - | - | - | 1 | 1 | |
| 1941 | урта | —"— | - | - | - | - | 5 | - | 1 | - | - | - | |
| | | Всего: | 2 | - | 2 | 1 | 133 | - | 1 | - | 1 | 1 | - |

Горький өлкәсендәге татар авылларына оештырылган
фәнни экспедициянең (1962) 1 нче отряды башкарган эш турында
хисапның дәвамы. (74 колл., 1 тасв., 1 сакл. бер.)

| N | Өлкә, район, авыл һәм колхоз исеме. | Авылның [illegible] хуҗалык саны. | Авылда [illegible] вакыт булуы | N | Кемнәрдән язып алынды. |
|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Горький өлкәсе, Спасский районы, Имәнавыл, "Кызыл йолдыз" колхозы. | 183 | 25–27 июнь. | 1 | Заринов Гәшир |
| | | | | 2 | Абдуллина Амина |
| | | | | 3 | Абдуллина Гөлҗиһан |
| | | | | 4 | Айтмасова Аминә |
| | | | | 5 | Мусиева Рәшидә |
| | | | | 6 | Садыкова Маншу[...] |
| | | | | 7 | Садыкова Кәүсәр |
| | | | | 8 | Фаттахов Бари |
| 5 | Горький өлкәсе, Спасский районы, Татар Моклокаев авылы, Чапаев исемендәге колхоз | 890 | 28 июнь – 5 июль | 1 | Абызов Садыйк |
| | | | | 2 | Хафизов Харрас |
| | | | | 3 | Тохфәтуллин Салах |
| | | | | 4 | Закирова Гәзилә |
| | | | | 5 | Рахимова Сафия |
| | | | | 6 | Җаббарова Рәшидә |
| | | | | 7 | Айзәтуллин Садыйк |
| | | | | 8 | Гадретдинов Мами[...] |
| | | | | 9 | Чамин Якуб |
| | | | | 10 | Абызов Хәсән |
| | | | | 11 | Шабаев Сабит |
| | | | | 12 | Тонтычин Айса |
| | | | | 13 | Динмухамедов Анис |

Экспедиция

10.07.62

| Туган ел | Белеме | Профессия | Җыентык | Бәет | Җыр: Көе б-н мәкамы | Җыр: Текст | Кыска җырлар | Җырлы | Җырсыз | Мәкаль, әйтем, табышмак | Йола истәлекләре | Авыл тарихы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1888 | мәдрәсә | пенсион. | – | – | – | – | – | – | – | – | 1 | 1 | – |
| 1941 | 8 | колхозчы | – | – | – | 1 | 34 | – | – | – | – | – | – |
| 1942 | 7 | —"— | – | – | – | 1 | 6 | – | – | – | – | – | – |
| 1947 | 7 | колхозчы | – | – | – | 1 | – | – | – | – | – | – | – |
| 1926 | 7 | —"— | – | – | – | – | 11 | – | – | – | – | – | – |
| 1929 | 4 | —"— | – | – | – | – | 33 | – | – | – | – | – | – |
| 1927 | 7 | кассир | – | – | – | – | 8 | – | – | – | – | – | – |
| 1939 | 7 | колхозчы | – | – | – | – | 4 | – | – | – | – | – | – |
| | | Всего: | – | – | – | 3 | 96 | – | – | – | 1 | 1 | – |
| 1913 | 7 | пенсион. | – | 2 | ~~2~~ | 2 | 6 | – | – | – | – | – | – |
| 1895 | 7 | зав. склад | – | – | – | 1 | – | – | – | – | – | – | – |
| 1891 | 4 | пенсион. | – | – | – | – | – | – | – | – | – | – | + |
| 1899 | н/г | ат җужа | – | – | – | 1 | 10 | – | – | – | – | – | – |
| 1939 | урта | хисапчы | – | – | – | – | 21 | – | – | – | – | – | – |
| 1943 | —"— | колхозчы | – | – | – | – | 11 | – | – | – | – | – | – |
| 1920 | —"— | зав. клуб | – | – | – | – | 8 | – | – | – | – | – | – |
| 1893 | н/г | пенсион | – | – | X | – | – | – | – | – | – | – | – |
| 1910 | 6 | колхозчы | – | 1 | – | – | – | – | – | – | – | – | – |
| 1920 | неок. высш. | укытучы | – | – | – | – | 210 | – | – | – | – | – | – |
| 1892 | 4 | пенсион. | – | – | – | – | – | – | – | – | – | 1 | – |
| 1944 | 8 | тракторчы | – | – | – | – | 10 | – | – | – | – | – | – |
| 1891 | н/г | пенсион. | – | – | – | – | – | – | – | 1 | – | – | – |
| | | Всего | – | 3 | 0 | 4 | 276 | – | – | – | 7 | 1 | |
| | | Итого: | 5 | 6 | 15 | 30 | 882 | 3 | 10 | 1 | 6 | 7 | |

Имзалар: 1) [имза] (И. Нафиков)
2) [имза] (Ш. Гамиржанов)

Горький өлкәсендәге татар авылларына оештырылган фәнни экспедициянең (1962) 1 нче отряды башкарган эш турында хисапның соңгы бите. (74 колл., 1 тасв., 1 сакл. бер.)

СССР Фәннәр Академиясенең Казан фили[алы]

1962 елның июнь (8/VI – 6/VII) аенда Горький өлкәсенә бар[ган]

экспедициянең 2-отряды тарафыннан җыйналган м[атериаллар]

Отряд җитәкчесе

| Өлкә, район, авыл һәм колхоз исеме | Авылда хуҗалык саны | Авылда кайсы вакытта булган. | Материал тапшырган кешенең исеме, фамилиясе | Туган елы |
|---|---|---|---|---|
| 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| Горький өлкәсе | | | Алимова Ләйлә | 1922 |
| Кызыл-Октябрь р-ны | | | Сахабова Сәрби | 1882 |
| Петрякс авылы | 460 | | Садриддинова Фәхрижиһан | 1912 |
| Петрякс авыл советы | | 8 июнь – | Нәҗемова Нәфисә | 1900 |
| Жданов исемен- | | 12 июнь | Даутова Кафия | 1916 |
| дәге колхоз | | | Абдуллина Хәлимә | 1914 |
| | | | Хәҗиева Мәрьям | 1907 |
| | | | Галиуллина Әминә | 1899 |
| | | | Алимова Сафия | 1897 |
| | | | Алимова Йолдыз | 1926 |
| Горький өлкәсе | | | Ибраһимова Зәйтүнә | 1907 |
| Кызыл-Октябрь р-ны | | | Даутова Һәнисә | 1868 |
| Красная горка (Саба- | | 12 – 14 | Хамитуллина Хафиза | 1897 |
| чәй) авылы | 750 | июнь | Вильданова Мәрьям | 1889 |
| „Киров" һәм | | | Сәгъдиева Зөһрә | 1915 |
| „Калинин" | | | Юнисова Фаизә | 1912 |
| колхозлары | | | Алимова Гафирә | 1905 |
| | | | Шабаева Мөхлисә | 1911 |
| | | | Исхакова Зәйнәп | 1930 |

1

Институт языка, литературы и истории Казанского филиала АН СССР
Рукописный фонд
Фонд 74
Опись 2
ед. хр. 30 (4б л.)

...мы теле, әдәбият һәм тарих институтының фольклорны җыйнау буенча оештырылган фәнни ...риаллар турында статистик отчет.
Х. Гатина, отряд члены Ф. Ахметова.

| Белеме | Профессиясе | Язып алынган материаллар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Әкият | Бәет | Җыр | Сюжетлы җыр (кайсы) | Табышмак һәм мәкаль | Халык уены | Мәзәк |
| 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | |
| урта | укытучы | – | – | 660 | 2 | – | 7 | – |
| н/г | пенсионер | – | – | 6 | – | – | – | – |
| башл. | санитарка | – | – | 52 | – | – | – | – |
| башл. | пенсионер | – | – | 16 | – | – | – | – |
| грамоталы | колхозчы | – | – | 12 | – | – | – | – |
| 7/б югары | укытучы | 1 | – | 92 | – | – | – | – |
| аз грамот. | колхозчы | – | – | ~~26~~ 180 | – | – | – | – |
| [illegible] | ″ | – | – | 12 | – | – | – | – |
| урта | укытучы | – | – | 24 | – | – | 5 | – |
| югары | укытучы | – | – | – | – | – | 5 | – |
| | Всего | 1 | – | 1034 | 2 | – | 17 | – |
| грамоталы | колхозчы | – | – | 99 | – | – | – | – |
| грамотасыз | ″ | – | – | 9 | 2 | 12/0 | 3 | – |
| грамоталы | ″ | – | – | 10 | – | – | – | – |
| грамотасыз | ″ | – | – | 6 | – | – | – | – |
| грамоталы | колхозчы | – | – | 13 | – | – | – | – |
| ″ | ″ | – | – | 70 | – | – | – | – |
| ″ | ″ | – | – | 9 | – | – | – | 3 |
| урта | укытучы | – | – | 80 | – | 0/38 | – | – |
| 7 | колхозчы | – | – | 39 | – | – | – | – |

Институтның 1962 елның июнендә Горький өлкәсенә оештырылган фәнни экспедициянең 2 нче отряды тарафыннан җыйналган материаллар турында хисап. Отряд җитәкчесе – Х. Гатина, отряд әгъзасы – Ф. Әхмәтова.
(74 колл., 2 тасв., 30 сакл. бер.)

| Өлкә, район, авыл һәм колхоз исеме | Хуҗалык саны | Авылда кайсы вакытта булынды | № | Материал тапшырган кешенең исеме, фамилиясе |
|---|---|---|---|---|
| Горький өлкәсе, Кызыл Октябрь р-ны, Красная горка авылы, „Киров" һәм „Калинин" колхозлары | 750 | | 20. | Хөсәенова Айшә. |
| | | | 21. | Шәкирова Адиля |
| | | | 22. | Фәтхуллина Рауза |
| | | | 23. | Фәттахетдинова Хәтим. |
| | | | 24. | Бәдреддинова Хәдичә |
| Горький өлкәсе Кызыл-Октябрь р-ны, Красный остров авылы „Новый путь" колхозы. | 250 | 14–16 июнь | 25. | Нуриманова Васбия |
| | | | 26. | Шакирова Әминә |
| | | | 27. | Фәттахова Сәимә |
| | | | 28. | Сибатуллина Мәдинә |
| | | | 29. | Шакирова Мөнәвәр |
| | | | 30. | Абулханов Хәлил |
| | | | 31. | Фәхретдинова Хәтимә |
| | | | 32. | Юсипова Аделифа |
| Кз.-Октябрь р-ны, Иске Мочали һәм Яңа Мочали авыллары „Родина" һәм „Россия" колхозлары, Мочали а/с. | 700 | 16–20 июнь | 33. | Юнисова Галия |
| | | | 34. | Хәсәнов Хәмзә |
| | | | 35. | Шабанова Сания |
| | | | 36. | Губасова Фәхриҗика |
| | | | 37. | Исаев Билал |
| | | | 38. | Газизова Фатыйма |
| | | | 39. | Тагзетдинов Абдулла |
| | | | 40 | Абдразаков Сафиулла |
| | | | 41. | Шәрәфетдинов Кәбир |
| | | | 42. | Насретдинова Аминә |
| | | | 43. | Локманов Хәлим |
| | | | 44. | Мулюков Абдулхак |

| Туган елы | Белеме | Профессиясе | Язып алынган материаллар: Әкият | Бәет | Сюжетлы җырлар: көйле | Сюжетлы җырлар: көйсез | Кыска җырлар | Табышмак, мәкаль | Уеннар | Балалар уены | Мәзәкләр, истәлекләр | Елау |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1914 | грамот. | колхоз | – | – | – | – | 15 | – | – | – | – | |
| | Всего | | 1 | | | 4 | 360 | 12/38 | 20 | – | 3 | |
| 1943 | 7 | колхоз. | | | | | 74 | | | | | |
| 1936 | 7 | " | | | | | 172 | | | | | |
| 1896 | грамот. | " | | | | | 8 | | | | | |
| 1903 | " | техничка | | | | | 19 | | | | | |
| 1913 | грам-сыз | колхоз. | | | | | 11 | | | | | |
| 1897 | грамот. | " | | | | | 7 | | | | | |
| 1922 | " | " | | | | | 11 | | | | | |
| 1901. | грам-сыз | " | | | | | 45 | | | | | |
| 1905 | грамот. | " | | | | | 41 | | | | | |
| 1874 | грам-сыз | " | 1 | | | 1 | | | | | | 1 |
| 1896 | грамот. | " | | | | | 25 | | | | | |
| 1901 | грамот. | " | | | | | 84 | | | | | |
| | Всего | | 1 | | | 1 | 497 | | | | | 1 |
| 1940 | 7 | эшче | | | | | 88 | | | | | |
| 1890 | грам-сыз | сторож | | | 1 | | 22 | | | | | |
| 1948 | 7 | укучы | | | | | 136 | | | | | |
| 1872 | грам-сыз | колхоз. | | | 1 | | | | | | | |
| 1892 | грамот. | пенсион. | | | 4 | | | | | | | |
| 1909 | урта | укытучы | | | | | 82 | | | | | |
| 1900 | грамот. | плотник | | | | | 13 | | | | | |
| 1890 | аз грам. | плотник | | | | | 10 | | | | | |
| 1894 | урта | укытучы | | | 2 | | | | | | 0/1 | |
| 1905 | грамот. | колхозчы | | | | | | | 1 | | | |
| 1893 | грамот. | " | | | 3 | | | | | | | |
| 1912 | " | " | | | 4 | | | | | | | |

1962 елның июнендә Горький өлкәсенә оештырылган фәнни экспедициянең 2 нче отряды тарафыннан җыйналган материаллар турында хисап (дәвамы). (74 колл., 2 тасв., 30 сакл. бер.)



отряд №3

Копия

Отчет

Музыкально-фольклорной экспедиции ИЯЛИ КФАН СССР (сектор народного творчества и истории искусств) в Горьковскую область в составе: музыковеда Махмута Нигмедзянова, внешт. сотр. Якубова Ильдуса Д. (Июнь 1962 года)

Руков. Экспед. Ильбарис Надиров.

| №№ нас. пункт. | Населенный пункт | № п/п | Ф. И. О. сообщающего | Год рождения | Образование | Записано песен | Записано инструментальных наигрышей | Примечание |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | с. Уразовка Горьковск. обл. (7–10 июня) | 1. | Мәҗетдинов Х. Я. | 1896 | высш. | 11 | – | |
| | | 2. | Бәдретдинов Х. Б. | 1902 | нач. | 3 | – | |
| | | 3. | Шарафетдинов К. Ш. | 1926 | ср. | ~~6~~ | 6 | |
| | | 4. | Хөснетдинова Р. Д. | 1907 | ср. | 4 | | |
| | | 5. | Юнусов Хәлиль Ю. | 1903 | нач. | 2 | | |
| | | 6. | Низаметдинов А. Н. | 1886 | нач. | 3 | | |
| | | 7. | Мансуров Х. Х. | 1912 | ср. | 3 | | |
| 2. | с. Овечий овраг (11–13 июня) | 8. | Фаттахов Н. Ф. | 1934 | ср. | 2 | | |
| | | 9. | Мөхәммәтҗанова С. | 1907 | нач. | 8 | | |
| | | 10. | Бәдретдинов Ю. Б. | 1898 | нач. | 2 | | |
| | | 11. | Юсупов Исхак Г. | 1899 | нач. | 6 | | |
| | | 12. | Хәйретдинов Ю. Х. | 1909 | нач. | 5 | | |
| | | 13. | Юсупов Р. Х. | 1912 | ср. | 2 | | |
| 3. | с. Петряксы (14–17 июня) | 14. | Алимова Л. М. | 1924 | ср. | 7 | | |
| | | 15. | Алимова Ю. М. | 1926 | высш. | 5 | | |
| | | 16. | Хор девушек | | ср. | 4 | | |
| | | 17. | Алимова С. Х. | 1897 | ср. | 7 | | |
| | | 18. | Бәдретдинова Р. А. | 1940 | ср. | 3 | | |
| | | 19. | Арифуллин И. А. | 1887 | нач. | 9 | | |
| | | 20. | Салахова Р. С. | 1910 | нач. | 2 | | |
| 4. | с. Собачий остров (18–19 июня) | 21. | Шабанов К. А. | 1900 | нач. | 3 | | |
| | | 22. | Батыршин А. Б. | 1897 | ср. | 5 | | |
| | | 23. | Алиев Х. И. | 1903 | нач. | 2 | | |
| 5. | с. Красный остров (20–23 июня) | 24. | Алихузина В. Н. | 1895 | нач. | 5 | | |
| | | 25. | Сикамова М. И. | 1896 | м/г | 5 | | |
| | | 26. | Юсипова А. Л. | 1860 | м/г. | 1 | | |
| | | 27 | Җәләев Б. [illegible] | 1891 | ср. | [illegible] | | |

Горький өлкәсенә оештырылган экспедициянең 3 нче отряды хисабы
(1962 ел, июнь). Экспедиция составы: музыка белгече М. Нигъмәтҗанов, читтән килгән хезмәткәр И. Якупов. Экспедиция җитәкчесе – И. Надиров.
(74 колл., 1 тасв., 2 сакл. бер.)

2

Красно-Октябрьский р-н
Горьковской области

1) Актуково. до Уразовки 3 км, Сергача 18 км
1) Ачкаровка (Ачкар авылы). Расстояние до Уразовка 1 км, до Сергача 13 км.
2) Грибанова. от Сергача 17 км.
3) Ендовищи. от Уразова 10 км, Сергача 18 км.
4) Кадомка. до Уразова 3 км, Сергача 12 км.
5) Камкино. от Сергача 20 км, (располож. на жд-разъезде)
6) Кара. от Уразова 11 км, Сергача 16 км.
7) Ключищи (Сук-су). от Уразова 6 км, до Сергача 25 км
8) Кочка-по~~тайки~~. от Уразовки 10 км., Сергача 5 км. (на ж/д Сергач)
9) Красный ~~остров~~. от Сергача 50 км.
10) Красный Яр. до Уразовки 2 км, Сергача 14 км.
11) Кузьминка (Кызым авыл). от Уразова 2 км, Сергача 13 км. Разъезд.
12) Медяны. до Уразова 13 км, Сергача 28 км.
13) Нов. Мочалей. Сергача 33 км.
14) Ст. Мочалей. Сергача 33 км.
15) Муравлейка (Дурбуле). от Сергача 25 км
16) Овечий овраг (Куй суы). Уразовки 7 км, Сергача 13 км.
17) Парша. от Сергача 40 км. Спасское
18) Пица (Пичь). до Сергача 23 км.
19) Богатово (Шубатово). до Уразовки 5 км, Сергача 10 км.
20) Больш. Рыбушкино. до Сергача 25 км.
21) Семеновское (Семеновка). от Уразовки 5 км, Сергача 10 км
мал. Рыбушкино. до Сергача 25 км.
(см. н/об.)

Экспедиция хисабының бер өлеше.
(74 колл., 2 тасв., 32 сакл. бер.)


Ойдэн чыгып киткэн чакда,
Үкенемне белмәдем,
Эркүле үлемгүгезне
Эткәйне күрмәдем.
Безнең аста тирэн елга,
Җете баш (?) сулары тулган,
Эркүле үлемэз үзе,
Ходайның әзләсешы булган.
Үзэе кок иртэ торып
чыгып киттем,
Авызымдин җаным чыкканчы
Килеп алырсыз дип көттем,
Бәләзем йорттем
Кайтып сезне күрмәдем.

1862 елгы экз.

Көнкүреш бәете

Рукописный фонд
Коллекция 74
Папка 2
ед.хр. 52

«Көнкүреш бәете». Оригиналы һәм гамәлдәге татар хәрефләренә күчерелгән тексты. (74 колл., 2 тасв., 52 сакл. бер.)



Кыска җырлар.

Горький өлкәсе, Кызыл-Октябрь районы, Петряксы авылында укытучы Ләйлә Алимовадан язып алынган җырлар. 669 так мак. Язып алучысы Әхмәтова. 1962 елгы экспедиция. 08-~~12~~.06.62.

Колл. 74
Ед. 2
ф. хр. 37 (60 бит)

Общая тетрадь №1

Кызыл Октябрь районы
Петрякс авылында
укытучы Ләйлә Алимовадан
язып алынган җырлар дәфтәре.
Анда 669 кыска җыр тупланган.
Язып алучысы Ф. Әхмәтова.
1962 елгы экспедиция. 08.06–12.06.
(74 кол., 2 тасв., 37 сак. бер.)



мәкальләр – 60
табышмаклар – 14

Рукописный фонд
Колл. 74
Ед. 2
ф. хр. 39 (12 бит)

ТЕТРАДЬ
для
ученика ______ класса
______ школы

СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор экс-се вакытында язып алынган материаллар.
1962 ел, июнь. Горький өлкәсе.
Х. Гатина



1

Мәкаль-әйтемнәр

1. Арба ватылса утын, үгез үлсә ит.
2. Туй килде капкага, кыз утырды кабага.
3. Ике бармак арасына ит үсми.
4. Ертык җиштегән кәлә.
5. Теләнчедән капчык сорама.
6. Имнеке диңгез, аны ашаган дуңгыз.
7. Үз-үзеңне мактама, кеше сине мактасын.
8. Мактанчыкның авызы ачык.
9. Ир сөйгәнне ил сөяр, ир какканны ил кагар.
10. Иренгән ике ~~ашар~~ эшләр.
11. Кул кулны юса, ике кул йөзне юар.
12. Кешегә баз казыма, үзең төшәрсең.
13. Аргамактан ат туа, кандаладан бет туа.
14. Ачу күрке бизү.
15. Буяч – борыч.
16. Кая диңгез, шунда яңгыр.
17. Килмәгән больпуган куркыш чабыр кормышлар.
18. Ачык бүлмә зур булмый,
Кечкенә кеше хур булмый.

Институтның фольклор экспедициясе вакытында язып алынган материаллар (1962 ел, июнь. Горький өлкәсе. Х. Гатина). (74 колл., 2 тасв., 39 сакл. бер.)




1962 елның июнь аенда Горький өлкәсе татарларыннан язып алынган әкиятләр. Экспедиция җитәкчесе – И. Надиров, язып алучы – Т. Галиуллин.
(74 колл., 1 тасв., 15 сакл. бер.)



Кыска җырлар дәфтәре. Дәфтәрне Горький өлкәсе Татар Моклокасы авылында Хәсән Абызов тапшырды (1962 ел, 2 июль).
(74 колл., 1 тасв., 24 сакл. бер.)



Пролетарии всех стран, соединяйтесь!

Газета Горьковского обкома КПСС и облисполкома для районов Лысковского территориального производственного колхозно-совхозного управления

**Приволжская правда**

Год издания 1-й
№ 32
26 июня 1962 года
Цена 2 копейки

Выходит четыре раза в неделю

№ 32 26 июня 1962 г.

**Письма в редакцию**

***Лекции на татарском языке***

В Базловском клубе, Спасского района, в последнее время для жителей села были прочитаны две содержательные лекции на родном татарском языке. Одна из них—о международном положении, другая—о жизни и деятельности Героя Советского Союза Мусы Джалиля.

С лекциями выступили представители Академии наук Татарской АССР тов. Галиев и Надиров.

**Диан Фаттахов,**
зав. клубом.

Диан Фаттаховның «Приволжская правда» газетасында (1962 ел, 26 июнь) басылган «Татар телендә лекцияләр» дигән мәкаләсе
(фольклор экспедициясе әгъзалары И. Надиров һәм Т. Галиуллинның лекция укулары турында)



Академия наук Союза Советских Социалистических Республик
КАЗАНСКИЙ ФИЛИАЛ
Казань, Лобачевского, 2/31. Для телеграмм: Казань, наука, Т/коммут. 2-13-07.

№ 355/I6/I4 "31" мая 1962 г.

Председателям Красно-Октябрьского,
Сергачского, Спасского районных
Советов депутатов трудящихся
Горьковской области

В татарские населенные пункты Красно-Октябрьского, Сергачского и Спасского районов с 5 июня 1962 г. сроком на один месяц направляется научная фольклорная экспедиция Казанского филиала Академии Наук СССР по собиранию татарского устного и музыкального народного творчества в составе шести сотрудников /3 отряда/. Руководитель экспедиции – кандидат филологических наук И.Н.НАДИРОВ.

Просим Вас оказать содействие в работе фольклорной экспедиции.

Заместитель Председателя
Президиума КФАН СССР,
профессор /Л.М.Миропольский/

Директор института
языка, литературы и истории,
кандидат философских наук /К.Ф.Фасеев/

При ответе просим ссылаться на наш №

Татполиграф, 001199

1962 елдагы экспедиция уңаеннан җирле җитәкчеләргә язылган үтенеч хаты.
(74 колл., 2 тасв., 33 сакл. бер.)



При ответе ссылайтесь на наш № и дату

Р.С.Ф.С.Р.
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРЬКОВСКОГО
ОБЛАСТНОГО СОВЕТА
депутатов трудящихся
Отдел
5. мая 1962
№ –/
г. Горький, Дом Советов
Телефон 3-23-43

Казанскому институту языка
литературы и истории

На Ваш запрос организационно-инструкторский отдел исполкома Горьковского Облсовета сообщает, что в области имеется татарское население в трех районах: Красно-Октябрьском – 13 сельсоветов, Сергачском и Спасском – по два сельсовета.

Зам.зав.Оргинструкторским отделом
исполкома областного Совета
депутатов трудящихся – /М.Лавров/

Горький өлкәсе җитәкчелегенең татар авыллары турында Институтка биргән мәгълүматы.
(74 колл., 2 тасв., 31 сакл. бер.)

«1959 елгы фольклор экспедициясе (Горький шәһәрендә икенче пароходка күчеп утырабыз)». Х. Гатинаның шәхси тупламасыннан



## Авторлар турында кыскача белешмә

*Миңнуллин Ким Мөгаллим улы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры.

*Башкурова-Садыйкова Айсылу Хөсәен кызы** – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Баязитова Флера Сәет кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Гарипова Фирдәвес Гариф кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Закирова Илсөяр Гамил кызы* – филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Илтубаева Лариса Васильевна** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге аспиранты.

*Кадыйров Рәшит Мәгъсүм улы** – тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Каюмова Эльмира Ринат кызы** – сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

*Мөхәмәтшина Ләйлә Миңнехан кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге фәнни хезмәткәре.

---

* Мәгълүматлар китапның беренче басмасы әзерләнгән вакытка бирелде.

*Рамазанова Дария Бәйрәм кызы* – филология фәннәре докторы, профессор, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре.

*Солтанова Рауза Рифкать кызы* – сәнгать фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире.

*Тукмачева Ләйсән Фәнис кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге аспиранты.

*Хәйбуллина Гөлчәчәк Халит кызы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге аспиранты.

*Шәрипов Илһам Рафаэль улы** – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге аспиранты.

*Юнысова Гүзәл Фәйзрахман кызы* – ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ = ВВЕДЕНИЕ
*Ким Миңнуллин*
6

ТАШЛАРНЫҢ ТАМЫРЫ ТИРӘН
Кулъязма мирас һәм ташъязмалар
*Рәшит Кадыйров*
26

САЛАВАТ КҮПЕРЕНДӘ КАМКА ТӨСЕ ДӘ БАР
Мәшһүр авыллар тарихыннан
*Фирдәвес Гарипова*
31

ЙОМШАК ТЕЛЛЕ МИШӘРЛӘРЕМ
Сергач татарлары сөйләше
*Флера Баязитова, Гөлчәчәк Хәйбуллина*
45

КАРДӘШЕМӘ ЯКЫН ИТЕП ДӘШӘМ
Туганлык атамалары үзенчәлекләре
*Дария Рамазанова*
97

СҮЗГӘ СҮЗ ЯЛГАНЫР ХИКМӘТ БЕЛӘН
Җөмлә төзелешенә җирле сөйләш йогынтысы
*Ләйсән Тукмачева*
110

МОҢ ЧИШМӘЛӘРЕ ТИРӘННӘН ЧЫГА
Түбән Новгород мөнәҗәтләре
*Айсылу Башкурова-Садыйкова*
135

ЗИМӘ БУЕ АРЫМСАК...
Риваятьләрдә – халкыбыз тормышы
*Илсөяр Закирова*
165

АУЛАК ӨЙЛӘРДӘН – САБАНТУЙ МӘЙДАННАРЫНА
Сергач татарларының йола һәм уен фольклоры
*Илһам Шәрипов*
177

КОРАЛ ЭШЛӘР, ОСТА МАКТАЛЫР
Сергач мишәрләренең туку эшчәнлеге
*Лариса Илтубаева*
189

УҢГАН КУЛДА УТ УЙНЫЙ
Традицион һөнәр-кәсепләр, гамәли сәнгать
*Рауза Солтанова*
225

ИБЕН БЕЛСӘҢ, КӨЕ КИЛӘ
Музыкаль фольклор һәм уен кораллары
*Эльмира Каюмова*
253

ӘЛЛҮ-БӘЛЛҮ БӘБКӘСЕ...
Кучкай Пожары авылындагы бишек җырлары
*Гүзәл Юнысова*
301

ТАКМАК – ЯНЧЫКТА, ҖЫР – КАПЧЫКТА
Халык җырларының төзелеше һәм эчтәлеге
*Ләйлә Мөхәмәтшина*
311

ЕРАК ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ
Институт мирасханәсеннән
359

Научно-популярное издание
*Серия «Из сокровищницы научных экспедиций»*

**Национально-культурное наследие**
**НИЖНИЙ НОВГОРОД**
2-е издание

Фәнни-популяр басма
*«Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» сериясе*

**Милли-мәдәни мирасыбыз**
**ТҮБӘН НОВГОРОД**
2 нче басма

Корректорлар *А. В. Әбдриева, Л. Г. Шәрифуллина*
Компьютерда биткә салучы *Н. Т. Абдуллина*
Китапта *Р. Р. Солтанова, Л. В. Илтубаева, Э. Р. Каюмова*
фоторәсемнәре файдаланылды

Басарга кул куелды 20.01.2021.
Форматы 60 x 84 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. Times New Roman гарнитурасы.
Офсет басма. Нәшер-хисап табагы 18. Шартлы басма табагы 22,3
Тиражы 500 д. Заказ

Оригинал-макет
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде
420111, Казан, К. Маркс ур., 12

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан, Бауман ур., 20